ISSN 0206-4

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

●

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

5

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

**М. МАЛИКОВА. Ак давылда тал бересе.** Роман . . . 3

МӨХӘММӘТ САДРИГА 70 ЯШЬ

**М. САДРИ. Төрле еллардан.** Шигырьләр . . . 68

**Ш. ГАЛИЕВ. Урам чатында булган хәл.** Шигырьләр . . . 73
**Г. РӘХИМ. Җирем.** Шигырьләр . . . 77
**Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Дүрт кыз.** Поэма . . . 81
**Р. ИШМОРАТ. И мөкатдәс, моңлы сазым.** Драматик повесть . . . 87
**Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Читлек.** Хикәя . . . 120

9 МАЙ — ҖИҢҮ КӨНЕ

**Ш. ХАММАТОВ, К. ТӘХАУ. Фронтовик әдипләр** 123

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

**М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Себер белән Париж арасы.** Очерк . . . 132

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**И. НИЗАМОВ. Күңел урталыгыннан** . . . 142

ГАРИФ ГАЛИЕВКӘ 80 ЯШЬ

**Х. ХӘЙРИ. Яңа авыл җырчысы** . . . 153

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Т. МИҢНУЛЛИН. «Күктә ни булмас...»** . . . 155
**С. ШӘМСИ. Вакыйга артында ни ята!** . . . 160

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Роб. ӘХМӘТҖАНОВ. Җил уңаена борылма.** Реплика . . . . . . . . . . 166
**А. ЯХИН. Фикер дәлилле булсын!** . . . . . . 169

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

**ТМИН. Шигырь язарга өйрәтәм** . . . . . . . 173

ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

**Д. ВӘЛИЕВ. Диоген фонаре** . . . . . . . . 176

КУЛЬТУРА ТАРИХЫНА

**Р. УРАЗМАНОВА. Борынгы һәм яңа бәйрәм** . . 180

СӘНГАТЬ

**И. ИЛЯЛОВА. Татар сәхнәсендә тәрҗемә әсәрләре** . . . . . . . . . . . . . . . 186
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

---

Производствога бирелде 22.02.1983 ел. Басарга кул куелды 13.04.1983 ел. ПФ 07029. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Я-83. Бәясе 90 тиен.

---

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## Мәдинә Маликова

# АК ДАВЫЛДА ТАЛ БӨРЕСЕ

РОМАН



Иртәнге рапорт вакытында Фидая Галимовна кесәсеннән хат чыгарып, Зәйтүнәгә бирде. Адресы ят кул белән язылган, фамилиясе куелмаган. Врачларга сирәк кенә булса да рәхмәт хатлары килгәли. Зәйтүнә конверттагы штемпельгә күз салды: хат Казаннан иде. Ул, рапорттан соң ачып укырмын дип, конвертны кесәсенә тыгып куйды.

Бүген Вафина Алтынчәч дигән хатын турында шактый озак сүз булды. Утыз биш яшендә беренче тапкыр буйга узган, йөклелеге егерме тугыз атна, анамнезы начар. Хәзер йөклелекнең соңгы чорында була торган токсикозның авыр формасы белән ята. Врачларның киңәш-үгетләренә җавабы һаман бер: «Баланың исән тууына гарантия бирә аласызмы?» Андый гарантияне мондый очракта ходай үзе дә бирә алмас!

Лариса, аягүрә басып, Вафинаның канындагы үзгәрешләрне бәйнә-бәйнә сөйләде. Сүзе нигезле, төгәл, ышанычлы иде. Профессор Ильясованың күз карашыннан ук доктор Нигъмәтуллинаны хуплавы сизелеп тора иде.

— Вафинаның ире килсә, миңа чакырыгыз әле, үзем сөйләшеп карармын,— диде Җәмилә Закировна.

Аңа Вафинаның ире әлегә кадәр бер дә күзгә күренмәгәнен әйттеләр.

Лариса тагын урыныннан калкына төшеп:

— Аларның никахлары законлаштырылмаган. Вафинаның хәленә тискәре кичерешләр бик зур йогынты ясый, шунлыктан дәвалау көтелгән эффектны бирми,— дип куйды.

Бу хакта сүзне йомгаклап, тагын нинди чаралар күрергә мөмкинлеген ачыклагач, профессор:

— Бирегә сүз авыр кичерешләр турында барды,— диде.— Бүгенге әңгәмәнең темасы — тискәре кичерешләр.

Профессор һәр чәршәмбе көнне иртәнге рапорттан соң ярты сәгатьлек әңгәмә үткәрә иде.

— Беркемнең дә тормышы тигез генә бармый, төрлесен кичерергә туры килә,— дип башлады ул бүгенге сүзен.— Кәефсезләнү, кайгы-хәсрәт, көнләшү, ару-талу организмга бик нык тәэсир итә.

---

Дәвамы. Башы 4 нче санда.

Зәйтүнә уң ягында утырган Ларисага карады. Лариса дикъкатен профессорга юнәлтергә тырышып, күзләрен зур ачкан, ләкин керфекләре авыраеп, әледән-әле йомылалар, Җәмилә Закировнаның сүзләре аның зиһенenә барып җитә алмый иде. Аның күз алмалары Сөембикә апаның банкаларда асрый торган бакаларын хәтерләтте. Бу чагыштыруыннан Зәйтүнә үзе үк куркып китте: «Нишләвем бу? Ни өчен болай яратмый башладым әле мин аны? Эше уңышлы барганга көнләшәмме?»

— Бервакыт Әбугалисина мондый тәҗрибә ясаган: ике кәҗәне ике абзарга ябып куйган да, берсенең каршына почмакка бүре бәйләгән. Ике кәҗәне дә бер үк төрле караган, ашатып торган ул. Буш абзардагы кәҗә күзгә күренеп көрәйгән, ә каршысында бүре торганы тиз арада ябыккан, хәлсезләнгән, озакламый егылып үлгән. Йөрәкне яндырып, бәгырьне талаган кайгы-сагыш, ярсулар нәкъ менә шул каршыбызда тешен шыгырдатып торган бүре кебек тәэсир итәләр дә инде... Алар йогынтысында канга күп микъдарда адреналин бүленеп чыга...

Зәйтүнә тагын Ларисага карады. Тәмам оеп-оеп китә теге, төнен йокысыз уздырган, ахрысы. «Менә мин аңа карадым да, каныма адреналин бүленеп чыкты инде»,— дип уйлады Зәйтүнә.

— Тискәре эмоцияләр никадәр көчле булса, аларның зарары да шул кадәр зуррак. Шуңа күрә үз-үзеңне тыярга, кайгы-хәсрәткә бирешмәскә кирәк. Тыгызлап ябып су кайнатсаң, чуен казан да шартлый. Ачуымнан шартлый яздым, дигән сүз халыкта да бар. Кайберәүләр кешеләрдән үч алып, башкаларны борчуга, хәсрәткә, газапка салып, үз күңелен бушата.

Бу сүзләрне профессор Зәйтүнәгә махсус карап әйтте кебек. Зәйтүнә кызарынып чыкканын тойды. Ул да, Ларисага ачуланып, үз борчуларын җиңеләйтергә маташа түгелме соң?

— Кайгы-хәсрәт килгәндә, күңел сызланганда нишләргә соң? — дип тыңлаучыларга күз йөртеп чыкты Җәмилә Закировна. Җавап көткәндәй, бераз тынып торды да: — Иң элек хәрәкәтләнү җаен карарга кирәк,— дип дәвам итте.— Саф һавада йөреп керсәң, баскычтан йөгереп менеп төшсәң, кеше арасына чыксаң, йөрәк ярсуы басыла төшә. Борынгыдан халык моны аңлаган, кешеләргә күрсәтми генә, мендәренә капланып күз яше түккән кызларны гаепләмәгән. Кайчак яшерен генә елап алу да файдалы.

Лариса сискәнеп, тураеп китте, авыр керфекләрен күтәреп, профессорның йөзенә текәлде.

— Ачулану, күңел сызлау — гомерне кыскарта,— дип сүзен йомгаклады профессор.— Сөенеч, шатлыклар, ихлас күңелдән көлү сәламәтлекне ныгыта. Җыр-бию, матур картиналар карау, моңлы көйләр тыңлау, башкалар кылган яхшылыкка соклану күңел яраларына шифа бирә.

«Көлү шифалы, димәк,— дип уйлады Зәйтүнә.— Менә мин, Әнвәр соң кайтты дип, тавыш куптармыйм, аның күңелен җәрәхәтләмәскә тырышам. Елмаеп-көлеп каршы алган чаклар да була. Ләкин күңел сызлауның аннан гына җиңеләйгәне юк шул».

Ашыкмый гына таралыша башладылар. Җәмилә Закировна тудыру бүлегенә, Вафина янына менеп китте. Лариса Зәйтүнәгә ияртде:

— Синең палатада бер хатын токсикоз белән ята, шуны икәү бергә карыйк әле.

Алар коридор буйлап янәшә атлап киттеләр.

— Фән өлкәсендә талантлы безнең профессор, ләкин тормыш мәсьәләләрендә арттарак калып бара, бигрәк беркатлы,— диде Лариса.— Хәзерге заман кешесе кәҗә түгел, аны бүре белән генә куркытып булмый! Хәзер әрләннәр заманы. Шәһәр халкы өендә әрлән асрый, белә ул үзенең кем белән уртаклыгын!

Нишләптер аның һәр сүзе Зәйтүнәнең ачуын кабарта иде. Ләкин ул бу халәтен сиздермәскә тырышты. Зәйтүнә нервыланып халат кесәсенә кулын тыкты һәм андагы кәгазьне йомарлады. Нәрсә бу? Ә, хат! Иртән хат бирделәр бит, ә ул аны һаман укымаган. Ул туктап конвертны ертты, Лариса аның җилкәсе аша хатны укырга үрелде:

— Менә хәзер синең гомерең озая инде. Рәхмәт хаты укыйсың бит.

«Кадерле Зәйтүнә Мәҗитовна! — дип язылган иде почмагына чәчәк төшкән ак кәгазь битенә карандаш белән.— Без, сезнең элекке авыруларыгыз, хәзер инде сәламәт хатыннар, сезгә мең рәхмәтләр укыйбыз».

— Әйттем ич! — Лариса алгарак китте. Аның өчен хатның кызыгы беткән иде инде.

Тагын берничә врачка һәм шәфкать туташларына рәхмәт сүзләреннән соң хәтта: «Сез кешеләргә бик күп яхшылыклар эшлисез, без сезнең үзегезнең дә бәхетле булуыгызны, тормышыгызның тигез-имин булуын телибез,— диелгән иде.— Шушы хис безне кулыбызга каләм алырга мәҗбүр итте дә инде».— Зәйтүнәнең күңеле сыза башлады. Профессорның киңәшләре бүген үк кирәк булмагае! «Сезнең гаиләгезнең иминлеген чагарга угын чыгарган елан шушы, Зәйтүнә Мәҗитовна! Сезгә мәңге төзәлмәслек йөрәк ярасы салырга, балагызны этисеннән аерырга, бәхетегезне тартып алырга омтыла ул елан. Уяу булыгыз, Зәйтүнә Мәҗитовна, ирегезне ул еланның сихереннән коткарыгыз! Ә сез беркатлылыгыгыз белән һаман аны яныгызга сыендырасыз. Ничек инде сез, башкаларның сызлануына шулкадәр сизгер була торып, үзегезгә янаган куркынычны сизмисез? Инде һаман да белә алмасагыз, без аның инициалларын куябыз: ЛСН». «Лариса Сөнгатовна Нигъмәтуллина,— дип өстәде Зәйтүнә үзеннән.— Мине белми дип уйладылар микәнни?»

— Әйдә инде, рәхмәт сүзеннән хәлең киттеме әллә? — диде коридорның аргы башында, баскыч астындагы караңгылыкта туктаган Лариса.

«Йөрәгемә кан сауды»,— дип кем беренче итеп әйтте икән? Сез хаклы түгел, Җәмилә Закировна, канга адреналин бүленеп чыгу гына түгел бу,— нәрсә ул адреналин! — бу нәкъ менә шул йөрәккә кан саву. Нинди киңәшләр бирдегез әле сез бүген, шөһрәтле профессор иптәш? Нишләргә тиеш инде Зәйтүнә шушы минутта? Икенче катка йөгереп менеп төшәргәме? Ләкин аякларның атлар хәле юк. Җырлап җибәрергә яки биеп китәргәме? Ләкин тамактан тавыш чыгарлык түгел, төер тыгылган. Мендәр почмагын тешләп, тавышсыз гына еларгамы? Ләкин күздә — яшь, янда мендәр юк. Ах, Җәмилә Закировна, сез сөйләгәндә барысы да шул хәтле аңлаешлы иде, үз башыңа төшкәч, бер чарасыз каласың икән лә!

Ярый әле, коридорның бу башында тәрәзә юк, баскыч астыннан узганда, йөзнең агарганы күренми, тез буыннарының йомшаганы сизелми.

— Чынлап торып ярдәм күргән кеше рәхмәтне сирәк әйтә ул,— диде Лариса аны көтеп алгач.— Авырулар — сәер халык, сихәтләнсә, мин врачсыз да терелер идем, дип исәпли, дәвалауның файдасы тимәсә, врачлар ялгыш дару биргән, дип уйлый. Беләсеңме, бер онколог миңа нәрсә сөйләде. Күкрәгенә операция ясап, рактан котылган бер хатын аңа бәйрәм саен открытка җибәреп тора икән. Һаман бер төрле сүз яза, ди: «Миндә бернинди рак булмаган, сез миңа операцияне ялгышып ясадыгыз, мине гомерлеккә имгәтеп калдырдыгыз. Ачы каргышым төшсен сезгә!» Ун ел буе шундый открытка алып кара әле син! Яңа елга да, Сигезенче мартка да, Май бәйрәменә дә. Әгәр теге врач операция ясап интекмәгән булса, үз башына мондый каргыш алмаган булыр иде.

— Чөнки ул хатын күптән кабердә булыр иде инде,— диде Зәйтүнә.

— Анысы инде хатынның үз эше!
— Ул врач андый открытканы алган саен куанырга тиеш. Рактан терелгән пациентың ун елдан артык яшәсен әле! Бу үзе зур бәхет бит! «Минем белән күзгә-күз карашып тынып калмас өчен шушылай такылдый бит бу»,— дип уйлады ул Лариса турында.
— Ништяк! Сине өзми-куймый каргасыннар да, син бәхетле бул, имеш!
— Зәйтүнә Мәҗитовна! — дип кычкырды коридорның аргы башыннан шәфкать туташы Анна Иванова.— Сезне сорыйлар.
Аның янында кызыл күлмәкле хатын-кыз күренде. Ул, башын кырын салыбрак, елмаеп басып тора иде. Зәйтүнә ерактан ук аның ике чигәсеннән сузылып киткән көмеш тасмаларны күреп алды.
— Сагындыгызмы? Тагын кунакка килдем менә! Чакырылмаган кунак шундый була ул!
— Әле үзем чакырырга тора идем,— диде Зәйтүнә.
— Күңелем сизде бит менә.
Динә Зәйтүнәгә түгел, аның җилкәсе аша караган, иреннәре елмаерга тырыша, әмма түгәрәкләнеп килгән күзләрендә кисәтүле сагаю чагыла иде. Ларисадан шикләнә, аның алдында сөйләшәсе килми иде аның.
— Лариса Сөнгатовна, гафу итегез! Без теге авыруны бераздан карарбыз инде,— диде Зәйтүнә башын артка бора төшебрәк. Ул авыру яныннан үзенең коллегасын куа, бу деонтологиягә — врачларның һәм авыруларның үзара мөгамәлә итү кагыйдәләренә берничек тә сыймый иде. Коллегаңны авыру каршында кимсетү иде бу! Зәйтүнә эчке бер үчләнү белән Ларисаның күзләрендәге гаҗәпләнүне күзәтте.
— Авыру белән икәүдән-икәү генә сөйләшә торган сүзебез бар,— дип кабатлады Зәйтүнә.
— Менә ничек! Сер, димәк?
— Сер!
Һәм Зәйтүнә аңа аркасы белән борылды.
— Мин сезгә направление белән килдем,— диде Динә. Һәм Зәйтүнәгә кечкенә генә кәгазь кисәге сузды. Учка сыярлык бу зәңгәрсу кәгазьгә хәтәр сүз язылган: участок врачы Динәдән шеш тапкан икән.
Зәйтүнәнең аяк астында идән чайкалып киткәндәй булды.
Ләкин бераздан ул үзе дә участок врачының мондый диагноз куярга сәбәбе барлыгына ышанды. Алай да Динәгә үзенең борчылуын сиздермәскә, күтәренке күңелле булып күренергә тырышты.
— Хәзер, өсләрегезне алышыгыз да, палатага кереп, тыныч кына ял итегез. Бүген үк мин сезне профессорга күрсәтергә тырышырмын, анализлар алырбыз, аннан соң нишләргә икәнен хәл итәрбез.
Тизрәк Җәмилә Закировнаны табарга кирәк иде. Зәйтүнә тудыру бүлегенә китте. Коридорда аңа Сөембикә апа очрады.
— Сөембикә апа, бишенче палатадан Хәйруллинага анализ ясагыз әле,— диде Зәйтүнә. Мондый анализ ясау Динәгә бөтенләй кирәк тә түгел иде югыйсә, Зәйтүнә моны үзе дә көтмәгәндә әйтеп куйды.
— Минем гөберчәкләрем пионер кебек, һәрвакыт әзер,— диде Сөембикә апа.
Зәйтүнә тудыру бүлегенә керүгә, каршы ишектән ак халатлы ике кыз килеп чыкты. Икесе дә, терсәкләрен бөгеп, озынча төргәкләр тотканнар. Яңа туган сабыйларны балалар бүлегенә илтүче акушеркалар иде болар. Зәйтүнә аларга юл биреп, стенага сөялде. Мондый хәлне күп күргән булса да, гаять мөһим вакыйганың шаһиты булганын тоеп, басып торды.
Менә тагын җирдә дүрт кешенең гомер юлы сызыла башлады. Тын, буш коридорда басып торган Зәйтүнәдән башка беркем бу бөек вакыйганы күрмәде. Шулай да акушерка кызлар, меңнәрнең карашы ас-

тында баргандай, башларын югары тотып, мәһабәт атлыйлар, чөнки үзләре башкарган вазифаның изгелеген аңлыйлар иде.

Без гомер юлыбызның башын да, ахырын да кеше кулларында узабыз. Әйе, адәм баласы үзенең гомер юлын башкалар кулында башлый, башкалар кулында тәмамлый.

Никадәр мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле булырга тиеш без бер-беребезгә!

*
* *

Балаларны имезергә иркен арбалар белән тарататалар. Арбаларга, бер-берсенә терәп, озынча сары төргәкләр салынган. Аларның күбесе тын гына ята, кайсылары кыймылдаша, елый.

Кайберәүләр яңа туган сабыйларны бертөсле дип күз алдына китерә. Һич юк. Туганда ук һәр адәм баласының үз кыяфәте, үз холкы. Берсе чырылдап елый, икенчесе калын тавыш белән таләпчән итеп кычкыра, өченчесе пых-пых итеп бөгәрләнә, ләкин еламый! Кайсының бите озынча, кайсының түгәрәк. Кайсы кара керфекле, кайсының керфеге бөтенләй үсмәгән. Берсе аскы иренен бүлтәйткән, икенчесенең өске ирене чыгып тора. Чагыштырып карасаң, һәрберсендә ата-анасының чалымнары ярылып ята.

Ә бер кырыйдарак хәрәкәтләнми-тавышланмый гына кечерәк өч төргәк ята, аларның бите чүпрәк почмагы белән капланган.

— Нишләп болай капладыгыз? — дип сорады Алтынчәч балаларны аниләренә өләшеп йөрүче яшь кенә шәфкать туташыннан.

— Алар иртәрәк туган,— диде кыз йомшак кына итеп, иркәләгән тавыш белән. «Җитлекми туган», димәде, «иртә туган»,— дип, матурлап әйтте.

Шуңа карамастан, Алтынчәч башкалардан шактый кечкенә, бөтенләй җансыз тоелган ул төргәкләргә тетрәнеп карады. Юк-юк, аның сабые, аның кызчыгы, аның Газизәсе болай булып тумас! Әнә, калын тавыш белән кычкыра торган, кашлары сызылып киткән, керфекләре тырпаеп торган шушы зур кызыл авызлы бала кебек булыр бу! Әйе, шундый җитлеккән, хәрәкәтчән булыр, томрап торыр аның баласы. Ана карынында тиешенчә яткан, җитлеккән балалар гына каш-керфек, куе чәч белән туа. Алтынчәчнең сабые каш-керфек үстереп туар.

Менә шушындый булып... Алтынчәч түшенә «35»ле клеенка кисәге тагылган сабыйга озаклап карап тора, кырыйдагы бите ябулы төргәкләргә ялгыш та күз төшермәскә тырыша. Менә шәфкать туташы аны читкәрәк этте дә, баланы алып, палатада, караватта ята торган хатынга кертеп бирде. Хатын битлек кигән булса да, ак, шома маңгаеннан, күзләреннән үк бик яшь икәнлеге күренеп тора. Ул сабыен мендәр өстенә җәелгән клеенкага салды да халат түшен чиште, йомры күкрәген чыгарып, күкрәк уртасында күгелҗемләнеп торган төймәне сабый авызына китерде. Алтынчәч сабыйның үз күкрәгенә орынганын тойгандай, күзләрен йомды.

— Сезгә монда йөрергә ярамый,— дигән тавышка күзен ачты ул. Шәфкать туташы палата ишеген ябып куйган иде.— Сезгә үз палатагызда ятарга кирәк,— диде кыз.

Алтынчәч теләр-теләмәс кенә коридорның аргы башындагы палатасына китте. Бала тудыру йортында өч сәгать саен кабатланып тора торган илаһи тынлык урнашты. Бу тынлык олы, бөек мәгънәгә ия, ул үзе бер тантана булып яңгырый иде шикелле: бу сәгатьтә әниләр бәбиләрен имезәләр иде.

Алтынчәч палатага кереп, караватына утырды да, мендәрен сыйпады. Аның саф, бәхетле дәвамы ятар бер көнне бу мендәрдә. Алтын-

чәч аңа гади һәм халыкчан, олы мәгънәле һәм балачакта да, олыгайгач та килешә торган, аның кадерен арттыра торган исем бирер — Газизә дип атар һәм беркайчан да, беркемнән дә ул исемне боздырып әйттермәс, беркем дә ул исемне ишеткәч көлемсерәмәс.

Аның шушы уйларын раслагандай, карынында баласы тибенә башлады. Врачлар:

— Баланның йөрәк тибеше бик яхшы ишетелә,— дип мактыйлар, тик менә малай булырмы, кызмы икәнен генә ачык әйтмиләр. Хәер, алар каян белсен! Алтынчәч үзе белә, үзе кыз булуын тели!

Дөрес, врачлар төрле хәл булуы ихтимал, диләр. Ләкин аларның ялгышканы азмыни? Әнә кичләрен, коридорда җыелышып утырганда, хатыннар ниләр генә сөйләми.

Бар төрле бәхетсезлек Алтынчәчкә генә килмәс инде! Ул врачларның кушканын җиренә җиткереп үти, биргән даруларын эчә, күз алларында ята. Каефе начар түгел, бер җире дә сызланмый, башы әйләнгән чак сирәк. Ә йөрәк кагу, тын бетү ишесе мондый чакта һәркемдә була.

Әнә, коридорда арба кирегә, балалар бүлегенә таба тәгәрәп китте, тынлыкны көр сабый тавышы ярып салды. Алтынчәч коридорга чыкты.

— Утыз бишенче, тагын шул утыз бишенче! — диешteләр анда хатыннар. Аннары теге шома маңгайлы яшь хатынга:

— Балаң туймый бит! — диделәр.

— Нишләп? Туктаусыз суыра югыйсә!

— Ә йотамы соң? Йотамы?

— Аның йотканын-йотмаганын каян беләсең инде?

— Сөтең җитмидер синең!

Һәм хатыннар яшь әнине өйрәтергә керештеләр.

Юк, Алтынчәч мондый булмас, ул күп итеп сөт эчәр, сабыеның тамагын туйдырыр!

Тудыру бүлегенә беркемне дә кертмиләр. Бары тик Алтынчәчкә генә бер-ике тапкыр лабораториядә бергә эшләүче кызлар белән очрашып сөйләшергә мөмкинлек бирелде.

Менә бүген дә, балаларны җыеп алгач, аны өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә чакырып керттеләр. Анда ак халат кигән Мөһимә басып тора иде. Алтынчәчкә күчтәнәчләр тутырылган полиэтилен капчык сузып:

— Ни хәлләрең бар? Күрергә килдем әле менә,— диде ул.

Алтынчәч яшерен өмет белән карады, ләкин Мөһимәнең кечкенә күзләре аңа туры карамый, читкә төбәлгән иде.

Алар янәшә урындыкларга утырдылар. Алтынчәч, соңгы баруында кимсенгәнен исендә тотып, Линар хакында туры бәреп сорашудан тыела иде. Ә шуннан башка Мөһимә белән ни сөйләшсен соң ул? Мөһимәнең исә теле тик тормый, хәл-әхвәлне сораша. Аннары ул Алтынчәчкә кайнар сулышын өреп, якынрак иелә төште дә:

— Үз кызым кебек якын кешем бит син минем,— диде.— Күңелдән бер дә чыкмыйсың. Әле менә врачлар белән дә сөйләштем. Алар әйтә, сүзне тыңламый, һаман үзенекен итә, бу хәлендә без аның исәнлеге өчен җавап бирмибез, диләр. Нишләп алай каршы киләсең, Алтынчәч? Алар галим кеше, белми әйтмәсләр. Гомерле булып туса, бала да яшәр...

— Минем хәлем әйбәт,— диде Алтынчәч аның сүзен бүлеп. Аның эче поша башлаган иде. Бу хатын һаман шул бер үк сүзне тәкърарлар өчен генә килде микәнни монда? — Үзем өчен үзем җавап бирәм мин.

— Токсикоз бик астыртын нәрсә, ди профессор. Аның кайчан аяктан егарын без дә әйтә алмыйбыз, кеше үзе дә белми, ди.

— Беләләр. Көн саен тикшереп торалар.

Алтынчәч кузгала башлады.

— Тукта әле,— диде Мөһимә.— И, мин үзем дә ана кеше бит, йөрәк түрләремнән китмисең! Әйтмәскә дә булгандыр инде, шулай да күңелем түзми: Линар килә бит, Алтынчәч! Тагын заводыннан командировкага җибәргәннәр. Бик сөйләшәсең киләдерме, булгай, менә килә үзе. Тик монда, больниска килә алырмы, анысын гына алдан әйтә алмыйм инде. Эш кешесе бит. Сөйләшсәгез, үзегез хәл итәр иегез тагын! Күрешсәгез, мин әйтте димәссең инде, яме.

— Рәхмәт, Мөһимә апа,— диде Алтынчәч аның кулына орынып. Ул шундук аңа булган бөтен үпкәләрен онытты.

Линар килә, димәк. Бик яхшы. Дөрес, ул хәзер Алтынчәчтән читләшә, аның белән араны бөтенләй өзәргә ниятли булса кирәк. Ләкин баланың атасы бит ул! Кызын ярата, бу баласын да бөтенләй үк чит итмәс. Әгәр дә Алтынчәч белән бер-бер хәл була калса, бала ятим калмас. Ни булса да сабыйга ата кирәк, исем өчен генә булса да кирәк бит.

— Кайчан килә соң ул?

— Бүген кич килеп җитәргә тиеш...— диде Мөһимә, нык әйткәненә үкенгән сыманрак итеп.

— Алайса китми тор, мин хәзер үк синең белән чыгам. Няня китеп өлгергән булса, кием-салымны бирмәсләр, син миңа пальтоңны бирерсең я такси чакырырсың. Шушы халат белән генә кайтырмын.

— Ай алла, ул хәтле кая кабаланасың? Бүген кире китмәс әле! Иртәгә дә соң түгел!

Ләкин Алтынчәч, аны тыңламыйча, бүлмәдән чыгып китте. Ул шундук Резеда Фәритовнаны күреп алды. Тудыру бүлегенең мөдире каядыр ашыгып, борчулы кыяфәт белән үтеп бара иде. Ул шактый вакыт фикерен җыя алмыйча, Алтынчәчнең сүзен аңламыйча торды.

— Мөһим мәсьәлә бу, Вафина,— диде, ниһаять.— Аны болай ашыкпошык кына хәл итеп булмый. Сезне врач күзәтүе астыннан чыгарырга ярамый, аңлагыз шуны!

— Мин расписка бирәм, сезнең мине көчләп тотарга хакыгыз юк!

Алтынчәчнең ахыр чиккә җитеп дулкынланганын, теләсә нинди тәвәккәллеккә әзер икәнен күреп, Резеда Фәритовна да йомшарды.

— Хәзер тота-каба чыгып китү — баланы куркыныч астына кую дигән, сүз. Әйдәгез, без болай итик: иртәгә иртән сезгә кирәкле даруларны табып бирерләр, нишләргә икәнен яхшылап аңлатырбыз. Яңадан бер тапкыр анализ ясарбыз. Ә хәзер тынычланыгыз, әйбәтләп йоклагыз. Сезне бу хәлдә чыгарган өчен без дә җавап бирергә тиеш булачакбыз бит! Аңлагыз шуны! Тынычланыгыз!

Ул ашыгып китмәкче иде, Алтынчәч аның артыннан нырде:

— Ә сез сүзегездә торырсызмы? Иртәгә чыгарырсызмы мине?

— Һәрхәлдә мин сезгә ярдәм итәргә тырышырмын.

Алтынчәч шуннан артыгына ирешә алмасын, ниһаять, аңлап, кире борылды. Аның хәзер генә чыкмасын белгәч, Мөһимә, җиңел сулап, саубуллашырга ашыкты.

*
* *

Профессор кабинетында республиканың баш акушер-гинекологы утыра иде. Мәскәү өчен отчетлар әзерли, киңәшергә килгән. Гадәттә алар институтта очраша торган иделәр, бу юлы Талия Гафаровнаның бирегә килүе профессорны бераз сагайтты.

Шиге юкка булмаган икән. Отчетлар турында сүз тәмамлангач, Талия Гафаровна стенадагы ана белән бала рәсеменә карап, көрсенеп куйды. Чал чәче, сулган йөзе аны олыгайтып күрсәтә, шуңа күрә ул профессор Ильясовага бераз гына олыларчарак карый иде.

— Әйтәсе килми килүен дә, әйтми дә булмый, Җәмилә Закировна. Сезне Мәскәү һаман расламады бит әле!

Әйе, чыннан да, Гыйльми советның Ильясованы кафедра мөдире итеп яңадан сайлаганына шактый вакыт узды инде, ә Мәскәүдән һаман раслау килгәне юк әле. Шулай да, моңа житди сәбәп бардыр, дип уйламый иде Җәмилә Закировна.

— Җитәкчеләрнең эше күп була, житешә алмыйлардыр,— диде ул җиңел генә итеп.

— Сезнең өстән жалоба ята анда, Җәмилә Закировна. Бик житди һәм озын жалоба.

— Анонимкадыр инде?

— Авторы кулын куйган.

«Дәүләтшин»,— дип нечкә бер тамыр сулкылдап куйды Ильясованың күңел түрендә. Ләкин бу исемне кычкырып әйтергә теле бармады. Остазына кул күтәргән шәкерт... Мөмкин эшме бу?

— Дәүләтшин,— диде Талия Гафаровна.

Җәмилә Закировна, жылытырга теләгәндәй итеп, кулларын угалады.

— Миңа шундый зур үпкәсе бар микәнни?

— Кафедрада яшьләргә үсәргә мөмкинлек юк, чөнки Ильясова берәүне дә үзеннән уздырырга теләми, дигән. Яшьләр кафедрадан китә, дип мисаллар китергән. Үзен... Мине...

— Сезне дәмени?

Заманында Талия Гафаровна шушы кафедрада аспирантура тәмамлаган иде. Ләкин диссертациясен яклый алмады, чөнки кияүгә чыкты, бала тапты, өч ел буе урын өстендә яткан ирен тәрбияләргә тиеш булды. Квартирны аларга Ленин районыннан биргәннәр иде, Талия Гафаровна өенә якынрак урынга эшкә күчәргә мәжбүр булды. Еллар узып, баласы үсеп, ире аякка басканда, аның фәнни эшкә омтылышы сүнгән иде инде. «Язу-сызудан болай да гарык, кәгазьдән күзне күтәреп, авыруларга карарга да вакыт юк»,— ди ул. Хатын-кызның гадәти язмышы, нишлисең. Дөрес, Талия Гафаровна уңган һәм кешелекле врач, югалып калмады, абруй казанды, республиканың баш акушер-гинекологы дәрәжәсенә житте.

Хәзер менә аның, үсәргә зур мөмкинлекләре булган кешенең, кафедрадан ник киткәнен югары оешмаларга аңлатып кара инде син!

— Үземә кагылган кадәресенә мин үзем жавап бирермен бирүен,— дип дәвам итте Талия Гафаровна.— Ә менә Дәүләтшин, Ильясова мине эзәрлекләвен һаман дәвам итә, дип бара. Авторитетымны төшерү өчен, минем авыруларны үзенә ала, дип язган, Ахунова фамилиясен телгә алган.

— Анысы хак,— диде Җәмилә Закировна.— Ахунованы мин аннан алдым.

— Сез алай димәгез инде, Җәмилә Закировна! Мәскәүдә Дәүләтшин турында бик яхшы фикер яши, белгеч буларак та мактыйлар, сүзе дә үтә.

Җәмилә Закировна Мәскәүдәге очрашуларны күз алдына китереп көлемсерәде:

— Беләм, беләм.

— Көлмәгез әле сез, Җәмилә Закировна. Монда бик житди итеп, төптән уйлап бирергә туры киләчәк жавапны. Анда әле кафедра клиникасында тәртип юк, диелгән, тиеш булмаган кешеләрне урынга салу очраклары китерелгән. Алары чеп-чи ялган, мөгаен!

— Ю-ук, Изаил Харисович бер дә юкны язмастыр,— дип Җәмилә Закировна көлемсерәп башын чайкады.— Аны алай ансат кына каптыра алмассың! Тикшереп карарга кирәк.

— Җәмилә Закировна, сез ни сөйлисез!

Профессор Ильясованың бу рәвешле үз-үзеннән көлгәндәй сөйләшеп утыруы Талия Гафаровнаның башына сыймый иде. Ул һаман мәсьәләнең җитдилеген, йөз аклыгы өчен көрәшергә кирәклеген аңлатырга тырышты.

Аны озатканда да, киенеп урамга чыкканда да, Җәмилә Закировнаның йөзе шат, адымнары җиңел иде.

Бакча кырыенда, зәңгәрсу машинасында аны Мөбарәк Таһирович көтеп тора, алар аэропортка барып, бер танышларын каршы алырга тиешләр иде.

Җәмилә Закировна машина ишеген ачкач, Мөбарәк Таһирович гаҗәпләнеп:

— Ни булды сиңа? — дип сорады.

— Ә нәрсә?

— Төсең качкан.

— Болай гына... Безнең эштә була инде. Алтынчы роддомга сугылып чыгыйк әле. Бер генә минутка.

— Беләм мин синең минутларыңны,— диде Мөбарәк Таһирович канәгатьсез тавыш белән.

— Тиз генә чыкмасам, үзең генә барырсың.

Татарстан урамына борылгач, Мөбарәк Таһирович кисәк кенә тормозга басты.

— Әнә, Изаил Харисович килә,— диде.— Аны да алыйк, бәлки, юл уңаедыр.

Дәүләтшин аларның өенә килеп йөргән чактан ук, Мөбарәк Таһирович бу ачык, тырыш егетне яратып калган иде. Җәмилә Закировна үзенең шикләре турында йомшак, сак кына әйтеп караса да, Мөбарәк Таһирович аларны зурга алмады. Диләрам белән булган хәл турында ишеткәч тә, бәндә хатадан хали түгел, диде. Кафедра мөдирлегенә Дәүләтшинның да гариза бирүенә дә исе китмәде: яшь кеше, үсәргә теләве бик табигый, ә син эшеңне аннан ким башкармасыңа ышансаң гына урыныңда кал, диде, мондый хәлне тормышның гадәти каршылыгы дип аңлатты.

Мөнәсәбәтләрнең чын асылы аның өчен караңгы булып калды, ләкин моны Дәүләтшин үзе яхшы белә, ул, әлбәттә инде, машинаны читләтеп үтәргә тиеш иде.

Әмма ул аларны күрмәмешкә салышырга теләмәде. Ерактан ук елмаеп, адымнарын кызулатып килде, тәрәзәгә иелеп, гадәттәгечә ачык чырай белән сәлам бирде. Аннары ишекне үзе ачып, арткы утыргычка утырды.

Ирләр һава хәлләрен, юлларның начарлыгын сөйләштеләр, ләкин сүзләре Җәмилә Закировнаның зиһененә бик томанлы гына барып җитте. Каршыдагы көзгедән ул доцентның түгәрәк, шома, үз-үзеннән канәгать йөзен, агы зәңгәрсуланып торган коңгырт күзләрен, яңа төр җәнлеккә карагандай, дикъкать белән кат-кат күздән кичерде. Изаил Харисовичның бөтен кыяфәтеннән вөҗдан сафлыгы бөркелә иде.

Шунда Җәмилә Закировнаның күңеленә яшен яшьнәгәндәй булды: бу кеше профессор Ильясова каршында, остазы каршында үзен тамчы да гаепле дип санамый иде. Оялу да, кыенсыну да, бу миңа үпкәләмәде микән, дигән шик әсәре дә юк иде бугай анда. Менә ул машинаны туктатуны сорады, рәхмәт әйтеп китеп барды. Аның артыннан ишекне яхшылап ябарга үрелгән Мөбарәк Таһирович тагын борчылып:

— Карале, Җәмилә, авырыйсың түгелме син? — диде.

— Авырганнан түгел ул...

— Ә нәрсәдән? Үзеңне дә карарга кирәк бераз. Менә хәзер баруга кан басымыңны үлчәтеп кара әле.

Алар Профсоюз урамына керделәр. Алда урам чаты, кырыйдагы йортның почмагына, җирдән ике метр чамасы биектәрәк, зур түгәрәк

күзгә беркетелгән, аркылы урамнан килгән машиналар шуннан күренә иде. Җәмилә Закировна күзгәдә күксел «Волга»ның чагылышын күреп алды, ул зурайганнан-зурая иде. Ә Мөбарәк Таһирович борчылып хатынына карый.

— Туктат...— дияргә теләде Җәмилә Закировна.

Ләкин әйтергә өлгердеме, юкмы, анысын белми калды, дөнья караңгылыкка чумды....

*

* *

Наил Хәйдәрович килеп кергәндә, Зәйтүнә авыру тарихларын тутырып утыра иде.

— Яңалыклар бармы, Зәйтүнә Мәҗитовна?

Беренче карашка Наил Хәйдәровичны һич кенә дә врач дип уйламассың. Аның шакмаклап ясалгандай киң, билсез, тәбәнәк гәүдәсендә, кыска муен, йомры башында, мичтә пешкән ак күмәч кебек түгәрәк ачык чыраенда ныклык, крестьян сабырлыгы ярылып ята, йомшак тавышында күңел киңлеге сизелә. Әйтерсең лә ул монда очраклы кеше, терелеп килгән хатынына сөенечле хәбәр китергән, бу бүлмәгә исә ак башлыгын түгәрәк баш түбәсенә кырын гына салып, халат төймәләрен эләктереп тә тормыйча, врачларга рәхмәт әйтергә генә кергән. Аны күрүгә, күңелне шомландырып торган нәрсәләр кичерәеп киткәндәй була, яшәүнең күңелле яклары күзгә ныграк күренә башлый. Врачларның да, авыруларның да кәефен күтәрә белә ул. Хәер, аның һөнәре шул — операция вакытында сызлануларны җиңеләйтүче, кешенең җан сагында торучы — анестезиолог Наил Хәйдәрович. Сугыш вакытында хирург булган, ә тынычта үзенә яңа һөнәр сайлаган.

Зәйтүнә аңа борылып ямансу гына елмайды.

— Менә яңа авыру керде бит, Наил Хәйдәрович. Шеш белән.

— Каяле, авыру тарихын бирегез әле.

Зәйтүнә коридордагы шкафтан Динәнең әлек ятканда тутырылган тарихын табып алды. Наил Хәйдәрович урындыкка береккәндәй җайлап утырды да зәңгәрсу кәгазь өстенә иелде.

— Син мондамыни әле? — дип ишекне ачып сорады Сөембикә. Ул Наил Хәйдәровичның хатыны иде.— Кайтканда ипи ал, димәкче идем.

— Туктале, карчык, зиһенне таратасың.

Сөембикә әчкәрәк, Зәйтүнә утырган өстәл янынарак узды.

— Анализ булды, Зәйтүнә Мәҗитовна. Минем гөберчәк Хәйруллинаны йөкле итеп күрсәтә.

— Йөкле итеп? Ялгышмыйсызмы?

Сөембикәнең тиз үпкәли торган гадәте юк, шулай да елмаю яктысы кимеде. Кабан күлендә һәм Болак буенда үскән гөберчәкләр беркайчан да ялгышмый. Һәрхәлдә андый очракның моңарчы булганы юк. Ә бәлки, бу аларның беренче ялгышуыдыр, бу методта нормага кирә торган йөздән ике очракның берседер? Әгәр ялгышмасалар?

— Тагын тикшертеп карыйсызмы әллә, Сөембикә апа?

— Анысын эшлибез инде, гадәттәгечә.

Ул чыгып киткәч, Наил Хәйдәрович уфылдап урыныннан кузгалды.

— Алайса, мин авыру белән танышып чыгыйм әле. Әгәр операция ясарга ниятләсәгез, төнгә калдыруда мәгънә булмас. Шулай бит?

Мондый очракларны профессор үзенә хәбәр итәргә куша. Ул алтынчы бала тудыру йортына киткән икән, Зәйтүнә моны бая ук белгән иде. Димәк, шунда шалтыратырга кирәк. Зәйтүнә трубканы алды. Телефонны теге башта тиз генә алмадылар, ә инде профессор Ильясованың фамилиясен ишеткәч, шундук трубканы кире куйдылар. Зәйтүнә

яңадан шалтыратып, баш врачны сорады. Анысы Зәйтүнәнең кемлеген, профессорны нинди максат белән эзләгәнен белешкәч кенә, көрсенеп: «Бу мәсьәләне сезгә мөстәкыйль хәл итәргә туры килер,— диде.— Җәмилә Закировна авыр хәлдә унбишенче больницада ята».— «Ничек алай булсын! Ул әле иртән генә монда рапортта булды! Сез башка берәү белән бутыйсыздыр!» Баш врач тагын тынып торды. Аннары тавышын әкренәйтә төшеп: «Сездән әле генә шалтыратып белештеләр бит инде,— диде.— Авариягә эләкте ул. Ире үлгән, үзе реанимациядә».

Бу — тиз генә башка сыя торган яңалык түгел иде. Шуннан соңгысы томан эчендәге кебек эшләнде. Врачлар, шәфкать туташлары ах итештеләр.

Тудыру бүлеге мөдире Резеда Фәритовна шунда киткән икән. Доцент Виктор Ефимович: «Барыбыз да анда китеп, авыруларны калдыра алмыйбыз бит инде! — диде.— Анда мөмкин булганны бездән башка да эшләрләр». Хәйруллина турында ишеткәч, ул да Наил Хәйдәровичның фикерен кабатлады: әгәр чыннан да читтә урнашкан яралгы икән, операцияне кичекмәстән ясарга кирәк. Югыйсә әчкә кан савуы бар.

Коридордагы кечкенә өстәлдә, кайнар сулы кастрюльдә «мунча» ясап, каннарның катнашу-катнашмавын тикшереп торганда, Фидая:

— Бәлки, бу — миллионга бер очрый торган үзенчәлекле очрактыр? — дип сөйләнде.— Бер кагыйдәгә дә буйсынмыйдыр? Бер анализ белән дә беленмидер? Операциягә салмасаң — соңга калуың бар, салып та диагноз расланмаса, юкка кисүең ихтимал...

— Ә шулай да син Хәйруллинага икенче тапкыр операция ясаудан котыла алмассың, ахрысы,— диде Зәйтүнә.

— Минме? Хәйруллинаның янына бару түгел, исемен генә ишетсәм дә колымнан әйбер төшеп китә минем.

Доцент Виктор Ефимович тудыру бүлегеннән китә алмый икән.

— Үзегезне сынап карагыз, Зәйтүнә Мәҗитовна,— диде ул тыныч кына.— Тәҗрибәгез җитәрлек, кулыгыз бу эшкә ятып тора. Мин сезнең мөмкинлекләрне беләм бит инде! — Доцент Зәйтүнәне операцияләрдә ассистент булып торган чакларында элек тә мактый иде.— Ул-бу килеп чыкса, мине чакырырсыз!

Мондый ышанычны яшь врачның теләсә кайсы куанып кабул итәр, үз язмышында зур борылыш дип санар иде. Зәйтүнә моны аңлый иде, әлбәттә. Ләкин көне, көне нинди бит! Нилләр генә кичерергә туры килмәде аңа бүген!

Наил Хәйдәрович белән сөйләшкәннән соң, Динә дә тынычланып киткән иде инде. Елмаерга тырыша, иреннәре ерылган, әмма барыбер күзләре түгәрәк күл кебек мөлдерәмә.

— Бик күп мәшәкатьләдем инде мин сезне, доктор. Гафу итегез, бусы, мөгаен, соңгысы булыр. Миңа хәзер барыбер инде,— диде ул ачы елмаеп.

Тавышында шундый зар ишетелде ки, Тимербулатның елаганын ишеткәндәге кебек, Зәйтүнә эчке сыкрану белән аңа таба иелде:

— Чыкмаган җанда өмет бар, Динә. Ышаныч белән, өмет белән тотыныйк без бу эшкә.

Зәйтүнә Динә янынннан чыгуга, Анна Ивановна юка стакан белән куе чәй кертеп бирде:

— Операция алдыннан хәл алыгыз, доктор!

Шактый күп операцияләрдә катнашканы булды Зәйтүнәнең. Операция сестрасы булып та, ассистент булып та. Ләкин беркайчан да ул бу бүлмәгә тыныч кына керә алмады. Бүген исә бусаганы аеруча дулкынланып атлады.

Операция ясаучы врачларны гадәттә шикәрдәй ак киемнән дип күз алдына китерәләр. Авыруның баш очында, сулыш аппараты һәм кан

салу җайланмасы янында басып торучы Наил Хәйдәрович белән наркология сестрасы Анна Ивановнаның халатлары чыннан да чем-ак. Ә менә хирургларның киеме карап торуга иләмсез һәм күргәргән салам төсле ямьсез. Идәннән сөйрәлеп торган халат, башларында күз туры гына уелган бөркәнчек. Бу киемнәр стерилизацияләүдән шулай ямьсез төскә керәләр. Операция вакытында хирургның киеме матур булу ул чаклы мөһим түгел, әмма хатын-кыз күңеле мондый ямьсезлек белән барыбер ризалашмый, тән җайсызлык тоя. Резин перчаткалар эчендә кул тирли. Махсус лампалар эсселекне арттырып, сулыш алуны кыенлаштыра. Ләкин барыннан да бигрәк Зәйтүнәне эчке дулкынлану яндыра иде: алар куйган диагноз дөресме? Зәйтүнә барысын да тиешенчә башкарып чыга алырмы? Аның кулындагы скальпель тәнгә бер генә миллиметр да артык җәрәхәт ясарга тиеш түгел, шул ук вакытта зарарланган күзәнәкләр дә калырга тиеш түгел.

Башта сүзсез генә эшләделәр. Иркен бүлмәдә бары тик сулыш аппаратының тигез ритм белән эшләгәне, Зәйтүнә куйганда, инструментларның бер-берсенә бәрелеп чыңлаганы гына ишетелеп торды. Хирургия сестрасы кирәкле коралны үзе биреп тора, Фидая Галимовнаның нечкә бармаклары җитез һәм төгәл хәрәкәтләнә иде. Ниһаять, бар сорауларга ачык җавап бирер мизгел җитте.

— Менә ул!

Фидая Галимовна күтәрелеп Зәйтүнәгә карады. Саргылт тукыма арасыннан аның күзләре шатлыклы елмая иде. Алар ялгышмадылар: Динәдә чыннан да шеш түгел иде. Диагнозны да дөрес куйдылар, операцияне дә нәкъ вакытында ясыйлар, әгәр азга гына кичеккән булсалар да, Динәнең хәле тагын да авырайган булыр иде.

Зәйтүнә белән Фидая сөенечләрен күз карашы белән генә аңлаштылар да янә аска иелделәр.

Хәзер инде тыныч күңел белән операцияне мәгълүм методика буенча дәвам итәргә була иде.

Ләкин скалпельне күтәргәч, Зәйтүнәнең кулы үзеннән-үзе туктап калды. Ул Динәнең: «Миңа барыбер инде»,— дип елмаерга тырышып, мөлдерәмә күзләре белән карап ятканын күз алдына китерде. Ничек барыбер булсын! Менә хәзер Зәйтүнә аның соңгы өметен юкка чыгарачак. Галим врачлар тәкъдим иткән методика зарарланган тукымаларны кисеп алганда, алар тирәсендрәге тукымаларны да бераз алырга куша. Һәм күпме алырга икәнлеген дә күрсәтә.

Әмма бу очрак китапта күрсәтелгәннән үзгәрәк. Әгәр дә зарарланган урынны бик төгәл, пөхтә итеп кенә алсаң, ул чакта аз гына булса да өметне калдырырга мөмкин булыр иде. Ана булу өметен...

Зәйтүнәнең скальпеле тәнгә якын килүгә, Фидая Галимовна аның ниятен аңлап алды, куркынып:

— Әгәр бер-бер хәл булса? Методиканы бозганыбыз өчен...— диде.

— Җавабын үзем бирермен,— диде Зәйтүнә һәм операция сестрасына борылмый гына: — тампон! — дип өстәде.

Марля төене кыстырылган тимер кыскыч аның учында иде инде. Фидая Галимовна җитез хәрәкәтләр белән кан тамырларын бәйли иде. Зәйтүнә назлы итеп маңгаен сөртеп алганнарын тойды. Динәнең баш очыннан Наил Хәйдәровичның тыныч тавышы ишетелде:

— Безнең хәлләр әйбәт, йөрәк тибеше дә, сулыш та нормада.

Бүлмәдәге киеренкелек кимеде, барысы да үз эшләрен җиңел итеп, күңел күтәренкелеге белән башкардылар. Зәйтүнә соңгы җөйләрне пөхтә, тигез итеп салырга тырышты. Узган операциядән соң, Фидая Галимовна Динәнең тәнен бик пөхтә теккән, ул җөй сул якта, нәфис тәнне әллә ни бозмый да диярлек. Матур булсын Динәнең тәне, ә бәлки аңа әле әни булырга да туры килер.

Ниһаять, Зәйтүнә сынын турайтып, гомерендә беренче тапкыр изге сүзләрне әйтте:

— Операция тәмам. Барыгызга да бик зур рәхмәт.

Бөтенесе елмаешып алдылар. Операция сестрасы зур ак эмаль тазга шалтыратып инструментларны тутыра башлады. Анна Ивановна Динәнең өстенә җәймә япты да, баш очына килеп, битенә суккалады:

— Диночка, Диночка, уян инде! Курыккан идең, менә котылдың да.

«Котылды микән?» — дип уйлады Зәйтүнә. Операциянең чын нәтиҗәсе шактый вакытлар узгач кына беленәчәк иде әле.

*
* *

Зәйтүнә киенеп, тышкы ишектән чыгуга, каршысына ир кеше очрады.

— Хәерле кич, Зәйтүнә. Әйдәгез, мин сезне илтеп куям.

Бу Мөдәррис иде. Аның башын иеп, күзен кыса төшеп каравында электән таныш соклану һәм ялвару күреп, Зәйтүнә гаҗәпләнеп куйды. Бүген бөтен дөнья үзгәрмәдемени соң? Анда әле кичәгечә яшәүчеләр бармыни? Бу кеше бүгенге хәлләрне белмәгәнгә генә шушылай саташып карыйдыр!

— Сез мине илтеп йөри алмассыз инде бүген. Хатыныгыз янына керсәгез яхшырак булыр иде. Төнне аның янында үткәрсәгез бигрәк тә әйбәт.

— Хатын-кыз больницасындамы?

Аның Динә хәлен сорамыйча, хатын-кыз больницасына керергә куркуы Зәйтүнәне тагын бер тапкыр сискәндереп җибәрде. Хәер, ир кешеләрнең күңелен аңлап житкермидер ул, шуңа гына сәерсенәдер. Динә янында шәфкать туташы да бар, әлбәттә. Ләкин ул күзен ачканда янында ирен күрсә, кәефе күтәрелер иде. Мондый авыр чакта хатыны янында оулу Мөдәрриснең үзе өчен дә файдага гына булыр, дип уйлады Зәйтүнә.

— Сез борчылмагыз,— диде ул Мөдәррискә.— Операция яхшы узды, бөтенесе әйбәт. Хәзер аны яхшылап карарга кирәк.

— Нинди операция? Тагын шундый операцияме?

— Шундый ук.

— Өмет беткән икән инде алайса...

Мөдәррис башын иеп, эшләпәсе астында кечерәеп калгандай булды.

— Исән калганына шөкер итәргә кирәк,— диде Зәйтүнә Динә өчен үртәлеп.— Төрле хәлләр була. Ә өметне өзәргә ашыкмагыз әле.

Ләкин Мөдәррис аның сүзләрен ишетми дә иде бугай, һаман шулай башын иеп басып торуында булды. Кечкенә, көчсез, чарасыз булып тоелды ул бу минутта. Зәйтүнә үрелеп аның каты салкын бармакларын тотып алды.

— Кич ашадыгызмы соң әле сез?

— Бер кире китсә китә инде ул. Бәхетсезлек ялгыз йөрми, диләр.

— Хәзер без болай итәбез. Сез ашап килегез, аннары тәрәзә чиртерсез дә дежур сестра сезне арткы ишектән генә кертер. Мин сестрага әйтермен. Арткы ишекне беләсезме? Әйдәгез, күрсәтәм.

Ул Мөдәрриснең кулыннан тартты, ә тегесе кире малай шикелле артка тайпылды.

— Болай ярамый,— дип үгетләргә кереште аны Зәйтүнә.— Хатыныгыз күзен ачып, сезнең мондый чыраегызны күрсә, өр-яңадан һушын-

нан язачак. Бүген сез — аның врачы, ә врач аз гына булса да артист ул!

Мөдәрриснең һаман кузгалмаганын күргәч, Зәйтүнәнең сабырлыгы төкәнә башлады:

— Ир кешеме сез, юкмы? Нәрсә җебеп төштегез? Мин дә монда сезнең белән төн куна алмыйм, яслердә балам көтә!

Мөдәррис кинәт аның бармакларын шундый каты итеп кысты, Зәйтүнә ыңгырашып куйды.

— Аның янында кеше бармы?

— Наркология сестрасы утыра, дидем бит. Эштән соң калып!

— Тагын бер сәгатькә генә түзәр иде. Әйдәгез!

Мөдәррис көч белән аны урам ягына тартты.

— Сез дежур сестраны күрмәдегез бит әле. Ишекне кем ачар? — диде Зәйтүнә.

— Үзем кирәсе ишекләрне сездән ачтырган юк бит әле моңарчы, табармын!

Һәм Мөдәррис аны җитәкләп бакча аша алып китте, аяк астында карга каткан яфраклар гына шыгырдап калды.

*

* *

Авыруларга күчтәнәчләр, кирәк-ярак бирү, аларның хәлен белү өчен билгеләнгән вакыт бетеп килә, сәгать алтынчы киткән иде инде. Шулай да, «П» хәрефе ясап салынган иске бинаның урта өлешендә, тудыру бүлеге каршында кеше һаман өзелми иде әле. Берсе китте исә, аның урынына башкасы килеп баса, башын күтәреп, икенче катка текәлә. Ә анда, ут балкыган тәрәзәләрдә, бумази халат кигән хатын-нар бер-берсен алыштырып тора, алар, учлары белән яктылыктан ышыкланып, тыштагыларга елмаялар, иреннәрен әкрен хәрәкәтләндереп нидер әйтәләр, әмма пыяла аркылы сүзләре аңлашылмый иде.

Уңда, «П» хәрефенең бер терәген хасил иткән өлештә, гинекология бүлегенә керә торган ишек, аның өстенә йөз илле лампа асылган. Ир-ат халкы ул ишектән башын иеп, бөрешеп килеп чыга һәм, як-якка карамый, тиз-тиз атлап урам караңгылыгына ашыга. Кичкенә бакчада, шәрә агачларның күзне алдый торган күләгәсендә басып торган Әнвәр, кыйгачлап салынган сукмактан, карга каткан яфракларны кыштырдатып берәрсе узган саен, койма янына елыша иде. Аңа гинекология бүлегенең арткы ишеге янына үтәргә кирәк, ләкин ул күләгәдән чыгыйм дигәндә генә ишектә яңа кеше күренә иде.

Болай йөрисе калмаган, дип уйлады ул, Лариса белән башка урында очрашасы калган. Ләкин бүген вакытны төгәл билгеләү кыен булды шул. Әнвәрнең укытучы булып эшләүче бер танышы мәктәп теплицасы корырга ниятләгән икән дә, бик үтенеп киңәшкә чакырган иде. Мәктәп шушы тирәдә. Телефоннан Лариса белән сөйләшкәндә, Әнвәр, бушагач сине үзем килеп алырмын, дип вәгъдә биргән иде. Зәйтүнәнең эше бишттә үк бетә, эчтә дежур врач белән сестра гына кала, ә Лариса көтеп торачак.

Ниһаять, ишегалды уртасында басып торучылар бетте, тәрәзәдән карап торган хатыннар да күздән югалды, үндагы ишек тә ачылмый башлады. Ләкин Әнвәр агач ышыгыннан чыгам дигәндә генә, бакча янына кызыл «Москвич» килеп туктады. Эшләпәле ир кеше, машина ишеген шартлатып ябып, кызу атлап ян ишеккә таба юнәлде һәм каршына килеп чыккан хатын-кыз белән бәрелешә язды. Алар кызып-кызып нидер сөйләштеләр, әмма сүзләре Әнвәргә килеп җитми иде.

Ак якалы кара пальто, ак бүрек кигән бу хатынның Зәйтүнә икәнлеге Әнвәрнең башына бераздан гына барып житте. Ул гажәпләнүеннән саклыкны да онытып, баскан урынында хәрәкәтсез калды. Менә Зәйтүнә теге кешенең кулына ябышты, артына борылып, үзе белән алып китмәкче булды. Тегесе аңа карышып, арткарак каерылды. Алар тагын бәхәсләштеләр, ахры, ниһаять, ир кеше, Зәйтүнәнең кулын ычкындырмыйча, мәҗбүр итеп диярлек, машинага таба алып китте. Алар, агач төбендә басып торган Әнвәрнең күләгәсен таптап, сукмактан ашыгып уздылар һәм «Москвич»ка утырып, китеп тә бардылар. Машинаның кызыл утлары Әнвәрне мыскыллап җемелдәштеләр һәм олы урам борылышында эреп юкка чыктылар.

Әнвәрнең зиһене таралып китте: бу ни дигән сүз? Зәйтүнә баланы ясленән алып, өйгә кайткан булырга тиеш бит инде...

Мөгаен, ул соңаргандыр да, шушы кешедән машина белән илтеп куюын үтенгәндер. Ләкин... ник соң Зәйтүнә аны бинага таба тартты, ә тегесе аңа карышып диярлек, машинасы янына әйдәде? Кыланмышлары да бик якын кешеләр шикелле иде...

Бакчада Әнвәрнең гәүдәсе генә басып калды, күңеле исә машина артыннан ашкынды. Беләсе иде: ни сөйләшәләр, кая баралар икән...

Әллә соң берәр машина тотып, артларыннан куа чыгаргамы? Һи, бу сәгатьтә Казан урамында машина тапканчы, алар инде әллә кайлардан урап килә алалар. Кала буйлап хатынын эзләп чапкан ирдән дә көлке һәм көчсез адәм дөньяда бар микән? Алай рисвай булудан ни мәгънә?

Әнвәр бакча почмагыннан кире борылды да, сак булырга кирәклеген дә онытып, бина артына чыкты. Түрдәрәк кечкенә болдыр шәйләнә, тәрәзәдә тоныку кына ут яна иде. Әнвәр, перчаткасын салып, учын пыялага куйды. Пәрдә ачылып, Лариса күренде, ул борынын пыялага терәп елмайды да, кире чигенде — ишек ачарга китте.

Әнвәр бусаганы атлауга, Лариса аның кочагына кереп, күкрәгенә сенде. Аннары бармакларыннан кысып тотып, бүлмәгә алып керде, Әнвәрнең куртка сәдәфләрен ычкындырганда, муенын кытыклап алды:

— Туңып беткәнсең бит, йолдызым! Җылынырга кирәк сиңа. Җылытырга кирәк сине!

Әнвәр курткасын аның кулына биреп, артсыз урындыкка утырды. Тимер абажурлы тәбәнәк өстәл лампасы гына янганга, бүлмә иркен, күләгәле почмаклар серле булып күренә иде. Әнвәр озын, тар өстәлнең караңгыда калган аргы очына, анда шәйләнгән штативларга, пыяла савытларга шикләнеп карады. Бу башка, яктыга нилардер куелып, өстенә ак кәгазь ябылган, кырыйдарак шома стаканда кызгылт-сары һәм ачык-сары кипкән чәчәкләр тора иде. Шушы кечкенә генә мәйданда да Лариса күзгә ямь бирә, күңелне кузгата торган дөнья булдыра алган иде.

— Йом күзеңне, йолдызым! Хәзер могжиза ясыйм! Тылсымлы ашъяулык, җәел!

Әнвәр күзен ачканда, өстәлдән кәгазь алынган, җыйнак кына табынның өсте ачылган иде. Колбаса юка итеп турап тезелгән, сыр кисәкләреннән чәчкә ясап куелган, кара ипи телемнәре, нәфис итеп киселгәнгә, күзәнәкләре белән ымсындырып, авыздан сулар китерә иде. Ә уртада, ут яктысында тылсымлы балкып, үтә күренмәле сыеклык тулы кечкенә колба утыра. Спирт, дип уйлады Әнвәр.

— Тагын авырулар премия бирдеме?

— Кеше биргәнне генә көтеп тормыйбыз, үзебез дә таба беләбез! Лариса өстәлнең аргы башыннан йөзәр грамм гына сыешлы ике шома стакан алып килде.

— Анализ ала торган савытлармы бу синең?

— Болары яңа, кулланууда булмаганнары.





РЕСПУБЛИКАНСКАЯ

Лариса яртылаш кына итеп стаканнарга спирт салды, графин белән су алып килде.

— Син басып торасыңмыни? — дип сорады Әнвәр.

— Монда урындык бер генә шул. Әйдә, мин йола буенча кадерле кунагымны аяк эсте сыйлармын.

— Утыр монда.— Әнвәр тезенә күрсәтте.

— Авыр булмаммы соң?

— Моннан авырракларын салдың инде син миңа!

— Чын сөю җиңел булмый шул ул, йолдызым! Син әле аның чын газапларын күз алдыңа да китермисең!

Лариса җиңел, хисле хәрәкәт белән аның тезенә менеп утырды. Ул бүген бик тыйнак киенгән: кара свитер, күксел юбка. Бу киеме аның буй-сынының исерткеч сылулыгын аеруча күзгә ташландырып күрсәтә иде. Ул яңагын Әнвәрнең башына терәде, аның алкасы егетнең чигәсен сыдыргалады, әмма бу да бик рәхәт иде.

— Беләсеңме, Анварчик, минем үз гомеремдә брудершафт эчкәнем юк бит әле.

Лариса кулындагы стаканны ут яктысынарак сузып, әйләндергәләде.

— Тәкъдим итүчеләр булмадымыни?

— Хәтерләмим... Тәкъдим итсәләр дә, эчмәгән булыр идем. Ә менә хәзер...

Әнвәр аның нечкә беләгеннән тотып үзенә таба тартты.

Спирт аңкауны өтте, уйларны чуалтып җибәрде. Әнвәр Ларисаның иреннәренә үрелде, шул чак аның күз алдын кызыл тап томалады, ул тап машина рәвешен алды. Брудершафтны аны машина эчендә дә эчеп була... Кызыл «Москвич»та да... Әнвәр аңына килергә тырышып, башын чайкады: Зәйтүнәгә тагын! Болай кайнарланып, бер йомарлам май кебек куенда эреп бетә аламыни соң ул, бөтенләй синеке була аламыни?

Әнвәр, сыр алырга үрелгән булып, Ларисаның тар аркасыннан учын алды да, хатынны аз гына үзеннән читләтте.

— Лорочка, сезнең врачлар арасында кызыл «Москвич»лы кеше бармы?

Лариса, иелә төшеп, аның йөзенә текәлде:

— «Москвич»? Кызыл? Ә нәрсә?

— Мин сораганга җавап бир син башта.

— Ильясовлар машина алган, дигәннәр иде. «Жигули» алганнар. Әйе, зәңгәрсу «Жигули». Ә «Москвич»... Күргән юк. Ай-һай, булыр микән. Врачның хезмәт хакына машина алып булмый... Кайда күрдең син аны?

Әнвәр әйтергәме-юкмы дип икеләнеп торды да тәвәккәлләде:

— Әле генә минем хатынны кызыл «Москвич»ка утыртып алып киттеләр.

— Ә-ә...

Лариса егетнең тезеннән төшеп, бүлмәнең аргы башыннан, күләгәдә тоныкына шәйләнгән пыяла савытлар янынннан әйләнеп килде.

— Шуңа синең эчең бик пошты инде, ә?

— Уйлап кара: әгәр Хөсәен шулай эшләсә?

— Таптың чагыштырыр нәрсә! Әгәр Зәйтүнә риза булса, мин сезне бүген үк алыштырам! Эх, бар булган нәрсәмне өстәп бирер идем әле! Син үзең әйтәсең бит, ул мине абыйсы кебек күрә, дип. Абый янына башка берәү сыя. Синең күңелеңә мин сыям бит әле!

— Лариса!

— Алайса сорама миннән! Ялганлый белмим, дөресен әйтсәм, юри сөйли диярсең...

Шул чак колак төбендә диярлек каһкаһәләп көлгәндәй ят тавыш яңгырады. Әнвәр урыныннан сикереп торып, аргы баштагы пыяла савытларга текәлде: аларга җан кергән шикелле тоелды. Тавыш тагын кабатланды: «Бака-ка-ка, ба-кака-ка!» Стена артында гына бака кычкыра иде. Лариса авызын каплап, тавышын чыгармаска тырышып, Әнвәрнең кыяфәтеннән көлеп җибәрде.

— Ни ул? — диде Әнвәр.

— Бака... Гап-гади бака!

— Каян килгән ул монда?

— Безнең бер тилемсә лаборант бар, шул асрый.

Калын тавышлы беренче бакага нечкәрәк тавыш белән икенчесе кушылды. Әнвәр каушавын сиздермәскә тырышып, өстәлдәге колбага үрелде:

— Шушындый җирдә дә ирләр белән очрашу җаен табасыз, ә?

— Әгәр дә син яхшырак урын тапсаң, без монда утырмас идек.

Лариса моны йомшак итеп, әрнү белән әйтте. Әнвәр аны кыстамыйча, стаканыннан спирт кабып куйды, йөзен җыерды.

— Син «Доктор Франсуаза Гайан» дигән фильмны караган идеңме? — дип сорады Лариса.

Әнвәр ул фильмны Зәйтүнә белән бергә караган иде. Франсуаза Зәйтүнәгә охшамады: «Ул Гиппократ антына хыянәт итә, врач үзенең пациентлары белән гыйшык-мыйшык уйнарга тиеш түгел»,— диде Зәйтүнә.

— Франсуаза бик сөйкемле хатын һәм әйбәт кеше, шулай бит? — диде Лариса.

— Аның безгә ни катнашы бар? Сез хатын-кызларны гына дәвалыйсыз бит!

— Монда аларның ирләре дә килгәли шул!

Кирәкми иде Ларисага һаман бер ноктага бәрергә! Болай итеп, Зәйтүнәне каралтудан да бигрәк, үзенә күләгә төшерә иде ләбаса ул! Җитмәсә, бу туктый белмәгән бакалары тагын! Әнвәр маңгай астыннан карап:

— Сиңа да киләләрме? — дип сорады. Лариса аңа таба бер адым атлады, ләкин бөтенләй үк якын килергә кыймады, ике йодрыгын күкрәгенә куеп:

— Анварчик, йолдызым, нигә син минем бәгыремне пара-пара телгәләп, һаман аны сөйләп утырасың? — диде.— Ни генә булмасын, ул минем дустым бит! Миңа җиңел дип беләсеңме әллә? Беләм, ярамый сине яратырга, ярамый, тик яратам, нишлим! Ялгыштык без, Анварчик, ялгыштык! Теге чакта минем үземә синең яныңа килергә кирәк булгандыр! Ә мин кыймадым! Инде ул да бу хатаны аңлыйдыр, бәлки...

Ул күңел түреннән актарылган тавыш белән сөйли, бу рәвешендә ул изге рух, мәхәббәтне раслаучы, аңа иман китерергә өндәүче фәрештә булып күренә иде.

— Мин гаепле, Анварчик, ләкин үз ихтыярымда түгел бит мин! Мин синең колың, син минем җирем, күгем, кояшым, аем, йөрәк тибешем! Син минем йөземне каралта да, агарта да аласың!

Лариса, сынган тал кебек биленнән сыгылып, Әнвәрнең кочагына ауды:

— Кайчанга хәтле болай газапларсың син мине? Гомер буе шушылай өчәүләп яшәрбезмени инде? Мин генә җитмим, сиңа ул да кирәкмени? Синең миннән башка берәү белән яшәвең үзе бозыклык, әхлаксызлык, чөнки мәхәббәт юк сезнең арагызда! Ул синең сеңелең булып кала бирсен, ләкин ярың, хатының, бердәнбереӊ мин генә! Мин генә!

Кипкән чәчәк таҗлары Әнвәрнең күз алдында ал, кызыл, сары таплар булып биештеләр.

— Ә Тимербулат? — диде ул суга батканда саламга тотынган шикелле.

— Бала үз урынында булыр. Ул синеке булып калыр. Зәйтүнә ата белән бала арасын бозмаячак, ул киң күңелле. Иртәгә үк мәхәббәтебезне бөтенесенә фаш итәбез дә бергә яши башлыйбыз.— Лариса идәнгә тезләнеп, астан үрелеп Әнвәрнең күзләренә карады, ике яңагыннан кысып тотты да:

— Вәгъдәме? — диде.

Аның күзләренә карау авыр, ләкин ул карашны үзеннән җибәрми, тылсымлы кодрәт белән тота иде.

— Вәгъдәме?

Ул Әнвәрнең кочагында утлы кисәү булып бөтерелде. Мәхәббәт утында рухы янып көл булган беренче егет Әнвәрмени? Шундый бер риваять тә бар бит: бер егеткә мәгъшукасы: «Сөюең хак булса, әниеңнең йөрәген китереп бир!» — дигән һәм егет аның теләген үтәгән.

— Вәгъдә, ял көнне абыйларга кунакка барырбыз,— диде Әнвәр саташкан кеше сыман. Бу минутта ул Зәйтүнәне күз алдына китереп кинәнде: аның да үзәге өзелсен әле!

Кинәт тышкы яктан бик каты итеп ишек шакый башладылар. Икесе дә шым булдылар. Эчке яктан ишек ачылды, кемдер тышкы ишеккә таба узды:

— Хәйруллина янынамы?

Тышкы яктан саңгырауланып ирләр тавышы ишетелде. Лабораториянең ишеген тартып карадылар, аннары калын хатын-кыз тавышы:

— Лариса Сөнгатовна, ишек ачкычын бирегез әле, авыру янына дежур торырга килгәннәр,— диде.

Лариса, Әнвәрне тар аркасы белән ышыкларга тырышып, ишек ярыгыннан гына ачкычны сузды. Әнвәр бөрешеп утырды, аның бу минутта бөтенләй юк буласы килә иде. Оят, әйтеп бетергесез оят иде аңа. Якында гына, стена артында кемдер үлем белән көрәшә, ә алар монда... Нинди эшкә этәрә аны Лариса? Менә алар — хатыннар! Берсенә дә ышанырлык түгел, берсенә дә!

Ул ашыгып ишек янындагы кадактан курткасын алды.

— Хәзер, хәзер! — диде Лариса өстәлне каплап. Ак кәгазь кырында кызыл, ал, сары чәчәкләр генә җемелдәп калды. Кипкән чәчәкләр! Алар тышкы ишекне ябып чыкканда каһкаһәләп көлгәндәй бакалар бакылдавы ишетелде.

Әнвәр ашыгып алдан атлый, Лариса аның артыннан килә иде. Бакча янында кызыл «Москвич»ны күргәч, Әнвәрнең эчен кайнар шырпы сызып үтте: бу шул, Зәйтүнә утырып киткән машина иде.

Лариса йомшак кына итеп Әнвәрнең терсәгеннән тотып алды. Әнвәр карышмады.

*

* *

Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, ди халык. Ләкин һәр очракта да ярый торган кагыйдә түгел бу. Врач янына килгән сырхау авыз эчендәген генә түгел, йөрәк түрендәген дә яшермәскә тиеш. Югыйсә аны ничек дәвалыйсың?

Әмма врачларның үзләре өчен дөрес бу кагыйдә. Алар тән сызлануларын да, җан газапларын да яшерә белергә тиешләр.

Кара син аларның эш урынында чакларын, ак халат киеп кабинетларда утырганын, авыру кеше өстенә иелгән минутларын, хәтта коридор буйлап узган чакларын гына кара. Алар башкалардан гәүдәлерәк, биегрәк булып тоела, бүтәннәр белмәгәнне алар белә, башкалар

күрмәгәнне алар күрә, аларның йөзеннән үзенә бер шәфкать нуры сирпеләдер шикелле. Яшәү белән үлем арасында эш йөртә торган бу кешеләргә бүтәннәргә гафу ителгән кимчелекләр, ялгыш-хаталар кичерелми, гадәти тормышта була торган вакчыллык, урынсыз шаярулар, уйламый әйткән сүзләр аларга килешми, чөнки без аларга илаһи затка караган кебек карыйбыз. «Кешеләрнең таләпчәнлеген без адым саен истә тотарга тиешбез, больницада, авырулар караганда гына түгел, урамда да, кунакта да, ял иткәндә без үзебезне ак халат кигәндәй тотарга тиешбез»,— дип кабатларга ярата иде Җәмилә Закировна.

Табип үзенең табиплыгын беркайчан да онытмаска тиеш. Ләкин халатын салып, дөньяга чыккач, белмәгән кешеләр арасында ул күпләрнең берсе булып кала. Трамвайда аның аягына басалар, кибет чиратында, мин монда тора идем, дип этә-төртә аның алдына керәләр, сатучыларның дорфалары, күзең чыкканмы әллә, сез монда күп, мин бер генә, дип тиргәп җибәрәләр. Андый чакта нишләргә врач кешегә? Халаты белән бергә үзенең абруен да эшендә калдырып, үз дәрәҗәсен онытып, этешергә, төртешергә, тиргәшергә-әрләшергәме? Әллә тын гына чигенергәме?

Андый очракларда Зәйтүнә дорфа-тупас кешеләргә дә авыруларга карата булган сабырлык белән кызганып карый, бу аның үзенә дә җиңеллек бирә, кызып китеп, дуамаллык эшләүдән саклый иде.

Ләкин менә үзен Мөдәррис мәҗбүри диярлек итеп машинага утырткач, ул үзен ничегрәк тотарга белми югалып калды. Рульгә ике куллап ябышкан, ирен читеннән төтен бөркеп барган бу кеше каршында кем ул хәзерге минутта? Врачмы, әллә арган-талган, бер көн эчендә бер кеше гомеренә җитәрлекне кичергән хатынмы?

Чын врач үз горурлыгын-дәрәҗәсен саклау белән генә чикләнми, ихтыярына башкаларны буйсындыра, башкалар белән идарә итә. Бу минутта Зәйтүнәнең андый көче калмаган, врач буласы да килми, хатын-кыз, бары тик хатын-кыз гына буласы килә иде аның. Җанга якын һәм көчле берәүнең киң күкрәгенә сыенып, бөтенесен дә: иртән килгән хатны, гомерендә беренче мөстәкыйль операцияне, үзенең башка сыймас тәвәккәллеген, Җәмилә Закировнаның фаҗигагә юлыгуын сөйлисе, күз яше түгеп зарланасы килә иде.

Мөдәрриснең дә хәсрәте зур, ул да өметләре киселгән дип белә. Моңлы-зарлы ике кеше, машинаны туктатып, бер-берсенә елышып, хәсрәтләрен бушатсалар, икесенә дә җиңел булыр иде, мөгаен.

Ләкин туктарга ярамый. Яслedә сабый көтеп тора. Авызын ачса хәсрәт буасы ачылыр, дип ахрысы, Мөдәррис тә яслегә барып җиткәнче бер сүз дә дәшмәде. Алар икесе дә, бер-берсенең хәлләрен сүзсез аңлап, бердәмлек тоеп бардылар.

Ясленең аслы-өсле ике тәрәзәсендә генә ут яна, тәрбиячеләр китеп беткән иде инде. Тимербулат коридорда каравылчы карт янында утыра иде. Бүреген кырын салган бабай аның кулына шырпы кабы тоттырган, нидер сөйләштергән була, ә сабыйның йөзе бик моңсу иде. Бары тик ваемсыз, гамьсез, үз бурычын оныткан ата-ананың баласы гына шушы рәвешле боегып утыра аладыр!

— Бәбекәччәем!

Зәйтүнә аны күтәреп күкрәгенә кысты.

— Гафу ит, улым! Үпкәләмә, бәгърем!

— Балалар китеп беткәч, елап алды беравык,— диде каравылчы.— Аннары нишләсен, тынды инде!

— Рәхмәт, бабай!

Баланың йөзеннән Мөдәрриснең чыраена да нур күчте, ул да иреннәрен урак-ай кебек түгәрәкләндереп, бит очларын чокырайтып елмайды, Тимербулат рульгә үрелгәч: «Әһә, шофер буласың киләмени, дөрес, егет эше!» — дип сөйләнде. Машина эченә тулган хәсрәт-борчулар, са-

бый сулышыннан курыккандай, ярыклардан чыгып качты, караңгы урамнарда калды.

Зәйтүнәнең соңгы борчуын да таратасы килә иде.

— Унбишенче больницага барып килик әле,— диде ул.

Больницаның биш катлы зур бинасы шәһәр кварталларыннан читтәрәк, зур бакча эченә салынган. Ул аермачык булып, зураеп, калкып тора, аның янына килгәндә, дүрткырлы биек баганалар арасыннан узып, авыр ишекне ачканда, кеше ирексездән шомлану катыш дулкынлану кичерә иде. Көн саен больницага барып күнеккән Зәйтүнәгә дә тәэсир итте бу халәт.

Менә хәзер ул Җәмилә Закировна янына кереп, аның хәлен тәгаен белер. Инде аңына килгәндер, дип үзен юатырга тырышты ул. Андый чакта авыруның хәле бер сәгать эчендә дә яхшыруы ихтимал.

Якты вестибюльдә басып торучы ак халатлы, йомшак чүәкләр кигән апаның тыныч тавышы аның бу өметен тагын да ныгытты:

— Рәхим итегез, профессор икенче катта, уналтынчы палатада,— диде ул Зәйтүнә кемлеген әйткәч. Апаның тавышы тыныч иде.

— Ничек соң, хәле бик авыр түгелме?

— Монда исән кергән кешегә үләргә бирмәсләр. Янында врачлар күп бит. Барыгыз, күңелегезне тынычландырып чыгыгыз.

Уналтынчы палата аргы башта ук икән. Әкрен генә шакыган тавышка әчтән халатлы бер хатын-кыз чыкты. Ул ишеккә аркылы басты да, сүзсез генә Зәйтүнәнең ни әйткәнен көтте. Аның кемлеген белгәч:

— Монда ул кафедрадан кешеләр бар бит инде,— диде.— Сез гафу итегез, бүлмә кечкенә, анда тиешле ярдәм күрсәтелә, хәл белү өчен генә кереп торуның кирәге бар микән? Һушына килмәде әле ул...

Шунда гына Зәйтүнә Җәмилә Закировнаның кызы Ләйләне танып алды. Артык дулкынлануданмы, әллә коридор ярым караңгы булгангамы, алар бер-берсен танымыйрак тордылар. Хәер, алар нык аралашкан кешеләр дә түгел бит!

Зәйтүнә аның көнчыгыш кызларына хас уем белән кыйгачлап уелган күзләренә, ак йөзенә карап торды. Бу хатын өстенә төшкән хәсрәтне ныклык белән күтәрү, сыгылып төшмәү мөмкин хәлме?

Ләкин Ләйләнең күзләре коры, иреннәре кысылган, йөзе кырыс, сыны тартылган иде. Бу минутта ул бөтен барлыгы белән бары бер максатка — әнисе гомере өчен көрәшкә генә багышланган иде.

Коридорда аяк тавышлары ишетеп, алар икесе дә борылып карадылар. Аргы баштан, халат итәкләрен җилбәгәй җибәреп, очып барган кош кебек җиңел адым белән мәһабәт гәүдәле ир кеше килә иде. Зәйтүнә ерактан ук Изаил Харисовичны танып алды. Шундый талпынып, атлыгып килә иде доцент, әйтерсең лә барлык сызлаулардан, хәсрәтләрдән котылу чарасын китерә иде.

— Ләйлә Мөбарәковна! — диде ул ерактан ук гөрелдек тавыш белән. Аның бөтен кыяфәтендә үзен кәтә-кәтә кәтек булганнарына һәм ул килгән сөенәчәкләренә шиксез ышану ярылып ята иде.— Ишеткәч тә килә алмадым, кичерегез! Кайгыгызны чын йөрәгемнән уртаклашам!— Ул озын бармаклы, эре, матур кулларын күкрәгенә куйды.— Ашыгыч операция! Беркемгә ышанып тапшыра торган түгел! Хәзер генә бушадым. Инде менә төн буена мин сезнең карамакта.

— Исәнмесез,— диде Ләйлә.— Хәзергә әни янында реаниматорлар тора. Аннан башка да әнинең коллегалары дежур торуның чиратын төзеп куйдылар инде.

Изаил Харисовичның ишек тоткасына сузылган кулы һавада асылынып калды, йөзендә сәер елмаю кабынды. Ләйлә аңа юл бирергә уйламый иде.

Зәйтүнә Ләйләне коткарырга теләп:

— Изаил Харисович!— диде.— Мин машина белән. Әгәр кайтырга теләсәгез...

Ләкин доцент аның сүзләрен ишетмәде. Ул хәрбиләрчә үкчәләрендә борылып китеп барды. Зәйтүнә теләктәшлек һәм кайгысын уртаклашуын белдереп, Ләйләнең кулын кысты. Бу минутта ул Җәмилә Закировнаның хәлен җиңеләйтү өчен бөтенесен бирергә, Ләйләне баскан авыр хәсрәтне күтәрешергә әзер иде. Аһ, теләк булган һәр очракта ярдәм итеп булса икән! Шушындый минутларда чарасызлыгы җаннарны кыйный бит аның!

Тышта өзек-өзек итеп машина кычкыртканы ишетелде. Тимербулат күкрәге белән рульгә яткан да, сигналга басып уйный, ә Мөдәррис радиодан соңгы хәбәрләр тыңларга тырыша икән.

Зәйтүнә улын кулына алды.

— Ничек соң?— диде Мөдәррис машинаны кузгаткач.

Зәйтүнәнең күз алдына Ләйләнең агарынган, ләкин сабыр йөзе килеп басты. Аның хәсрәтен башкаларга ансат кына сөйләп ташларга мөмкинме?

— Анына килмәгән әле,— диде Зәйтүнә.

Хәбәрче шомлы тавыш белән шәрык илләрендәге тынгысызлык, дөньяның төрле тарафдарларындагы канлы бәрелешләр, кешеләрнең һәлакәте турында сөйли иде.

— Бер уйласаң, башка сыймый,— диде, радио музыка тапшыра башлагач, Зәйтүнә.— Кешенең гомере шул хәтле кыска, гомер азагы шундый аянычлы, хәсрәтле, аннан котылу чарасы да юк. Барыбыз да бу җиргә вакытлыча гына килгәнбез. Нигә без, кешеләр, тыныч кына яши белмибез, нигә бер-беребезгә хәсрәт артыннан хәсрәт китерәбез, нигә? Кешелекнең уртак дошманнары да күп бит әле югыйсә: чир-чор, картлык, үлем... Җир тетрәүләр, туфан, давыллар, корылык... Шулардан котылу өчен бергәләп тырышырга, үлемне чигендерү, яшьлекне озайту турында уйларга тиеш бит адәм балалары! Кемнәрнеңдер сугыш ачарга тырышуы, кешеләрне үтерү кораллары ясавы минем башыма сыймый! Меңнәрчә еллар буе гаделлек, дуслык, мәрхәмәт-шәфкать турында сөйли кешелек, ә шулай да бу хакыйкатьне барча балаларына сеңдерә алмый...

— Чөнки кеше — дөнья кебек катлаулы һәм каршылыклы,— диде уйчан тавыш белән Мөдәррис.— Аның күңелендә яхшылык та бар, явызлык та җитәрлек.

— Һәркемдә дәме?

— Бу дөньяда нәрсәнең тигез бүленгәне бар соң? Бар аның кара явызлары, бар керсез күңелле изге кешеләр.— Мөдәррис иреннәрен кысып тынып торды да, һич көтмәгәндә, тавышын әкренәйтеп:— Сезнең кебекләре,— дип өстәде.— Изге һәм бәхетлеләре.

Аның тавышында көнләшү сизелде.

— Сез шулай уйлыйсызмы?

— Кочагында баласы тыпырчынып утырган ана бәхетсез була алмый.

Алар Зәйтүнәләр турына кайтып җиткәннәр иде инде. Мөдәррис үрелеп, караңгы тәрәзәгә карады. Аның соңгы сүзләре, әле дә өенә кайтмаган, авыр көннәрендә дә хатынына ярдәм итми торган кеше — Әнвәр турында иде.

Зәйтүнә аның белән хушлашырга ашыкты. Каян белгән бу кеше караңгы тәрәзәле, караңгы өйгә кайтып керүнең шушы хәтле читен икәнен? Әнисе монда чакта бик бәхетле булган икән Зәйтүнә.

Арылган, кулларның хәле юк, күкрәк эченә кайнар ком кергән шикелле, нәрсәдер авырттырып кырып тора. Ләкин ятып торырга вакыт юк, өйдә мең төрле эш көтә. Барысы да күнегелгән чират белән: баланы чишендерергә, су бирергә, кулына берәр төрле ризык тоттырырга,

итне вак кына турап шулпа куярга... Ипи алып булмады инде, ярар, токмачлы ашны ипісез дә ашап була... Кухня иданен сөртеп алырга, аннары бала әйберләрен юарга.

Ләкин соңгысына чаклы тагын бер эш бар әле — анысы иң рәхәте, тәнне-җанны ял иттерә торганы.

Зәйтүнә улын караватка сала да, култыксага беләгән куеп, тәнендә иркенлек, җанында тынычлык тоеп, сабыена таба иелә. Тормышның бөтен кере-карасы — көнчелек, чир, хыянәт, үлем — барысы, барысы ераклаша, торшерның яшел абажурыннан төшкән яктылык дөньясында ана белән бала икәүдән-икәү генә калалар. Ак мендәрдән елмаеп Зәйтүнәнең үз җылысы, киләчәге, мәңгелеге карап ята.

Әлли-бәлли ит, балам,
Сине йокыга салам,
Син йокыга киткәнче
Үзем янында калам,—

дип әйтеп бетермәслек наз белән әкрен генә җырлый Зәйтүнә. Күптән, бик бәхетле көннәрендә ишеткән назлы тавышны, таныш җырны кабатлый ул. Әнисе җырын өр-яңадан кабатлый ул бу минутларда.

Сабыйның сулышы салмаклана, керфекләре йомыла башлый. Аны инде йокы баскан, ләкин ул әледән-әле күз кабакларын күтәреп куя, әнкәсенең янәшәдә икәненә тагын бер тапкыр ышанасы, тавышын тагы бер тапкыр ишетәсе килә аның.

Кисәк ул нәрсәдәндер сискәнеп китте. Күзләрен зур ачып, куркынып түшәмгә карады, иреннәрен турсайтты. Бөдрә башын мендәрдән күтәрә төшеп, нәни кулларын әнисенә сузды.

— Кил, бәбием, кил миңа. Нидән курыктың болай?

Зәйтүнә аны кочагына алып, аркасын тераэп караватка утырды.

— Курыкма, бәбием, әниең янында чакта бер нәрсәдән дә курыкма!

Сабый җылы йомгак булып аның кочагына сыенды.

Ә тышта җил тынып калган, чалт аяз күк йөзенә эре йолдызлар сибелгән, аларның кыйпылчыгы кебек, урам баганаларындагы утлар турында җемелдәп сыкы коела иде. Тын иде төн, тантаналы, мәңгелек кебек мәһабәт һәм кодрәтле иде. Җемелдәгән эре йолдызлар, каядыр ашкынган кометалар, галактикалар арасыннан җир шары үзенең мәңгелек юлын дәвам итә, салкын һәм чиксез галәм уртасында ул яшәешнең җылы чаткысын алып бара, үзендәге барлык сабыйларның уртак бишеге булып тирбәлә иде.

*
* *

Тынлык шартлап ярылды — тышкы ишек ачылып ябылды. Кемдер, Зәйтүнәнең чигәләренә баскандай дөпелдәп, баскычтан менә башлады. Менә аяк тавышлары ишек турына җитте, менә алар узып, өскә менеп китте. Иөрәк, хәлсезләнеп, тибешен әкренәйтте.

Зәйтүнә сак кына кузгалып, Тимербулатны үз урынына салды.

Тормыштан беркая да качып булмый икән. Янган йөрәкне кисеп ташлардай буласың! Нигә кирәк иде аңа дөреслекне белү? Үлем түшәгендә ятучыга тиздән бу дөньядан китәчәген әйтергә ярамаган кебек, кешегә сөйгән ярының хыянәтен әйтергә дә кирәкмидер, мөгаен. Дөрес, баштарак Зәйтүнә үзе үк хакыйкатьне белергә тырыша иде. Теплицага шалтыраткан чаклары да булгалады, ләкин андагы телефон йөрәкне өшетә торган салкын һәм сузынкы тавыш белән: «Ю-у-у-ук, ю-у-у-ук»,— дип кенә җавап бирә. Әнвәр кайткач, сорасаң: «Нишләп телефон саклап утырыйм мин анда?— дип кенә җибәрә.— Теплицалар-

ны карап йөрим лә мин. Хәтерлисеңме, узган елны бер торба тишелеп, кыяр тамырларын кайнар су пешерде. Күпме хезмәт әрәм булды. Мастерлар утырып елардай булдылар». Бүген дә шулай дияр микән?

Мондый кичләр бөтенләй хәлен ала Зәйтүнәнең. Үрмәләп йөрисе килә башлый: алай җинелдер, сабыйлар юкка гына дүрт аяклап йөрмиләрдер... Суларга һава җитми, урамга чыгасы килә.

Якын кешеннең газапларын күңел ерактан сизә, диләр. Әнвәр аны якын итми, күрәсең, югыйсә бу хәлгә ничек түзәр иде?

Зәйтүнә ашык-пошык киенеп, тышка чыкты.

Ә тышта — төн, каты җир өстенә галәм салкынлыгын сипкәндәй, газап-януларга битараф ай карап тора, аның нурын әҗәткә алган урам фонарьларының күз яшедәй булып, аксыл сыкы коела.

Трамвай туктальшы ягыннан икәү узып китте, егет кызны иңеннән кочып алган. Тыңмыйлар, ашыкмыйлар, алар кеше бәхетен таптап бармыйлар, җаннары тыныч, рәхәт аларга!

Әнә тагын икәү килә, болары да парлы... Хәер... Зәйтүнә арткарак, ай нурыннан читкә, өй күләгәсенә чигенде. Буйга калкурак, капюшонлы куртка кигән кешенең Әнвәр икәнен таныды ул. Алымы, йөреше аныкы иде. Менә алар әкрен генә атлап килгән җирләреннән бөтенләй туктадылар, менә ике урынына бер кара шәүләгә әйләнделәр; кочаклашып үбештеләр. Менә аерылышып икесе ике якка юнәлделәр: Әнвәр Зәйтүнәгә таба, Лариса — кыеклап каршыга. Ләкин ул да түгел, Лариса борылды. «Тукта!» — дип кычкырды. Һәм, ике кулын канат итеп җәеп, Әнвәргә таба йөгерде. Йөгереп килгән уңайга Әнвәргә беректе, сеңде. Зәйтүнә чытырдатып күзләрен йомды.

Әнвәр Зәйтүнәне, кире килгәч, ишекне ачканда гына күреп алды. Бу минутта ул югалып, каушап калыр, аклана башлар, дип уйлаган иде Зәйтүнә. Ләкин Әнвәрнең тавышы бик тыныч яңгырады:

— Нәрсә, кунагыңны озаткач, керәсең килми йөрисеңме әллә?

— Нинди кунакны?

— Сине кем китереп куйды соң? Һәм беренче тапкыр гына да түгел!

— Ул бит... Ул бит...

Ләкин Әнвәр аның сүзен тыңлап тормады, ишекне ачып, эчкә узды. Зәйтүнә гаепле бала шикелле аның артыннан иярде. Шунда ул бик зур мөмкинлекне ычкындырганын аңлады: ул иренең гаебен сиздереп, анда вөҗдан газабы уята алмады һәм шуңа күрә Әнвәрнең хыянәте табигый, нормаль бер хәл сыманрак килеп чыкты. Һәрхәлдә Әнвәр моны шулай итеп куйды.

Әнә ул торшер яктысында рәхәтләнеп чишенә, гаепле кеше итеп түгел, гаепләүче итеп тота үзен! Ул хатынының сүзен юньләп тыңламый да, гүяки баштан ук аның ни әйтәсен дә, бу сүзләрнең арзанлыгын да белеп тора. Зәйтүнә ачыргаланып әйткән сүзләренең, җил очырган кибәк кебек, ире колагына эләкмичә очканын күреп, тынып калды. Я ходаа, синең белән бер бүлмәдә яшәгән кешенең, синең белән тормышың бер иткән кешенең бу кадәр чит һәм шәфкатьсез булуы мөмкинме?

Зәйтүнәнең өйне дер селкетәсе, күк күкрәтәсе, яшен яшьнәтәсе, иренең йөзендәге гамьсезлекне йодрыклары белән төеп куасы килде.

Әмма ул бу хәлдән алай чыгып булмаганын аңлый иде. Тыелырга кирәк иде, сабыр итүдән башка чара юк иде.

*
* *

Билгесезлектән дә авыр нәрсә дөньяда юктыр. Алтынчач төн үткәнен көтә-көтә тәмам гаҗиз булды. Чыгарырлармы аны, юкмы? Линарны күрергә насыйп булырмы, күрсә, күңелен йомшарта алырмы?

Ул аңаниләр әйтәсен кат-кат күңеленнән кичереп, сүзләр эзләп чыкты. Аның йөрәк түреннән кайнап чыккан сүзләр ташны да эретер кебек иде!

Төннәрен больницада вакыт үзе тукталып йоклап ала дип белерсең. Ниләр генә уйлап бетермәде Алтынчәч! Ләкин бер нәрсә — кылганнарына үкенү аның күңелен кыйнамады бу юлы. Әгәр ул гөнаһка бармаса, карынында бала яралмаган булыр иде, җирдә яшәячәк бер кешенең гомере башланмас иде. Моның өчен ул үзен гаепли аламыни? Ләкин әгәр дә баласының хакын ахыргача хаклый алмаса, Линарны үз сүзләренә ышандыра алмаса, менә шунда булачак инде аның иң зур гөнаһы һәм йолып булмаслык гаебе!

Шуңа күрә бу очрашуга Алтынчәч бик нык<br>лап әзерләнде. Иртән ул хәтта сабыйларны карарга коридорга да чыкмады. Авыз эченнән генә Линарга әйтәсе сүзләрен кабатлады.

Менә, ниһаять, бүлмәгә аның зарыгып көткәне — Лариса Сөнгатовна килеп керде. Ул барында, палата ничектер үзгәреп киткәндәй була, аның пөхтә кыяфәтеннән, керсез халаты белән ак башлыгы астыннан бөселеп чыккан җирән бөдрәләреннән, нечкә үкчәле түфлиләреннән үзенә бер җиңеллек сирпелә, дару исләрен затлы хушбуй исе күмеп китә, авыруларның йөзендә җилбәзәк елмаю кабына торган иде. Әйтерсең лә, кәефсезләнеп яткан сабыйларга матур уенчык күрсәтеп юаталар. Ул үзе дә кешенең саулыгына, гомеренә бәйле мөһим эш башкарып түгел, ә бәлки бала-чага уены гына корып йөри сыман тоела, больницаның бөтен җитдилеге юкка чыга иде.

Хатыннар аны бу уены өчен гаепләмиләр, әмма үзләре аңа катнашырга бик омтылып тормыйлар: чөнки Лариса Сөнгатовнаның кулы каты икәнлеген, кан алганда авырттырып чәнчегәнен яхшы беләләр. Дәвалау эшендә кул яту дигән нәрсә бар бит: бер шәфкать туташы уколны сиздерми ясый белә, икенчесе исә шөпшә тешләгәннән дә болайрак итә, бер врач тәнгә иркәләп кенә орына, икенчесе авыртмаган җирне сызландыра. Лариса Сөнгатовна шул икенчеләреннән иде. Аның күтәренке тавыш белән барысына берьюлы: «Ну, назлыкайлар, һаман иркәләнеп ятасызмы әле, ирләрегез янына кайтасыгыз килмиме?— дигән соравына шаярышып җавап бирәләр, әмма башка врачларга сөйләгән шикелле аңа тормыш хәлләрен ачылып сөйләргә ашыкмыйлар иде.

Бу юлы да ул Алтынчәчнең караваты янына килеп утыргач, палатада тынлык урнашты. Ул кулындагы штативны тумбочкага куйды да, ялтырап торган кечкенә пәке алды. Алтынчәч бармак бите авыртканын бөтенләй тоймады. Менә Лариса аның җәрәхәтенә пыяла көпшә очын якын китерде, аның буенча өскә таба кызыл кара йөгергәндәй булды. Менә ул көпшә штативка куелды. Ни әйтер андагы кызыл кара? Алтынчәчне Линар белән очраштырырга ярый, диярме, юкмы? Я алла, безнең язмышлар нинди юк нәрсәгә бәйле кайчакта!

Алтынчәч врачның йөзенә текәлеп карады. Лариса Сөнгатовнаның чырае караңгы, күз төпләре күгәреп чыккан, төн йокламаган, исәпле кеше кебек күренә иде ул бүген. Ул көпшәләрне штативка чирканган кыяфәт белән куйды, нәни пәкесен идәнгә төшереп җибәрде, аны ала алмый шактый азапланды. Таркау иде бүген Лариса Сөнгатовна. Алтынчәч аның белән ныгытып киңәшергә дә уйлаган иде бер мәлне, ни дисәң дә алар элек курсларда очрашкан кешеләр бит, ләкин врачның шушы караңгы чырае бу нияттән ваз кичерде.

«Һич булмаса, дәгъвәләшеп, расписка биреп булса да чыгармың»,— дип уйлады Алтынчәч.

Врач чыгып киткәч, палатадагы дүрт хатын бергә җыелышып, больница хәлләрен, дөресрәге — гайбәт сөйләшә башладылар. Лариса Сөн-

гатовна кереп чыкса, ни сәбәптәндер хатыннар үз хәлләрен онытыбрак торалар, башкаларның хәл-әхвәле белән кызыксына башлыйлар иде.

Алтынчәч бүген сүзгә катнашмады, түземсезләнеп анализ нәтиҗәсен көтте.

Берәр сәгатьтән палатага, зәңгәр штемпельле кәгазь кисәге тотып, Резеда Фәритовна килеп керде.

— Анализыгыз ярыйсы бүген,— диде ул кәгазьдән күзен алмыйча. Аның йөзендә шикләнү ярылып ята иде.— Озак дәвалауның нәтиҗәсе кинәт сизелгән очраклар була булуын. Шулай да ашыкмаска иде, тагын бер көн булса да сабыр итәргә, анализны тагын бер кат кабатларга иде.

Ләкин Алтынчәч нык торды: аңа бүген, менә хәзер үк чыгарга кирәк: бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе бар.

Ахырда Резеда Фәритовна киңәшләрен бирә башлады: борчылмаска, даруларны үз вакытында эчәргә, аз гына үзгәреш сизелсә, тизрәк монда килергә, һич булмаса телефоннан шалтыратырга. Ләкин Алтынчәч аны рәтләп тыңламады, күңелендә сулкылдап бер үк сүз кабатланды: «Чыгам! Чыгам! Бүген барысы да хәл ителә!»

Урамда чыннан да бөтен дөнья өр-яңача күренде. Аяз, рәхәт, сулыш алуы җиңел, күз күреме иркен! Бина эчендә чакта борчулар да стеналарга бәргәләнеп зурая икән, монда алар аз булса да таралып киткәндәй булдылар. Больница каршындагы кечкенә бакчаның шәрәләнгән агачлары, туң җирне каплап та бетермичә керләнеп өлгергән кар, биек фабрика биналары — барысы да җанга якын булып тоелды.

Трамвайда аңа шундук торып урын бирделәр, ә төшкәндә яшь кенә бер егет, кулын сузып, йөзенә кайгыртучан кыяфәт чыгарып, бик кадерләп ярдәм итте. Аннары кызу-кызу атлап китеп тә барды. Алтынчәчнең күзенә яшь килде. Аның әле беркайчан да мондый кадер-хөрмәт тоеп йөргәне юк иде. Көзгегә караса, ул үзенең ямьсезләгән күрә, ләкин менә кешеләрнең йөзе аңа карагач яктырып киткәнен сизә иде. «Хатыннарның бөтен матурлыгы, бөтен күрке — ана булуда»,— дигәндә шагыйрь ана буласы хатынның тышкы кыяфәтен күз алдына китермәгәндер, ул моны аналарга булган шушы якты ихтирам хисен уйлап әйткәндер. Йөзләрне ача, мөнәсәбәтләрне пакьлый торган бу хис аналар янында һәр игелекле кешенең карашында кабына.

Алтынчәч шушы якты хисне Линарда да кабызырга тиеш иде. Яшь егетнең юл уңаенда гына күрсәткән кайгыртучанлыгы Алтынчәчнең бөтен рухын яңартып җибәргәндәй итте.

Күршеләр эштә иде, Алтынчәч өйдә тулы хуҗа булып йөрде. Ванна коенды, чәчләрен бигудига урады, ял итә-итә бүлмә идәнен юып чыгарды, хәтта ванналарны, кухняларны тазартты. Ә бәлки Линар килер? Нигә килмәсен? Килер, әлбәттә! Алар Мөһимә каршында түгел, икәүдән-икәү генә калып сөйләшергә тиешләр бит инде. «Кичкә кадәр генә булса да өмет белән яшим әле!» — дип, Алтынчәч үз күңеленнән бөтен шикләрен куды.

Ул, Мөһимәнең ишеге йозаклы икәнен күрсә, күңеле бик төшәсен белә иде, шуңа күрә кич кенә барды. Ишекне Мөһимә ачты. Өйдә ят телдә өзеп-өзеп җырлаган тавышлардан ук Линарның килгәне беленеп тора иде. Әнә ул диванда иркенәеп, кырын ягып тора, ишек ачылгач та башын борып карамады.

— Кунак килде, кунак!— дип шактый кычкырып дәште Мөһимә, магнитофон тавышын басарга тырышып. Шуннан соң гына Линар урыныннан кузгалды, саргылт күлмәгенең чалбар өстеннән чыгарып салган итәген тарткалап куйды. Аның йөзендә сөенү дә, каушау да сизелми, ике күзе дә тоныкъ елтырый, кайсы күзе пыяла икәнен дә белерлек түгел иде.

Әлбәттә, үзе өчен булса, Алтынчәч бу өйнең бусагасын гомерендә башка бер тапкыр да атлап кермәгән булыр иде. Үлсә үләр иде, килмәс иде ул монда! Ләкин бала! Хәзерге минутта тибенеп, әнисенә хәл кертеп куйган бала! Аңа әти кирәк. Инде әти булмаса исеме генә булса да кирәк. Ул зинадан туган булырга тиеш түгел. Ул тумыштан ук башкалардан ким булырга тиеш түгел.

Шуның хакына Алтынчәч ике күзеннән ук төбәгәндәй — йөрәкне яралый торган ук төбәгәндәй!— карап торган кешенең, бөтенләй чит-ят кешенең каршына елмаеп бара. Аның күңелен йомшартырга кирәк. Ул балага исемен бирсен, фамилиясен генә бирсен ул аңа, атасы дигән графага исемен генә яздырсын. Калган берни дә сорамаячак аннан Алтынчәч, сабыйны үзе тәрбияләячәк. Ләкин ул чакта бала — ата баласы булачак!

Линар аның хәлен сорашуны кирәк тапмады. Аякларын җәеп, диванга урнашты. Аның бу кыяфәтен утырды дип тә, ятты дип тә әйтергә була иде. Ул Алтынчәчне санга сукмавын, ихтирам итмәвен күрсәтү өчен шулай утырадыр сыман тоела иде.

Мөһимә кухняга кереп киткән иде. Алтынчәч пальтосын чөйгә элеп, аның янына узды. Мөһимә:

— Юк, юк, үзем карыйм, син рәтен белмәссең,— дип аны бер нәрсәгә дә якын җибәрмәде. Алтынчәч залга чыгып, диванның икенче башына утырды. Линар сүз башламады.

Чәйләр эчеп, инде эш беткәч, Мөһимә тыр-тыр йөреп табын җыя башлагач, бер яктан магнитофон уйнатып, икенче яктан телевизорда хоккейчыларның ары-бире чапканын караштырып, диванда корсагын бүлтәйтеп яткан Линарга карагач, Алтынчәч сөйләшер өчен шуннан да җайлырак вакытның булмасын аңлады. Линар аны озатмаячак, үзе сүз башламаячак — бу көн кебек ачык иде.

— Минем синең белән сөйләшәсе бар иде,— диде Алтынчәч.

— Да, лапочка, тыңлыйм, сөйләш.

— Икебез генә.

— Монда башка кеше юк бит.

Чыннан да Мөһимә кухняда савыт-саба шалтырата иде.

— Монда өй тулы кеше,— диде Алтынчәч идәндәге магнитофонга һәм түрдәге телевизорга ишарәләп.

— Син аларга игътибар итмә. Мин сине тыңлыйм бит.

Алай да үзе янтая төшеп, магнитофон тавышын әкренәйтте. Телевизорга караган килеш:

— Тыңлыйм,— диде.

Шул рәвешле, бала язмышын, кеше язмышын хәл итә торган, Алтынчәч айлар буе хыялланып йөргән сөйләшүне «адью, адью, адью» дип көрсенеп һәм астыртын бер мәгънә белән җырланган сүзләр фонында һәм телевизор экранында әвәрә килгән таза егетләр каршында башларга туры килде.

Ләкин Алтынчәч анысына да риза иде. Бала хакына дигәндә ул үзенең горурлыгын, кешелеген, гомерен шушы адәмнең аяк астына салырга, борыны белән җир сөрергә, теләсә нинди кимсетелүгә әзер иде.

— Озакламый безнең балабыз булачак,— диде ул үзе дә бу сүзләрнең мәгънәсезлеген аңлаган хәлдә. Хыялында ул бу сөйләшүне бөтенләй башкача башларга ниятләп куйган иде югыйсә. Ул Линарга сыенып утырырга, аның сирәк аксыл чәчен сыйпарга, иңнәренең ныклыгын тоярга һәм: «Ни исемле куярбыз икән?» — дияргә тиеш иде.

Ләкин Линарга якынлашып булмый, әйтерсең лә ул ниндидер акыл ирешмәс кодрәт белән үзеннән читкә этәреп тора. Һәм хәтта шул хәлендә дә Алтынчәч аны бөтенләй чит итә алмый, ул аның өчен бердәнбер кеше булып калган иде.

Алтынчәч сүзнең асылын әйтергә кирәген аңлады.

— Линар,— диде ул аның янынарак шуышып.— Миңа Мөһимә апа әйтте, син монда күчеп килергә ниятләмисең икән инде.

Ул егетнең күңелен ничек тә йомшартырга омтылып, аның иңбашына орынды. Ләкин Линарның иңе кигәвен тешләгәндәй читкә тайпылды.

— Курыкма, мина синнән берни кирәкми,— диде Алтынчәч.— Мин синнән бер генә нәрсә үтенәм: балага исемеңне бир, ул әтиле булсын. Синең балаң бит ул!

Линар әкрен генә башын борып, салкын тавыш белән:

— Алимент аласың киләмени?— дип сорады.

Алтынчәчнең сулышы кысылды:

— Юк, ант итәм, акча сорамам! Бирсәң дә алмас идем мин аны!— дип кинәт кычкырып куйды ул. Аннары үз-үзен кулга алырга, йомшак сөйләшергә тырышып:— Бала атасыз булмасын,— дип өстәде.— Син бала кадерен белә торган кеше бит!

— Ну, лапочка, минем хәлне дә аңларга кирәк. Мин монда бик сирәк булам. Үзеңне минем урынга куеп кара! Без икеме-өчме тапкыр очрашканбыз икән, аннан мондый житди нәтиҗә чыгару кыен бит әле.— Линар башын телевизорга борды да, эчендә кайнаганын әйтеп салды.— Юк нәрсә аркасында башны гомерлек камытка тыгарга син мине ахмак дип белдеңме әллә?

Алтынчәч тынсыз калды. Ә Линарның сүзе бетмәгән иде әле:

— Син үзең дә сабый түгел. Алданрак уйларга кирәк иде. Ирләр кулыннан килми торган эшләр бар бу дөньяда. Врачка синең урынга мин бара алмыйм!

Алтынчәч соңгысын — төннәрен башына килеп тә Линарга әйтмәм дигән авыр сүзне — аның йөзенә бәреп әйтте:

— Синең кызың бар. Күз алдыңа китер: әгәр дә ул буй житкәч синең шикелле берәүгә юлыкса? Минем хәлгә калса? Ни диярсең ул чакта?

Линар кинәт пружинадай тартылып, сикереп торды. Алтынчәчкә аның күзләре ике көпшәле мылтык булып күренде, алардан ут чәчелгәндәй булды:

— Житәр сиңа. Җыен җилбәзәк хатын минем кызым белән авыз чайкамый торсын әле!

Алтынчәчнең дөньясы сүнде, ул кинәт юкка чыккандай булды. Диван култыксасына яны белән бәрелеп идәнгә шуып төшкән хатынның авызыннан күбек килә, башы өстәл аягына бәргәләнә иде.

— Апа! — дип кычкырды Линар. — Апа!

Кухнядан йөгереп чыккан Мөһимә өстәлдән кашык алып Алтынчәчнең теш арасына кыстырды.

— Бар, йөгер, «скорый» чакыр!

— Моннан ярар микән? Урамнан озатсак, яхшырак булмасмы? — диде Линар.

— Син күренмәсәң, үзем озатырмын.

— Ну, апа, рәхмәт сиңа! Син минем башны бума хатынга бәйләргә йөргәнсең икән әле!

Линар ишекне дыңк итеп ябып, баскычны дер селкетеп чыгып китте. Өйдә магнитофонның ирләр тавышы белән чинап җырлаганы гына ишетелеп калды.

* * *

Аңына килеп, карашы яктыргач, ул кызын күреп елмайды, аннары күз алмаларын йөртеп кенә, тирә-ягына карады.

— Ә Мөбәрәк? Әтиең кайда?

Ләйлә аңа таба иелде.

— Хәлең ничек, әнием?

— Ни булды миңа? Кайда мин? Әтиең ник юк?

— Сез машинага бәрелдегез бит, әни. Хәтерлисеңме?

— Машина? — Җәмилә Закировна күзен йомып, бераз аңын җыеп ятты. — Юк, берни хәтерләмим. Әтиең кайда соң?

— Борчылма, әни. Син ике тәүлек һушсыз яттың бит. Ике тәүлек.

Җәмилә Закировнаның йөзендә канәгатьсезлек чагылды. Ул Ләйләдән әтисе турында сүз көтә иде. Күңеле сизә иде, күрәсең.

— Машина син утырган яктан бәргән, әни. Әтигә бөтенләй диярлек зыян тимәгән. Тик аның йөрәге генә... Юк, юк... син әйтеп бетергәнне көт. Микроинфаркт булган аңа. Гидувта ята. Ул да сине гел сорашты-рып кына тора. Тик үзе килә алмый, торырга рөхсәт итмиләр.

— Янында кеше бармы соң?

— Равил гел шунда утыра инде. Ул — анда, мин — синең янда. Үзебез шулай яхшырак булыр дидек.

— Бар, тизрәк шалтырат, минем хәл яхшырганны әйт. Борчылып ята күрмәсен!

— Хәзер, әни.

Ләйлә бүлмәдән чыккач, бераз стенага терәлеп, хәл алып торды. Аның гомерендә бер тапкыр да әнисенә ялган сүз сөйләгәне юк иде әле. Әйтми калган серләре булды, андыйлар булмау мөмкин түгел, ләкин күзенә карап ялганлаганы булмады. Хәзер менә елмаеп, шат кыяфәт белән әнисен алдавы ифрат авыр аңа. Үзенә җиңеллек китерү өчен ул моны беркайчан да эшли алмас иде, ләкин сүз әнисе турында бара, аның исәнлеген саклап калу хакында бара!

Ләйлә әнисен шиккә салмас өчен, коридор буйлап читкәрәк китте, бераздан әйләнеп килде. Әнисе аның аяк тавышларын ишетсен. Кергәндә йөз бик тыныч булсын, сөйләгәндә керфек тә тибрәнмәсен. Бигрәк сизгер, күз карашы аша җанны күрә Ләйләнең әнисе.

— Әти үзе телефон янына килә алмый әле, әни. Равилне чакырып сөйләштем. Әти үзен яхшы хис итә, инде синең хәлең яхшырганны белгәч, күңеле күтәрелер.

Җәмилә Закировна кызының күзенә текәлеп карады, әмма аны-моны сизенмәде, тынычланып, мендәренә башын җайлабрак салды. Ире өчен борчуы кимегәч, ул үз тәненең сызлауларын сизә башлады ахрысы, маңгае җыерчыкланып чыкты.

— Сул янбашым бик сызлый,— диде ул. — Ничек аякка басармын соң мин?

— Врачлар, сөякләр исән, диләр. Аңына килсә, тиз терeләчәк, диделәр сине.

— Тиз кирәк шул. Әтиеңне беркем дә минем кебек карый алмый. Аның янына барырга кирәк.

— Ә аның өчен сиңа күңел тынычлыгы кирәк, шулай бит. Син үзең әйтә идең бит: җан тынычлыгы бик шифалы, күңелле уйлар уйларга кирәк, дип. Шулай түгелме?

— Син бар әле, әтиең янына үзең барып кил. Минем сызланганны әйтмә, хәле бик әйбәт, диген.

Ләйлә дежур шәфкать туташын чакырып кертте дә, әнисен елмаюлы карашы белән юатып, чыгып китәргә җыенды. Җәмилә Закировнаның сөйләшерлек хәле калмаган иде, ак җәймә өстендә үтә күренмәле булып тоелган бармакларын тибрәтеп кенә ишарә ясады: «Бар тизрәк!»

Ләйләнең барыр юлы ерак түгел, ветеринария институтының ак бинасы янәшәдә, бәс сарган, тездән карга чумып утырган агачлык артында гына. Дөнья шундый ак, пакь, оеп, тирбәлеп ябалак кар ява, якындагы тимер юлдан, тәрәзәләрне тоньк кына елкылдатып, яшел поезд

йөгереп узды. Урамнарда машиналарның каядыр өзлексез ашыкканы күренә, ә сирәк узгынчылар якаларына, бүрекләренә кар мамыгы җыеп, салмак кына атлыйлар. Йокысыз узган төннәр Ләйләнең хәлен алган, соңгы минутларда әнисе янында шат, хәрәкәтчән, ваемсыз булырга тырышудан җаны-тәне талчыккан иде. Хәзер менә әнисенең дә, башкаларның да карашыннан читләшкәч, аңа бөтенесе төш кебек тоела башлады. Зиһене ярым томанланып, хыялый дөньяда итеп сизде ул үзен. Миңгерәйгән хәлдә, агачлык арасыннан салынган сукмак буйлап узды. Институтның ишегалдына кергәч, ныклыгын кайтарырга теләп, иелеп учына кар алды, яңакларын, маңгаен ышкыды, салкын дымны теләнә тидерде. Кайчан ашаган иде соң әле ул? Шәфкать туташы чәй керткән иде бит аңа, тамагыннан үтмәде.

Актлар залыннан урындыкларны алганнар, уртасына биек ятак ясап, аңа табут куйганнар. Табут кырыйлары бихисап веноклар белән уратылган, ә аларны һаман бер-бер артлы кертә торалар. Зал тулы халык, әкрен тавыш белән сөйләшү дә тоташ гөжләү булып ишетелә. Бу гөжелдәүгә микрофоннан килгән үзәк өзгеч скрипка моңы килеп кушыла.

Ләйлә залдагы төркемгә күз йөгертеп чыкты, беркемне танымады. Кемнәрдер аның кулын кыса, кайгылы тавыш белән нидер әйтә, ләкин зиһендә аларның йөзләре дә, сүзләре дә тоткарланмый, баштагы томанга уралып шундук юкка чыга иде.

Табутның дүрт ягында почетлы каравыл тора. Ләйлә чәчәкләр арасыннан үрелеп әтисенең йөзенә карады. Ул тыныч, ләкин хәлсез булып күренде. Шушы хәлендә аны җиргә илтеп күмәргәме? Ләкин бу ул — әти бит! Бите, чәчләре, кашлары, борыны шул хәтле газиз, тик күзләре генә йомык, тик иреннәре генә күгәргән. Ә бәлки, әнине һушына китергән шикелле, аны да бу хәленнән айнытып буладыр! Мөмкиндер андый эш, тик кешеләр бу чараны моңарчы тапмаганнардыр гына. Әгәр дә Ләйлә врач булса, ул шундый чараны эзләр иде. Табар иде ул андый чараны. Бөтен гомерен шул эшкә куяр иде, барыбер табар иде!

Шунда ул ишек янында бүреген кулына тотып басып торган Равилне күреп алды. Маңгай турыннан чәче нык сирәкләнгән башын түбән игән, аркасы белән ишек яңагына сөялгән, менә-менә егылыр шикелле. Ләйлә кинәт айнып киткәндәй булды, энесе янына ашыкты.

— Равил, нык бул, без дә егылсак, әни ничек түзәр!

Равил гәүдәсе белән апасына таба авыша төште, аның күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәп чыкты. Күптән инде елаганы юк иде аның. Кайчан күрде соң әле Ләйлә энесенең күз яшен? Бакчага йөргән чагында бугай, урамдагы явыз малайлар башын тишеп керткәч. Ләйләнең шул чактагы кебек аның башын кукрәгенә кысасы, «Хәзер мин явызларның кирәген бирәм!»— дип йөгереп китәсе килде.

Ләкин үлемне куып җитеп үчне алып булмый шул. Ләйлә өчен чарасызлыктан да авыррак хәл юк иде.

— Адәм баласының башына гомер эчендә килә торган хәсрәт бит, нихәл итәсең. Мин дә күптән түгел әтиемне җирләдем...

Кем сөйли бу сүзне?

Алар янына Изаил Харисович килеп баскан икән. Ләйлә аңа каршы сүз әйтергә авызын ачты. Ни сөйли ул? Ләйләнең әтисе китмәгәндә һәлак булды, вакытсыз, очраклы рәвештә!

— Минем әти дә кинәт үлде. Яшь иде әле.

Изаил Харисовичның гадәттә елтырап торган күзләре тирәннән, йөрәк түрендәге ярасын ачып карыйлар, алардан чын-чынлап олы хәсрәт чагыла иде. Ләйлә аның үзләренә килеп йөргән чакларын исенә төшерде. Ничек сокланып, зурлап, кызыгып карый иде бу кеше профессор Ильясовка! Аның белән сөйләшеп утырырга, ничек эшләгәнен, нинди ачышлар ясаганын, чит илләрдәге галимнәр белән ни рәвешле элем-

тә тотканын сорашырга ярата иде. Ихлас иде андый чакларда Изаил Харисович һәм бүген дә бу югалтуны ул чын йөрәге белән кичерә иде.

Дөрес, шул ук вакытта бу фаҗига аңа юлны ача иде. Лэйлэ бер генә минутка: йөрәк түрендә сөенечле җиңеләю кичерә микән бу кеше, дип үз-үзеннән сорап куйды. Ләкин бу сорау җавапсыз юкка чыкты. Хәзер анысы ул хәтле үк мөһим түгел кебек тоелды. Изаил Харисовичның сул җиңенә кызыл тасма бәйләп почетлы каравылда торуына да, мәрхүмнең якыны яки хезмәттәше булмавына карамастан, аның барлык галимнәр өчен якты үрнәк булуы хакында сүз әйтүенә дә, табутны алып чыкканда күтәрешүенә дә рәнҗи алмады Ләйлә.

Урамга чыккач, оркестрны күреп, Ләйлә сискәнеп куйды. Болытлы көндә дә елтырап торган торбалар, барабаннар хәзер аның хәсрәтен бөтен калага игълан итәчәкләр, якын-тирәдәге һәммә кешенең күңеленә шом салачаклар. Бу хәсрәтле моң агачлык артындагы зур больница бинасына да барып ирешәчәк бит! Әниләре тетрәнеп күзен ачар: «Нинди тавыш бу? Матәм маршымы? Кемне күмәләр? Кайда?» Аларның әнисе һәрнәрсәнең төбенә төшенмичә туктамый, сәбәбен белмичә тынычланмый. «Якын-тирәдә уйный бу оркестр,— дип уйлар ул.— Ә монда зур йортлар юк. Институт кына... Кемне күмәләр анда шундый зур тантана белән?»

Ләйлә баскычтан атылып төште дә оркестрга әмер бирү өчен кулын күтәргән офицер каршына барып басты:

Офицер аңа гаҗәпләнеп карады.

— Монда уйнарга ярамый. Әнием ишетә. Аңлатыгыз әле шуңа! — диде ул артына борылып. Изаил Харисович офицер янына килеп, аның белән сөйләшә башлады.

Ләйлә, башын күтәреп, йөзен кар бөртекләренә каршы куйды да күзләрен йомды. Карлар җиргә явар, эрер, агачлар бәсен коеп, яфрак ярыр, җир яшәрер, күктән кояш көләр. Тик аның әтисе генә булмас... Ансыз дөнья була ала микәнни соң?

Юк-юк, бу хакта күп уйларга ярамый Ләйләгә. Күзләре кызарып, иреннәре шешенсә, әнисе шикләнер...

Зираттан Ләйлә туры больницага кайтты. Процедуралар бүлмәсенә керде дә:

— Миңа хәл кертә торган укол ясагыз әле,— диде. — Көчлерәген!

Врач белән шәфкать туташының йөзе аның күз алдында ак тап булып кына шәйләнә иде.

«Әгәр үзем врач булсам, даруның көчлерәген сайлар идем,— дип уйлады Ләйлә. — Әгәр врач булсам, әнигә дә ныграк ярдәм итә алган булыр идем. Әгәр врач булсам...»

Берничә минуттан аңа әнисе янына дәртле адымнар белән, шат кыяфәттә, елмаеп барып керергә кирәк иде.

*

* *

Иртән тәрәзә пәрдәләрен ачкач, ишегалдына шактый карап торды Зәйтүнә. Тышта оеп йомшак кар ява, көн соңарып, бик әкрен килә, дөнья серле һәм пакь иде. Мондый көннәрдә яшь күңелләрдә дәрт кузгала, картларны сагыш баса, авыруларның хастасы көчәя.

Ямансу да, ярсу да Зәйтүнәнең күңеле. Аның артында Әнвәр Тимербулатны түшәмгә чөеп уйната, баланың көлгәне, гөрелдәгәне ишетелә. Бүген ял, Әнвәр өйдә булыр, шулай бала белән генә сөйләшеп, үзара дәшешмичә, бер-берсенә карамаска тырышып узар микән көннәре?

Алай да тышка карап, ямансулап озак торырга ярамый. Ял көненә мең эш җыелган була. Яңа килгән медицина журналын укыйсы, күптән башланган фәнни хезмәтне тәгәлләп, мәкалә рәвешендә язып бетерәсе, житешә алса, кыз балалар өчен махсус яза башлаган китапчыгын дәвам итәсе бар. Барсына да өлгерергә кирәк! Зәйтүнә кухняга чыгып, балага ботка пешерде, чәй куйды. Әнвәр аның белән сөйләшми, ләкин Зәйтүнә таш атканга таш атып җавап бирү ягында түгел: өстәлгә өч чынаяк куйды.

Әмма ул борылып караса, Әнвәр киенеп тә куйган. Тимербулатка: «Сау бул, сау бул!» — дип кул болгады да чыгып та китте.

Бала баштарак аны уйный гына дип, менә-менә кире керер дип ишеккә карап көтте, аннары ныгып җитмәгән тәпиләре белән ишек янына талпынды, абынып егылды да елап җибәрде. Башка чактагыча иркәләнеп, юри кычкырып түгел, бер чарасыз калгандай нечкә итеп, әкрен генә елый, ике бит очыннан мөлдер-мөлдер яшь бөртекләре тәгәри. Зәйтүнә аны күкрәгенә алып кысты: «Елама, бәбкәчәем, елама. Әтиең хәзер кайта, мәми алып кайта...»

Үзеңнең иң якын кешеләреңне газаплы яшь коярга мәҗбүр итәрлек сәбәп булырга мөмкин? Бу хәсрәтне акларлык сәбәпнең булуы мөмкинме? Нинди көч алып чыгып китте Әнвәрне өеннән?

Эчкечене — аракыга, тәмәкечене — тәмәкегә, бозык гашыйкны сөяркәсенә тарта торган көч иде бу, һәм баланың зәгыйфь кулларында да, Зәйтүнәнең үпкә белән әйтелгән сүзләрендә дә аны җиңәрлек кодрәт юк иде.

Барыбер бала кочып, яшь түгеп утырырга ярамый. Эчендә ут янса да елмай, көл, баланны уйнат, эшеңне кара. Ана эшләп йөргәндә, сабый үзен тыныч хис итә, уен белән мавыга, гамьсез була. Җәмилә Закировна хаклы: хәрәкәтләнсәң, кайгы җиңелрәк кичерелә. Гел уйланып кына утырсаң, пыскып янган кисәү кебек сызарсың. Ярый әле эш күп, кер юарга, өйне җыярга, кибеткә барырга, бала белән йөреп керергә. Аннары китап-дәфтәр алып утырырга. Үзеңә тын алырга да бирмәскә кирәк!

И, оеп та ява соң ябалак карлар, шуларны ерып, адашкан адәмдәй, кая китте икән Зәйтүнәнең Әнвәре?

Кинәт телефон шалтырады. Зәйтүнәнең килендәше Кәүсәрия икән.

— Нишлисең әле син?

— Юам, җыям, тазартам.

— Бар эшеңне ташла, матур итеп бизән, баланны курчак итеп киендер дә, хәзер үк безгә кил.

— Хәзер генә бара алмыйм бит, Кәүсәрия. Эш бик күп.

Зәйтүнәнең бу хәлендә кеше күзенә күренеп йөрисе килми иде.

— Өйдә эш бетмәс, үлгәндә дә өч көнлек кала, ди ул. Ә менә шушы минутта безгә килмәсәң, гомерлек үкенеч булачак. Ишеттеңме: гомер буе үкенәчәксең. Идәнеңне юарсың, китабыңны укырсың, ә бу көнне кайтара алмассың, бел аны!

Кәүсәрия бераз тынып торды да, Зәйтүнә аны-моны дәшмәгәч:

— Гөл итеп киенегез дә елмаешып килеп керегез,— диде. — Тик мин чакырды димәссең, хәл белергә килдем, диярсең.

Шушы сүзләре белән ул Зәйтүнәне сәерсендерде дә, ышандырды да. Тормышны көйләп алып бару мәсьәләсендә Кәүсәрия профессор иде. Өстәвенә килендәшен ярата, ихтирам итә, аңа яхшылык теләп яши. Инде болай чакыра икән, җитди сәбәбе бар, димәк. Ә бәлки, кунаклар килгәндер дә, Зәйтүнәнең күңелен ачарга теләвеләр.

Тышта дөнья бөтенләй икенче икән. Ябалак кар аяк астына мамык булып түшәлә, тирә-юньдә күбәләк булып бөтерелә иде. Оеп яуган бу пакьлыктан бар мохит чистарган, сихри халәткә кергән, ак давыл күзне алыштыра, авыр уйларны тарата иде.

Ишекне Әнвәрнең абыйсы Әзһәр ачты. Ул кыяфәте, йөз сызыклары белән Әнвәргә охшаган, тик бераз юантыграк, тәбәнәгрәк, чәче дә сирәгәйгән, йөзеннән җылы нур да ул хәтле яктырып сирпелми. Зәйтүнәне күргәч, ул кыенсынып киткәндәй булды, арткарак чигенде:

— Ә-ә, килен, синмени әле бу? — дип, сызганып куелган җиңнәрен төшерә башлады. Зәйтүнә, аның иңбашы аша үрелеп, эчкә карады: зал уртасында табын әзерләнгән иде.

— Вакытсызрак килдек мәллә? — диде ул каенагасын кыен хәлдән чыгарырга теләп. Ул арада кухнядан кызыллы-зәңгәрле алъяпкыч бәйләгән, бөдрәләткән кара чәчен шундый ук кыекча белән җыеп куйган, түгәрәк бит очлары алланган Кәүсәрия килеп чыкты:

— И-и, көтелмәгән тансык кунаклар килгән икән! Мактап йөрисез, бәхетле авызлар, мичтән бәлеш чыгуга өлгердегез! Әйдә, чишен, түргә уз, килендәш!

— Кунак көтәсез, ахрысы. Без белмәдек, хәл белергә дип кенә килгән идек,— диде Зәйтүнә үзенә тапшырылган рольне ышандырырлык итеп башкарырга тырышып.

Ләкин Әзһәр аны рәтләп тыңламый, кая басарга белмәгәндәй, ишек төбендә таптана, күлмәк җиңен бер күтәрә, бер төшерә иде. Кысан коридорга Кәүсәрия чыгып, ирен эчкәрәк этте:

— Бар әле, кереп тор. Кунакларны чишендерик.

Кәүсәрияне беренче карашка чибәр димәссең: кыска буйлы, зур башлы, чәчен күпертеп йөргәнгә башы тагын да зуррак күренә. Киң йөзендә киң борын, калын иреннәр. Ак битендә су чәчәгеннән калган нәни уемнар бар. Таза тормыш һәм ваемсыз холык аны тагын да түгәрәкләндереп җибәргән иде. Ләкин ул бер карауда үзенә мәхәббәт тудыра, чөнки башын артка ташлап, тигез тешләрен җемелдәтеп, кычкырыбрак сөйләшүеннән үк гадилеге, эчкерсезлеге, ярдәмчеллеге күренеп тора иде. Ул тормыштагы һәртөрле көйсезлекләрне җиңел үткәрә, башкаларның хәсрәтен дә күпереп торган кыска бармаклы йомшак куллары белән таратып ташлагандай итә иде. Кыскасы, килендәшләр, капма-каршы кыяфәтле һәм фигыльле булуларына карамастан, ә бәлки шуның аркасындадыр, баштан ук килешеп яшәделәр.

Каенагасын исә Зәйтүнә моннан берничә ел элек вафат булган каената урынына күрә иде. Аңа карата татар хатыннарының борынгыдан килгән йоласы — тел яшерү кебегрәк мөнәсәбәт саклый иде ул. Һәр сүзен зурлап кабул итә, сораганына төгәл җавап бирә, аның алдында юк-бар сөйләшми, һәр даим зурлавын сиздереп тора иде.

Кәүсәрия Тимербулатның тунын салдыра башлады:

— Иң кадерле кунагым менә шушы инде минем!

Алар өс киемнәрен салып эчкә үтүгә, Әзһәр ашыгып киенә башлады, каракүл якалы пальтосын иңенә генә салды да, бүреген кулына тоткан килеш, чыгып та китте.

Кәүсәрия табын уртасындагы аяклы пыяла савыттан алма алып, Тимербулатка сузды:

— Мә, улым, ашый тор! Әрчеп бирәсеңме әллә, килендәш?

Савытның ике ягында ике шешә — аракы белән коньяк тора. «Безнең өчен әзерләнгән табын түгел»,— дип уйлады Зәйтүнә моны күргәч. Алар өчен булса, аракы гына торыр иде — Әнвәр белән Әзһәрнең коньяк дип исләре китми. Зәвыгы билгесез кешеләр өчен, ятлар өчен әзерләнгән табын иде бу...

Кәүсәрия, аның күзенә туры карарга кыенсынгандай, артыгын каударланып кухня белән ике арада йөри башлады. Әнә, табын уртасыннан тәлинкәләрне читкәрәк этәрде дә, таба белән шулпалы бәлеш китереп утыртты. Аннан тәмле ис таралып, өйне тагын да ямьләндереп җибәрде. Гадәттә кунак җыйганда бәлеш табынга башта ук куелмый, аштан соң гына китерелә. Йорт башы Әзһәр аны, аягүрә басып, изге



*Т. Хажиэхмэтов рәсеме.*

йола башкаргандай мәгънә белән ача иде. Бу юлы исә Кәусәриянең кыланышыннан, без монда үзебез генә, башка беркемне дә көтмибез, диясе килгәне сизелеп тора иде.

Ишек ачылганы ишетелде, җылы курткасының изүен ачып җибәргән Әнвәр килеп керде.

— Син каян монда килеп кердең әле? — диде ул Зәйтүнәнең йөзенә карап, әкрен тавыш белән. Ләкин бу тавышта эчке бер ярсу сизелә иде. Зәйтүнә аны-моны аңлап өлгергәнче, арага Кәусәрия кереп басты:

— Килендәшнең миңа сүзе бар икән, якын итеп килгән,— диде ул гамьсез тавыш белән.

Әнвәр аның яныннан эчкә, Зәйтүнәгә таба узды.

— Ю-ук, синең янга килмәгән ул, мине эзләп йөри! Үзе барасы җиренә машина белән чаптырып кына барып кайта да, аннары минем арттан шымчылык итәргә керешә. Көн дими, төн дими, мине эзәрлекли! Һич котылыр чара юк!

Зәйтүнә уң кулы белән Тимербулатны кочкан килеш, башын тагын да югарырак күтәреп, иренең йөзенә текәлде. Тукта, иреме соң бу аның? Бу шул нур шәүләсенә тиң Әнвәрме, керфегеннән гөлләр тамган сөйгәнеме аның? Бу караңгы, усал, шул ук вакытта куркынган чырайлы кешене Зәйтүнә, бәлки, бүген беренче тапкыр күрәдер?

Кем үзгәрткән Әнвәрне бу рәвешле, кем китергән аны шушы хәлгә, кем качырган аның йөз нурын?

— Ни сөйлисең син? Әллә инде кешенең килендәше янына килүе дә гаепме? Син монда әллә кемнәрне алып килер, дигән уй каян килсен аның башына? — диде Кәусәрия.

Зәйтүнәнең бөтен күңелен яшен кебек сызып шундый уйлар узды. Менә нинди икән аларның мөнәсәбәте: кешенең йөзен каралта, аны шәфкатьсез итә торган хис бәйли икән аларны! Мәхәббәт, чын мәхәббәт шундый буламыни? Зәйтүнәне яраткан чагында, хатынының йөзләренә нур сирпеп караганнан соң, берничә адым китүгә, икенче берәүгә шушы рәвешле каралып, ярсып, үчләнеп каравы мөмкин идеме соң Әнвәрнең? Туганнарын, якыннарын, баласын шушылай артык күрүе, чит итүе мөмкин идеме?

Чыннан да Әнвәрме соң бу? Зәйтүнә аны ничек тә булса тынычландырырга, аның йөзеннән бу усал ярсуны сөртеп алырга теләгәндәй, үзе дә сизмәстән кулын күтәрде. Әнвәр кисәк артка тайпылды. Ул Зәйтүнәне үзенә сугарга кизәнде дип уйлады, ахрысы. Ул хәтта шундый хәлне дә мөмкин дип саный иде, чөнки бу минутта үзенең хаксызлыгын, түбәнлеккә төшкәнен аңлый иде. Ләкин бирешергә теләми иде әле, кул белән булмаса, сүз белән кизәнде, Зәйтүнәнең бәгыренә кадарлык итеп кизәнде Әнвәр:

— Сулыш алыр җай калмады,— диде күлмәк изүен чишеп. — Шунда минем арттан чапканда трамвай да басмый ичмасам үзеңне!

Бу чыннан да аяктан егарлык итеп сугу иде. Әгәр шунда аягына терәлеп баскан Тимербулат булмаса, Зәйтүнә чыннан да егылган булыр иде. Ул, иелеп, баласының йөзенә карады. Тимербулатның йөзе агарынган, әмма күзләре коп-коры иде. Әле бүген иртән генә әтисе артыннан елап калган бала бу минутта җитди итеп карап тора иде.

Эш елаудан узган иде шул. Зәйтүнә керфеген дә какмады, ул Әнвәрнең нурсыз калган кара упкын кебек күзләренең төбен күрергә теләгәндәй төбәп карады. Әйе, ул аның күз төпләрендә талпынган иң яшерен уйларын күргәндәй булды: бу минутта Әнвәр хатынына бик зур гаепләр ташлап акланырга тырышса да, үзенең хаксызлыгын, хыянәтче икәнен, түбәнлеккә төшкәнен бик яхшы аңлый иде. Сызланудан бәргәләнгән вөҗданын күрде Зәйтүнә аның күз төпләрендә.

Бүлмәдә нәрсәдер үзгәрде, бөтенесенә дә оят булып китте: Әнвәр артында Әзһәр тора икән, ул кисәк энесе каршына чыгып басты да:

— Җиттеме сиңа, юкмы! — диде. — Кемне каргыйсың син? Кемгә бәхетсезлек телисең? Менә синең гомерлеккә дип сайлап алган хәләл хатының, менә хәләл балаң! Моннан ары минем алда Зәйтүнәгә авыр сүз әйтәсе булма!

Ул хәтта ботинкасы белән идәнгә тибеп куйды. Әнвәр кырт борылып чыгып китте.

— Бар-бар, кәнтәең каршында дула, монда килеп табынның ямен җибәреп йөрмә! — дип калды аның артыннан Кәүсәрия.

— Ә син нәрсә авызыңны ердың, бик кызыкмы әллә? — диде аңа Әзһәр.

— Кызык шул! Көләбез! Намусыбыз чиста. Пычранганнар еласын! Шулай бит, килендәш!

Әзһәр кулын селтәп чыгып китте. Аңа да оят, аның да килене каршында басып торасы килми иде.

— Кара син аны! — дип баш селкеп калды Кәүсәрия. — Аерылышабыз дип минем бозауны тәмам ышандырып бетергән бит синең тилең. Имеш, эш судта, көнен генә көтәсе калган. Хәзер безгә киләләр дә ярәшү кичәсе сыман нәрсә үткәрәләр янәсе. Килми торсыннар әле! Җыен кәнтәйгә ашатырга артык ризыгым юк. Тапкан! Ирләрнең асылларына асылыналар үзләре, бер дә койма янында аунаган артык-портыкка карамыйлар!

Ул Зәйтүнәгә шикләнеп карады: еламыймы, бик бетерешмиме, янәсе. Килендәшенең баласын тезенә алып өстәл янына утырганын күргәч, җиңеләеп:

— Әйдә, килендәш, рәхәтләнеп ашыйк әле,— диде. — Ашауның тәнгә мең дә бер шифасы бар бит аның. Сезнең медицина ни сөйли бу хакта?

Зәйтүнә үзен тыныч тавыш белән сөйләргә мәҗбүр итте:

— Башкасын белмим, син пешергән бәлешнең шифасы бик зур була!

— Чыннан да шулай бит, килендәш,— дип күтәреп алды Кәүсәрия бу уенны. — Мин пешергән бәлешләр чырайга төс кертә. Менә каралып кайтып кергән була инде Әзһәр эшеннән. Заводта мастерның нервысын ике яклап ашыйлар бит аның: бер яктан житәкчесе, икенче яктан эшчесе. Әйдәле, килен, уймак хәтле генә берәрне җибәрик әле! Аларга ачы булсын, безгә татлы булсын!

Кая татлы булсын! Сөйгән ярның сиңа үлем теләвеннән дә ачырак нәрсә бармы бу дөньяда!

Бу уй Зәйтүнәнең йөрәген пычак кебек телеп узды. Ләкин ул сызлавын басарга тырышты. Күрәш бара, сине — тол, баланы ятим итәргә тырышалар, ә син җәрәхәтеңнән сызланып ятарсыңмы? Сизмәскә тиеш син аны бу минутта!

— Мондый чакта бик файдалы бер дәвасы бар аның,— диде Кәүсәрия рюмкадагы коньякны кабып куйгач. — Әйбәт кенә, ипле генә, сөйкемле генә бер кеше белән сөйләшкәләп йөрү яхшы. Кеше-кара белмәсен, үзең генә бел. Зарә юата. Шифасы бик зур.

Зәйтүнә, аның сүзләреннән чиркангандай, тетрәнеп куйды.

— Ай алла, мин сиңа эшәкеләнеп йөрергә кушмыйм лабаса,— диде Кәүсәрия аның бу хәрәкәтен күреп. — Үзеңнең төшеп калганнардан түгел икәнлегеңне белер өчен генә. Дәрәҗәңне үстерер өчен генә, төшенкелеккә бирелмәс өчен генә!

— Юк андый кеше! — диде Зәйтүнә Кәүсәриянең сүзеннән дә бигрәк ире ташлаган гаепкә каршы.

— Әй, юкны сөйләмәсәнә! Шундый яшь, чибәр, талантлы, акыллы, ягымлы хатын өчен ут йотып йөргән кеше булмыймыни!

Ул рюмкасын Зәйтүнә каршында торган озын аяклы бокалга китереп бәрде дә, башын кырын салып, бәллүрнең чыңын тыңлап торды, ә үзе керфекләре арасыннан җентекләп килендәшен күзәтте.

Зәйтүнәнең күз алдыннан Мөдәрриснең башын кырын салып, кыенсынып карап торган чагы, тезендә Тимербулатны уйнатып, машинада утырган чагы чагылып узгандай булды.

Әйе, бу минутта Зәйтүнәне яралап, аның дәүләтен басып алдылар. Ләкин ул көрәшәчәк әле. Бу көрәштә Мөдәррисне үзенә союздаш итә алмы ул?..

Тукта, тукта, ашыгырга ярамый, аңа көчен тупларга, хәл җыярга кирәк, ә бу тиз генә бирелмәячәк.

— Кәүсәрия, хәтерлисеңме, син миңа бер хатынны җибәргән идең? Илзирәк исемле? — дип сорады Зәйтүнә кинәт.— Кызы туган иде бит аның. Ничегрәк үсә икән?

Кәүсәрия аңың җыя алмыйча аңа карап утырды. Аннары урыныннан торды да янына килеп:

— Зәйтүнә, килендәшем, бәгърем, мондый минутларда ничек исеңә төшерә аласың син аны? — диде.— Терекөмеш кебек кызы, тәгәрәпләр үсеп килә! Хәзер икенчесенә корсаклы инде Илзирәк, анысын бик җиңел күтәрде, табар чагы җиткәндер инде! Их, изге җан бит син, Зәйтүнәкәй, нинди сихер белән томаладылар икән Әнвәрнең күзен шуны күрмәскә! Ахмаклар бу ирләр, Зәйтүнә! Ниләр генә күрсәтмәде минеке дә!

Кәүсәрия, авыр гәүдәсе белән аның иңбашына сарылып, елап җибәрде.

Зәйтүнә исә бер кулы белән баласын кочып, икенчесе белән килендәшенең иңеннән сыйпап, тыныч утырды.

Кайтырга чыккач, ул башын күтәреп күзләрен йомды. Ак күбәләкләр йомшак, салкын канатлары белән кызган маңгайны, кипшенгән иреннәрне сыйпадылар, гүяки юатырга теләделәр. Их, шушы карлар арасында эреп юкка чыксаң иде дә, бүтән беркайчан да күзләреңне ачмасаң иде!

Ләкин Тимербулат кулдан тарта, нәрсәдер бытылдый. Ишегалдыннан чыгып киткәндә, Зәйтүнә кинәт туктап калды. Өй буендагы тәбәнәк койма артында карасу-күгелҗем, нык чыбыкларда тезелешеп... тал бибиләре күкрәп утыра иде. Зәйтүнә, күзләренә ышанмыйча, койма аша үрелде: әйе, бу чыннан да тал бибиләре, йомшак, назлы, җылы бөреләр иде. Бозланып каткан җир өстендә, ак давыл уртасында яшәеш тантанасы, яз сәламе булып калыкканнар иде алар.

*

* *

Бала тудыру йортларының гади больницалардан бик зур аермасы бар. Башка больницаларда авырулар ята, ә монда — сәламәт кешеләр. Алар биргә табигать биргән изге вазифаны үтәү өчен — яңа тормышны башлап җибәрү өчен кергәннәр.

Монда башка больницаларда булмый торган күтәренке, шатлыклы рух хөкем сөрә, сүзләр дә чыр-чор, даулар хакында түгел, сәламәт тормышка хас сүзләр: бала тәрбияләү, мәхәббәт, туганнар белән мөнәсәбәт, киенү-ясану турында.

Монда иртәнге биштән алып, төнге сәгать бергә кадәр — сабыйларның соңгы тапкыр имезеп яткырганчы ыгы-зыгы тынмый.

Бары тик Алтынчәч кенә бу куанычлы мәшәкатьләрдән читтә кала. Ул олы, таза бер гаиләнең аяктан егылып яткан хастасы кебек монда. Коридорда үтеп-сүтеп йөргән хатыннарның ачык ишектән карап нидер пышылдашканнарыннан ук бу аерымлык сизелеп тора.

Теге чакта, Алтынчәчне һушсыз хәлендә китереп салгач, баланы аның рөхсәтеннән башка таптырганнар.

— Улың бик тере, тугач та чүпрәк аша бармагын эзләп табып, авызына капты,— диде соңыннан көлеп врач.

— Сусаганнан ул,— диде Алтынчәч. Соңгы атналарда аңа сыеклыкны тәүлегенә нибарысы дүрт стакан гына эчәргә рөхсәт иттеләр, шуңа Алтынчәч гел сусап яшәгән иде. Мескен бала да шулай интеккән икән!

Башка әниләргә бер тәүлектән соң бәбиләрен китерәләр. Иң элек шәфкать туташы яшел клеенкадан тегелгән капчык кертеп, караватбашына асып куя. Капчык эчендә чиста клеенка кисәге, ак кыекча, биткә бәйли торган битлек. Сабыйны битлек киеп, мендәр өстенә чиста клеенка җәеп каршы алырга кирәк. Яшел капчыкның карават башына асылуы — һәр ана өчен зур сөенеч. Ләкин Алтынчәчкә ул сөенечне күрергә тиз генә насыйп булмас инде. Иртә белән врач: «Башта сезнең үзегезгә сәламәтләнергә, ныгырга кирәк әле»,— диде. «Әллә минем сәламәтләнмәвем дә ихтималмы?» — дип сорады Алтынчәч. «Хәзер без өчәү: сез, мин һәм чир. Әгәр дә сез минем яклы булып, чиргә каршы көрәшсәгез, без икебез җиңәрбез, әлбәттә. Әгәр дә сез чиргә бирешсәгез, мин берүзем нишли алам? Әйдәгез, бергәләп көрәшик!»

Алтынчәч аның йөзен томанлы гына күрә иде. Егылганда аның күзлеге ватылган, күз алдында бөтен нәрсә ачыклыгын җуйган, ул үзенең баш авыртуын да шуннан күрә иде.

Врач киңәшен тотып, ул күзләрен йомды, күңелле нәрсәләр хакында уйларга тырышты. Алтынчәч — сугыш чоры баласы. Абыйсы Закир белән яшь аермасы зур булганга, ул ялгыз бала кебегрәк үсте. Ул бәләкәй чакларда басулардан башак җыю бар иде. Укуда алдынгы Алтынчәч башак җыюда да беренчелекне бирмәскә тырыша иде. Басуга килүгә, үзенә бер буразна сайлап ала да, башын иеп, шуның буйлап бара. Бик тырышып эзли ул, ләкин башак сирәк очрый. Иптәшләре сикергәләп-йөгергәләп әллә кайларга китеп баралар. Уйнап кына йөриләр кебек, ә укытучы янына килеп җыйган башакларын үлчи башласалар, икешәр-өчәр кило тарта. Бер Алтынчәч кенә ике йөз грамм белән кала. Шул чакта да аның начар күргәнен беркем белмәде!

Аннары аны кич белән көтүдән кайтмаган малларны эзләргә җибәрәләр иде. «Син, кызым, аларны урам буйлап эзләп йөрмә, әнә ындыр артындагы үргә генә менеп кара, безнең бер сарык кара битле бит, әллә каян күренә»,— ди торган иде әнисе. Ул да үз баласының хәлен аңламый иде!

Кич балалар белән болынга сыер сакларга чыккач, уен белән мавыгып, малларның таралышып беткәнен күрми дә калалар иде. Аннары караңгы төшкәч, басу буйлап сыер эзләргә таралышалар. Алтынчәч берәрсенә ияреп йөри. Ул кеше сыерын куышып кайта, үзенеке әллә кайда кала. Иртән яктыргач, әнисе сыерны берәрсенең ындырыннан табып кайта.

Тормыш буйлап җитәкләп йөри торган кешегә балачактан ук мохтаҗ иде Алтынчәч.

Бу хәлләрне исенә төшергәч, аның күзләренә яшь килде. Тукта, еларга ярамас. Күңелле нәрсәләр уйларга кирәк.

Алтынчәч бервакыт «Кызыл галстук» дигән спектакльдә уйнарга тиеш иде. Инде көне җиткәч кенә авырып китте. Еш авырый иде ул бала чакта. Укытучы Мәрьям апа хәлен белергә килгән иде. «Синең рольне Ләйләгә бирергә туры килер, ахрысы»,— диде ул. «Үзем, үзем»,— диде Алтынчәч. Спектакльне яхшы уйнады ул, сүзләрен әйбәт ятлаган иде. Тик соңыннан малайлар: «Алтынчәчнең артына гер аскан-

нар иде бугай, гел утыру ягын гына чамалады»,— дип сөйләп йөрделәр.

Алтынчәчнең тагын күңеле тулды.

Ишектән озынча ак шәүлә булып җыештыручы апа килеп керде дә, таяк башына уралган чүпрәк белән идәнне сөртә башлады.

— Ни кайгыларың бар, ник елыйсың? — дип сорады ул.

— Баланы имезергә бирмиләр,— диде Алтынчәч. Апаның бер йомшак сүзе, буаны ачып җибәргәндәй итте, яшь тамчылары бит очларын пешереп ага башлады.

— И җаны-ый! — дип сузды апа. — Сакла күз яшьләреңне! Балаң үскәч бик күп түгәселәрең булыр әле!

Ападан соң дежур врач кереп, Алтынчәч янында шактый утырып чыкты.

— Иртәгә сезне башка больницага күчербез, мөгаен,— диде ул.— Анда бик яхшы белгечләр, менә дигән аппаратлар бар. Ә без үз вазифабызны үтәдек, бәбине кулга алдык бит инде.

— Баланы күрәсем килә,— диде Алтынчәч.

— Иртәгә хәл итәрбез. Тыныч кына йокларга тырышыгыз.

Аннан соң шәфкать туташы кереп укол ясады да, тыныч йокы теләп, утны сүндереп чыгып китте. Ярый әле ишекне япмады. Һава керсен, алай-болай тавыш бирсә, ишетелеп торсын, диптер инде.

Кичке сәгать уникедә, балаларны соңгы тапкыр имезергә таратканда, Алтынчәчнең күңеле бик тә ярсый башлады. Менә балаларның елаган тавышлары якынайды, коридорда чаж-чож аяк тавышлары ишетелде. Менә мәгънәле тынлык урнашты: җир йөзендә мөкатдәс бер эш— тормышны, яшәешне дәвам итә торган, безнең кан кайнарлыгын киләчәккә илтә торган эш башланды.

Башкалар өчен башланды... Ә менә Алтынчәчнең улы, сабые коридорның аргы башындагы ишек артында ялгызы калгандыр. Шәфкать туташлары балаларны тарата, ә ул нишли? Ятим итеп сизми микән үзен?

Ятим... Ятим...

Алтынчәч урыныннан калкына төшеп кычкырып җибәрде:

— Сестра! Сестра!

Ут кабынды.

— Ни булды? — дип сорады ишектән кергән яшь кыз.

— Баланы китерегез миңа!

— Врачның рөхсәте юк бит.

— Минем балам! Үзем җавап бирәм! Китерегез!

— Аны ашаталар бит! Имезәм дип ник шул хәтле өзгәләнәсез?

Сабыйларча нечкә тавыш белән әйтелгән бу сүздә таш битарафлыгы сизелде.

— Сеңелем! Әгәр син шуны да аңламыйсың икән, монда эшләмә. Ә миңа балалар сестрасын чакыр. Чакыр, юкса хәзер мин үзем аны эзләп табам!

Ишектә киңрәк шәүлә күренде — балалар сестрасы өлкәнрәк яшьтә иде булса кирәк, тавышы да калын иде.

— Баланы китерегез әле, башкалар әниләре янында, ул анда берүзе.

— Мин аны туендырып куйган идем шул инде,— диде апа.

— Янымда гына ятып торсын бераз. Бик күрәсем килә...

— И, ачулансалар ачуланырлар, китерәм,— диде апа кинәт тәвәккәлләп. — Бу врачларны да аңламассың! Маска ки!

Алтынчәч калтыранган куллары белән баланы күтәреп алды.

— Улым, газизем, бәхетем...

Ул баланың битенә якын ук иелде, аның чүпрәгенә учын чак-чак

кына тигезеп, кулын буеннан буйга йөртеп чыкты, тәпиләрен тотып җылытты.

— Күз нурым, йомшагым, аппагым, бәгырь кисәгем...

Сабыйның күзләре йомык, саргылтрак йөзендә каш урыннары чак кына калкынып тора, керфекләре күренми иде.

— Бәхетең белән үс, балам. Җирдә тынычлык, иминлек булсын!

Бала тыныч сулый, ә йөрәге кош баласыныкыдай еш-еш тибә иде. Зәгыйфь, хәлсез иде әле бу тормыш, аны яклау өчен ана кулы, ана йөрәге кирәк иде. Алтынчәч аны кочагына алды.

Бер сәгать бәхет бишегендә тирбәлде ул. Сәгать буе үзен сәламәт, көчле хис итте.

Сабыен шәфкать туташына биргәндә:

— Бик зур рәхмәт сезгә, баламны күрсәттегез,— диде. — Мин аны әллә күрәм бүтән, әллә юк,— дип өстәде үзе дә сизмәстән.

— Авызыңнан җил алсын! Баланы ятим калдырып китәләр димени! Ананың үләргә хакы юк, шуны белеп тор!

Ул утны сүндереп чыгып киткәч, Алтынчәч тынычлап күзен йомды. Аның тәнен татлы хәлсезлек биләп алды.

«Әгәр миннән баланың әтисен сорасалар, ул еракта килгән иде, баланың туасын да белмичә, үлеп китте, диярмен. Биек күпердән суга сикереп һәлак булды, дип әйтермен»,— дип күңеленә беркетеп куйды ул.

Бу кичтә ул Линар турында уйларга теләмәде, аны бөтенләй искә алмады. Бу төндә ул үзендә сафлык, изгелек тойды. Әйтерсең лә, баланың орынып кына торуы да аның кайчандыр башка сыймас, гөнаһлы һәм газаплы ләззәттә янган тәнен бөтенләй ярлыкаган, кердән арындырган иде.

Алтынчәч яшь аралаш елмайган килеш йокыга талды. Аның төшенә лаборатория керде. Тәрәзә төпләрендә лаләләр, кактуслар, яраннар — барысы берьюлы чәчәк аткан, имеш, ә ул, гаҗәпләнеп, кызларга әйтә: «Нишләгәннәр болар? Кактус яңа ел алдыннан чәчәк ата бит, ә яраннар җәй көне, лаләләр иртә язда чәчәк ата. Ничек болай бөтенесе берьюлы туры килгән?» — «Синең улың туганга шулай туры китергәннәр алар,— дип көлә, имеш, кызлар. — Бәхетле булыр улың!» Ул арада ишектән бөдрә башын тыгып Нәҗия Нәкыйповна кычкыра, имеш: «Алтынчәч! Бар, заводтан аккан суларның анализын алып кил әле». Алтынчәч мензурка алып чыга һәм күл буена килеп суга иелә. Ә су тонык, төбендә ялтырап кояш таңкаләре уйный, алар арасында кызыл канатлы эре балыклар йөзеп йөри. «Кай арада шушы кадәр чистарган соң әле безнең заводның сулары? — дип гаҗәпләнә Алтынчәч. — Ә, минем улым туды бит, шуңа бу, шуңа...» Ул суга кулын тыга, ә балыклар җим сорап аның учына төртеләләр. Аларның борыннары йомшак, җылы...

Бу төн язмышның Алтынчәчкә биргән соңгы бүләге иде.

*
* *

Палатага кояш нуры төшми — тәрәзәләр көнбатышка караган. Ләкин барыбер көннең аязлыгы, матурлыгы, яктылыгы сизелеп тора.

Җәмилә Закировна кызына күңелле итеп, дәртләнеп карап ята. Әле кайчан гына ул сызлаган кул-аягын кая куярга белми иде. Бүген инде аягына басарга, моннан чыгып китәргә омтыла.

— Озак яттым инде, торырга кирәк, эш күп бит,— ди.— Мөбарәкне дә тизрәк аякка бастырырга иде.

Аның күңел күге аяз, кояшлы. Озакламый аны кара болыт каплар — иренең һәлакәтен әйтерләр. Ә хәзергә Лэйлә әнисенең кояшын озаккарак сакларга тырыша.

— Нигә соң Равил бер дә килеп чыкмый? Ул-бу булмагандыр бит?

— Әти яныннан институтка йөгерә, аннары заводка. Яңа компрессорларын һаман көйләп җибәрә алмыйлар бит әле.

— Эше бик җаваплы шул,— ди Җәмилә Закировна. — Үземнең дә клиникада көн саен булганда гына җаным тыныч.

Юк шул, Равилнең әнисе янына килмәвенә сәбәп эш күп булуда түгел, бөтенләй башкада! «Яшерә алмыйм, апа,— ди ул,— күземә бер карау белән бөтенесен сизәчәк әни». Чыннан да кайгыга нык биреште ул: ябыкты, олыгайды, йөзе агарып китте. «Яшерә алмасаң килмә,— ди аңа Лэйлә дә. — Әни бөтен йөрәкне актарып карый».

Лэйлә сүзне башкага борырга ашыкты:

— Әйдә, әни, яшь чагыңны сөйлә әле!

— Минем сүзем шул бер инде: әтиең турында.

Нәрсәдер сизенә иде бугай аның күңеле, Мөбарәк дими авыз да ачмый бу көннәрдә.

— Врач булуым да әтиең аркасында гына бит. Бервакыт безгә әтиеңнең дусты килгән иде. Өйләнгән, хатыны врач икән. «Өйдә врач булу — зур бәхет инде ул»,— диде әтиең. Ә минем ветеринария институтының аспирантурасында укып йөргән чак. Әтиеңнең шул сүзе күңелемә кереп калды бит. Уйладым, уйладым да медицина институтының икенче курсына кердем.

Лэйлә аңа йомшак кына каршы төште:

— Юк, әни, алай гына түгел. Кешеләрне ярату китергән сине бу өлкәгә. Шулай бит?

— Бәләкәй чакта миңа маэмайлар, авырган чебиләр, бәтиләр кызганыч тоела иде. Бервакыт безнең үрдәк бәбкәләре борчак ашаганнар. Аннары су буена төшкәннәр. Әле дә күз алдымда: бер бәбкә тәмам күбенгән, хәле киткән, ә үзе һаман тамчы-тамчы су каба. Теле юк, зарлана да алмый. Әни аның бүксәсен тишеп, борчакларын алып та караган иде, барыбер үлде бичара. Ә аларга су бирмәскә, абзарда гына ябып тотарга кирәк булган икән. Соңыннан моны белдем дә хәйран калдым. Гади генә чара белән дә ярдәм итеп буласы икән мескен бәбкәләргә!

— Шуларга ярдәм итү теләге сине ветеринария институтына китергән...

— Яши торгач, мин адәм балаларының тагын да кызганычрак булганнарын һәм ярдәмгә мохтаҗ чакларын күрдем.

— Менә шулай шул,— диде Лэйлә. — Ә син әти аркасында дисең.

— Кешеләргә мәхәббәт ул ата-анаңны, иреңне, балаларыңны яратудан башлана. Ата-аналарына дорфа булган, ирләренең данын саткан, балаларын рәтләп карамаган кешеләрнең яхшы врач булуы мөмкин түгел.

Җәмилә Закировна сүзләрен ныгытырга теләгәндәй, ярым утырып торган урыныннан калкынып куйды. Кайбер мәсьәләләрдә үтә дә катгый Лэйләнең әнисе!

— Ирләрнең төрлесе була, кабынган мәхәббәтне дә сүндерә кайберәүләр,— дип йомшак кына каршы төште Лэйлә.

Җәмилә Закировнаның ризасызлыгы йөзенә чыкты.

— Инде үзең сайлап ир иткән кешедән дә күңелең суына торган булгач, чит кешеләрне ничек күңел биреп карарсың! Авыруның төрлесе бар: карты, ямьсезе, көйсезе... Барысы өчен дә янып-көеп торсаң гына, дәвалау шифа бирә.

Ишек шакыдылар. Лэйлә ялт итеп артына борылды. Кем икән бу? Ишекнең тышкы ягына эре хәрефләр белән: «Тукта! Бу бүлмәгә кер-

гәнче, авыруның якыннары белән киңәш!» — дигән язу эленгән элен-ен, ләкин берәрсенең укып тормыйча да килеп керүе ихтимал бит.

— Әйе, әйе, керегез! — диде Җәмилә Закировна түземсезләнеп. Ашарга китергәннәр икән.

— Хәзер, әни, әйбәтләп ашыйбыз,— диде Ләйлә җиңел сулап.

— Минем ашыйсым килми.

— Безнең хакка, әни! Минем өчен берне кап, Равил өчен тагын берне. Үзең безне шулай ашата идең бит әле.

Табын әзерләгәндә һәм ашаганда Җәмилә Закировна өзелгән сүзен дәвам итте.

— Урыныма кем килерен уйлаганда, мин ул ягын да карыйм, беләме, осталыгы, таланты өстенә намуслы да булсын, гаиләсендә дә матур яши белсен иде, дим.

— Син, әни, үз балаларын яратмаган кеше авыруларны да ярата алмый, дисең. Ләкин үзең алар хакына безнең яннан еш китеп тора идең. Аларны артыграк күргән чакларың күп булды бит.

Ләйлә шаярган булып тырышса да, аның тавышында хәзер дә узмаган үпкә, эчке бер сызлану ишетелгәндәй булды. Җәмилә Закировна кашыгын куеп, аңа текәлде:

— Сездән мин кешеләрне авыр хәлдән коткару өчен генә китә идем, кызым.

Ләйлә кузгалып, чынаякларга чәй ясады.

— Кечкенәдән мин телефонны яратмадым. Чөнки ул сине бездән алып китә иде.

— Бик кирәк чакларда гына...

Ләйлә нидер эзләгән булып тумбочкага иелде.

Төннәрен телефон трубкасын әтисе ала иде. «Хәзер,— ди иде ул трубканы учы белән каплап.— Машина җибәрегез». Аннары торып киенә дә чыгып китә. Өстәл лампасы яктысында тавышсыз хәрәкәтләнә, ишекне сак кына ача. Урамга машинаны каршы алырга чыга ул. Аннары яңадан керә, иелеп, хатынының маңгаеннан сыйпый. «Нигә тапкыр әйттем бит инде мин сиңа, Мөбарәк, шалтырату белән уят, дип».— «Әз булса да йокласын, дидем». — «Минуты кадерле бит!» Җәмилә Закировна сикереп тора да урындык аркасында эленеп торган күлмәген ала.

«Кем шулай саклар синең йокыңны, әнием, кем маңгаеннан сыйпап уятыр?»

— Ләйлүк, ни эзлисең анда? — дип сорады Җәмилә Закировна.

— Ә, менә, таптым. Күчтәнәч конфетны эзли идем. Әйе, әни, кара дошманыбыз иде ул безнең кара телефон. Хәтерлисеңме, миңа ун яшь иде: Яңа ел кичендә карнавал ясарга әзерләндек. Әти — хан малае, син — хан кызы, мин — куян, Равил — соры бүре... Ә сәгате җиткәч кенә тагын телефон шалтырады.

— Әйе шул, Балык бистәсенә санитар самолет белән очарга туры килде,— диде Җәмилә Закировна.

— Матур бәйрәм итегез, мин бару белән сезне котлап, шалтыратырмын, дип киткән идең. Бәйрәмнең яме китте, синсез уенның рәте калмады. Әтигә урларга хан кызы юк иде шул. Без һаман синең шалтыратканыңны көттек. Ә телефон үч иткәндәй тып-тын иде.

— Ул төнне янымда гына телефон юк иде шул,— диде Җәмилә Закировна аклангандай.

— Радиодан даң-доң итеп сәгать уникенә суга башлагач, мин әллә нишләп киттем. Чыршы каршына бастым да, кулларымны күкрәгемә куеп: «Мин врач булмаячакмын! Мин беркайчан да врач булмаячакмын!» — дип ант иттем.

Җәмилә Закировна күзләрен зур ачып кызына карап торды.

Ул төнне самолет билгеләнгән вакытка барып җитә алмады, мотор кинәт сүнеп, алар ялан уртасына төшеп утырдылар.

— Мин исән-сау әйләнеп кайттым бит, кызым,— диде ул.— Авыру янына вакытында барып җитеп, ярдәм дә күрсәтә алдым хәтта.

— Ләкин синең шунда һәлак булуың, безне ятим итүең ихтимал иде.

— Тәвәккәлләми генә кешеләргә яхшылык кылып булмый шул...

Юк, әнисенә бу хакта юкка гына сөйләп ташлады бугай Ләйлә. Җиңелчә генә сөйләшергә теләгән иде бит ул, бу хәлләрне бер кызык итеп кенә искә алырга уйлаган иде. Ә әнисенең йөзеннән елмаю яктысын качырды.

Ләйлә сүзне үз кафедрасындагы хәлләргә юнәлтте, әнисенең йөзенә төшкән күләгәне куарга тырышты.

Шәфкать туташы кереп укол кадагач, әнисен ял итәргә яткырып, эшенә барып килергә чыкты ул.

Ике кат пыяла аша караганда гына кояш җылы тоелган икән, урамда ачы җил исә, аяк асты бозланып, тайгакланып каткан иде. Ләйлә баскычтан атлауга таеп китә язды, ялангач куллары белән кытыршы, салкын баганага тотынды. Башын күтәреп карады: аксыл рәшә эчендә җансыз һәм битараф түгәрәк булып кояш эленеп тора иде.

Ләйлә этисенең: «Сез, балалар, безне гафу итегез инде, бездән соң дөньяда бик күп җайсызлыклар кала»,— дигәнен исенә төшерде. «Ничек сездән соң?»— дип сагаеп сорады ул чакта Равил. «Ну... без китәрбез... әйтик, пенсиягә. Әниең дә, мин дә җирдә сугыш афәте дә, чирчор да калмасын дип бик тырыштык югыйсә, булдырып бетерә алмадык. Сез инде үз балаларыгызга җирне яхшыртыбрак калдырырсыз».

Бу сүзләрнең чын мәгънәсен, зурлыгын, җаваплылыгын Ләйлә менә хәзер генә төшенә башлады. Әтисе китте, әнисенең дә хәле икеле. Элеккечә нык итеп аягына баса алырмы ул, кире кафедрага кайта алырмы?

Моңарчы Ләйлә баганага тотынып торган сабый хәлендә яшәгән икән. Ни генә кылса да, кая гына барса да, аңа юнәлеш бирүчесе, бар эшен гадел бизмәнгә салып бәяләүчесе, артында зур көч булып биегәеп торучысы, көч бирүчесе булган икән аның. Дөньяның бөтен торышы өчен аның каршында җавап бирүчесе булган.

Хәзер бу зур җаваплылык тулысы белән Ләйләнең үз җилкәсенә төште.

Еларга, йомшап төшәргә хакы юк иде аның. Ул ялтыравык юлдан нык басарга тырышып атлап китте.

*

* *

Резеда Фәритовнаның иртән офыктан күтәрелеп килгән кояш төсле түгәрәк, алсу йөзенә бу көннәрдә болыт күләгәсе төшкәндәй булды. Табигате белән йомшак һәм мәрхәмәтле бу хатын Җәмилә Закировнаның кечкенә, ләкин нык гәүдәсенә ышыкланыбрак яшәргә күнеккән һәм гомере буе аның канаты астында эшләргә өметләнеп йөри иде.

Ләкин көтелмәгән хәлләр аның киң, әмма йомшак иңнәренә зур авырлык салдылар.

Клиникада, профессор кайта алмас инде, дигән сүзләр йөри башлады. Нәкъ шул көннәрдә сирәк була торган авыр хәл килеп чыкты.

Иртәнге конференциядә профессор Ильясова урынына утырган Виктор Ефимовичка Резеда Фәритовна уңайсызланып, нәрсәдер өмет ит-

кәндәй карады. Ләкин башка төшкән баланы беркем киметә алмый иде. Төнен алтынчы больницада, Алтынчәч янында дежур торып үткәргән Резеда Фәритовна карлыккан тавыш белән:

— Таң алдыннан Вафина үлде...— диде.

Соңгы көннәрдә һәр иртәне Алтынчәч хакындагы сүз белән башлап җибәрүгә барысы да күнеккәннәр иде инде. Ул үзе дә, сабые да күңелләргә аеруча якын булып беткәнгә, бүгенге хәбәр бәгырьгә авыр таш булып килеп төште. Башка чакта, бер-бер хәл чыккан саен: «Ә хәтерлисезме, теге чакта...» яки: «Фәлән елны бер хатын кергән иде бит әле...» — дип, шуңа охшашлы вакыйгаларны искә алырга керешәләр иде. Бу юлы сүзне ялгап китүче булмады. Ни әйтәсең? Болай да ул Вафина хакында күп сөйләшенгән һәм тагын күп сөйләшүләр булачак бит әле. Хәзерге вакытта хатыннарның бала табудан үлүе бик сирәк була, андый һәр очрак республика күләмендә күңелсез вакыйга булып санала һәм министрлык төзегән махсус комиссия тарафыннан җентекләп тикшерелә.

— Теге чакта аны чыгарасы калмаган,— диде, ниһаять, бер тавыш. Зәйтүнә иде бу.

— Кем белгән бит аны. Бик нервыланган иде. Монда көчләп тотып булмый бит. Аннан да файда булмас, дидек. Аннары Лариса Сөнгатовнаның заключениесе...

Ишек янында утырган Лариса, пружинасы тартылган уенчык кебек, кинәт сикереп торды:

— Ништяк! Мин аны чыгарып җибәрергә дип заключение бирмәдем лә! Мин кан составын гына билгеләүче, э нәтиҗәләрне башкалар ясады.

Виктор Ефимович башын чайкап куйды:

— Без монда гаепләне эзләмибез бит әле, Лариса Сөнгатовна. Мондый хәл бүтән кабатланмасын өчен, үзебезгә сабак алырга тырышабыз.

— Хаталанган кеше сабагын да алсын, нәтиҗәсен дә ясасын. Гаепне башкага ягарга маташмасын.

Резеда Фәритовна Ларисага гаҗәпсенеп карады: әллә ызгыш-талаш чыгарырга маташа инде бу хатын! Профессор барда бер тел-теше сизелми иде югыйсә! Кара, ничек тавышы ныгып киткән! Әкрен генә, тыныч кына әйтеп, иң сабырсызларның да телен тыярга мәҗбүр итә торган Җәмилә Закировнаның юклыгы торган саен ныграк сизелә башлады.

Виктор Ефимович сүзне башка авыруларга күчерергә ашыкты.

Рапорттан чыгуга, Резеда Фәритовнаны янып торган битле, җирән чәчле бер хатын көтеп тора иде. Вафинаның җитәкчесе Нажия Нәкыйповна иде бу. Резеда Фәритовна аны профессор бүлмәсенә чакырды. Бусагадан атлауга, Нажия Нәкыйповна стенадагы рәсемгә — тоташ бер сызык белән ясалган ана белән бала сурәтенә карап алды. Бүген алар шушы бөтенлекнең югалуы турында, ятим калган сабый хакында сөйләшергә тиешләр иде.

Резеда Фәритовна профессор урынына узмады, өстәлгә яны белән утырды да, кунакка кәнәфи тәкъдим итте. Нажия Нәкыйповна төлке бүрекен салып, өстәлгә куйды, сумкасыннан кулъяулык алып, тирләгән маңгаен сөртте, кабинетка хуш ис таралды.

— Вафинаның этисе — сугыш инвалиды, әнисе — авыру,— диде ул.— Абыйсының үз балалары күп икән. Моны алырга җиңгәсе риза булмастыр, мөгаен.

— Баланың этисе дә үлгән икән,— диде Резеда Фәритовна.

— Үлмәгән, кая үлсен! Алтынчәч гомерен дә яшәр әле!

Резеда Фәритовна аңа гаҗәпләнеп карады:

— Вафина миңа үзе әйтте: баланың этисе эрактан килгән кеше иде, суга батып үлде, диде.

Нажия Нәкыйповна, бүреген сыпыргалап, ямансу гына елмайды.

— Гомер буе бергә эшләп тә белеп бетереп булмый икән кешене. Инде Алтынчәч тә шушындый булгач, башкалар хакында ни димәк кирәк. Баланың әтисен сорашып белдек инде без. Кызлар бергә пляжда ятканнарын күреп калганнар икән, күршесе дә күргән. Ник аның исемен, адресын үзе әйтмәде икән соң Алтынчәч бичара?

— Мин сорадым...— диде Резеда Фәритовна.— Ничә төнне бергә үткәрдек бит инде. Баланың әтисе, дип авыз ачсам, аркасы белән борылып кына ята иде... Баланы аңа бирдерәсе килмәгәндер, күрәсең...

— Я тегесенең алмаячагын белгәндер,— диде Нажия Нәкыйповна каты итеп.— Их, шул баланы берәр туганы алсын иде дә, квартирын сакласын иде. Үскәч, өйләнеп җибәрергә квартиры әзер булыр иде. Ятимнәр йортына озатсагыз, я берәрсенә бирсәгез, квартирсыз кала инде ул бала!

Резеда Фәритовна аңа сәерсенеп карады: сабый, квартир... Нажия Нәкыйповнаның ерак елларга карап фикер йөртүе хәйран калырлык иде. Шулай да, ниндидер чынлык бар иде аның сүзендә, тормышның нигезен тәшкил иткән ныклык бар иде.

Аларның сүзе шунда өзелде, ишекне каерып ачып, кара каеры тун чабуларын җилбәгәй җибәргән Изаил Харисович килеп керде.

— Кем хуҗа монда хәзер? Кунакны кем кабул итә?

Резеда Фәритовна Нажия Нәкыйповна белән хушлашкан арада ул, тунын салып, кәнәфигә иркенәеп утырды.

— Кафедрада бик күңелсез хәлләр булган икән, ә?

Биредә бергә эшләгән чакларда, Резеда Фәритовна аңа баштарак кызыгып һәм сокланып карый иде. Ләкин тора-бара бу хискә сагаю, шикләнү килеп кушылды. «Артык шома, артык эре,— дигән иде ул бервакыт иренә аның хакында.— Елгыр, салкын. Күзне кызыктыра, ләкин җанга җылысы юк».— «Замана кешесе инде»,— дигән иде аңа ире.

Шуннан соң шактый үзгәргән Изаил Харисович, тазарган, тагын да шомарган.

— Минем халатлар сакланды микән әле монда? — дип сорады ул астыртын мәгънә белән.— Бу араларда килеп тә булмады. Эш өстенә эш өяләр, борылырга да җай юк. Министрлык махсус комиссия төзи икән, бүген иртән шуны җитәкләргә тәкъдим итеп шалтыраттылар. Тулы бер комиссия белән тикшерә башлаганчы, башта үзем генә килеп хәлегезне белергә булдым.— Ул үз итеп елмайды.

Резеда Фәритовна дәшми-тынмый гына чыгып китте дә, кесәсенә «А. Р. Ф.» дип үз инициаллары чигелгән халат кертеп бирде. Доцент Дәүләтшинның халатлары сакланмаган икән шул, ул үз халатын биреп тора. Гәүдәләре бер чама, халат та таман гына икән.

Шәһәрдә грипп таралган, клиникада бөтен кеше авызын битлек белән каплап йөри. Изаил Харисович ак башлыкны уң колагына шудырды, битлеген ияк астына гына элеп куйды да туп-туры гинекология бүлегенә юнәлде.

Өске каттагы уникешәр кеше ята торган палаталарны караганнан соң ул:

— Һаман шундый тыгызлык икән әле,— диде.— Фән өчен бу авыруларның ни кызыгы бар? Аның ишеләрне предприятиеләрнең медсанчастьларына тапшырырга кирәк! Юкса монда төрле вак-төяк белән врачлар үзләре дә ваклана кайчак. Дөресен генә әйтегез әле, Резеда Фәритовна, без инде күптән таныш кешеләр, төрле хәлләр була бит, әйеме! Ялган белешмә күтәреп килгән хатыннар кереп ята, кайбер врачлар авырулардан күчтәнәчләр дә алгалый.

Резеда Фәритовна болыт пәрдәсе астына кергән кояш кебек алланды.

— Күрәм, сез кафедрадагы хәлләр турында миңа караганда да хәбәрдаррак икәнсез,— диде ул.

— Клиника — үзе бер катлаулы организм ул, Резеда Фәритовна. Җитәкче — аның табибы. Ул үз кул астындагы кешеләрнең тышындагын гына түгел, эчендәген дә күрергә тиеш!

Аскы катка төштеләр. Процедуралар кабинетында доктор Уразова авыру белән сөйләшеп тора иде. Көтмәгәндә ишекне ачкан Дәүләтшинга борылып, ул коры гына:

— Әгәр мин кирәк булсам, ярты сәгатьтән бушыйм,— диде.

Бу аның ишекне ябыгыз, бимазалап йөрмәгез, дигәнен аңлата иде. Изаил Харисович елмайды, ләкин аның бу елмаюы ачы иде. «Бурычлы булып калмам, исәпләшербез»,— дигәнне аңлата иде аның карашы.

Тар өстәлләр һәм эскәмияләр тезелеп куелган аудитория аша узганда, Изаил Харисович, тәрәзә төпләрендәге башкаларда тыпырчынган бакаларга карап, ачы көлемсерәде:

— Хан заманындагыча монда хәлләр,— диде ул.— Кафедра дип аталабыз үзебез!

Аннары эре атлап түргә узды, кечкенә лаборатория бүлмәсенең ишеген шулай ук хуҗаларча хәрәкәт белән иркен итеп ачып җибәрде. Өстәл янында Лариса Сөнгатовна штативындагы көпшәләр, пробиркалар белән булашып утыра икән. Ул ризасызлыгын белдереп, кашынкүзен җыерып борылган иде дә, Изаил Харисовичны күргәч, кинәт үзгәреп китте, ак тешләрен җемелдәтеп елмайды. Ул бөтен кыяфәте белән кибетләрдә сатыла торган «Врач» дигән курчакны хәтерләтә иде. Изаил Харисовичның йөзенә уенчыкка кызыккан малай елмаюы чыкты.

— Доктор Нигъмәтуллина токсикозның иртә стадиясенә диагноз кую методларын эзли,— диде Резеда Фәритовна мөмкин кадәр коры тавыш белән. Ләкин аның сүзенә игътибар итүче булмады. Доцент белән ординатор арасында минут эчендә бер-берсенең уртаклыгын тою хисе урнашты. Алар диссертациянең темасы, кан составы, төрле матдәләр турында сөйләшәләр, ә карашлары, тавыш үзгәрешләре үзенчә аңлаша иде. Бүлмә җылынып киткәндәй булды. Резеда Фәритовна бу икәү арасында үзенең артык икәнен тойды, аның монда басып торуы, шаһит булуы үзе үк әхлаксызлык шикелле иде.

Ләкин Резеда Фәритовна чыгып китмәде. Берләшергә ашыкмасыннар әле!

— Лариса Сөнгатовна,— диде ул.— Сез онытмагансыздыр бит, бүген заводта безнең кафедраның прием көне.

— Профессор юк ич,— диде Лариса гаҗәпләнеп.

— Ләкин авырулар бар. Аларны карап, консультация бирергә кирәк.

— Нинди прием, кайсы завод?— диде Изаил Харисович.— Ул эшләрдән күптән котылырга вакыт бит инде! Яшь галим җитди тикшеренүләр белән мәшгуль, ә аны гап-гади врач башкарырга тиешле эшкә җигәсез!

— Авыруларга ярдәм күрсәтү — беркем өчен дә чит эш түгел. Без беренче чиратта авыруларны кайгыртырга тиеш — профессор Ильясова безне шуңа өйрәтте.

Изаил Харисович, баланың ахмаклыгын кичергәндәй, башын чайкап куйды.

— Заманалар үзгәрә, Резеда Фәритовна. Без заман белән бергә барырга тиеш. Элегрәк, врачлар җитешмәгәндә, профессор да гади авыруларны карарга тиеш булган. Хәзер гади врачлар җитәрлек бит,

галимнәр үзләрен җитди эшкә багышлый алалар. Хәер, картайган кешедән эш стилен кинәт үзгәртүне таләп итеп булмый инде.

— Минем сезнең белән күптәннән киңәшәсем килә иде,— диде Лариса гаҗәп җитди, төпле итеп.— Тик моңарчы кыюлыгым гына җитмәде, Изаил Харисович. Сез бу өлкәдә бөтен дөнья фәненең дәрәҗәсен яхшы беләсез. Аннары мин бүгенге көндә, әйтергә кирәк, бөтенләй фәнни җитәкчесез калдым бит.

— Кулымнан килгәнчә ярдәм итәрмен. Гомумән, кафедраның юнәлеше турында ныклап сөйләшәсе бар әле...

Резеда Фәритовна бу ике кешегә каршы тора алмавына ачынып, эчтән сызды.

*
* *

Көннең иң ямансу чагы — икенде белән ахшам арасы, ди торган иде Динәнең әбисе. Нәкъ шул сәгатьтә, көн узып барганда күңелне моң, сагыш баса. «Шуңа күрә дә кичкә таба намазны еш укыйлар. Иртәнге намаз бер генә, ә кичкеләре өчәү: икенде, ахшам, ястү».

Динә бервакыт Джек Лондонның «Кадими шагыйрь» исемле әсәрен укыгач, анда да әбисенең бу фикере раслануын күреп, гаҗәпләнгән иде. Җирдәге иң беренче шагыйрь дә үзенең иң беренче шигырен кояш баеган сәгатьтә язган икән: «Көн үтте, йолдызлар калыкты, аһ миңа ямансу, ямансу, ямансу...»

Бу халәт клиникада да нык сизелә. Иртәнге сәгатьләр дәвалану, врачлар белән сөйләшү, якыннарның килгәнен көтү белән үтеп китә. Кичкә таба бу эшләр бетә дә, йөрәк түрендә яшеренеп, посып яткан уйлар калка башлый.

Динәнең хәтерендә теге чакта төшенә кергән сабые җанлана. Исән туган, имеш, ул. Килде дә әнисенең йөзенә төкерде. Динә коты очып, шабыр тиргә батып уянды. Төрле хорафатларга, ырымнарга ышана торганнардан түгел югыйсә. Укытучы бит ул, башкаларда да тормышка аек караш тәрбияләргә тиешле кеше. Ләкин менә шул төшеннән соң ул, дөньяда әле безнең акыл ирешеп бетмәгән нәрсәләр дә бардыр, дигән фикергә килә башлады. Мәсәлән, аның үзенә дөньяга килеп тә өлгермәгән шул сабый каргышы төште. Каргыш төшү булмаса, Динә башына килгәннәрне бүтән ни белән аңлатырга мөмкин?

Югыйсә беркемгә дә начарлыгы тигәне юк бит аның, гөнаһы юк, намусы чиста. Бу заманда бала төшерүне кем гөнаһ саный? Дөрес, Мөдәррисне рәнҗетте ул. Беренче балалары тугач, сүзгә килешкән чакларында, Динә ирене: «Бүтән бала тапмаячакмын!» — дигәли иде. Мөдәрриснең кыска куе керфекләре тырпая, яңа туган ай кебек ирен читләре кысыла. Хатынының буйга узганын белгәч ул: «Әгәр аңа кул тигерәсе булсаң, мәңге бәхиллегем юк!» — диде. Динәне юмаларга, аңа ярарга тырышкан чаклары да булмады түгел. Ләкин барыбер дә ахыр чиктә хатыны күңелен күреп кенә яши алмады! Завод, диде, эш, диде, нәкъ Динәгә иң кирәк чакларында озак-озак командировкаларга йөрүендә булды. Ә авырлы Динә каенана белән, килен эшеннән гаеп табып кына тора торган, чәя телле, бизәнеп-ясанып йөрергә яраткан каенана белән яшәргә тиеш иде. «Баланы мин генә карап үстерәм!» — дип күпме теңкәгә тиде ул. «Китмә, бу айларда өйдә тор!» — дип шуңа күрә ялынды да инде Динә иренә. Юньле ир хатыны белән баласы хакына эшен дә, хәтта һөнәрен дә алыштыра! Ләкин Мөдәррис аны тыңламады. Поездга утырды да китеп барды. Динәне шул убырлы карчык белән яшәргә калдырып китеп барды ул. Я хода, кара син табигатьнең могҗизасын! Үзәкләрне өзә торган, минут та күңелдән китми торган

Мөдәррис, дөньяда бердәнбер Мөдәррис менә шул сөйкемсез хатыннан туган бит, ә! Болай җентекләп карагач, охшашлык та бар бит алар арасында, ләкин каенана шул хәтле күңел кайтаргыч, ә Мөдәррис шул хәтле күңелгә якын! Берсе дөньяның бөтен ямен качыра, икенчесеннән башка яшәп булмый... Ә Мөдәррис аның хәлен аңламады, аңларга теләмәде.

Мөдәррискә булган рәнҗү, каенанага булган ачу аның бөтен эчен казандагы пар кебек тутырды. Тагын да бала булса, каенана аны да авызын шапылдатып ашарга, сүзләрнең азагын йотып сөйләшергә өйрәтер, телен дә «әннә» дип түгел, «әббә» дип ачтырыр, дип уйлады. Һәм больницага керде.

Ул чакта барысы да бик гади һәм аңлаешлы иде: ул иреннән үч ала, аның газапланганын күреп кинәнә, аны акылга утырта. Ә инде ире Динәгә мөнәсәбәтен үзгәртсә, аралар яхшырса, бала кирәксенсәләр, тагын булыр әле — яшь чаклары!

Ләкин чынбарлык алдан күз алдына китергәнчә булып чыкмады. Үзенең бәгыре пәрә-пәрә телгәләнгән Динәгә иренең кичерешләре җиңеллек китермәде, ә бәлки аның сагышын көчәйтте генә. Аларның мөнәсәбәтендә үк җылылык кимеде: Мөдәрриснең карашы ук үзгәрде, ул хатынына вакыт-вакыт бик текәлеп, аны үтәли күрергә теләгәндәй сынап карый торган булды.

Шулай да арадагы бу киеренкелекне Айгөл киметә, аның лепелдәп йөрүе өйне ямьли, җылыта иде әле.

Һәр бәхетсезлеккә сәбәп табылып тора. Нәкъ шул көзне алар парлашып Төркиягә барырга булдылар. Тиктормас, тынгысыз Мөдәррис гомумән ялны кырын ятып уздыра белми, Динәгә дә аның янында шөгыльсез тору читен иде, икесе дә бу мөмкинлекне хуплап каршы алдылар. Еракларга барып карагач, тормыштагы көйсезлекләр, ыгы-зыгылар кечерәеп кала, күз күреме белән бергә фикерләү дә киңәя икән. Чит җирдә алар бер-берсенә янә якынаеп киткәндәй булдылар, студент чакта кабынган мәхәббәт гүя яңадан терелде. Кичләрнең берендә, кунакханә бүлмәсенең балконына чыгып, шәрык каласының шау-шулы һәм чуар урамына карагач, Динә, янында торган иренә борылып һәм аңа таба авыша төшеп: «Бар икән бәхет тә! Әкият дөньясына килдем бит!» — дигән иде.

Әссе иде чит җирдә. Самолет белән берничә сәгать очканнан соң, туган якның салкынча һавасын күкрәк тутырып сулау бик рәхәт булган иде. Ләкин өйдә аларны чүл эссесе бугандай итте: Айгөл ут эчендә ята иде.

Әлбәттә, врачлар барысын да аңлаттылар, менингитның авыр формасы, коткарып булырлык түгел иде, диделәр. Ләкин Динә үзе белә: теге сабыеның каргышы төште аңарга. Мәет үзе артыннан башкаларны да тарта, диләр бит.

...Ишек ачылды. Динә, уйларыннан арынып, мендәреннән башын калкытты. Палата врачы Зәйтүнә Мәҗитовна икән. Яшь, сөйкемле, бераз гына моңлы шикелле. Сары чәчләрен артка шомартып тарагангамы, маңгаендагы сизелер-сизелмәс ике сыры күренә, уң як ирен читендәге түгәрәк миңе ак йөзенә сабыйларча әчкерсезлек төсмере бирә. Гаҗәп, шушы яшь врач белән Динәнең юллары һаман кисешеп тора әле.

— Хәлләр яхшымы?— ди ул бөтен палатага мөрәҗәгать итеп.

— Доктор, менә минем...— түрдәге өлкән яшьтәге хатын аны үз янына чакырып алды. Динәнең дә сөйләшәсе килә Зәйтүнә белән, ни өчендер бу врач белән уртак моңнары бар шикелле тоела. Ләкин ул моң-зарларны монда, чит хатыннар күз алдында түгеп була торган түгел. Шуңа күрә Зәйтүнә хәл-әхвәл сорашканда да Динә аны-моны әйтмәде.

Ул чыгып киткәч, Динә одеалын күтәрә төшеп, ак күлмәк белән капланган гәүдәсен күздән кичерде. Менә ул, Динә үзе. Күтәрелеп торган күкрәкләр, батыбрак кергән эч, башкалар әйтүенә караганда, төз, матур аяклар. Ул аларны теләгәнчә хәрәкәтләндерә ала, аларның авыртканын тоя. Ләкин эчендә ни барын белә алмый. Анысын әле генә чыгып киткән врач кына белә ала. Ул ак йөзле, сагышын эченә яшереп елмая белүче врач әйткән сүз акланырмы? Динә аны була алырмы?

Ничек сәер һәм гаҗәп бу хәлләр!

— Хәйруллина, әйдәгез!

Ишектән башын тыгып, шәфкать туташы дәшә. Динәне физиотерапия бүлмәсенә чакыра. Бүлмә икенче катта, тудыру бүлеге белән янәшә. Елтырап торган аппаратлар белән тулы ул бүлмәгә көн дә бер сәяхәт Динәнең сызланган күңеленә ял бирә. Сары бөдрә чәчле, мөлаем шәфкать туташы Динәне тар ятакка яткыра да, кулына озын саплы кечкенә чүкеч төсле прибор тотып, иркәләп кенә аның эч турын сыйпый. Үзе бертуктаусыз сөйләнә. Сүзе күбрәк тудыру бүлегендәге хәлләр турында. Ул элекке көннәрдә бер хатынның ирсез корсакка узган булуын, токсикоз белән ятуын сөйләгән иде. Бүген сүзен:

— Теге Вафина үлгән бит!— дип башлады.— Ни генә кыланмадылар врачлар, тирәсендә ничә профессор бөтерелеп йөрде, әҗәле җиткән булгач, алып кала алмадылар шул.

— Ә бала?— дип сорады Динә.

— Бала калды. Мескен, кыз көткән иде, Газизә куярмын, дигән иде. Малае туды. И сабыр иде үзе, и түзем иде. Күпме хәл эчендә ятып, бер зарланмады. Үлгәндә дә баласын гына сораган, диләр. Ә була бит шундый хатыннар, әз генә сызланганда да әллә ниләр кыланып кычкыралар, бәргәләнәләр. Авырта, имеш. Авыртмый нишләсен! Тәненне ярып, адәм яралсын әле!

— Баласы кая соң аның?— дип сорады Динә.

— Бездә әле. Юрист балалар йортына җибәрергә йөри бугай, менә сиңа кеше язмышы. Туганда ук бәхетсез, бичара. Язмышың үз кулыңда, диләр тагын. Булыр, көтеп тор!

...Гинекология бүлегендә утларны иртә сүндерәләр. Коридорда шәфкать туташының әрле-бирле йөргәне, шприцларны шалтыратып юганы һәм стерилизаторга салганы ишетелеп тора. Палата тынып калды. Динәнең генә күзенә йокы кермәде. Тәрәзә артында шәрә ботаклар чайкала, сирәк кенә үткән машина фараларының яктысыннан ул ботаклардан палата эченә төшкән челтәрле күләгә караватт башларыннан, йоклаган хатыннарның өстеннән шуып уза.

Йокы керми Динәнең күзенә. Колак салып тыңлагач, аргы баштан, тудыру йорты ягыннан өзми-куймый бала елаганы ишетелгәндәй була. Теге ятим бала елыйдыр. Ир бала... Беркемгә кирәксез, кадерсез сабый... Аның белән бергә туган балаларны, атлас җәймәләр белән биләп, кочактан-кочакка гына алып, күңел җылысы, бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт белән үстерергә дип күтәреп китәрләр.

Бу сабыйны исә тамга суккан казна юрганына урап, балалар йортына илтеп тапшырырлар. Анда аның килүенә беркем сөенмәс, бары тик караучы хатын гына, башка балалардан берәзга аерылып: «Ә-ә, яңаны китерделәрмени?»— дип куяр. Дөрес, аны да ким итмәсләр, юарлар, ашатырлар, вакыт җиткәндә башыннан сыйпап узарлар. Ләкин ул беркайчан да ана назын тоймас. Ир баланың эче авыртучан була, диләр, төннәрен сызланып еласа, аны кем күтәреп йөрер? Егерме-утыз балага бер караучы, кайсын гына күтәреп йөреп бетерсен соң ул!

Кем аның беренче елмаюына, беренче сүзенә куаныр, кем үчтеки итәр, тәпи атлатыр, тайт-тайт уйнатыр? Кем аңа бишек җыры җырлар? Бишек җырын утыз балага берьюлы җырлап булмый, ул һәр балага аерым җырланырга тиеш...

Балалар йортында үскән сабыйлар яшьтәшләреннән соңрак тәпи йөреп китә, соңарыбрак сөйләшә башлый, азрак шаяра, азрак белә. Ә күңелләре нишли? Ата-ана назыннан мәхрүм үскән кешеләрнең күңелендә нинди хисләр тумый һәм үсми кала икән?

Ятимлек теләсә кайсы заманда да ятимлек шул инде ул!

Ә, бәлки, ул ятим булмас, аны үстерергә алырлар. Хәзер сабыйларны тәрбиягә алучылар күп бит.

Тудыру йортында яткан бала хәзерге язмышының башкалардан аермалы икәнен белми әле. Ләкин ул башкалар төсле түгел инде, ул — ятим. Башкаларның тавышын әниләре колак салып тыңлый, башкаларны тиешле сәгатьтә әниләре кочагына илтеп салалар, ә аның тавышын ишетеп үзәге өзелүче юк, аны көтеп алучы юк.

Нигә шулай бу язмыш, нигә болай тигезсез бу дөнья? Динә менә үз кылганнарының әҗерен ала, ә сабыйның ни гаебе бар? Без кылганнарның, безнең хаталарның җәзасын ала сабыйлар...

Башта туган уйларның очы-очка ялганмый, карават башларыннан, идәннән челтәрле күләгәләр шуып уза.

Бу больницада моңлы-зарлы ике кеше бар: алар Динә дә ятим калган сабый. Аларның бәхетсезлеге дә охшаш: берсе баласын югалтты, икенчесе — анасын...

Тышта коры ботакларны тирбәлдереп, идәндә күләгәләр шудырып, кышның озын төне бик ялкау гына узып бара. Динә төн буе керфек тә какмады, төн буе, бала елаган тавыш ишетелмиме, дип тыңланып ятты.

Иртән обходка кергәч, Зәйтүнә:

— Динәгә ни булган безнең?— дип сорады.

— Йоклый алмадым.

— Борчылырга сәбәп юк. Анализлар яхшы, дәвалау курсы тәмамланып килә, шушы арада без сезнең белән саубуллашырга ниятләп торабыз.

Зәйтүнә башка хатыннар белән сөйләшеп бетергәч, Динә ана ияреп чыкты да, коридор почмагындагы суыткыч янына басты.

— Сез белмисезме, теге баланы алырга сораучы бар микән?

— Кайсы баланы?

Зәйтүнә аны бераздан гына аңлады. Юк, баланың язмышы ачыкланмаган әле. Андый эшләр тиз генә эшләнми бит ул: документлар җыясы бар, тегесе-монысы...

— Күрсәтегез әле миңа аны!

Алар бер буйда диярлек, шуңа күрә күзләре бер-берсенә бик туры, текәлеп карадылар. Динәнең күз кабаклары шешенке, кызыл. Зәйтүнә аның бу төндә кичергәннәрен сүзсез аңлады, гаҗәпләнмәде.

— Тудыру йортында балаларны чит кешегә күрсәтү рөхсәт ителми.

— Әгәр берәрсе аны тәрбиягә алырга теләсә?

— Ул чакта врач сүзе белән генә алалар.

— Мин аны күрергә тиеш,— диде Динә катгый итеп.

— Кичкә таба, дежур врач белән сөйләшеп карасак кына инде,— диде Зәйтүнә.

Кичке сәгать алтыда, дәвалаучы врачлар китеп, клиникада дежур врачлар гына калгач, балаларны имезү сәгатендә Зәйтүнә Динәне чакырып чыгарды. Динәгә халат, битлек бирде. Башлык табылмады, мендәр тышын яулык итеп бәйләргә туры килде. Алар дәшми-тынмый гына озын коридор буйлап үттеләр, аннары өске катка күтәрелделәр.

Өлкән яшьтәге апа беләгенә салып сары чүпрәккә төргән озынча төргәк алып керде дә, баланы кулында килеш кенә Динәгә үзе белән борып күрсәтте.

Динәнең йөрәге сулкылдап куйды: бу — ул иде. Теге чакта Динәнең төшенә кергән бала иде бу.

*
* *

Мөдәррис өчен иң авыры — шушы гинекология бүлегенә килү иде. Динә монда кереп ятканын таныш-белештән яшерергә тырышты, шунлыктан көн саен диярлек Мөдәррискә йөрергә туры килде.

Бу юлы Динә бик серле кыяфәт белән аны арткы ишектән керергә чакырды. Алар класс кебек бер бүлмәдә очраштылар, укучылар кебек икәү янәшә тар өстәл артына утырдылар. Ярый әле Мөдәррис утырган иде, югыйсә хатынының сүзен ишеткәч, егылып китүе дә ихтимал иде.

Кеше баласын тәрбиягә алырга... Мондый дуамал уй бары тик Динәнең генә башына килүе мөмкин!

Ә үзе иренең йөзендәге үзгәрешне күрми дә, ахрысы, бумази халат кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарып, анда язылган унике пунктны укырга кереште: зәңгәр юрган, зәңгәр тасма, ике чүпрәк...— кыскасы баланы тудыру йортыннан алып кайту өчен кирәк буласы әйберләр иде болар. Бу хатын гомер буена Мөдәррис өчен табышмак булып калыр, мөгаен. Бергә яшәгән кеше белән серләрең килешә, уйларың бер була, диләр тагын. «Син кеше баласын карарга алынганчы, үзеңне яхшылап карарга өйрән!»— димәкче булды Мөдәррис, әмма хатынының авыру икәнлеген, үзенең больницада икәнлеген исенә төшереп, телен аркылы тешләде.

— Зинһар, документларын тизрәк әзерлә,— диде Динә.— Бездән алда берәрсе алып китә күрмәсен!

— Ата-анасын белдеңме соң? Чирле түгел микән?

— Чирле баланы бигрәк тә яхшы карарга кирәк түгелмени? — дип уйламый әйтеп салды Динә. Аннары иренең йөзендәге үзгәрешне күреп:— Ата-анасы сәламәтләр, белештем,— дип ашыгып өстәде. Бу сүзләрнең генә ышанычлы яңгырамаганын аңлап, бераз тынып торды да, эчтән сыкрап чыккан тавыш белән:— Ул безнең балага охшаган,— дип өстәде.— Гел безнеке төсле!

Ничек инде кеше баласын үзеңнеке белән чагыштырырга мөмкин? Ләкин Мөдәррис тагын хатынының күзенә карады да каршы әйтә алмады. Ул аның күзләрендә сызланудан туктамаган җан җәрәхәтен күргәндәй булды. Ни генә булмасын, сызланулары уртак иде шул аларның!

Хатыны яныннан чыккач, ул больница каршындагы кечкенә бакчада әрле-бирле йөренеп тәмәке тартырга керешге. Болай гына китә алмый, бер акыллы кеше белән киңәшәсе, сере сыя торган берәү белән сөйләшәсе килә иде аның.

Әнә ул кеше: ян-яктагы ишектән килеп чыкты. Ак бүрек, ак яка фонында йөзе нур чәчеп тора шикелле. Аны күргәч, Мөдәрриснең күңелен кызганулы хис сызып узды.

— Сез тагын килгәнсез,— диде Зәйтүнә шелтәле тавыш белән.— Яхшы түгел.

— Ә мин врач янына килдем. Врач буларак, сезнең миңа ярдәм күрсәтүдән баш тартырга хакыгыз юк.

— Врачны урамда аулап йөрмиләр, кабинетына керәләр.

Зәйтүнә моны йомшак итеп, үпкә беләнрәк әйтте. Мөдәрриснең эченә җылы керде: чит кешегә үпкәләмиләр, якын кешеңә генә үпкәләп була.

— Доктор, минем йөрәгем сызлый,— диде Мөдәррис.

— Әгәр белгән булсам, мин сезгә валерьян тамчылары алып чыккан булыр идем.

Мөдәррис тәмәке кабызды, дәшмәде. Бу хатын әйтмичә дә аңларга тиеш ирләрнең хәлен: иң гайрәтле ир-егетләрнең дә бары тик хатын-

кызларга гына сөйләп була торган эч серләре була. Аларның да нечкә күңелле бер зат каршына барып, язмышның шәфкатьсезлегеннән зарланасы, кызгандырасы, һәм шул затның өф дип өргән сулышыннан җиңеллек табасы килә.

Зәйтүнә дәшми-тынмый янәшә барудан уңайсызланып китте булса кирәк, аңа борыла төшеп:

— Йөрәк сызлаганда, елап алу файдалы, ди безнең профессор, елап алыгыз булмаса,— диде.

— Акыллы сезнең профессорыгыз. Дөрес әйткән. Ләкин үзең генә елауның кызыгы юк бит. Бәләкәй малайлар да күз яшьләрен сөртеп торучы кеше булганда гына елыйлар.

Алар караңгы, тынгысыз урамнан трамвай юлына килеп чыктылар. Мөдәррис сәгатенә карады:

— Сез Тимербулатны алырга соңармадыгызмы?

— Аны күрше хатын ала. Үз кызы белән бергә. Мин еш соңарганга, шулай сөйләштек.

Мөдәррис көрсенеп куйды: аның малайны күрәсе килә иде.

— Бәлки, бераз җәяү барырбыз? Минем сезнең белән сөйләшәсе сүз бар иде.

Алар бакча кырыннан тротуар буйлап киттеләр. Мөдәррис адымын Зәйтүнә атлавына яраклаштырды.

— Буталып калдым әле мин, доктор Зәйтүнә,— диде ул.— Сез инде кеше тәнен яхшы беләсез, шуның осталары, ә менә хатын-кыз күңелен аңлатып бирә алмассызмы? Әлек без бер-беребезне ярата да, аңлый да идек шикелле. Ә хәзер мин аның дуамаллыгына, шәфкатьсезлегенә хәйран калам. Нәрсә ул хәйран калу гына! Гаҗиз мин бу хәлдән. Узган елны командировкадан кайткач, мин аның больницага кереп чыкканын белеп, бөтенләй чарасыз калдым. Мин, гомумән, үземнең кайчан да булса елаганымны хәтерләми идем, ә бу юлы утырып еладым... Мин балалар яратам, доктор Зәйтүнә. Минем иң зур хыялым — ун бала булдыру. Эштән кайтуыма ун балам уралсын иде тирәмдә. Ә ул мине бер бөртектән мәхрүм итте.

— Юк, сез хаклы түгел, ул мәхрүм итте, дия алмыйсыз!

— Барысы да шуның аркасында килеп чыкты инде! Ни уйлаганын да, нишләгәнен дә аңламый бугай ул. Хәзер инде кеше баласын алырга ниятләгән. Уйлашмаган, сөйләшмәгән, бөтенесен хәл итеп тә куйган. Ә мин аның янында бер пешка гына!

Зәйтүнә бераз тынып барды.

— Ә сез ул чакта нигә еладыгыз? — диде ул, ниһаять.

— Кайгыдан, әрнүдән, хыялларым юкка чыгудан! Мин улым булуын теләгән идем! Әгәр дә мин хатыннан башка гына бала булдыра алсам, сезгә ялынып та тормас идем! Ә ул үзенең табигать биргән өстенлеген минем бәгыремә яра салу өчен файдаланды. Шулмы хатын-кыз! Шулмы кешелеклелек!

— Димәк, сез ул чакта үз-үзегезне кызганып елагансыз,— диде Зәйтүнә аның йөзенә борылып карап.— Ә аның хәлен аңладыгызмы соң?

— Нәрсә булган аның хәленә? Ул үз эшен эшләгән иде инде!

— Аңа да җиңел түгел иде бит! Сез авырлы хатынның хәлен күз алдына да китермисез! Аның сүзен тыңламыйча, калдырып китеп баргансыз! Аның яшисе килмәгән минутлары булгандыр. Нигә аның хәленә кермәдегез, нигә янында тормадыгыз?

— Мин хатын сагында гына утыра алмыйм бит инде. Цехтагы хәлләрне үзегез дә беләсез. Анда да хатын-кызлар эшли, сез цехны ябарга йөрисез.

— Барысы да — үзегез теләп алган йөк. Икесенә дә житешергә кирәк... Бу юлы да аны аңларга тырышып карагыз. Әгәр ул баланы үз

баласына охшаткан икән, бу — бик житди нәрсә. Әгәр дә сез каршы килсәгез, бу аның өчен тагын бер югалту булачак.

— Ә сез медицина казанышлары белән мактанасыз тагын,— диде Мөдәррис. Лампа яктысында аның бит очлары уелып, ирен читләре күтәрелгәне күренде.— Безнең әбиләр мондый кайгыларны белмәгән. Унар бала тапканнар, сәламәт картайганнар. Медицина зуррак уңышларга ирешкән саен, бу мәсьәлә катлаулана төшә.

Монысына Зәйтүнә түзеп тора алмый иде инде. Аның кыйбласына, иманына — медицинага гаеп ташлау иде бу. Ул Мөдәррискә таба борылды да:

— Шулай микән?— диде.— Ун баланың ничәсен генә исән-сау үстерә алган соң ул әбиләр? Элек хатыннар, беләсезме, ничек яшәгән: корсак күтәрә, бала имезә, бала күмә, тагын бала таба, имезә, күмә... Әгәр дә үзе исән калса. Бала тапканда күпмесе һәлак булган әле аларның! Хәзер хатыннарның хәле чыннан да бик нык үзгәрде. Алар баланы теләгәндә табалар да исән-сау үстерәләр. Шуңа күрә ирләрдән калышмыйча эшли алалар, иркен сулыш белән яши алалар. Болай яшәүче без икенче буын хатыннар гына әле. Бу мәсьәләне хәл итми торып, хатын-кызның җәмгыятьтә тигез хокуклы булуы хакында җитди сүз алып бару да мөмкин түгел иде. Әгәр дә хатыннар элеккечә бала табу, аны карау, аннан соң бала үлү хәсрәте белән генә, шуларга күмелеп кенә яшәсә, ул чакта аның тигез хокукы турында сүз дә алып барып булмас иде. Менә нәрсә эшләде безнең өчен медицина — ул безне кеше итте, беләсегез килсә!

— Ышандырдыгыз,— диде Мөдәррис эчке көлемсерәү белән, әмма тавышы җитди иде.— Тик менә хатыннарны ул хокуклардан дөрес файдаланырга кем өйрәтер икән соң?

— Анысын медицина гына эшли алмый шул.

Алар трамвайның арткы ишегеннән менеп, иң арткы утыргычларга утырдылар. Вагон буш, аларның сүзенә колак салучы юк иде, ләкин Мөдәррис Зәйтүнәгә сыенып утырды.

— Трамвайда сөйләшү уңайлы түгел, ләкин мин сезне башка җирдә очрата алмыйм, шуңа күрә әйтәсемне әйтеп калырга ашыгам,— диде ул.— Мин кайчак төннәр буе күңелемнән сезнең белән сөйләшеп чыгам. Мин сезгә болай дип әйтермен, ә сез тегеләй дип җавап бирерсез шикелле. Дөрес, соңыннан сезнең сүзләр бөтенләй башкача булып чыга... Сез мин уйлаганнан да акыллырак, сизгеррәк, тирәнрәк... Гафу итегез, әгәр без көн саен очрашып торсак... әгәр бергә булсак... сез мине аңлар идегез кебек тоела миңа...

Зәйтүнә аннан читкә тайпылды, сулышы кысылды. Аның бу хәрәкәтен сизеп, Мөдәррис башын иде дә тынып калды. Зәйтүнә дә дәшмәде, бозланып каткан тәрәзәне учы белән эретеп, кырыйда чагылып үзган шәһәр утларына карап барды.

Трамвайдан төшкәч, алар шулай ук бераз дәшми бардылар. Инде өй янына килеп җиткәч, Мөдәррис кулы белән аны туктатырга теләгәндәй хәрәкәт ясады.

— Тагын бер генә сүземне әйтим инде,— диде ул.— Тукайның бер шигыре бар, хәтерлисезме икән: «Һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы...» Мин бу юлларны укыгач, хәйран калдым. Аның хакындагы истәлекләрне җентекләп укып чыктым. Ул хак дөресен язган икән бит. Чыннан да, Тукайны бөек шагыйрьгә лаек дәрәҗәдәге хис белән яратучы, аңа тормышын, язмышын багышлаучы кеше булмаган. Булмаган андый хатын-кыз! Авырган чакларында аны тәрбияләүче, аның иҗатына илһам бирүче, язганнарын бөртекләп җыеп баручы, аны мәхәббәте белән җылытучы, аның кадерен белүче булмаган бөек шагыйрь Тукай янында! Ә шул ук вакытта җирдә олы җанлы күпме гүзәл кызлар яшәгәннәр әле! Ләкин алар башкаларны яратканнар, баш-

каларны күңел җылысы белән җылытканнар, башкаларның сызлануларын җиңеләйткәннәр. Кемнәрне сөйгәннәр ул саф күңелләр, изге хисләрен кем аяк астына салганнар? Уйлап карасаң, ул чорда безнең татар халкында Тукайдан да мәхәббәткә лаеграк һәм мохтаҗрак башка кеше булмагандыр да бит әле. Минемчә, шундый изге бер җанның мәхәббәтенә юлыкмау Тукайның гомерен иртә кискән сәбәпләрнең берсе булгандыр да.

Зәйтүнә гаҗәпләнеп тынып калды. Аның бу хакта мондый тирәнлек белән чыннан да уйлый алганы юк иде әле.

— Мәхәббәт хисе күңелдә яхшы кеше очраган саен түгел, ә бәлки яратыр вакыт җиткәч кабына бит ул. Ә ул чакта синең янда зур хискә лаек кешенең туры килмәве дә мөмкин. Тукайга лаек кыз аңа туры килмәгән, димәк...— диде ул.— Ул кыз аны белмәгән.

— Ничек инде ул алай, халыкның күз өстендә каш кебек күргән шагыйрен кызлар белмәсен, ди? Ю-ук, монда ниндидер башка бер сәбәп бар. Хатын-кызның әлеге дә баягы шул сәерлегеннән, тормышны аңламавыннан киләдер ул. Әйтегез әле, сез хатын-кызлар ни өчен гашыйк буласыз егетләргә? Ни өчен кайчак асыл кызлар хисләрен юк кына кешеләрдән таптаталар, ә үзләренә лаек булганнардан йөз чөерәләр? Нәрсә моның сәбәбе?

— Ә сез соң, егетләр, ирләр, һәрвакытта да лаек булганнарны гына сөясезмени?

Зәйтүнә моны шулкадәр ачынып әйтте, Мөдәррис ирексездән тынып калды. Бу сорауга бик зур мәгънә салынган иде.

Зәйтүнә үзе дә артыграк ачылып киткәнен сизеп, артка чигенеп куйды. Тукта, ул да, бәлки, хата ясыйдыр? Ул да иң изге хисләрен түбән кешенең аяк астына салып таптатадыр? Таптый бит Әнвәр аның мәхәббәтен, ике аяклап таптый! Менә хәзер бу кешенең күкрәгенә капланып бөтен моң-зарларны түгәсе иде. Ә аннары... аннары, Әнвәр аның һәлакәтен теләгән чакта да, Зәйтүнә үзен өзелеп сөйгән кешенең барлыгын, үзен аңлый торган, күңелгә якын башка берәүнең барлыгын белеп торыр иде. Бу — Зәйтүнәнең хатын-кыз буларак та, кеше буларак та дәрәҗәсен күтәрер, җиңеллек китерер иде.

Шунда күз алдында Әнвәрнең теге чакта Әзһәр абыйларында каралып килеп кергәне чагылып үтте. Нурсыз иде аның йөзе, кая карарга белми иде күзләре. Зәйтүнә дә аның каршында кайчан да булса шулай, йөзеннән нур качкан хәлдә, үзенең хыянәтче икәнлеген аңлап, үзенең түбәнлеген тоеп басып торырмы?

Юк-юк, бу мөмкин түгел!

Һәм ул Мөдәррис белән хушлашырга ашыкты.

*

* *

Мәхәббәт — изге, бөек хис, барча халыкларның даһи шагыйрьләре аны юкка гына җырламаган. Әгәр икәүнең күңелендә тыелгысыз сөю уты кабынган икән, аларның юлына аркылы басарга беркемнең дә хакы юк. Алар бергә булырга тиешләр, хәтта соңарып очрашкан булсалар да.

Шулай дип уйлый Лариса һәм бу карашын Әнвәргә дә сеңдерергә тырыша.

Ләкин нигә соң аның белән йөргәндә Әнвәр таныш-белешләрнең күзенә чалынудан курка, нигә үзен кечерәеп, вакланып киткәндәй хис итә?

Бу хис — гаепле лек һәм ваклану хисе — теге көнне абыйсы Әзһәрләрдә очрашканнан соң аеруча көчәйде. Йөзе кара иде Әнвәрнең, бу

каралык Ларисадан төшә иде. Ләкин шул ук вакытта ул Ларисадан башка яши дә алмый, башын иеп, кич саен аның белән очрашуга юнәлә, тыелгысыз бер тарту көче аны бөтерчек кебек тыгыз гәүдәле, хәрәкәтчән һәм шат күңелле хатын янына алып китә иде.

Чыннан да, мәхәббәттән дә өстенрәк хис юк иде шул, күрәсең.

— Инде кыяр өлгергәндер, нигә мине сыйламыйсың?— дип сорады Лариса.

— Алып килермен.

— Ә минем сабагыннан өзеп ашыйсым килә. Хәзер теплицалар урман кебек булгандыр инде, ә? Тропиклардагы шикелле: эссе, бөркү, тастымал-тастымал яшел яфраклар арасында маймыллар сыман шәрә хатыннар йөри. Экзотика! Минем дә шундый урманда адашасым килә. Синең белән бергә. Әллә барып адашабызмы?

Ларисаның бу шаяруы Әнвәрнең эчен пошыра башлады: кем белә бит бу хатынның күңел түрендә ниләр ятканын! Әллә чынлап торып адашасы килә аның, әллә инде Зәйтүнәгә, ирең тагын теплицага чит хатыннар алып килә, дигән гайбәт ишеттерәсе килә! Ә бәлки, аның үзенә генә рәхәт күрү әз сыман тоела торгандыр, ул әле башкалар күңелен газаплап та ләззәт табадыр! Нәрсә дигән иде әле ул: ләззәт сызлану белән бергә була, дигән идеме?

Әнвәр аны култыклаган кулын тартып алудан чак кына тыелып калды. Кулның шуышканын сизеп, Лариса аны терсәге белән тыгыз тәненә китереп кысты.

— Тамак ачты, кыяр белән генә туеп булмас,— диде Әнвәр.— Әйдә, ресторанга керәбез.

Трамвай көткән арада, Лариса кечкенә, тыгыз, хәрәкәтчән кулын аның беләге буйлап аска таба шудырды, Әнвәрнең бөтен тәненә кайнар дулкын таралды, бөтен шикләр эреп юкка чыкты, икәүләп янәшә басып торуның рәхәтлеге генә калды.

Лариса аның күзләренә сөеп, тәмам аныкы икәнлеген аңлатып карады. Ләкин бу караштa эчке бер тантана да бар иде. Ул үзендә бу үзсүзле, горур егет белән идарә итәрлек көч булуына куана иде.

Трамвай баскычыннан икәү янәшә басып менү уңайсыз, ләкин Лариса кулын алмады. Алар вагонның арткы мәйданчыгына терәлешеп бастылар. Трамвайда халык аз, артка карауча да юк иде. Әнвәр берни уйламыйча, бүгенге кичне генә күз алдына китереп барды. Аларның әле бу кичтә рәхәтләнеп сөйләшәселәре, бергәләп караңгы урамнарны гизәселәре, ә аннары бөтенләй икәүдән-икәү генә каласылары бар. Ахыр чиктә, кешеләр гомернең татлы минутлары һәм сәгатьләре хакына яшиләр бит, шулай түгелмени?

Җәннәтнең үзендә булудан да бигрәк аңа илтә торган юллардан бару рәхәттер.

Алар шәһәр читендәге кечкенә, иске ресторанга кереп утырдылар. Монда танышлар очрашудан куркырлык түгел иде, ләкин, сакланганны ходай саклар, дип Әнвәр ишеккә аркасы белән утыру ягын карады. Кем белә: ә бәлки кеше күзеннән качып йөрүчеләр тагын бардыр?

Ресторанда рәтле вино да, теләгән ризык та юк иде. Ит салаты, цыплята-табака алдылар, коньяк сорадылар. Бер рюмка эчкәч, Ларисаның бит очлары алланып чыкты, күзләре очкынланып китте. Ул Әнвәргә балаларча ярдәм сорагандай итеп, моңаеп карады.

— Эшләр гел артка китеп тора әле, Анварчик,— диде.— Теге чакта син вәгъдәңне үтәмәгәч, китте дә китте...

— Ну, Лорочка, әйттем бит инде, көтелмәгән хәл килеп чыкты, дип...

— Көтелмәгән хәлләрдән тора инде безнең язмышлар,— дип көрсенде Лариса алдындагы тәлинкәгә карап.— Бу Ильясованың көтелмәгәндә аварияга юлыгуын әйт... Эшне төгәлләп килә идем бит инде. Хәзер кайта алмаячак инде ул.

— Кайта алмас микәнни?

— Кая инде, андый имгәнүдән соң... Көтмәгәндә тудыру бүлегендәге бер хатын үлеп китте. Аны миңа сыларга маташалар тагын. Мин дөрес анализ бирмәгәнмен, имеш. Бу вакыйга минем методыма күләгә төшерә, дияргә теләүчеләр дә табылды!

— Нинди анализ? Син тудыру бүлегендә түгел идең бит?— дип һич көтмәгәндә төпченә башлады Әнвәр.

Ларисаның җавабын тыңлагач, ул инде чын-чынлап кызыксынып китте:

— Ничек алай килеп чыкты соң ул? Методың дөрес булса, аның хәле начараерга тиеш түгел бит!

— Әллә син дә миннән шикләнәсең инде?— диде Лариса ялварулы елмаеп.

— Үпкәләмә, Лорочка, ләкин мин бу мәсьәләгә бөтенләй икенче яктан карыйм бит. Авыру ягыннан карыйм мин моңа, чөнки мин, больницага эләксәм дә, авыру буларак кына эләгәм. Безнең техникада болай бит ул: әгәр безнең эштә берәр нәрсәнең очы-очка ялганмый икән, без аны кат-кат тикшерәбез, сәбәбен белергә тырышабыз. Синдә бәлки, инде нәтиҗә андый көтелмәгәнчә килеп чыккан икән, ул чакта анализны кат-кат алырга кирәк булгандыр. Ә бәлки син берәр нәрсәне бутагансыңдыр, ялгышкансыңдыр?

Ларисаның йөзенә чыккан алсулык әкрен-әкрен кимеп, йөзе ак агачтан уелгандай булып калды, күзләре түгәрәкләнде.

— Мин дә кеше!— диде ул ниһаять.— Ялгышуым ихтимал. Ләкин мин аны больницадан чыгарыгыз, димәдем. Аннары, чыккач, аның нинди хәлләр кичерүе дә билгеле түгел, хәле кинәт үзгәрүе ихтимал! Ә син, хәтта син дә миннән шикләнәсең? Хәле авырайган һәр кеше өчен врачларның башын ашый башласалар, кая китә ул?

— Андый очракта дәшми калу да ярамый шул,— диде Әнвәр.

— Ничего,— диде Лариса, кулында рюмканы әйләндергәләп.— Хәзер кафедрада зур үзгәрешләр булачак әле. Фәнни эш белән шөгыльләнгән яшьләргә юл ачылачак.— Ул бераз тынып торды да, әкрен, ләкин каты тавыш белән, каядыр почмакка карап, таш стеналар, зур урамнар аша үзенең максатын күргәндәй итеп:— Башларына басып үтәрмен, барыбер үземнекен итәрмен!— диде.

* * *

Бу бәладән котылу Әнвәрне кире элекке нур шәүләсе хәленә кайтару чарасы да булгандыр. Ләкин Зәйтүнә андый чараны белми иде. Аның күңелендә хәнҗәр булып һаман бер уй айкалды: ул Әнвәргә кирәкми, кирәкми, кирәкми...

Яшәүнең мәгънәсе сүнгән кебек булган иде. Ләкин Зәйтүнә йомылып берни күрергә теләмәгән күзләрен ачарга мәҗбүр итте. Ул яшәргә тиеш иде, ул сөекле улына кирәк, аны кайгыртып яшәргә тиеш иде. Эшендә аны өмет һәм сорау тулы караш белән авырулар каршы ала. Зәйтүнә алар өчен яшәргә тиеш иде.

Һәм ул шушы яшәеш өчен, шундый тормыш өчен үзенә бер мәйдан булдырды. Шул мәйданда көчен туплап, көн итә башлады.

Сагышка бирелеп, мендәр почмагын тешләп күз яше түгеп яшәргә теләмәде ул. Эштә чакта җинел, кичләрен Әнвәрнең кайдадыр башка берәү белән очрашып йөргәнен уйлап утыру авыр. Һәм Зәйтүнә хәтта уйларын да башка максатка юнәлдерергә тырышты.

Ул һәр минутын уйлап, үзе өчен һәр кичкә катгый план төзеп куя торган булды. Һәм, башка берәү белән идарә иткәндәй, үзен бу планны

кичекмичә үтәргә мәҗбүр итте. Ул кайбер газның кеше организмына тәэсире турындагы нәтиҗәләрен гыйльми хезмәт рәвешенә китереп, тәмамлап куйды. Ул хәзер мәйданга чыккан ат шикелле, туктап калырга тиеш түгел иде. Һәм ул зур бер проблемага — табигатьтәге үзгәрешләрнең, ел фасылларының, көн сәгатьләренең кеше организмына, аерым алганда, организмның төрле препаратларны үзләштерүенә йогынтысын өйрәнүне максат итеп куйды. Бу — озак еллар буена дәвам итәчәк һәм бик күп көч сораячак мәсьәлә иде.

Кеше — табигать баласы һәм ул табигать белән аерылгысыз бәйләнгән. Ләкин медицина практикасы, кешене дәвалаганда, табигатьтәге үзгәрешләрне тиешенчә исәпкә алып бетерми әле. Авыруларны кышын-җәен, көнен-төнен бер үк даруларны бер үк микъдарда биреп дәвалыйлар. Әгәр дә табигатьтәге үзгәрешләрнең организмга йогынтысы ныклап өйрәнелсә, ул чакта даруларны да азрак биреп, яхшырак нәтиҗәгә ирешү мөмкинлеге туар иде. Бу — бала табучы хатыннарга ярдәм итүдә дә бик мөһим.

Зәйтүнә хәзергә бу темага язылган фәнни хезмәтләрне барлап, аларны укып чыгарга, клиникадагы авыру тарихларын өйрәнергә, метеорологлар белән элемтә булдырып, алардан мәгълүматлар алырга булды.

Кичләрен эштән кайткач, ул үзенә тын алырга да ирек бирми иде. Баланы карап яткыра, өй эшләрен барлый, аннары яшел лампа яктысына кереп утыра. Кайчандыр алар Әнвәр белән бергәләп утырган яшел лампа яктысына. Ләкин ул бу хакта уйламаска тырыша, үзен мәҗбүр итеп, кулына китап, дәфтәр ала һәм чыннан да бераздан йөрәк түрендәге яраның сызлавы кимегән кебек була иде.

Шулай итеп, алар Әнвәр белән бер йортта, ләкин шул ук вакытта бөтенләй аерым яши башладылар. Зәйтүнәнең тормышында Әнвәр өчен бөтенләй вакыт калмады, шулай ук аңа булган үчлелек тә бетеп киткәндәй булды. Алар бары тик бала хакында гына берничә сүз алышалар, башкасына вакыт та калмый иде кебек.

Алай да бер тапкыр Әнвәр аерылышу турында сүз кузгаткан иде, Зәйтүнә аңа тыныч кына борылып карады да:

— Ник ашыгасың, минем белән ялгышкан кебек, тагын ялгышудан курыкмыйсыңмыни?— диде.— Болай гына... яшәп карагыз. Анысына мин комачауламыйм бит. Мин улыма эти итеп үзем сине сайладым, ул этиле булып калсын өчен бөтенесен эшләргә тиешмен,— диде.— Син дә аны этисез калдырырга ашыкма!

Гаҗәп, мөнәсәбәтләрне шушы рәвештә ачыклаганнан соң, Әнвәр өйгә иртәрәк һәм ешрак кайта торган булып китте.

Эшен дәвам итү өчен Зәйтүнәгә Җәмилә Закировна белән киңәшергә кирәк иде. Ләкин ул аның янына берничә минутка гына кереп чыга алды. Профессор Ильясова янында дежур торырга бик тәҗрибәле һәм исемле врачларны гына билгеләгәннәр, Зәйтүнә кебек яшьләрне анда теләмичә генә кертәләр иде.

Профессорның бу хәлдә ятуы Зәйтүнәгә эшендә ашыгырга кирәклеген кисәтеп тора иде: кеше гомере кыска, ә эшлисе эшләр шундый күп икән!

Бер кичне, фәнни мәкаләләр башына керми башлагач, баскычтагы аяк тавышларын йөрәк сызлавы белән тыңлап утырганда, Зәйтүнә кулына популяр журнал алып, аның уртасыннан ачып укый башлады. Анда борынгы майя һәм инк халыкларының гаҗәеп сәнгать әсәрләре, манаралары, калалары турында язылган иде. Зур үсешкә ирешкәннәр бу халыклар, ләкин менә хикмәт — тәгәрмәчне белмәгәннәр. Гаҗәп. Безнең өчен гап-гади бер нәрсә бөек халыклар өчен сер булып калган. Әгәр дә алар тәгәрмәч тә уйлап чыгарган булсалар? Ул чакта, бәлки,

тагын да зуррак үсешкә ирешкән булырлар иде! Ә бәлки без дә тәгәрмәч кебек үк гап-гади нәрсәләрне белмибездер әле.

Ә бәлки Зәйтүнә дә шундый бер нәрсә ача алыр да ул чакта бик күпләргә яшәү, чирдән сихәтләнү җиңелрәк килер?

Бу дөньяда Зәйтүнәнең бары тик ул гына башкара алырлык эшләре бар әле. Фәндә кеше кешене алыштыра ала, диләр. Дөрес түгел, әгәр шулай булса, майя халкының тәгәрмәче булыр иде. Дөньяда һәркемнең үз урыны бар, кеше кешене алыштыра алмый. Зәйтүнәнең дә бу тормышта үз урыны, яшәешенең үз мәгънәсе бар. Һәм ул бу мәгънәне акларга тиеш.

Аңа ашыгырга кирәк иде. Болай уйлаганда, ул хәтта профессор Ильясованың аякка басып эшенә чыгуын да көтеп тора алмый иде. Алай гына да түгел, ул Җәмилә Закировнаны эшкә чыгарга үзе мәҗбүр итәргә тиеш, чөнки табигать белән кешенең бәйләнешы турындагы идеяны да профессор әйткән иде, тик моңарчы кафедрада аңа алынган кеше генә булмаган. Йөрәге типкәндә, башы эшләп торганда профессорның да бирешергә хакы юк иде. Аннары ни авыр хәсрәттә дә эшен, башкалар хакында уйлауның зур шифа биргәнен профессор үзе дә яхшы белә бит!

Бу юлы Зәйтүнәне беркем дә туктата алмый иде инде. Ул ишек төбендә торган апа янына барганчы ук халаты белән башлыгын киеп куйды, «Исәнмесез» дип баш кына какты да узып китте һәм профессор Ильясова яткан палатаның ишеген саклык белән, ләкин шул ук вакытта нык итеп какты.

— Керегез!— диде әчтән таныш тавыш.

Җәмилә Закировна караватта аякларын салындырып утыра, кырыйга таяк сөялеп куелган иде. Зәйтүнәне күргәч, агарынган, ябыккан йөзендә елмаю балкыды. Аның күзләренә карауга, Зәйтүнә үз күңел түрендәге сызлануны күргәндәй булды. «Ире үлгәнен әйткәннәр икән!»— дип уйлады ул.

Ишек янындагы урындыкта Ләйлә утыра икән. Бу юлы ак халаттан түгел, гади күлмәктән. Зәйтүнә кергәч, ул да торып басты. Җәмилә Закировна караваt кырыеннан шуышып төште дә, Зәйтүнәгә таба атлады. Ул сул аягына нык кына аксый иде. Зәйтүнә аңа хәсрәтен уртаклашуын белдергәндә, йөзеннән теш сызлагандай калтырану узды. Профессор тизрәк сүзне икенчегә юнәлдерергә тырышты.

— Клиника хәлләрен сөйлә миңа,— диде ул.— Ачыктан-ачык.

— Башта үз хәлләремне сөйлим әле,— диде Зәйтүнә. Алар каршы-каршы утырыштылар.

Зәйтүнә сумкасыннан кәгазь битләрен алып Җәмилә Закировнага сузды. Бу аның газлар турындагы эше иде.

— Бушрак вакытта укып чыгармын,— диде Җәмилә Закировна.— Ә практик нәтиҗәсе ничек соң?

— Бу хәлдән котылу чараларын эзлиләр. Ләкин мин дә туктап тора алмыйм, мин яңа темага керештем инде. Менә тикшеренүләрнең планы.

Артта Ләйләнең тамак кырганы ишетелде.

— Безнең әнинең больничныйдан чыкканы юк бит әле,— диде ул үпкәләгән кебек, ләкин аның тавышында елмаю сизелә иде.

— Карыйм, карыйм, ансын да карыйм, ә син Ләйлүк безгә комачаулама. Галимне шәкертләреннән аерып тора торган больничныйлар юк дөньяда.

Җәмилә Закировна планны шунда ук җентекләп карап чыкты, берничә киңәш бирде. Аннары тагын клиника турында сораша башлады. Монысы турында сөйләргә Зәйтүнә бик үк теләми иде. Зәйтүнә Динәгә операция хакында әйткәч, Җәмилә Закировна:

— Хәйруллинаны күздән ычкындырма инде хәзер,— диде.— Тотынгансыз икән, ахырынача илтеп җиткер. Әгәр дә ялкынсынуларны булдырмый калдыра алсагыз, ә бәлки чыннан да теләгегез тормышка ашар! Гел күзәтеп торырга кирәк аны! Баланы алу мәсьәләсен үзләре хәл итсеннәр. Анысына басым ясарга ярамый.

Авыруны борчырга кирәкми иде, ләкин Җәмилә Закировнадан яшереп буламыни: Зәйтүнә аңа комиссия төзелгәнен дә, Изаил Харисович килеп йөргәнен дә әйтте.

— Максатыма ирештем, дип уйлый торгандыр,— диде Ләйлә.— Профессор Бернардларның даны тынгы бирми аңа. Дөньяны шаккатырырлык операцияләр ясап, дан аласы килә.

Җәмилә Закировна караваттан торып, таягына таянып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөреп килде. Сул аягына янтаеп атлагангамы, кызылга ак бизәк төшкән бумази халаттан ул бераз кечерәеп калгандай тоела иде.

— Медицинада карьеристларны тану җиңел түгел,— диде ул.— Алар карьерага омтылганда да кешегә яхшылык эшлиләр — авыруларны дәвалыйлар бит.

Ул Зәйтүнәгә таба борылды да:

— Әйдә соң комиссия үз бурычын үтәсен,— диде.— Безнең күз күп нәрсәгә күнеккән, кайбер кимчелекләрне күреп җиткермибездер. Яңа кеше килгәч, бөтенесен яңача күрә. Безгә сабак булыр. Кара дошманның сүзендә дә хаклык була, аны кабул итә белергә генә кирәк!

Зәйтүнә остазына гаҗәпләнеп карады: бу арада күргән хәсрәтләр өстенә ул яңа борчулар алырга, аларны кабул итәргә әзер иде!

— Менә чыгыйм гына, гыйльми советка кафедраның отчетын куячакмын. Ныклап сөйләшергә, ә бәлки кайбер мәсьәләләрдә эшне яңача алып барырга кирәктер. Ләйлүк, син ничек уйлыйсың, берәр атнадан аксавым бетәр микән минем? Гыйльми совет каршына таякка таянып барып керү ярамас бит!

— Әни, син башта каядыр барып керү турында түгел, моннан сихәтләнеп чыгу турында уйларга тиеш!

Бераздан Җәмилә Закировна кызына:

— Ләйлүк, син соңармыйсыңмы?— диде.

— Хәзер, әни. Мин синең яныңа иртәгә килермен инде.

Ул чыгып киткәч, Җәмилә Закировнаның йөзе сулып киткәндәй булды. Юк, фаҗига аның өчен эзсез узмаган, ул бары тик үзен нык тотарга гына тырыша иде.

— Өегездә хәлләр ничек соң, Зәйтүнә?— дип сорады ул.— Бала ничек үсә?

Кайгы пәрдәсе аша сорады моны Җәмилә Закировна. Ләкин сүз өчен генә түгел, чын күңелдән сорады һәм аңа ихластан җавап бирергә дә кирәк иде.

— Улыбыз үсә... Ә әтисе... әтисе ятларга карый, Җәмилә Закировна!

— Кемгә икәнен дә беләсеңме?

— Сез дә беләсез аны. Лариса Нигъмәтуллина.

Җәмилә Закировна, башын иеп, бераз уйланып утырды.

— Синең иреңә авыр чир йоккан, димәк. Ә чирлене гаепләп булмый. Ничек, ни сәбәптән чирләгәнен ачыкларга, дәваларга кирәк аны. Бу чир аңа йокмасын өчен, син барын да эшләгән идеңме? Анысын да уйла. Әгәр дә ул терелсә, соңыннан беркайчан бу хакта аның исенә төшермәскә кирәк. Онытырга кирәк ул чирне.

— Андыйны онытып буламыни, Җәмилә Закировна?

— Бөтен нәрсәне төзәтеп була, Зәйтүнә, үлгәнне генә кире кайтарып булмый. Мәхәббәткә дәва бар, әҗәлгә чыннан да дәва юк икән.—

Җәмилә Закировна күз яшьләрен күрсәтмәс өчен йөзен тәрәзәгә борды.— Ансыз яши алмам шикелле. Ник исән калдым икән, дим ялгыз калган чакларымда. Кырык елдан артык бергә яшәп, мин аны соңгы юлына озата да алмадым.

Зәйтүнә аяк өсте басып, аның иңенә кулын салды. Һәм беренче мәртәбә бер генә минутка булса да үзен остазын юатырлык, аңа көч бирерлек дәрәҗәдә итеп тойды.

— Чын табип беренче чиратта ярдәмгә мохтаҗ кешеләр хакында уйларга тиеш, дип өйрәтә иде безне остазыбыз профессор Ильясова,— диде ул.

— Әйе, әйе, эшләргә кирәк, тын да алмый эшләргә. Яшәтсә шул эш кенә яшәтә ала инде мине...

Аның белән саубуллашып чыккач, Зәйтүнә коридорда Изаил Харисовичны хәтеренә китерде. Ашыккан икән доцент Дәүләтшин, артык ашыккан икән. Төркем башындагы кыр казы урынын башкаларга бирмәячәк иде әле.

Җәмилә Закировна Зәйтүнә артыннан ямансу гына елмаеп карап калды. Бу яшь хатын кереп чыккач, бүлмә яктырып киткәндәй булды аңа. «Минем яшьлегем бит бу, минем ныгып, чыныгып кына килгән чагым»,— дип уйлады ул.

*
* *

Суларның да җайсыз юлдан аккан чаклары була. Ганлә тормышын әйткән дә юк. Күпме парлар үзләренә җайсыз итеп яшиләр! Болай яшәргә ярамаганын да аңлый алар, тик күңелләрдә яткан ташлар тормыш агышын әйбәт көйгә салырга ирек бирми. Ә гомер уза тора, тормыш һаман җайсыз бара, күңелләр бу җайсызлыкка күнегеп китә, гадәтләнә хәтта.

Әнвәр белән Зәйтүнәнең тормышы да шундый иде. Ләкин болай яшәп бетерү мөмкин түгел. Нәрсәдер — давыллы, көчле яңгырмы булыр да елганың суларын ташытыр, күңелдәге авыр ташларны юып алып китәр, я булмаса яңаларын китереп өстәр дә тормыш җайлануга өметләрне бөтенләйгә юк итәр төсле иде.

Телефоннан ят ир тавышы ишетелгәч, Әнвәрнең йөрәге жу итте.

— Мин Зәйтүнәнең хезмәттәше, Наил Хәйдәрович,— диде тавыш исәнләшкәч.— Шимбә көнне безнең көмеш туебыз була. Минем иптәшем Зәйтүнә белән дус. Бәлки, сөйләгәндер дә Сөембикә апасын. Сезне бик үтенеп чакырабыз.

Әнвәрнең теле кипте, ул ничек җавап биргәнен үзе дә тоймады. Рәхмәт әйтте ахрысы, ә рәхмәт үзе ризалык бирү дигән сүз.

Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, билгеләнгән сәгатьтә алар, баланы күршедә калдырып, парлашып кунакка киттеләр. Кәгазьгә төрелгән чәчәк бәйләме күтәреп, ярым караңгы урам буйлап култыклашып барганда, алар артыннан бер хатын-кызның:

— Кунакка баралар!— дигәне ишетелеп калды. Бу тавышта кызыгу яңгыраган кебек иде.

Сөембикә апаларның олы бүлмәсендә буйдан-буйга өстәлләр куеп табын әзерләнгән иде. Табындагы бәллүр савытларда алма-әфлисун, конфетлар, кыйммәтле графиннарда эчемлекләр, ак ашъяулык өстендә көмеш кашыклар — барсы да якты ут астында җемелди, балкый. Бу матурлыкны, муллыкны күреп, Зәйтүнә:

— Ай-һай мул әзерләгәнсез!— дип куйды.

— Хуҗиндә бары инде, махсус җыйган мал түгел,— диде Сөембикә

кә.— Менә бу вазаларны туебызга бүләк иткәннәр иде, көмеш кашыкларны беренче улыбыз тугач котлап бирделәр..

— Шуннан бирле сакладыгызмы?

— Кая китсен соң алар? Сезнең көмеш туегыз безнекеише генә дә булмас, заманалар икенче хәзер, бай замана.

Әнвәр аларны тыңлап бетерә алмады: зал ишегендә Лариса күренде. Барлык кунаклар ирексездән шул якка борылдылар. Идәнгә тиеп торган киң итәкле, озын җиңле зәңгәр ефәк күлмәк кигән Лариса бер мизгелгә генә туктап калды һәм ишек яңаклары арасында рамга алынган картинага охшап китте. Әйтерсең лә, аны рәссам бик ачык буяулар белән ясаган: куе җирән бөдрәләр, кып-кызыл иреннәр, колак очларында алкалар һәм ак муендагы бер рәт мәрҗән зәңгәр очкын сибә. Әнвәрне күргәч, ул башын тагын да арткарак ташлап әчкә атлады, итәге аякларына сыланып, аның сынын аермачык күрсәтә иде. Әнвәр ашыгып китап шкафына таба борылды һәм андагы хикмәтле савыт-сабаларның, шәмдәл-сыннарның нинди очраклар белән бүләк ителгәннәре турында сөйләп торган Сөембикәне игътибар белән тыңлаганга салышты.

Белепме-белмичәме, Сөембикә кунакларны табынга бик оста урнаштырды. Түрдә утырган Әнвәргә ишек катындагы почмакка туры килгән Лариса бөтенләй диярлек күренми иде. Әнвәрнең сул ягында Зәйтүнә, аннан соң, өстәл башында, яшьләре кырыктан узган булса да, ыспай кыяфәтен, күзенең яктысын саклаган шома чырайлы ир кеше белән ябык битле хатынны утырттылар.

Борынгы йоланы саклап, хуҗалар кунакларын аяк өсте сыйладылар. Наил Хәйдәрович хатынын иңнәреннән кочты да:

— Чирек гасыр узып киткән, бер көн кебек тә тоелмады, инеме, карчык,— диде.— Малайларга карыйм да аптырап китәм кайчак.

Малайлар дигәне офицер киемендәге яшь егет белән чандыр гәүдәле үсмер иделәр. Алар икесе дә ишек төбендәге урындыклардан әтисе белән әнисенә елмаешып карап утыралар иде. Бу елмаюда ярату да, бераз гына кечерәйтү, өлкәннәрнең гаепләрен гафу итәргә әзерлек тә бар иде. Тормыш дилбегәсен әле генә кулларына алган яки алырга әзерләнгән яшьләр үзләре өчен кадерле булган өлкән кешеләргә шулай карыйлар.

Юбилярлар һәм аларның балалары хөрмәтенә бер-ике тост күтәргәннән соң, Зәйтүнә янында утырган ыспай ир кеше сикереп торды да:

— Әйдәгез, табындагы яшь парларга бәхет теләп берне күтәрик әле,— диде.— Алар да, Сөембикә белән Наилдән үрнәк алып, тату-тигез гомер итсеннәр, көмеш туйларында яннарында буй җиткән уллары-кызлары бөтерелеп йөрсен!— Соңгысын ул ни өчендер Зәйтүнәгә карап әйткән сыман тоелды.

Әнвәр күзләрен кыса төшеп, елмаеп, үзен Наил Хәйдәрович урынына куеп карады. Әйе, Тимербулат ул чакта менә шушы офицер кебек, сынын ныгыткан, җилкәләре киңәйгән, карашы зирәкләнгән егет булыр. Ә Әнвәр үзе кемнең иңнәренә кулын салып басып торыр соң? Ларисагамы? Ул чакта табын мондый күркәм була алмас, Тимербулат та аңа болай яратып карамас. Чөнки бары тик ата белән ана янәшә һәм тату булганда гына балаларның карашы шушындый якты-җылы була ала... Әнвәр уйларының очына чыгарга курыкты, кулындагы бокалын иреннәренә китерергә ашыкты.

Офицер егет бер кулына табуретка, икенчесенә тальянка күтәреп керде. Наил Хәйдәрович, уртага утырып, гармун уйнап җибәрде. Тамак ялганган, тостларның иң кирәкләре әйтелгән, мәҗлеснең иң күңелле вакыты — җырлап-биеп күңел ачар сәгате килеп җиткән иде.

Гармунчы төрле көйләр башлап карады, табындагылар тамакларын кыргалап куйдылар, ләкин бер көйгә дә шома гына кушылып китә

алмадылар: җырларның сүзләрен рәтләп белүче юк иде. «Сарман» белән «Шахта»ның бер-ике куплетын җырлап алдылар да тагын тынып калдылар. Наил Хәйдәрович авыл көен уйнап җибәргәч, өстәлнең аргы башындагы бер таза гәүдәле хатын:

Безнең авыл бик зур авыл,
Килә кыйбладан давыл,—

дип җыр башлады. Аңа кайсылары кушылмакчы иделәр дә җырның азагында тотлыгып тукталып калдылар:

Бәлки рәхәт тә күрербез,
Хәзергесе бик авыр...

Гасырлар буе хәерчелектән һәм хәсрәттән михнәт чиккән халыкның бу моң-зары якты бүлмәдә, мул табын янында утырган кешеләргә бик сәер булып ишетелде, күпләр түзә алмыйча пырхылдап көлеп җибәрделәр.

— И, уйламаганбыз, Наил, җыр китабын алып, сүзләрен күпләп күчереп куясы калган икән,— диде кунаклар арасына утырган Сөембикә.

— Барсын да уйлап бетереп булмый шул,— диде Наил Хәйдәрович.

Зәйтүнә янындагы ыспай ир тагын торып басты:

— Әйдәле «Алмагачлары»н!

Моның җыры шаян булып чыкты:

Алмагачны үстерәләр
Алмасы булмаса да;
Яр сөюләре күңелле
Гомерлек булмаса да.

Җырның ертыгы булмый, диләр тагын. Була икән шул! Ярларын гомерлеккә сөя белгән кешеләрнең тигез тормышы хөрмәтенә җыелган бу табында әлеге сүзләр тагын урынсыз яңгырады.

Табындагы халык бер-берсенә карашырга кыенсынып, оялчан елмаеп утыра иде. Күңелдә матур хисләр ташый, аларны әйтеп бирәсе килә, ләкин әйтеп бирер чарасын белмиләр, телсезләр хәлендә калганнар иде алар.

Уй-фикерләребезне уртаклашыр өчен безгә ата-бабаларыбыз тел бүләк итеп калдырганнар, хисләребезне бүлешер өчен җырлар мирас иткәннәр. Бу хәзинәне һәр заманның талантлары өсте-өстенә баетып тора. Ул байлыкны алу һәркемнең үзенә генә бәйле. Ә без аны ала белмибезме, әллә алырга теләмибезме? Никадәр байлыктан мәхрүм калабыз бит без шушы рәвешле!

Сөембикәнең башы иелгән, шома кара чәче лампа яктысында елтырый иде. Менә ул йөзен күтәреп, тешләрен җемелдәтеп ялынгандай елмайды:

— Зәйтүнә, җырлап бир әле безнең хөрмәткә!

Барысы да өстәлнең түренә төбәлделәр. Зәйтүнә артык кыстатмый гына торып басты. Аның өстендә ак ефәк күлмәк иде, туйда кигән күлмәге. Артык тантаналы кыяфәтен киметер өчен, Зәйтүнә аның түшенә һәм җиң очларына кызыл белән зәңгәрдән чәчәкләр генә чикте. Бу бизәкләр күлмәкне гадиләштеребрәк җибәрде, шул ук вакытта аңа сафлык, самимилек өстәде. Сары чәчен баш артына зур төен итеп җыеп куйган, чигәләрендә җиңел бөдрәләр бөтереләгән Зәйтүнә бүген чигүле кофта киеп кичке уенга чыккан авыл кызын хәтерләтә иде.

Менә ул башын күтәрде дә каршындагы ишек өстенә, ә бәлки үзе

МӨДИНӘ МАЛИКОВА ◆ АК ДАВЫЛДА ТАЛ БӨРЕСЕ ◆

генә белгән бер ноктага төбәлеп, тирән аһәңле тавыш белән әкрен генә башлап җибәрде:

Шам-шәриф дигән калада, дусларым,
Кич ахшамсыз капкалар ябылмый,
Ай-һай, дусларым...

Наил Хәйдәровичның кыска бармаклары тальян телләре буйлап биеп үттеләр, ләкин ул, борынгы бу көйне уйный алмасын белеп булса кирәк, аваз чыгармады, йомры башын алга табарак сузып, тынып калды. Бүлмәдә шундый тынлык урнашты ки, әйтерсең лә, бер кыз ялгызы гына җырлый, күңел түрендәге иң яшерен серне, иң тирән сагышны почмактагы зур гөлгә, түгәрәк җиз телен салмак кына чайкаган сәгатькә генә сөйли иде шикелле.

Узган гомер, калган хәтер, дусларым,
Сатып алыйм дисәң дә табылмый,
Ай-һай дусларым...

Хатыны җырлаганны күп тапкырлар тыңлаганы бар Әнвәрнең, әмма мондыен ишеткәне юк иде әле. Җырчы һөнәренә махсус өйрәнмәгән кеше гомерендә бары тик бер генә тапкыр шушылай үзәк өзгеч итеп җырлый аладыр, мөгаен. Анда да хисләре, сызлануы, әрнүләре йөрәгенә сыя алмаслык булып ташып чыкканда гына. Аның диңгездәй сагышлы җыры башкалар күңеленә түгелә, җанга үтеп, бәгырьләрне парә-парә телгәли:

Узган гомер, калган хәтер
Сатып алыйм дисәң дә табылмый...

Җыр әкренәйде, сагыш диңгезе ерагайды, ләкин дулкыннарын йөрәкләрдә калдырды.

Бераздан Әнвәр, каш астыннан күз сирпеп, табындагыларга карады: барысы да әле генә яңгыраган моң тәэсиреннән айный алмый тын утыралар иде.

Менә стена янында нечкә сынлы яшь бер хатын торып басты:

— Бигрәк моңлы җырлыйсыз, Зәйтүнә Мәҗитовна! Җырыгыз да бик гыйбрәтле. Ләкин моңаю сезгә килешми, Зәйтүнә Мәҗитовна! Сездән дә бәхетле кеше юк бит бу дөньяда. Сез бит... Сез... бүтәннәргә бәхет өләшүче! Иптәшләр, туганнар! Зәйтүнә Мәҗитовна безне уллы итте бит! Ул булмаса исән калмый иде бит безнең Шамилебез! Их, карточкасын алып килмәгәнбез! Гөл кебек үсеп килә хәзер улыбыз, Зәйтүнә Мәҗитовна, бер алып килеп күрсәтәм әле мин аны сезгә! Сөембикә апа, Наил абый! Сез гаеп итмәгез, мин Зәйтүнә Мәҗитовна хөрмәтенә тост күтәрәм! Анда дәваланган, аның җылы сүзеннән үк шифа алган йөзләгән хатын-кызлар исеменнән рәхмәт әйтәм мин аңа!

Кунакның хуҗалардан уздырып икенче бер кунакны күккә күтәреп мактавы әдәп кысасына сыеп бетми иде, билгеле. Табында Зәйтүнәдән зуррак врачлар, аннан күбрәк игелек кылган кешеләр дә күп иде. Ләкин берәү дә ризасызлыгын сиздермәде, киресенчә, Зәйтүнәгә борылган карашларда хуплау, ярату, соклану чагылды.

— Рәзилә хак әйтә,— диде Наил Хәйдәрович урыныннан күтәрелә төшеп,— Зәйтүнәне ходай олы җанлы, якты күңелле, талантлы итеп яраткан. Менә әйткән иде диярсез, бик олы кеше булачак әле ул. Андыйлар белән эшләү безгә дә күңелле!

Зәйтүнә үзе каушаган, кичерәергә теләгәндәй башын иеп, иңнәрен күтәребрәк утыра, лампа яктысында аның чәч бөртекләре алтынсуланып җемелди, күперенке чәче алтын таҗ булып тоела иде. Ул бармак-

ларын ияк уемына куйды, аннары үз хәрәкәтеннән курыккандай, кулларын аска төшерде.

Аның хәлен аңлапмы, әллә табынны тагын да җанландыру теләге беләнме, Наил Хәйдәрович кунакларны күрше бүлмәгә чакырды. Анда түшәмдәге аркылы-торкылы сузылган бауларга кызыллы-зәңгәрле чыршы утлары эленгән, өске ут сүндерелгәнгә серле һәм бәйрәмчә мохит булдырылган иде. Почмактагы өстәлдә стереомагнитофон тора, кунаклар керүгә үсмер малай заманча көйләрне уйнатып та җибәрде.

Башкалар бер-берсенә карашып торган арада, уртага Лариса чыгып басты.

Әгәр дә безгә, дәрья салкыныннан тәмам туеп, кайнар канлы җир егетенең көйдергеч назына сусаган су кызын күз алдына китерергә мөмкинлек булса, бу минутта Лариса шул су кызы иде. Төсле лампочкаларның алдавыч яктысында гүзәллек, мәхәббәт, ялвару төене булып бөтерелде ул. Аның күлмәге дә ефәк түгел, ә бәлки гәүдәсе буйлап аккан су агымы гына булып күренә, сыгылмалы тәненең һәр хәрәкәте күзне алырга ирек бирми, ымсындыра, мавыктыра, үз янына чакыра иде. Бию аның хисләрен әйтеп бирү чарасы, аның көчле коралы иде. Берәүнең дә аның янына уртага чыгарга кыюлыгы җитмәде, барысы да сокланып карап калдылар, иреннәрдә сәер елмаю уйнады. Табындагы татлы шәраб кебек исерткеч көчкә ия иде Ларисаның биюе. Әнвәр дә, аның сихеренә бирелеп, кузгала алмый торды, ул аның нечкә беләкләре көчен, тәненең тыгызлыгын, иреннәренең авырттырып үбүен өр-яңадан тойгандай булды, тыны буылды. Кинәт ул сискәнеп китте: биюченең менә хәзер аның кулыннан эләктереп уртага тартачагын, бөтен тәне белән аңа сарылачагын, ихтыярсыз итеп үз янында әйләндерәчәген, тәмам үзенеке итәчәген сизеп алды ул. Бию генә түгел иде бу, гыйшык утында янган йөрәкнең җан ачысы белән үз бәхете өчен көрәш алып баруы иде. Хәзер, менә хәзер су кызы җир егетен үзенә алып, җиңү тантанасын тирә-юньгә белдереп бөтерелер. Башкалар да моны аңлар, аларның күз карашларында җиңелүчегә нәфрәт чагылыр. Бу карашлар астында калу дәрья чоңгылына бату белән бер булыр...

Әнвәр кисәк борылды да, артында торган кешеләрне аралап, артка тайпылды. Баскыч мәйданчыгында тәмәке тартып торган ирләр янына чыгып, ишекне япканда, аның куллары калтырый иде.

Кире борылып кергәндә, ул иң элек Зәйтүнәнең агарынган йөзен күреп алды.

Алар башкалардан алда киттеләр.

— Кызыгырлык итеп яшисез,— диде Зәйтүнә хуҗалар белән саубуллашканда.

— Төрле чак булды инде, һаман бәйрәмчә генә яшәдек, дип әйтсәк ялган булыр иде,— диде Сөембикә.

— Гаепләрне оныт син, карчык, яхшы чакларны гына истә тот,— диде Наил Хәйдәрович аның иңеннән кочып.

Алар урамнан янәшә барганда да, таксида кайтканда да дәшмәделәр. Зәйтүнә Тимербулатны күршеләрдән алып чыккан арада, Әнвәр урын салды, ике мендәрне янәшә куйды.

Зәйтүнә күптән инде ире алдында күлмәген алыштырмый иде. Бу юлы да ул төнге күлмәген ванна бүлмәсендә киеп чыкты. Ул итәге идәнгә тигән ак күлмәктән караваты янына килеп басты. Алар арасы бер адым, әмма бу адым төпсез упкынга тиң, аннан искән бозлы җилне икесе дә тоялар кебек иде. Әнвәр сак кына кулын сузды, аның бармаклары тукымага орындылар.

Ә Зәйтүнә үзен самолет канатында басып торган кебек хис итте.

Аста — упкын, колакта җил шавы, шул шау аша, катгый, таләпчән сүз ишетелә: «Сикер! Сикер!». Ләкин куллар чытырдатып тимергә ябышкан, тән упкынга төшәргә теләмичә, кире кабинага керергә омтыла... «Сикер!» Шунда Зәйтүнә күлмәге тибрәнгәнен тойды — салкын упкын аркылы гүя нурлы сират күпере сузылгандай булды. Зәйтүнә алгарак авышты, Әнвәрнең кайнар бармаклары аның ялангач беләгенә орынды, хатынның тәне тетрәнеп җавап бирде...

Кайчандыр бала чакта әнисе Зәйтүнәгә шундый бер кыйсса сөйләгән иде. Таһир белән Зөһрә яралганчы, бер әүлия аларның әтиләренә бер алманы урталай бүлеп ашаткан, имеш. Кыз белән егет шул бер алмадан яралганнар һәм шунлыктан бер-берсеннән башка дөньяда яши алмас булганнар...

Таһир белән Зөһрә генә шундыймыни? Без барыбыз да бөтен түгел, ярты алмалардан гына яратылган бит! Кайчак гомер буе эзлибез без үзебезнең яртыбызны, гомер буе таба алмыйбыз. Ә кайчакта тапкач та тиң икәнлегебезне аңлап җиткерә алмый җәфаланабыз. Шул рәвешле нинди газапларга дучар итәбез без бер-беребезне!

Ләкин тиңен тапкан кешеләрнең шуны аңлаган сәгате — гомернең иң бәхетле мизгеле ул.

*
* *

Әле кайчан гына кыш иде, әле кайчан гына Мөдәррис белән Динә, сабыйны калын юрганга төреп, зәңгәр тасма белән бииләп, тудыру бүлегеннән алып киткәннәр иде.

Әллә кай арада яз җитте, клиника каршындагы бакчада өрәңгеләр яшелгә төренде. Күңелне алгысытып, ботакларда сыерчыклар сайраша. Бакча эченнән узганда, Зәйтүнәнең исенә язгы бер әйтем килде: «Сыерчык, сыерчык! Чирем чык, чирем чык!» Язын беренче сыерчыкларны күргәч, җиргә ятып, шулай такмаклап аунасаң, ел буе чирләмисең, имеш. Хәзер, соңгарак калып аунасаң да шифасы тимәс микән? Яңа күтәрелеп килгән йомшак чирәмдә тәгәрәү бик рәхәт булыр иде югыйсә...

Кинәт салкынча җил исеп куйгандай булды: бакча кырыеннан эре-эре атлап килгән көрән мыеклы берәүнең Хөсәен икәнен танып алды Зәйтүнә. Хөсәен дә аны күрде, туктап, бакчадан чыкканын көтеп торды. Ике ел эчендә ул тагын да үсеп киткән, чын мәгънәсендә ныгыган иде.

— Синең йөзеңә багана башына караган кебек карарга туры килә,— диде Зәйтүнә аңа кул биреп күрешкәч.

— Син дә чибәрләнеп киткәнсең, рәхәт яшисеңдер, мөгаен.

Хөсәеннең бу сүзләрендә яшерен киная сизелгәндәй булса да, Зәйтүнә моны аңламаганга салышты, егетнең биредә нинди йомыш белән йөргәнен сорашты. Хөсәен кан составындагы үзгәрешләрдән кан югалтуның микъдарын билгеләү ысулын тикшерә икән. Күзәтүләрнең нәтиҗәсен хирургларга җибәргән дә, бу методның гинекологлар өчен дә кызыклы булуын исәпкә алып, хирурглар аны профессор Ильясова игътибарына тәкъдим иткәннәр. Хөсәеннең Җәмилә Закировна белән киңәшергә килүе икән.

Алар икесе дә шул хакта гына сөйләшеп туктарга тырыштылар, ләкин арадагы берәү хакында бер сүз әйтми калу мөмкин түгел иде. Хөсәен Ларисаның исемен телгә алырга ашыкмады, Зәйтүнә үзе башларга тиешлекне аңлады.

— Әле мин синең килгәнеңне белмәгән идем,— диде.— Лариса күрше кафедрага, Дәүләтшин кул астына күчкәннән бирле, аның белән дә сирәк күрешәбез, һаман вакыт тими.

Хөсәен аңа карашы белән генә җавап бирде. Ул белә иде, барысын да белә иде, ләкин Зәйтүнәне, арада берни булмагандай тыныч сөйләве, ир белән хатын арасын бутарга теләмәве, үз хәсрәтен үзе генә кичереп бетерергә әзер торуы өчен, чын күңеленнән ихтирам итә иде.

— Безнең юллар аерылды инде,— диде Хөсәен йомшак кына.— Аралар бозылганда, ниндидер бер киртәгә димме, бусагага димме килеп терәләсең икән. Шул бусаганы атлап үтмәсәң, кире чигенергә, araларны җайларга була әле. Аны атлап чыксаң, кире кайтып булмый икән. Мин ул бусаганы күптән атладым инде.

Кичен Зәйтүнә бу очрашу хакында Әнвәргә әйтәм дип авыз ачкач туктап, тыелып калды. Әнвәр, артына Тимербулатны бастырып, кулларын тоткан да: «Күк-күк, чыпчык, тәрәзәдән очып чык...»— дип көйләп уйнатып утыра, ә малай тешләрен җемелдәтеп көлә иде. Бу минутта үткәннәрне хәтерләткән сүзне башлау урынсыз булыр иде. Үз вакытында Зәйтүнә, Хөсәен әйткән биек киртәне атлап узарга ашыкмыйча, ничек дөрес эшләгән икән!

Баланы яткызып, пәрдәләрне корып, яшел абажурлы лампа яктысына утыргач, Хөсәен хакында сөйләшү тагын урынсыз булыр, өйгә салкын җил бәреп кергәндәй итәр кебек тоелды.

Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәеп, готовальнясын ачып куйды. Кызыл бәрхет эчендә ак тимер җәзбә, каләмнәр елкылдап ята иде. Әнвәр элеваторда эшли, анда ашлык киптерү өчен яңа җайланма ясауны максат итеп куйган иде.

Зәйтүнә китабын тотып өстәл янына килеп утырды да:

— Әнвәр, синең бу машинаң эшли башлагач, баыйбыз инде без, әйеме?— диде.

— Яңаны уйлап чыгарып кемнең баеганы бар соң, Зәйтүнгөл! Һәр заманда уйлап табучыларны ачышлар бөлдергән генә. Бөлдергән дә кеше көлдергән. Әле ярый, безнең заманда «молодец» дип җылы сүзен әйтә беләләр.

Алар көлешәләр дә, һәркайсы үз эшенә иелә.

Ә шәһәр өстенә тыныч төннең зәңгәрсу-кара канаты җәелгән. Урамнарда, юлларда, тәрәзәләрдә кешеләрнең иминлеген саклап утлар яна, Җирдә безгә кадәрле яшәгәннәрнең изге мирасы — күңел җылысы һәм яктысы булып яналар алар.

# МӨХӘММӘТ САДРИГА 70 ЯШЬ



*Өлкән шагыйребез, сугыш һәм хезмәт ветераны, 1938 елдан КПСС члены, 1939 елдан бирле СССР Язучылар союзында торучы әдип Мөхәммәт Садрига 70 яшь тулды.*

*Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов 1913 елның 20 маенда Казанда эшче гаиләсендә туган. Бик яшьли ятим калып, балалар колониясендә тәрбияләнгән малай М. Вахитов исемендәге химия комбинаты каршында ФЗУда белем ала. Аннары заводның үзендә эшләп, хезмәт чыныгуы уза, шунда ук беренче шигырьләрен яза. Шигырьгә ул эшче-ударниклар сафыннан килә. Яшь шагыйрьгә Һ. Такташ, К. Нәҗми, Х. Туфан, Г. Гали, М. Җәлил кебек әдипләр игътибар итә; 1932 елда аның «Җыр башлана» исемле беренче шигырьләр китабы басылып чыга. Аннары ул Мәскәүгә китеп, театр сәнгате институтына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлагач, Казанга кайтып, Татарстан Сәнгать эшләре идарәсенең музыкаль фольклор кабинетында фәнни хезмәткәр була.*

*1941—46 елларда Совет Армиясе сафларында Бөек Ватан сугышының төрле фронтларында артиллерия, танк, автотранспорт частьларында хезмәт итә, «Ватан намусы өчен» исемендә татарча чыга торган фронт газетасында эшли. Шагыйрь Польша, Чехословакия, Румыния, Венгрияне азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. Батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнә.*

*Сугыштан соң М. Садри Татарстан Язучылар союзында әдәби консультант, җаваплы секретарь булып эшли, «Социалистик Татарстан» газетасында әдәбият бүлеге мөдире вазифасын башкара.*

*Илле еллык иҗат дәверендә шагыйрь күп санлы шигырь, очерк, тәрҗемә китапларыбастырып чыгарды — алар арасында «Бәхет турында җыр» кебек укучыларга киң билгеле поэма, композиторларыбыз көй язган күп санлы җырлар, гражданлык хисләрен калку чагылдырган публицистик һәм балалар өчен шигырьләр дә бар.*

*Шагыйрьне зур бәйрәме белән котлап, бу санда укучыларыбызга аның төрле елларда язган шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Мөхәммәт Садри

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Слесарьлар

Слесарьлар —
оста докторлары
Цехлардагы машиналарның;
Тиски, метчик,
зубило һәм чүкеч,—
«Дарулары»
шулар аларның.
Терелтәләр алар
машинаны,

Авыруының серен беләләр,
Гөрләттереп
аны эшләтергә
Йөрәк ялкыннарын бирәләр.
Һәрбер цех һәм
һәрбер станокчы
Ышанычын баглый аларга,
Машиналар
бик тиз ходка китеп
Мактау көйли
слесарьларга.
Слесарьлар
корыч кисәкләрен
Иң кирәкле
деталь итәләр;
Сизелеп тора:
корыч белән бергә
Үзләре дә
чыныгып үсәләр.

*М. Вахитов исемендәге завод, 1930.*

## Хәнҗәр

*Чиләбе танкистлары — гвардеецлар миңа хәнҗәр бүләк иттеләр.*

Фашистларның кара өнәренә —
Германиягә бару юлында,
Гвардеецлар хәнҗәр бүләк итте
Миңа шунда — сугыш кырында.

Ул бүләкне горурланып алып,
Башны идем батыр дусларга:
Ике йөз миллион штык ударында
Бу хәнҗәр дә сизелер дошманга.

*Польша, 1944.*

## Алтын Прага, Злата Прага!

Алтын Прага, Злата Прага!
Килеп яз таңнарыннан,
Дошманнарны себереп түктек
Влтава ярларыннан.

Алтын Прага, Злата Прага!
Балкый халкың йөзләре;
Невский кылычларыдай —
Йөз башняң шпильләре.

Алтын Прага, Злата Прага!
Җырың җирне гөрләтә,
Азатлык әләмнәреңне
Май җиле җилфердәтә.

Алтын Прага, Злата Прага!
Йөрим кылып тамаша;
Мәңгелек дуслык кулын без
Суздык сиңа ут аша.

*Май, 1945, Прага.*

## Хәтерлисезме?

Хәтерлисезме сез Шюньбронда
Каштәнәләрнең чәчәк атканын,
Эссе бакчада агач астында
Вена картының хәлсез ятканын?

Без аны шул чак күтәреп алдык,
Ул су сорады, көчкә эндәшеп;
Авызына аның Сан суы салдык,
Аңлашкач шулай бергә ымлашып...

Ул Бельведерга чишмәгә килгән,
Тилмереп килгән бер тамчы суга;
Ә чишмә кипкән, үләннәр көйгән...
Өметсезләнеп, карт ауган шуңа.

Без штык белән җирне актаргач,
Чыкты атылып чишмә сулары;
Шушы суларны эчеп хәл алгач,
Күтәрде бу карт башын югары.

Карап торды ул көнчыгыш якка,
Кәстәнәләргә, Дунай артына...
Киң итеп сулап менә шул чакта:
«Күп рәхмәт,— диде,— совет халкына!..»

*1945—1955, Вена — Казан.*

## Син горурлыгым, Казан

И Казан, нурлы Казан, яңа калам,
Туып синдә үскәнемә шатланам.

Яшь Ленин салкын, кара бер заманда,
Кояшлы Байрак күтәрде Казанда.

Ауды бит канлы каракош дивары;
Ленин Байрагы җилферди югары!..

И Казан, нурлы Казан, син зур калам,
Туып синдә үскәнемә шатланам.

Баш иеп, Казан, һәрбер почмагыңа,
Сыенам зур бәхетле кочагыңа.

Мин тоям миллион йөрәкнең тибүен,
Һәр ягың җанга рәхәт нур сибүен.

Эшчеләр горурлыгы — заводларың,
Нурга нур фән-мәгърифәтең утлары.

Цехларда кайнып хезмәт ярышлары,
Алга өнди Сәйдәшең маршлары!

Һәр милләт тигез, туган, нык дуслашкан,
Мәңгегә син Мәскәү белән тоташкан.

Ал Байрак җиргә нур сипкән заманда,
Мин яшим Ленин яшәгән Казанда!

*1979*

## Учак ягып төнне куам...

Ярга якын алма бакчасында
Күңел кайнар хискә күмелде.
Биек таудан зәңгәр Идел аша
Аллы-гөлле киң юл күренде.

Моңсу баеп барган алсу кояш,
Ярда танып газиз баласын,
Ялгыз булсаң, әйдә, кил, дигәндәй,
Идел аша җәйде паласын.

Әйе, ялгыз көтәм сөйгән дусны,
Аның өчен яна хисләрем,
Аны көтеп кошлар җыелдылар,
Роза сибә иң хуш исләрен.

Җем-җем иткән аллы-гөлле палас
Сихри сират кебек күренде.
Очар келәм булып тауга менде,
Кояш белән янды, сүрелде...

Кара төндә нидер сөйли суга
Мүкле ташлар Идел ярында.
Ташка учак ягып төнне куам:
Бәхет кошым балкыр таңымда!

*1980*

## Катык

Кояш белән бергә кузгалышып,
Киек казлар кебек тезелеп,
Катыкчылар килгән ал таңнарны,
Яшь чакларны сагынам өзелеп.

Яулыклары белән йөзен каплап,
Яшь бер ана — «вожак» артыннан,
Килә иде алар тау ягыннан,
Оялып кына Казан халкыннан.

Алмалы ал көянтәләренә
Элеп калын әбәт чиләген,
Кызыл эчле калошлары белән
Өзмәс өчен язның чирәмен,
Килә иде алар йомшак басып,
Киек казлар кебек тезелеп...
Катыкчылар килгән ал таңнарны,
Яшь чакларны сагынам өзелеп.

Кызлар безгә завод яннарында
Салкын катык салып бирсәләр,
Җиңел булып тоела иде цехта
Сабын туңган авыр плитәләр...

Ә бер көнне завком бүләк иткән
Исле ал сабынны берсенә
Биргән идем, битең юарсың дип,
Үзем кебек сипкеллесенә,—

Шифалымы булды минем сабын,
Сипкелләре әллә беттеме,
Матурланып минем бүләк белән
Кияүгә ул чыгып киттеме?—
Килмәде бу тагын, күренмәде,
Тәмле иде сые бигрәк тә...
Дусларының артларыннан гына
Йөргән бу кыз калды йөрәктә.

Арча ары икән, Чыпчык бире,
Уртасында икән Чүриле...
Әллә Чыпчык, әллә Чүрилене
Уйлап җырлап йөрдем мин тиле:

«Катыкчы кыз нигә килми,
Сыйлап җибәрер идем,
Ә катыгы җылы булса,
Кыйнап җибәрер идем!..»

Шуннан белдем: минем «Гөлҗиһан»ым
Кызның битен ап-ак иткән, ди,
Ялга кайткан яшь шахтерга чыгып,
Миңа рәхмәт әйтеп киткән, ди.

...Кайнар кулдан салкын катык эчкән
Хатирәләр истә бүген дә.
Кызлар биргән дәрман белән яшим
Бәхетле бу картлык көнемдә!

*1981*

## Ышаныч

Җир өстенә кылыч селтәгәндәй
Күкрәү аша яшен чатнады...
Күкри-чатный, яшьни-дөрли шулай
Үтеп китте яшьлек чаклары.

Матур яшьлек! Үкенечле түгел
Яшен кебек яшьнәп үтүең,
Беләм нигә чәчкә чал төшкәнне,
Нигә көмеш сакал үсүен.

Без яшәдек кызларыбыз өчен,
Гайрәт бирдек кыю улларга,
Юл күрсәттек алар иркен сулап
Барырлык киң, якты кырларга.

Сезнең бәхет өчен, яңа буын,
Туры килде барысын эшләргә:
Кан коярга безгә ут эчендә,
Кайнар дары исен иснәргә.

«Ай күрде дә кояш алды» — диеп
Кем дә әйтмәс безгә — картларга.
Ватандашым! Синең белән бергә
Көч җитәрлек әле атларга.

Яшьнәдек без яшь-гайрәтле чакта,
Кичтек утлар-сулар аркылы,—
Бүгенге һәр кыю яшь йөрәктә
Яна безнең йөрәк ялкыны!

*1982*

# Шәүкәт Галиев



*Күренекле шагыйрь, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев 1982 ел өчен Халыкара премия — Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы диплом белән бүләкләнде. Дәрәҗәле диплом аңа 1980 елда Татарстан китап нәшрияты рус телендә бастырып чыгарган «Заяц на зарядке» («Физзарядка ясаучы куян») исемле китабы өчен бирелде.*

*Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча Халыкара жюри тарафыннан ике елга бер тапкыр бирелә торган бу Почетлы диплом — татар совет балалар әдәбиятының зур уңышы турында сөйләүче вакыйга.*

*Бу санда шагыйрьнең балалар өчен яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Урам чатында булган хәл

Урам аша бер абзый
Тиз-тиз йөгереп узды,
Светофорда кызыл ут —
Абзый тәртипне бозды...
Чыгып җитте, дигәндә
Челтерр! итте сыбызгы.

Абзый куйды сискәнеп,
Каранды як-ягына.
Кечтек кенә бер малай
Килә аның янына...
— Әй, син, сыбызгы борын,
Ник сызгыртасың монда!

Килде малай тәз басып:
— Тәртип бозасыз,— диде,
«Тукта», дия кызыл ут,
Ә сез узасыз,— диде.—
Иптәш гражданин абзый,
Юкка кызасыз,— диде.

Кызыл тасма җиңендә —
Пионер тәртип саклый.
Абзый тора аптырап,
Акланырга сүз тапмый.
Светофордай кызарып
Урамнан әкрен атлый...

## Асфальттагы дөнья

Акбур гелме ак була?
Юк шул, төрле чак була:
Күкләргә мансаң әгәр —
Акбур булыр зәп-зәңгәр.
Кояш нурлары төшсә —
Керер ул кызыл төскә.
Ямь-яшел дә булыр ул
Үләннәр белән үссә!

Дәфтәрем минем — урам,
Мин шунда басып торам —
Рәсем ясыйм асфальтка.
Нурулла да, Асфат та
Кояш ясап яталар.
Шатланыша абыйлар,
Сөенәләр апалар.

Маэмай асфальтка керә,
Борынын төртеп өрә:
Жираф, юлбарыс, филләр
Ерак илләрдән килгән,
Җылы урын тапканнар,
Рәсем булып ятканнар!

Санасаң иренмичә —
Кояшлар әллә ничә.
Кай төштә зәңгәр һава,
Кай төштә — бомба ява...
Очалар самолетлар,
Танклар чәчә утлар!

Көннәр гелме ак була?
Җирдә төрле чак була,
Бомбалар төшсә әгәр,
Каралып кала зәңгәр...
Дөнья башына төшсә —
Әверелә ал төскә...
Әнә, аяк астында
Зур бомбалар яталар.
Җитдиләнә абыйлар,
Сискәнәләр апалар...
Без ясаган рәсемнәр
Яңгыр астында калды,
Танк, самолетларны
Җәяүлеләр таптады.
Үтте җиргә сеңдереп
Бомбаларның башыннан —
«И К М Ә К» дигән машина
һәм «С Ө Т» дигән машина!

## Капкада бар усал язу...

«Усал эт бар!»—дип язганнар—
Бик явыздыр, күрәсең,
Умырып алмасын, диеп,
Куркып кына керәсең...

Куркуыңны да онытып,
Елмаясың бераздан:
Дөрес булыр иде, агай,
«Матур эт бар!» — дип язсаң!

## Авылча, бабайча ял...

Авылда торып китим,
Тазарып, ныгып китим,
Спорт яратам бит мин!
Алып кайттым шәһәрдән
Бадминтонны, теннисны,
Эспандерны, гантельне
һәм ике потлы герне!

Бабай боларны күрде,
Бабай кеткелдәп көлде:
— Үсәр бездә мускулың,
Булмас бер дә буш кулың...
Куй боларны читкәрәк,
Менә сәнәк тә кирәк,
Менә балта да чалгы —
Без авылча, бабайча
Оештырырбыз ялны!

## Кыргый мәче

Бик үзгәргән җәйдән соң —
Усал карый очраса,

Сыртын кабартып баса,
Якын китерми — кача.

Өркеп, сагаеп кына
Йөри ул кырыйлардан,
Сөю-сыйпау күрмәгәч
Ничек тиз кыргыйланган...

Бер ялгызын дачада
Күзен ташлап киткәннәр,
Бу дөньяда беркемгә
Ышанмаслык иткәннәр...

## Юл хәрефе

«Казанга!»— дигәч, яшь әтәч
Кикриген чөйде:
«Мондый данлы юл бәхете
Тик миңа тиде!
Минем көчле тавышымны
ишеткән алар,
Үз янына алдырмакчы
Ничек тә алар!»

...Казан ерак түгел иде,
Бик якын иде,
Астында кикрик шикелле
Ут-ялкын иде...

Нишләргә дә белми әтәч
Шом-хәвефеннән:
«Бу казан языла икән
Юл хәрефеннән...»

Үкенгән әтәч, кайгырган,
Тәмам ут янган:
«Ах, дип, кычкырып йөргәнче,
Укыйсы калган!»

## Авторучка тапкан малай

Авторучка тапкан малай.
Бер көтмәгән чакта тапкан.
Сөенечтән алып чапкан —
Ул бит аны көтеп яткан!

Шундый матур, шундый яңа,
Моныңише юк дөньяда,
Нинди тигез, шома яза:
«Ул бит минем авторучка!»

Бераздан ул аптыраштa:
Мин таптым, дип сөенәм дә,
Югалтучы көенә лә!
Ул да аны яраткандыр,
Ялгыш кына югалткандыр.
Шундый матур, шундый яңа,
Моныңише юк дөньяда...

Малай бер бит кәгазь ала,
Рәхәтләнеп игълан яза:
«Авторучка җирдән таптым!
Авторучка кем югалтты?»

## Читлектә аю баласы...

Күрдем читлектә кызганыч
Аю баласын:
«Аю баласы, дускаем,
Ник моңаясың?»

«Йөрисем килә минем дә
Читлексез төштә,
Читлекләргә сыймас урман
Исемә төшә...

«Менмә!»— дигән агачларга
Мин менгән идем,
«Йөрмә!»— дигән чытырманда
Мин йөргән идем.

Тәртипсез, дип, ахры әткәм
Озаттыргандыр...
Әйтегезче, мин бит монда
Озак тормамдыр?

Мин бит хәзер бик тәртипле,
Кайтыймчы илгә,
Әнигә ияреп кенә
Йөрисем килә...»

...Зоопаркта күрдем тагын
Аю баласын,
Көтә һаман әниләре
Килеп аласын...

## Дүрт яшьлек абый

Алар икәүләп
Әнисен көтә —
Кызчык — бер яшьтә,
Абыйсы — дүрттә.

...Электрдан кинәт
Төтен ургылды,
Шундый куркыныч
Ялкын ыргылды!

Борыл да йөгер,
Тизрәк кач кына —
Шкаф артына,
Өстәл астына...

Качар иде дә,
Сеңлесе кайда?
Сеңлесе кала...
Сеңлесе кала!

Ишек артыннан
Тапты да эзләп,
Төтенне ерып
Йөгерде тизрәк!

Бик тә вакытлы
Әйтеп өлгерде —
Күршеләр килеп
Утны сүндерде.

*
* *

Өлкән янгынчы:
— Зур рәхмәт!— диде,—
Өч тәгәрмәчле
Велосипед бирде.

— Сине бик мактап
Сөйләргә була —
«Ут кичкән егет!»
Дияргә була!

## Шәһәр урамнарында

Ай-һай күңелле шәһәр —
Акка күмелде шәһәр!
Шәһәр урамнарында
Авыл бураннары ла:
Җәяү килгәннәр алар,
Кырдан кергәннәр алар,
Урамда уралуны
Кызык күргәннәр алар!

Асфальт юлны тутырып,
Машинага утырып,
Трамвайларга ябышып,
Йөргәннәр шаярышып,
Шәһәр белән танышып.

Ап-ак, ап-ак бураннар
Йортларга уралганнар,
Урамнарга тулганнар.
Югалганнар урамнар —
Танымаслык булганнар!

Морҗаларга чолганып,
Төтен белән болганып
Буранннар да арганнар:
Басылганнар, тынганнар,
Җиргә ятып калганнар.

Иртәрәк шатланганнар...
Иртән ап-ак булганнар,
Кичкә шапшакланганнар:
Корымга уралганнар,
Сөремгә буялганнар —
Шәһәрнеке булганнар...

# Гәрәй Рәхим

## Җирем

И, Җирем син, Җир шарым,
Минем яраткан ярым!..
Мин сиңа карап торам —
Син бит илаһи бер җан.
Син үзеңә туплагансың
Бар Галәмнең уйларын,
Бар җиһанның моңнарын;
Безнең бөтен аһларны,
Аһларны, аһ-зарларны;
Иң олы шатлыкларны,
Иң кече ваклыкларны.

Синдә, тик синдә генә
Бу дөньяның өннәре,
Бөтен рәхәт көннәре,
Газап тулы төннәре;
Зәңгәр тасма Сөннәре;
Афродита сыннары;
Мәхәббәтнең чыннары.
Моңсу-татлы җырлары,
Иңнәреңдә зур таулар,
Илләреңдә зур даулар.
Ракеталардан ут ачарга
Әзер торалар яулар.
Кыл өстендә тетрәп тора
Ничә миллиард җаннар.
Сукма, Җир, сукма чаңнар,
Акмасын янә каннар,
Тетелмәсен ул җаннар.

Без булмасак, кемнәр әйтер
Сиңа дөнья рәхмәтен?!.
Кемнәр татыр ташып торган
Бу дөнья мәшәкатен?!.
Кемнәр язар яшәешнең
Йөрәкләрдә сулгып торган
Рәхәтен, җәрәхәтен?!.
Туймадык рәхәтеңнән,
Ташлама рәхмәтеңнән.

Югалтма син, югалтма,
Болын тулы гөлләрне,
Гөлләр төсле илләрне,
Илләр күрке телләрне;
Иминлекләр теләп искән
Дипломатик җилләрне,
Инде сугыш булмый икән,
Дигән изге сүзләрне.
Шулар өчен канын койган
Асыл җанлы ирләрне.

И, Җирем син, Җир шарым,
Минем бердәнбер ярым.
Галәмнең йөзек кашы,
Дөньяның асыл ташы;
Ай, Кояш, Венераларның —
Җиһанның акыл башы;
Адәм затның бишеге,
Чиксезлекнең киң Галәмгә
Баккан алтын ишеге —
Синдә... Синдә Ватаным,—
Татлы Татарстаным!
Синдә назым — Казаным,
Бөтен җырым, язганым.
Никтер мин гомер сөрүнең
Күрмәм кебек азагын,
Һәм дә үлем газабын.

...И Җирем син, Җир шарым,
Булчы мәңгелек ярым...

## Февраль уртасы

Инде хәзер нидән куркасы —
Килеп җитте Февраль уртасы.
Күптән узды кышның яртысы,
Алда яңа язның балкышы.

Тик алданма, кыш бит үтмәгән,
Явасы кар явып бетмәгән.
Суыклардан чатный буралар —
Алда әле иң зур бураннар.
Әле язның юк бит эзе дә —
Февраль патша ич җир йөзендә.

Тик шулай да, һич юк куркасы,
Февральнең бит инде уртасы!
Кул сузымы гына — март тора,
Анда өр-яңа яз яктыра.
Анда кояш карый бүтәнчә,
Җылыта ул нәкъ без дигәнчә!

Ләкин... Ләкин чынлык бик ачы —
Урамда тик Февраль уртасы.
Тәрәзәләрдә калын боз тора,
Салкын битне өтә, куыра.
Тирә-якта чып-чын кыш әле —
Кыен адәм, җанвар, кош хәле.

Әмма... инде ниләр кылсаң да,
Февраль бетә, ышан-ышанма...
Инде елның шундый ноктасы,
Ни әйтсәң дә — Февраль уртасы.

Әрләмә, дус, чуар күңелең
Сине ике якка тарта, дип,
Я сурәтлә юньләп Февральне,
Яки мактау җырла Мартка, дип.

Бу җырымны яздым гомеремнең
Килеп җиткән мәлдә яртысы...
Гомер уртасы ул — кешенең
Гаҗәбрәк чоры, ахрысы...

●

*— Шагыйрьләрнең гомере нигә кыска була икән?*
*— Сиксәнгә кадәр яшәгән шагыйрьләр дә бар ич.*

Әдәби кичәдә шигырь сөючеләр сөйләшүеннән

Кайсыбыз җитәр сиксәнгә?..
Үлемгә мин «Юк!» дисәм дә,
Ул чикне үтәрмен бер.
Яшәү дигән мәңгелекне
Үлем дигән бер мизгелдә
Алмашып китәрмен бер.

Кайсыбыз җитәр сиксәнгә?..
Мәңгелек түгел дисәң дә
Озын булсын гомерләр.
Тормыш дигән бу учакта
Без чаткы булып очсак та,
Эзсез чаткы түгелләр.

Кайсыбыз җитәр сиксәнгә?..
Яшьтәшләр, сезгә сүзем.
Без — дуслар, дуслар, дисәк тә,
Бөтенегез белән бердәй
Мин дус булмадым үзем.

Ә шулай да барыгыз да
Сиксәнгә җитсен иде.
Бер-ике көн уйлансын да
Туксанга китсен иде.
Мин ышанам, шул ике көн
Уйлатыр әле безне.
Гомергә уйнатмаганны —
Уйнатыр күңелебезне:
Бер-беребез алдындагы

Гонаһлар өчен шунда,
Тезләнеп гафу сорарбыз
Намусыбыз каршында.

Кайсыбыз җитәр сиксәнгә?..
Менә бит сорау кайда!
Гонаһлардан арынырга
Өлгермичә китеп барсак,
Үкенүдән ни файда?!

Кайсыбыз җитәр сиксәнгә?..

## Сабан туе

Сабан туе — авыл туе,
Уйна, гармун, җырла, курай.
Әйттер шуны, әнә шулай —
Сынатма!..
Сабан туе — авыл туе,
Җырла, кияү, бие, килен,
Бии торган көнең бүген —
Һоп!. Һоп-па!..
Сабан туе бер генә,
Күңел ачып йөр генә.

Сабан туе — ярыш туе,
Туп-туп итеп атлар килә,
Тояклардан утлар сибә,
Чаткылар.
Сабан туе — батыр туе,
Көчең булса, күрсәтеп кал,
Күтәреп ал, сыртына сал —
Һоп!.. Һоп-па!..
Сабан туе бер генә,
Батыр булсаң җиң генә.
Сабан туе — хезмәт туе,
Осталыгың, булганлыгың,
Өлгерлегең, уңганлыгың
Югалтма!
Сабан туе — хезмәт туе,
Егет булсаң, шундый бул син,
Кулыңда эш уйнап торсын:
Һоп!.. Һоп-па!..
Сабан туе бер генә,
Истә калсын гомергә —
Уйна, җырла көне буе,
Уртага ук төшеп бие —
Һоп!.. Һоп-па!..

## Автобуста

Нигә миңа карамыйсың, әй, чибәр кыз?!
Мин бит сиңа күзем тутырып карап барам...
Син бик яшь шул, аңламыйсың, йөрәгемдә
Һаман әрни төзәлмәслек яшьлек ярам.

Син ул кызга бик тә охшаш... бик тә охшаш —
Яшьлегемдә гашыйк булган ул кызыйга.
Белсәң иде, никадәрле авыр миңа...
Сине күргәч бөтен җаным тузгый гына.

Мин бит аны бик тә көчле, бик нык сөйдем.
Ул да мине сөймәгәндер миннән кимрәк.
Шулай булгач инде безгә, без икәүгә
Кавышудан башка тагын ниләр кирәк?!.

Юк шул, кызый, ул чагында без яшь идек...
Синең кебек тәҗрибәсез, үсүзләләр,
Мәхәббәттә максималист, ә тормышта
Һәр ялганга, ясалмага ут күзләләр.

Язмыш безнең икебезнең өчен генә
Әзерләгән булса да бер уртак сукмак —

Ул сукмакның уң ягына киткәнмен мин,
Сул ягына киткән ярым, тормый туктап.

Шулай итеп, безнең юллар аерылган...
Ә мәхәббәт йөрәкләрдә яши һаман.
Бер-берсеннән ераклаша-ераклаша
Бер зарядлы ике яшен яшьни һаман.

Ә син кызый, Аңа бик тә, бик тә охшаш...
Сине күргәч бөтен җаным тузгый гына.
Күпме газап, кыенлыклар узды миннән —
Сөю дигән татлы чирем узмый гына.

Бер мизгелгә мин бәхетле булыр идем,
Онытылып торыр иде йөрәк ярам.—
Нигә, нигә карамыйсың, чибәр кызый,
Мин бит сиңа томырылып карап барам.

## Күкләрдән

Күкләрдән килеп ява яңгырлар,
Күкләрдән агыла яп-якты нурлар.
Бөеклеккә оеп, калгып торам мин —
Күкләрдән иңә илаһи уйлар.

## Тирмәләр һәм төрмәләр

Борынгыда, надан чакларында
Тезгән кеше биксез тирмәләр.
Акыл кергәч, ясый башлаган ул
Мең йозаклы тимер төрмәләр.

## Тураймаслык булып

Тураймаслык булып бөгелсә уйларың —
Дошманыңа атарга син җәя яса.
Бу җәяң һичшиксез берәүгә кирәгер —
Син үзең дә кемгәдер дошман ласа.

## Җәйнең соңгы көне

Соңгы тапкыр кошлар сайрады
Моңга күмеп таллар арасын.
Кошлар әйтте безнең бу очрашу
Бер хатирә булып каласын.

Инде җәйнең соңгы көне иде.
Безгә рәхәт тә иде, кыен да...
Җәйнең соңгы көне иде
Аккош күле буенда.

Җилләр моңсу итеп истеләр...
Саргылт төсләр кунды үләнгә.
Күзләремә сөеп карадың син,
Сагынмаклык булсын дигәндәй.

Ничә еллар буе сагынам
Шул җәйнең шул соңгы мизгелен.
Онытмадым сине, син бит минем
Күз дә сулмый торган үз гөлем.

Ә ул көнне җәйнең соңы иде.
Безгә рәхәт иде... кыен да...
Җәйнең соңгы көне иде инде
Аккош күле буенда.

Флера Гыйззэтуллина

# ДҮРТ КЫЗ

ПОЭМА

*Кызларның камыш биле.*
*Кагылма, сугыш җиле!*

## Ул еллар

...Халыкчан матурлык, халыкчан батырлык —
Зур яшьлек ул эзсез каламы?—
...Уемда — Карурман!— Каршыдан — Сырхабә![1]
Каршыда — Мирсәет аланы!

Әнә шул урманга, әнә шул аланга
Хәзер дә һәрьяклап юл ачык...
Карурман хәлләрен төшендек, белдек без
Урманның үзеннән сорашып.

Әсәйне[2] ничә кат уратып килсәк тә,
Урман гел сөйләде дөресен...
Олаулар артыннан озата җибәрде,
Улатып бер көтү бүресен.

Бүреләр — канечкеч! Бүреләр — ерткычлар,
Ә фашист — ерткычның ерткычы!
...Моңнарда ятлана, тыннарга каплана
Сугышның чатнама дүрт кышы.
Дүрт кыш һәм берочтан атасыз дүрт ятим
Хәтердә, хисләрдә терелә...

Сагышлы, шәфкатьсез җилләргә йөз куеп,
Бер төркем атлылар үр менә.

Бер төркем атлылар! Иң алда Рәйхана!
Чанада печәне — ат-яллык!..
Рәйхана ат каулый; кара шәл астыннан
Маңгаен балкыта ак яулык.

---

[1] Сырхабә — сырхау һәм сугыш җиле. Ваба җиле (халыктан).
[2] Әсәй — авыл исеме.

Ул чакта ак яулык, кара шәл модада!
Мода ул түгәллек ярата.
Модасын китереп, җил улый үкереп:
Таң ата, урманда таң ата.

Уйласаң: авылның җан көче — без икән!
Түз икән, яшь килсә күзеңнән!
...Чаналар шуыша, заманнар шуыша
Тарихи шул еллар эзеннән.

## Бишмәт хикмәте

Тарихлар түреннән, чаналар төбеннән
Ажгырып куба да Сырхабә,
Гел безгә сырыша, калмаска тырыша
Язмыш кай ярларга бәрсә дә.
Гел генә колакта бер чинау, бер сорау:
— Әйт, кызый, кемнеке бу сырмаң?—
Атыңны, йөгеңне, сырмаңны бирмәсәң,
Дөньяңны юк итәм — очырам!
Фашистлар, вәхшиләр ил талый, җан талый,
Җил талый өстәге бишмәтне...
Тик дуслар, «иске» дип, исегез китмәсен!
Ул бишмәт әкәмәт хикмәтле.
Ул бишмәт нибары бер сыңар балаклы
Табылдык чалбардан тегелгән!
Кемнәрнең кайларда нинди зур яуларда
Аяксыз калганын кем белгән!
Очраган, тапканны, җиң, гәүдә сапканны
Җилдәнме — кем кемнән яшергән?..
Нужаны нахакка күтәртте җил-дошман
Халыктан — картыннан-яшеннән.
Ситсаның яңасы булмагач тегәргә
Яшь, зифа буй-сынга үлчәтеп,
Искене яңартып кидек тә йорт саен
Йөрдек без яңалык күрсәтеп...
Ихата-йорт саен йөреде Сырхабә —
Авышты җил каккан коймалар:
— Әминнәр, Әюпләр сырхауга сабышты...
Мәетләр сакларга куна бар!
Унарлап, йөзәрләп саналды авылда
Ятимнәр һәм толлар исеме...
Өйләрдән өйләргә хәл сорап кергәндә,
Шакыла тәрәзә, ишеге.
Ишектән каршыга чыксалар, сүз әзер:
— Урманга китәбез, ярармы?!.
Чатнаулы башларны, ярар, дип идек без,
Белсәк тә борыннар канарны,
Халыкта мәкаль бар: «дошманың каршында
Белдермә, йотсаң да кара кан!..»
Елата-юата, йокыдан уята
Кайгыга камалган кара таң.
Ул таң — ил сагышы! Ул таң — йөз сарысы!—
Әрнешнең гомерлек җирлеге!
...Гомерләр үреннән, урманнар түреннән

Ачылды урамнар киңлеге.
Безнең күз ачылды — хезмәткә чакырган
Илдәге чыдамлык, түземнән.
...Чаналар шуыша, заманнар шуыша
Тарихи шул еллар эзеннән.

## Олылап туасы таң хакын

Яшьлекнең хаклыгын туган ил каршында
Кирәксә яңадан акларга,
Карурман эченнән без дәррәү чыгарбыз
Төялеп җигүле атларга.
Ил-көнгә иминлек, бәрәкәт юрарбыз!
Урарбыз урманның кышкысын.

...Гармундай сыздырып, җил-буран туздырып
Рәйхана сайрата пычкысын.
Рәйхана кычкыра:— Каенны аударам!—
Кайгыдан аумагыз, карагыз!!!

...Билдән кар!— Кар упты.
Аудык та, калыктык.
Калыкты атыбыз, чанабыз.
Сырхаулар азынды — безгә юл сузачак
Таңнарын томалап дөньяның...
Шул таңнар аша без дөньяга күз салып
Аңладык яралы ил җанын.
Мин һаман әнә шул олы җан ачысын
Дошманга нәфрәттә кулланам:
Тормышлар — нужасыз, алышлар — корбансыз,
Күңелләр моң-зарсыз булмаган...
Бабамның булмаган бер сыңар аягы.
Уң кулда булмаган биш бармак...
Җәзалап өзелгән биш бармак хакында
Аланда көй суза биш нарат.
Наратлар таң сулый, бармаклар җан сорый.
Яшьлегем, син дә бер сораштыр!—
Ихтимал, минем бу хикмәтле бишмәтем
Бабамнан — Сәеттән мирастыр?..
Урманчы кәсебен яшүсмер чагымнан
Нәселемә йөклимдер мин шуңар:
Ирек һәм эш эзләп таң белән кузгалган
Бабамнар — борынгы юлчылар.
Бабамнар да минем бар көчкә куганнар
Нужаның җигелгән пар атын...
Бердәнбер аллага гыйбадәт кылганнар
Олылап туасы таң хакын.
Үзе бер хокуксыз ярлы җан булса да,
Булса да Сәет карт чи надан,
Михнәтле халыкны карурман эченә
Наратлы аланга җыйнаган.
Гармунда уйнаган, моңаеп җырлаган;
Урыны, җыр-моңы — уртада!
Наратлар сыкрана, каеннар сыкрана:
— Мирсәет, туктама! Туктама!

— Мирсәет, туктама!!!— әйтерсең бу тавыш
Каеннар чугына үрелгән.

...Бабамнар сагышы, әткәмнәр тавышы
Туган ил моңына әверелгән.

...Берләшкән шул моңны мең тәрдә тибрәтеп
Акылдан шашканмы Мирсәет?
Юк! Ихлас күңелдән Ленинны көткән ул:
«Көрәшкә өйрәтер, килсә»,— дип.
Ленинчыл көрәшләр, ленинчыл җиңүләр
Юл алган урманга турыдан.
Безнең дә хезмәтне зур итте шул юла!
Шул йола — бер алла, бер иман!
...Иман — бер! Без — дүрт кыз! Яшьлектән дүрт очкын!
Пычкылы дүрт нәни урманчы!
«Ачлык!» — дип тормадык, «Буран» — дип тормадык:
Җырладык күңелләр тулганчы.

Җырның да, эшнең дә нормасын тутырдык:
Утырдык дүртебез дүрт атка...
Кыш чыккач салынып мәктәпкә, клубка
Буралык наратлар — Норлатта!
Без барып кунасы фатир да Норлатта.
Җылымы ул фатир — сорашма!
Казанда пар бөркеп, быкырдап аш кайный:
Тоз каян алырга ул ашка?
Бу юлы — тоз юкка Рәйхана гаепле:
Тозын ул төп йортта оныткан!
Яз җитсә, ел тула ишеген-тәрәзен
Кадаклап чыкканга ул йорттан.

Ел тула — бригадта өйдәшлек иткәнгә,
Юл йөреп киткәнгә Норлатка...
Камыты тузса да, дугасы сынса да,
Кыз-хатын инәлә ир-атка.
Ә ир-ат дигәнең — яралы ярты җан:
Я кулсыз, я култык таяклы!
Кул эшкә ятмауга, киткәннәр кайтмауга,
Әйтерсең, яшь кызлар җаваплы!

Әйтерсең, урманга без качып китәбез
Бригадта почмаклар тарлыктан!
Бригадта бау ишкән яралы «конюх»ның
Тавышы сугышта карлыккан.
Яраның сызлавы, тавышның гыжлавы
Тагын да көчәя кичкырын...
Бригадның шул өе сыйдырды үзенә
Сугышның дәһшәтле дүрт елын.
Морҗада дистәләп күшеккән кул булды,
Бригада мичләре ягылса!—
Тиз генә җылын да ат эчер, тирес түк!—
Эше күп, кешесе табылса.
Эш йөкләр һәр язмыш — катлаулы табышмак!
Серенә тапкырлык белән үт!..
Тапкыр сүз кирәксә, Рәйхана һичкайчан
Кермәде күршегә теләнеп.
Ә менә ипи-тоз хакына килгәндә —

Муеннан батты ул бурычка.
Тагын шул тырышкан кадәрле тырышса
Бурычлар түләнер бу кышта.
Бурычлар түләнер кайтмасаң — эш йөкләп
Алынган антыңнан, сүзеңнән!

...Чаналар шуыша, заманнар шуыша
Тарихи шул еллар эзеннән.

## Әткәем ут аша хәлемне сораша

Җил-давыл хакында, сугышлар хакында
Тарихта күпме сүз сөйләнгән!
Без дүрт кыз — берочтан көрәшчән, сугышчан!—
Киләбез тарихтан, тирәннән.
Без — дүрт кыз: Рәйхана! Рәсимә! Банат! Мин!
Каршыдан шәфкатьсез Сырхабә!—
Йөзләрне сагышлый: ул бездән калышмый,
Язмыш кай ярларга бәрсә дә.

Сагышлы, каргышлы ул сугыш җиленә
Иң элек Рәйхана камала.


...Бишмәтләр ямала... модалар яңара!
Исәннәр — арада! Арада!
Исәннәр хезмәткә, Җиңүгә табына
Бүреләр табына улауга...
Сөйгәннәр кайдадыр? Кемнәргә файдадыр:
Каеннар-кайгылар — олауда!
Их, безне көтәргә, олауны этәргә
Дүрт кызга булса бер ир-егет!..
— Егетләр! Егетләр! Соңгы кат күрик!— дип,
Йөгердек, булмады өлгереп.
Алар да ауганды́р, без кискән каендай
Карларга йөзтүбән капланып.

Шуңадыр ак сынлы каеннар образын
Хәтердә без сөеп сакладык.
Ә безне карурман хәвефтән саклады.
Карурман — безнең җыр төбәге!
Ыржайган тешләре шакырдап сынса да,
Безгә ул бүреләр тимәде.

Ач бүре өере, буранга күмелеп,
Үрләргә чигенеп торганда,
Бар дәртне, кодрәтне җыр-моңга кордык та
Без «десант төшердек» урманга.
Һәр төшкән сукмагым, һәр кискән агачым
Билгеле, өлгеле, чамалы!
...Әткәйләр — фронтта, без монда — урманда —
Десантлар, аталы-балалы.
Хыяллар очканда, каеннар кочканда
Яшьлегем — канатлы парашют!
Әткәем ут аша хәлемне сораша,
Урманда калынса адашып.
Гүрләргә кергәч тә, ил-бала кайгысы
Бирмидер атага тынгылык...

Һәр җирдә батырлар һәйкәле өстенә
Мәңгелек иңәдер моң булып.
Әткәмнән, бабамнан күчкән моң мәңгегә
Безне хөр яшәргә өндәде.—
Хезмәткә тумыштан тугрылык тудырган
Ленинчыл антыбыз — көндәге.
Бу җирдә көндәлек һәр эшкә, көрәшкә
Халыктан бар кадер, бар ул сан!..
Ялкыны алланып шәфәкъкә иңәчәк,
Утынны кадергә яндырсаң...
Кич чыра яндырсаң, булачак кайнанаң
Ут сорап киләчәк бу кичкә...
Чыралар телсәк без, кызганып телмәдек,
Ут бирсәк — бирмәдек үтечкә!
Ут бирсәк кисәттек:— Бу утта тормыш бар!
Сулыш бар! Хуш исле ылыс бар!..
...Туксанга түнә йөк: көннән-көн күбәеп,
Йөкләнә иңнәргә бурычлар.
Көннән-көн өр-яңа карарын чыгара
Бригада, идарә, сельсовет...
Бер безнең авылдан гына да сугышка
Юл алды ничәмә Мирсәет!
Сәетләр югалмас! Кыйбласын югалтмас
Олаулы, юлаулы урманым!..
Таң ата... Бу таңда:— Җиңү! дип, Хаклык!..— дип
Бар көчкә дәшүе дөньяның.

Таң ата — урманда без кулда уйнаткан
Пычкылар, балталар йөзеннән!
...Чаналар шуыша, заманнар шуыша
Тарихи шул еллар эзеннән.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

## Риза Ишморат

# И МӨКАТДӘС, МОҢЛЫ САЗЫМ...

**ДРАМАТИК ПОВЕСТЬ**

**Ике бүлектә**

КАТНАШАЛАР:

Т у к а й — Габдулла Тукай.
К а м а л — Галиәсгар Камал.
Ф а т и х — Фатих Әмирхан.
Р ә м и — Сәгыйть Рәмиев.
С ә г ы й т ь — Сәгыйть Сүнчәләй.
Р ә ф ы й к — Рәфыйк Акбирдин—шпик, әдәбият тирәсендә чуалучы.
З ә й т ү н ә — Тукайның сөйгәне.
С у ф и я — врач, Гафур Колахметовның сеңелесе.
С ә л ә х и бай.
Җ ә м и л ә — Сәләхи байдагы асрау кыз.
Н у р г а л и — Тукайның танышы, жырчы егет.
М ә р ф у г а апа — хуҗа хатын.
Д у б а с о в — жандармерия идарәсе начальнигы, полковник.
Б ы к о в — жандармерия капитаны.
А н а — Тукайның әнисе
Б а л а — Кечкенә Тукай
К у р а й ч ы б а б а й
(Тукайның хыялындагы образлар.)
Ш ә м ә т — сукбай, соңрак йөк ташучы.
Р ә х м ә й — Тукайның якташы, япон сугышы солдаты.

### Пролог

**Пәрдә алды. Пәрдә аша шәһәр, мәчет, өйләр, кешеләр күренә. Көчле җил. Давыл. Караңгылыкны ярып, яшен ялтырый. Болыт агыла. Тавышлар. «Марсельеза» һәм «Тукай маршы» яңгырый.**

— Лә иләһә иллә лла! Аллаһу, бисмиллаһу!
— Гарасат! Мәхшәр!

Н у р г а л и *(пәрдә алдыннан йөгереп уза).* Яшен! Яшен уты!

**Артта факелчылар уза. Тукай, Камал, Рәми, Фатих, Акбирдин.**

Ф а к е л ч ы л а р. Иң бөек максат безем—
хөр мәмләкәт, хөр Россия! Хөр Россия!
Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Ул тормыштан илгә файда юк...

Н у р г а л и *(кереп).* Яшен! Яшен уты!
Бай абзыйлар, ишан, хәзрәт һәм хаҗилар,

сакланыгыз! Яшен ташы! Шагыйрь Тукай язган «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» бу!

**Күк күкри, яшен яшьни.**

Факелчылар *(артта)*. Хөр мәмләкәт! Хөр Русия!

— Лә илаһә илләллә!.. Аллаһу, бисмилләһу!

— Боже, царя храни!..

Нургали *(алгы якта)*. Абзыкайлар, түтәйләр! Әбиләр һәм бабайлар! Менә сезгә шәп товар. Дөньяда юк, миндә бар. *(Кашык сугып җырлый.)*

Ни кылырсың, хажи абзам,
тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там,
тотса мәскәүләр якаң?
Сыгмас ирдең киң җиһанга,
малыңа мәгърур булып,
Даже в тюрьму сыярсың,
тотса мәскәүләр якаң.
*(Кашык сугып бии.)*

Тратта-тат-та,
Тратта-та, тарра-тит-та-та-там.

Артта: Хөр мәмләкәт, хөр Русия!

Сәләхи *(керә)*. Утерәм!.. *(Гали өегерә.)*

Артта: Хөр мәмләкәт, хөр Русия.

Сәләхи. Тотыгыз, тот, явызны!

**Күк күкри. Яшен. Давыл көчәя. Утлы, шау-шулы хәлләрдән соң тынлык урнаша. Сәхнә караңгылана. Бераздан, иртәнге шәфәкъне хәтерләтеп, алсу таң сызыла.**

## Беренче бүлек

### I

**Моңсу музыка: «Моңлы сазым» җыры ишетелә. Аргы Кабан күле буе. Кечкенә өй. Агачлар. Куаклык. Мәрфуга тышкы якта кемнәрнедер көтә.**

Суфия *(өйдән чыгып)*. Фатих абыйның авыруы куркыныч ук түгел, Мәрфуга апа. Ул сәламәтләнәчәк.

Мәрфуга. Мин дә шулай дип уйлыйм, Суфия сеңелем.

Суфия. Дару алу өчен рецепт язып калдырдым. *(Әкрен.)* Доктор Ямашев авыруның хәлен белергә кемнәр киләсен әйткәндер бит?

Мәрфуга. Әйтте.

Суфия. Галиәсгар ага Камал килгән дә инде.

Мәрфуга. Ул — тәгәллекне ярата торган кеше.

Суфия. Башкалар да озакламас. Ямашев та нәкъ үзе билгеләгән вакытка килеп җитәчәк.

Мәрфуга. Анысын беләм, Суфия сеңлем.

Суфия. Ят кешеләр килеп чыга калса, Фатих әфәнде нык сырхаулап тора дип, кертмәскә тырыш.

Мәрфуга. Беләм. Иншалла, чарасын табармын.

Суфия. Ышанам, Мәрфуга апа, син — дөнья күргән хатын.

Мәрфуга *(озата барып)*. Хөсәен духтырың өчен тыныч бул.

Суфия. Тыныч, тыныч, Мәрфуга апа. Беләм ич мин — син яхшы күңелле, ышанычлы... *(Кочаклый.)* Хуш! *(Кызу гына чыгып китә.)*

Мәрфуга *(паузадан соң)*. Уһу-һу... Авыр заманнар. Ярабби, үзең ярдәм бир. Явыз кешеләрдән сакла. Кадыйр кисәтеп әйтте: күзеңне ачык тот, изге юлда йөрүче кешеләрнең язмышы тапшырылган сиңа, диде. *(Як-ягына карана.)*

Рәми *(кереп)*. Исәнмесез, Мәрфуга апа?

Мәрфуга. Исәнме, туганым? *(Текәлеп карый.)*

Рәми. Фатих авырый дип ишеткән идем...

Мәрфуга. Авырый, туганым, хәлен белергә килсәң, рәхим ит.

**Рәми өйгә керә. Аның артыннан Акбирдин керә.**

Мәрфуга *(сынап карый)*. Рәфыйк дисәм...

Акбирдин. Үзе, Мәрфуга апа, Акбирдин. Онытмагансың. Фатих дустыбыз авырый дип ишеттем.

Мәрфуга. Авырып тора шул ул, туганым. Әйдә уз!

Акбирдин. Ямаш үзе биредәдер бит?

Мәрфуга. Кем дидең?!

Акбирдин. Шикләнмә, Мәрфуга апа. Мин — үз кеше. *(Керeп китә.)*

Хор: Очты дөнья читлегеннән тарсынып
күңлем кошы,

Шат яратса да, жиһанга
ят яраткан раббысы.

Т у к а й *(керeп)*. Исәнме, Мәрфуга апа.

М ә р ф у г а. Исәнме, Габдулла туганым.

Т у к а й. Фатих авырый дип ишеттем.

М ә р ф у г а. Шулайрак шул, туганым.

Т у к а й. Кадыйр абзыйның ни хәлләре бар?

М ә р ф у г а. Һаман каравылда. Заводта имгәнеп чыккач, шулайрак шул инде. Инсәсе зәгыйфь булса да, күзе күргәч, эшли һаман. Бер кулында шакылдавык, бер кулында синең китап, укый-укый да кет-кет көлә, кайчак күзләреннән яше тама. Рәхмәтләр яусын сиңа, раббым алла гомер бирсен.

Т у к а й. Рәхмәт, Мәрфуга апа... Завод белән арасын өзгәне юк әлләйсә?

М ә р ф у г а. И-и, үзәме соң, бергә эшләгән дус-ишләре, Кадыйр абзый, дип, аһ итеп тора. Берсе килмәсә, икенчесе килә.

К а м а л *(ишекне ачып)*. Тукай!.. *(Ымлый.)*

Т у к а й. Хәзер!.. *(Өйгә керeп китә.)*

## II

**Өй эче. Гади генә җиһазлар, уртада махсус эшләнгән креслода, өстенә ак ефәк күлмәк кигән, куе кара чәчләрен матур итеп тараган Фатих Әмирхан. Аның тирәсендә — «авыру» янына килгән Камал, Рәми, Акбирдин, Тукай.**

Ф а т и х *(бөтен гәүдәсе белән күтәрелеп)*. Юк! Мең мәртәбә юк! Без ят кешеләр түгел!!! Ят кеше дигән фикерне бөтен вөҗүдем белән кире кагам! Без — дөньяның да, Россиянең дә үз кешеләре! Максатыбыз: хөр мәмләкәт! Хөр Россия! Халкыбыз, милләтебез азатлыгы! Әмма ләкин без милләтчеләр түгел. Кайберәүләр кебек Аксак Тимер түккән кан, харап иткән шәһәрләр белән мактану безнең өчен хурлык! Татар исеме белән йөртелгән халкыбыз өчен иң мәтлубы[1] — Азиянең борынгы вәхшиләрен сагыну түгел, заманыбыз идеалларын, культурасын үзләштерү, шуңа омтылу.

К а м а л *(ишеккә карап алып)*. Ләкин безне монда җыйнаган хәл... синең авыру.

Ф а т и х. Кашки шулай гына булса икән! Иң куркынычы, барыбызның да авыруга дучар булуы. Тукайның сыкрануы, Рәминең сызлануы, Камалның «Яшен» журналы туктатылгач, сөмсере коелуы, ялкынлы журналистыбыз Акбирдинның сыгылып төшүе...

К а м а л. «Урал» газетасы туктатылгач, хәтта корыч ихтыярлы Хөсәен Ямашның да борыны салынды.

Ф а т и х. Ләкин ул үзен югалтмады, сыкранмый, хәер, килгәч үзе турында үзе сөйләр...

А к б и р д и н. Үзеңне дә читтә калдырма, Фатих абзый.

Ф а т и х. Яшермим, мин дә гомуми атмосферага бирелми кала алмадым. Бишенче еллардан соң сезне агулаган тынчу һава миңа да йогынты ясамый калмады. Барыбызга да бүген олы максатыбызга дөрес юл табу турында уйларга кирәк. Сизенәсездер, илебездә кара чор үтеп бара.

Т у к а й. Бик акрын.

Ф а т и х. Шулай да үтеп бара. Реакциягә каршы яңа көчләр күтәрелә. Зур, ныклы көч! Ә без — милләтебез факелчылары — шул көчкә кушылып, халкыбызны да чакыру урынына җылыйбыз, сыкранабыз. *(Тукайга карап.)* Үзем сүнәм, сазым сына, имеш, мин — җиһанда ят кеше!.. Рәминең бөтенләй коточкыч! Алдандым, имеш, үләм! Беттем, бетәм!

Р ә м и *(зәһәр белән)*. Юкка битәрлисең, Фатих! Кайда ул син сөйләгән көч? Төн һаман караңгы! Бөтен җирдә зобанилар караулый! *(Үзлегеннән чыгып, ачынып җырлый.)*

Әй сез, зобанилар!
Караулагыз теләгәнчә, мин барыбер
качалмыйм.
Бик шат качар идем дә шул,
Эх! Богауларны ачалмыйм!

*(Тыңлап.)* Нигә акайдыгыз? Әйтегез нишләргә икәнен...

Ф а т и х *(тәрәзә пәрдәсен күтәреп)*. Әнә Хөсәен дә килеп җитте!

К а м а л. Самавыр кайнап чыкканны гына көткән икән.

А к б и р д и н. Акыллы! Вакытын белеп йөри.

**Кунакларның күзләре ишеккә.**

**Картина алмашына.**

---

[1] Мәтлүб — иң кирәге мәгънәсендә.

## III

**Жандармерия идарәсе. Николай Романов рәсеме һәм башка җиһазлар. Ашыгып, Дубасов килеп керә. Папкасын өстәлгә ташлап, базык гәүдәсен көчкә күтәреп, кызу-кызу йөренә башлый. Кайбер сүзләрне әйткәндә, теле тотлыга.**

Дубасов. Барын да кырып бетердек, калганнары тез чүкте, буйсынды, дип уйлаган идек тә, юк, хәтәр ут сүнеп бетмәгән. Тагын баш күтәрергә азаплана черно. Русы-татары барысы бергә. Азиатлар! Завод, фабрика, университет, мәдрәсә, гимназия... Тагын черт белсен кайда... *(Кыңгырау шалтырата.)* Хөсәен Ямашев бер бала булса, без йолкыш шәкерт дип уйлаган Тукайлары — үзе йөз бала!

**Мәһабәт гәүдәле, озын мыеклы капитан Быков керә.**

Быков. Беренче номер папкалар. *(Өстәлгә куя.)*

Дубасов. Өч көн элек Питердан бер социал-демократ килеп, Казанда булып киткән. Ниндидер яшерен йомыш башкарып. Ни-нигә ул турыда безгә мәгълүм түгел? А-а... Гады! Болытлар тагын куера. Яшен, давылның көчлерәк булуы мөмкин. Донбасс, Баку, Урал, Себер якларында эшчеләр туплана. Яшерен генә коралланалар... Ә бездә хәлләр ничек? Белмибез. Питердан килгән социалистлар кайда, нишлиләр? Күрмибез... Ямашев, үз тирәсенә бөтен татар литераторларын туплап, дөньяны айкарга җыена. Ту-ту-кай, Камал, Әмирханнар тагын күк күкрәтеп, яшен яшьнәтмәкче...

Быков. Эн-юк! Не позволим!

Дубасов. Алар рөхсәт сорап тормаячак.

Быков. Ул чакта беспощадно...

Дубасов. Ашыкма!.. Ду-ду-дума заманы.

Быков. Россияне үз кулында тоткан бөек император ике Думаны куды, өченчесен дә, дүртенчесен дә куар...

Дубасов. Нәрсә ул Дума... Балаган! Большевиклар әнә бөтен Россия патшалыгын — бөтен Думаларын төбе-тамыры белән актарып ташлаячакбыз дип әйтәләр, ди.

Быков. Ә?!. Хо-х! Ашыкмасыннар!

Дубасов. Сез артык дорфа. Заманны, кемнәр белән көрәшкәнне аңламыйсыз. А-а-акыл кирәк бүген безгә. Дошманны бөтен нечкәлеге белән белергә кирәк. Теориясен, тактикасын, кемнәргә таянып эш итә алар. Казан — большевикларның нык таралган җире. Бүген ул татарларга да йогып бара. Аның интеллигенциясенә. Ә бу куркыныч. «Ха-халык дуслары»н биргән идем. Укыдыгызмы?

Быков. Укыдым.

Дубасов. Беләсезме авторы кем?

Быков. Үзебезнең Казан студенты. Террорист Ульяновның энесе.

Дубасов. А-а-абыйсы патшаның үзенә генә һөҗүм иткән булса, энесе Владимир бөтен җәмгыятебезнең астын-өскә китерергә, барыбызны себереп түгәргә җыена.

Быков. Господи, помилуй... *(Чукына.)*

Дубасов. Капитан, сез күбрәк күкләргә түгел, үзегезгә ышаныгыз. Ямашев нәкъ шул Ульянов партиясендә.

Быков. Тукай, Камал, Рәмиев. Эн-юк! Инде каптылар кармакка. *(Папкаларга сугып.)* Кичә Ямашев аларны аргы Кабанга җыйнаган. Аяксыз Әмирханов яшәгән дачага.

Дубасов. Так, так. Я?

Быков. Рәмиевне чакырттым. Тиздән килергә тиеш.

Дубасов. Бик яхшы.

Быков *(сәгатенә карап)*. Ул интеллигент. Төгәллекне ярата...

Дубасов. Төгәллеген безгә бик күрсәтми. Патша белән аллага җикеренергә түгел, табынырга кирәген аңламый. Аңлатырбыз. *(Быков биргән язуга күз йөртеп.)* Син оста шагыйрь булсаң, без үз эшебездә оста.

Быков. Точно!

Дубасов. Тагын шул: бөек Романовлар династиясенең патшалык итә башлавына өч йөз ел тулу уңае белән зур юбилей үткәреләчәк. Шуңа кадәр без бөтен шакшыдан, төрле татарва чиреннән, аеруча бо-бо-большевиклар заразасыннан арынырга тиешбез. Пе-петербургның указы шулай.

Быков. Указ точно үтәлер, господин полковник. *(Чыга, аннан кире керем.)* Рәмиев килде.

Дубасов. Әйтегез, керсен!

Быков *(папканы күрсәтеп)*. Бирелә яхшы ук тулы язылган. Акбүрене иртәгә чакырачакмын. *(Китә.)*

Дубасов *(көзге алдында)*. Мм! Рәмиев? Ха...

Рәми *(керә)*. Рөхсәт итегез!

Дубасов. О-у, рәхим итегез. Сагыйть

Лотфуллович. Купме айлар сезне, шагыйрьләр патшасын, күргән юк.

Рәми. Артык күтәрәсез мине, Николай Николаевич.

Дубасов. Мин генә түгел, халык күтәрә. Тәнкыйтьчеләр.

Рәми. Шагыйрьләрнең миннән өстенрәкләре дә бар. Мәсәлән, Тукай.

Дубасов. Тукай?! Юк! Үзегезне кимсетмәгез. Тәнкыйтьчеләр хәтта аны шагыйрь түгел, диләр. Бары тик стихоплет, ка-ка-как говорят у вас — такмакчы.

Рәми. Шулай да шигыре халык күңелендә, халык телендә.

Дубасов. Тукай бүген сүнде инде. Сынды аның сазы. Сез әле һаман гөрлисез...

Рәми. Минем дә иҗатым сүрелде бүген. Сүнде!

Дубасов. Сүнде?! Сезнең бөтенләй башка. Кайбер хәлләр нәтиҗәсендә рухыгыз төшкән икән... Бу табигый хәл.

Рәми. Шулай да авыр минем өчен.

Дубасов. Аңлыйм. Үзегезнең уткәнегезне сагынасыз. Аллага, патшаларга каршы... җикеренгән чорыгызны.

Рәми. Сагынам!

Дубасов. Төрмәдә дә социал-демократ Горькийның революцион рухтагы җырын тәрҗемә иттегез!

Рәми. Иттем.

Дубасов. Браво! Мактыйм кыюларны. Ләкин ул көннәр үтте. Алла белән патша өстен булып калды. Сез дә кылган гөнаһларыгыз өчен тәүбә иттегез.

Рәми. Бүген ни белән бурычлымын сезгә?

Дубасов. Ярый, эшкә күчик. Кичә Ямашев сезне, Тукай, Камал, Акбирдин әфәнделәрне Әмирхан дачасына чәй мәҗлесенә чакырган. Дөресме?

Рәми. Дөрес. Тик сезгә бирелгән информациядә хата бар.

Дубасов. Хата? Я, я?

Рәми. Беренчедән, Ямашев чакырмады. Икенчедән, чәйгә түгел, ә авыру Фатих әфәндене хәлен белергә бардым.

Дубасов. Бардым түгел, бардыгыз!

Рәми. Мин үзем генә.

Дубасов. Билгеле. Ялгыз, ялгыз... Ямашев та...

Рәми. Ул — Фатихның дусты. Авыру икәнен ишеткәч үк килеп җиткән. Ләкин озак тормады. Авыру белән күрешеп, хәлен белде дә ашыгып китеп тә барды.

Дубасов. Башкалар белән сөйләшмичә үк?

Рәми. Сөйләште: хәл-әхвәлләребезне сорашты.

Дубасов. Нинди дә киңәшләр, күрсәтмәләр бирде...

Рәми. Әйе, әйе...

Дубасов. Я, я? Нинди киңәш, мәсәлән?

Рәми. Борынгызны салындырмагыз, диде. Фатих дустыбыз терелачәк, ул әле тагын да элекке дәрт белән иҗат итәчәк, диде. И... китеп барды.

Дубасов. По-по-подлец!

Рәми. Улмы?

Дубасов. Курчак уены уйнамагыз, господин Рәмиев!

Рәми. Сез артык шаян, Николай Николаевич.

Дубасов. Ша-ша-шаян? Ха-ха-ха! Характерымны дөрес аңлыйсыз. Шаяра-шаяра сезне дарга да астырачакмын!

Рәми. Нәрсә әйтим. Сезнең алда мин көчсез. Бәлага тарган башымны алып, беркая да кача алмыйм. Шуңа карата күңелемдә бернечә юл шигырем йөри.

Дубасов. Анысын да тыңлап карыйк.

Рәми. Очрыймсың бәлаләргә,
башым, очра,
Чыгарсың бер бәлки барып очына.
Хак тәгалә әйткән үзенең
корьәнендә:
«Иннә мөгал гөсри йосра-
гөсри йосра».

Дубасов. Ничек, ничек?.. Соңгы юлы?

Рәми. Һәрбер кайгы-хәсрәттән соң шатлык килә.

Дубасов. Һәм сез шул шатлыкны көтәсез?

Рәми. Кайгыга караганда һәркайсыбыз шатлыкны ярата.

Дубасов. Шатлык патшага турылыклы хезмәт аркасында гына киләчәк. Монархия — Россия өчен алтын багана. Аны какшатмас өчен без бөтен чараны күрергә тиешбез. Тагын бер сорау: кем ул Тукай?

Рәми. Тукай?! Минем кебек үк шагыйрь.

Дубасов. Сезнең кебек үк? Алайса ни өчен сез түгел, ул күбрәк айкый халык күңелен? Бөтен җирдә Тукай, Тукай!..

Рәми *(ирония белән)*. Мин — күкләргә ашкан талант! Ә ул кем? Гади җырчы. Халык ни уйлый, ни тоя, шуны яза. Халык көлсә — көлә, җыласа — җылый, җырларын көлтәләп кенә сибеп тора. Мөгътәбәр татар байның, ишаны, хаҗие кебек галиҗәнапларының күкрәгенә кадала торганнарын...

Дубасов. Шулай ук ул сезнең дә дошманыгыз, куркыныч көндәшегез.

Рәми. Әйе, көчле дошман! Аның көче

халык белән бәйле булуында. Халыктан ничек аерасың аны? Юк бит андый чара. Дөрес, аның «Яшен» журналы ябылды. Ләкин алар хәзер, яңаны, дәүләт кешеләренә тел-теш тидерми торганын чыгара башлады. Һич ни эйтеп булмый. Чөнки Дума заманы.

Дубасов. Патша өчен Думаны авызлыклау да берни тормый.

Рәми. Авызлыкланган атның үрә тора торган гадәте дә бар.

Дубасов. Господин Рәмиев! Житте! Кисәтеп әйтәм. Сезнең шәхси бәхетегез өчен бер генә юл кала: *(патша рәсеменә ишарә итеп)* ул да булса — бөек династия мәнфәгате өчен жаныгыз-тәнегез белән хезмәт итү. Сезне төрмәдән патшага каршы бер төрле дә революцион эш алып бармау һәм бер сүз дә язмау шарты белән азат иттек. Безгә хыянәт итә калсагыз, һәлакәт көтәчәген аңлатып, кулыгыздан язу алдык. Оныткан булсагыз... *(Папкадан язу алып күрсәтә.)*

Рәми. Онытмадым.

Дубасов. Алайса, ни өчен Ямашев жыйнаган мәҗлескә бардыгыз?

Рәми. Ямашев түгел, дустым Фатих Әмирханның хәлен белергә бардым.

Дубасов. Әгәр ялганыгыз өчен без сезне ябып куйсак?

Рәми. Бөек император әмере белән төзелгән Дума чорында авыру дуслар хәлен белү өчен төрмә дисәгез, бу инде, хөрмәтле полковник әфәнде...

Дубасов. Миңа сафсата кирәкми, господин Рәмиев. Исегездә тотыгыз: большевик Ямашев турында сезнең тарафтан әйтелгән кечкенә генә ялган хәбәр дә үзегез өчен зур күңелсезлек белән бетәчәк...

Рәми. Аңламыйм.

Дубасов. Ямашев Тукай белән кайда очраша?

Рәми. Белмим.

Дубасов. Ни өчен Ямашев Ту-ту-тукай белән артык нык кызыксына? *(Рәми дәшми.)* Әйтмисез?

Рәми. Тукай булганы өчендер, мөгаен. Үзегез дә бит Тукай белән минем шәхесемә караганда күбрәк кызыксындыгыз.

Дубасов. Безнең белән су-су-кыр тәкә уены уйнамагыз! Хәлләр күңелсез төс ала калса, Ямашев абзагыз белән бергә сезне дә, Тукай дустыгызны да тәртипкә буйсындыру чарасын табарбыз. Безнең тә-тәртипкә! А-а-аңлашыладыр?

Рәми. Аңлашылды. Рәхмәт!

Дубасов. Барыгыз! *(Рәми кызу гына чыгып китә.)* Баш бирәсе түгел. Зарары юк! Әмәлен табарбыз.

Быков *(ашыгып килеп керә).* Акбүре! Мөһим хәбәр, дип ашыгып килгән.

Дубасов. Әйтегез, керсен!

Быков. Есть. *(Чыга.)*

Акбирдин *(керә).* Сәламәтлек телим, господин полковник.

Дубасов. Димәк, яңа хәбәрләр?

Акбирдин *(кәгазь бирел).* Менә, бары да язылган.

Дубасов. Яхшы-с. Утырыгыз!

Акбирдин. Рәхмәт. *(Утыра.)*

Дубасов *(укып).* Та-ак... Болары билгеле, монысы да. Ничек? Ямашев?!. Та-ак. *(Укый.)* Ямашев әйтә: Фатих Әмирхан авыруы, Тукай, Рәми яки башка әдип, журналистлар авыруы гына түгел, падишаһымыз Романов һәм палачларының... Ах, гад! *(Укый.)* Халык канын кою нәтиҗәсендә туган кара реакция чире, димәк, бөтен халкыбыз, татар һәм рус, шулай ук башка милләт хезмәт ияләренең дә авыруы ул, ди. Ямашев әйтә: бүген безнең бурыч халкыбызның өмидсезлеккә бирелгән рухына азык бирү, күтәрү, аны яктылыкка, көрәшкә чакыру... Көрәш?! Күрсәтермен мин сезгә көрәшне. Шарлатан!!! Кара козгын!!! *(Зәһәрләнеп.)* Тагын нәрсә? *(Укый.)* Туктатылган «Яшен» урынына яңа журнал? «Ялт-Йолт»? Сволочьлар! *(Тирен сөртә.)* Та-ак! *(Укый.)* Иң әлек безгә Тукайның сәламәт булуы... кирәк, ул халкыбызның... *(Кулындагы кәгазьне атып бәрә.)* Юк-юк! Хәзер инде ул... *(Акбирдинга текәлеп.)* Тукай?.. Бәлки ул да Ямашев партиясендәдер?

Акбирдин. Юк, ул берниндн партиядә дә тормый.

Дубасов. Димәк, партиясез социалист? Демократ? Ямашев сүзләрен такылдаучы саескан? Чөкердәүче чәперчек?

Акбирдин. Нәкъ шулай. Чәперчек. Безнең якларда чәперчекне боз ваткыч дип тә йөртәләр.

Дубасов. Во-во-вот! Боз ваткыч. Туктаусыз чәп-чәп-чәпердәп, койрыгы белән боз вата. Яз китерә. Та-ташкын! Яшен уйната.

Акбирдин. Нәкъ шулай. Карап торуга бер гөнаһсыз кош сыман. Ә бозны вата. Шагыйрь генә түгел, сихерче ул Тукай. Зур акыл иясе.

Дубасов. Җаек кебек провинциядә, схоластик мәдрәсәдә укыпмы?

Акбирдин. Күп кенә телләр белә. Төрек телендә шигырь яза. Гарәп, фарсы... Гомәр Хәйям, Әбугалисина, Ширазн һәм

Сәгъдиләрне ана телләрендә укый. Үзбәк, кыргыз, төрекмән, уйгурларны әйткән дә юк.

Дубасов. Ха-ха-ха! Бәлки кытай телен дә белә торгандыр?

Акбирдин. Юк, белми, аңламый кытай телен...

Дубасов. Ул белгән телләр бары да чүп! Варвар халык... Азиат алар. Төрек, үзбәк, таҗик, гарәп... Нинди фән аларда?

Акбирдин. Шулаен шулай да, тик Бохара белән янәшә, Әшфан авылында туып үскән Әбугалисинаның медицина тәгълиматы Париж, Лондон, Берлин университетларында биш йөз ел буе дәреслек булган, шулай ук алгебра дәреслеге...

Дубасов. Причем тут алгебра!

Акбирдин. Алгебра — гарәп сүзе. Әлҗәбер дип башлап исем биргән галим дә Төркестаннан, Хәрәзм шәһәреннән, Мөхәммәт Хәрәзми, үзбәк, азиат! Шулай ук бөек астроном Улугбәк тә...

Дубасов. Житте! Беренчедән, Әбугалисина түгел, А-а-виценна и Омар Хайям. Алар бүген юк дөньяда. Юк! Күптән үлеп беткән, юкка чыккан. Да-да, да! Дөнья, тарих барышы бер алла кулында. Алар урынында хәзер ярым кыргый азиатлар яши. Именно азиатщина! Дөнья хакимнәре бүген — Англия лордлары, француз бароны, рус алпавытлары. Романовларның бөек династиясе. Алар бергә-бергә изге союз — Антанта төзеделәр. Революциягә, бөтен плебейларга каршы көчле йодрык...

Акбирдин. Шулай да, Николай Николаевич, Авиценна һаман Авиценна.

Дубасов. Нәрсә? Ах-ха-ха-ха... Үзең дә азиат булгач...

Акбирдин. Юк! Европалы мин. Бөек рус патшасы алдында баш игән фәкыйрь бәндә.

Дубасов. Син — син инде ул. Ә менә Тукайның халыкка тәэсирен ничек бетерергә?

Акбирдин. «Дума һәм сугыш» исемле мәкаләсен янсә Алексей Бахның «Ачлык патша»сын, ягъни марксизм әлифбасын татарчага тәрҗемә итеп бастырган көннәрдә булса, я «иң бөек максат безем — хөр мәмләкәт, хөр Россия!»— дип кычкырган чагында булса, бәлки үзегезгә чакыртып...

Дубасов. Хе-хе-хе! Хәзер ул кычкыра алмый. Җылый, сыкрана.

Акбирдин. Аның сыкравы — халык сыкравы. Ачуы — халык ачуы. Ә бу куркыныч, барыбыз өчен дә!

Дубасов. Стало быть, үзе үлеп котылмаса, без көчсез? Без берни дә эшли алмыйбыз? *(Пауза.)* Бәлки моны тизләтергә мөмкиндер?

Акбирдин *(сикереп торып)*. Үлемен? Халык алдында мәңгелек ләгънәт һәм каһәр алып...

Дубасов. Халык ул — кара сарык.

Акбирдин. Аны халык мәхәббәтеннән аеру өчен юл бар барын...

Дубасов. Я, я?

Акбирдин. Тукайның Ахиллес үкчәсенә басарга...

Дубасов. Ахиллес үкчәсе?! Димәк, гомерен кисә торган иң нечкә җире...

Акбирдин. Әйе, җирлегеннән, халыктан аерырга. Дусларының җанын тетрәтеп, шулай ук халыкның да...

Дубасов. Я, я, нишләргә?

Акбирдин. Үземә тапшырыгыз. Тукайның якын дустына.

Дубасов. Сиңа?

Акбирдин. Тукайның иҗаты һәм тормыш юлы турында мәкалә, юк, кечкенә бер китап язу дигән уй йөри башымда. Бу миңа олы юл ачачак. Һәр эшен, һәр хәрәкәтен белеп тору, беренче нәүбәттә дус-ишләрен, сезгә мәгълүм Ямашевның, башкаларның, кыскасы, зур мөмкинлекләр...

Дубасов. А-акыл бу. Я-ясно! Словом, действуй!

**Акбирдин аягүрә басып, баш ия.**

**Картина.**

## IV

**Сәхнә алды. Бик ашыгып Тукай узып бара. Кулында кәгазьләр.**

Тукай *(туктап)*. Кая ашыгам? Язмышымның якты биеклегенәме? Әллә төпсез упкынгамы? Куркырга, сыкранырга хакым юк. Яшен уты икәнмен — янарга, бары тик янарга тиешмен! Изге максатым бар. Кулаягым богаулы милләтем, халкым бар. Ачлыкта, богауда газап чигә торган халык... *(Кулындагы кәгазьләрне барлап.)* Чү! Ашыга торгач, иң кирәкле язмаларымны оныткан мын. *(Ашыгып кире китә. Тукталып.)* Иртәгә Ямаш үзенә чакырды. Ялгызымны

Бары тик ялгызымны. Киңәшәсем бар, ди. Яхшы! *(Китә.)*

**Икенче яктан ашыгып Акбирдин килә. Туктала.**

Акбирдин. Кая ашыгам бу кадәр? Моңлы сазыбызның хәл-әхвәлен белергә. Шулай ук дусларының. Аеруча Ямашевның. Яза торган китабым тулырак булсын өчен— барысы да кирәк. *(Пауза.)* Аңлавы кыен дөньяны. Берничә ел элек кенә революция, хөррият дип кычкырып йөргән «Таң йолдызы»нда эшләүче Акбирдин, кыю эс-эр бүген... Ха! Дубасов ялчысы? Юк!! Бары тик үз җанының турылыклы сакчысы. Үз җанын кайгыртмаган адәм бармы соң бу дөньяда? Әгәр мин Адәм улы Адәм икәнмен, димәк, дус-ишемне иркәли, назлый алам, кирәксә... *(Куллар хәрәкәте.)*

Тукай *(күреп)*. Синме соң бу, Рәфыйк?

Акбирдин. Тукай?! Әй, дустым! Миңа бит нәкъ син кирәк идең. Синең турындагы күптән уйланган җаваплы эшемне ашыктырасым килә хәзер.

Тукай. Рәфыйк, калдыр...

Акбирдин. Беләм, син үзең каршы моңа, ләкин халык, нәширләр...

Тукай *(кабынып)*. Нәширләр?!

Акбирдин. Юк! Юк! Иң элек халык мәнфәгате... Милләт... Бөтен тәрҗемәи хәлеңне беләм. Шигырьләреңнең һәр юлына кадәр... Идеалың, уртак идеалыбыз — хөр Россия, халык бәхете... Ә менә аңа ирешү юллары, чаралар дип әйтимме...

Тукай. Чаралар? Ха-ха! Шигырьләремне беләм дисең, аларда минем бөтен барлыгым, бары да ачык.

Акбирдин. Ачык булмаганнары да күп. Хәер, алар турында монда гына сөйләшеп булмый.

Тукай. Дөрес. Мин дә ашыгам. *(Кәгазьләрен рәтли.)*

Акбирдин. Сизәм. Яшен бит син. Ялт-йолт. Ярый, өеңә килермен.

Тукай. Өйдә булмасам, редакциягә кил. Кузна да уйнарбыз...

Акбирдин. Мин чынлап сөйләшәм, Тукай.

Тукай. Мин дә чынлап. Минем бөтен кузналарым редакциядә, валлаһи! Ярый, хуш. Ашыгам! *(Китә.)*

Акбирдин. Хуш... Кем соң бу? Атаклы шагыйрь Тукаймы? Әллә бала-чагамы?..

**Китә.**

## V

**«Болгар» номерында Тукай бүлмәсе. Бик гади җиһаз — өстәл, ике урындык. Тимер карават, тумбочка. Өстәл өстендә китаплар, газета, журналлар. Кара савыты. Кечкенә көзге.**

Шәмәт *(ишекне ачып, як-ягына карана)*. Өйдә юк. Җәлке. *(Яба, шунда ук яңадан бүлмәгә керә. Сәләмә киемнәрдән. Күптән кырынмаган. Шадра йөз. Башында иске кырпу бүрек.)* Ф-ф-ф! Монда да җылы юк. Эх-э, Тукай җаный, синдә дә рәт юк икән. Баш шундый чатный. Дус-ишләрең бай булмагач, җылынырлык та җай юк. *(Көзгегә карап.)* Кыяфәт ничава, кәнишне. Хе-хе-хе! *(Әзләнә.)* Китап, китап, гәҗит, журнал. Әһә! Икмәк! *(Бер кисәк икмәкнең яртысын сындырып ала. Ашый, өстәл тартмасын ача.)* Портманет? Оһо! *(Ача. Бер сумлык көмеш алып.)* Бер сум! Булды бу... Тагы бар. Ике тиен?.. Их-х унбиш тиен булса... Юк, ярамый. Мужет соңгы бер сумыдыр... *(Акчаны портмонетка салып, кире куя.)* Миңа нибары унбиш тиен житә. *(Тәрәзәдән күреп.)* Үзе кайта. *(Ишек янына килеп баса.)*

Тукай *(ашыгып керел, өстәле янына уза. Кесәсендәге язуны ала. Укый.)* Гаҗәп! Нәрсә?! Зәйтүнә туташ... кетә? *(Елмаеп, уйга кала. Күз алдына прожектор яктысында искиткеч гүзәл кыз — Зәйтүнә килеп баса. Шәмәтне күреп.)* Син?!

Шәмәт. Мин, жаный, мин. Шадра Шәмәт. Первый гильди сукбай.

Тукай. Үзеңне кимсетмә, Шаһиәхмәт.

Шәмәт. Кая инде хәзер Шаһиәхмәт булу. Крушник Шәмәт и... Ярканат... Кара төн житкәч кенә... хәрәкәтләнәбез. Шунысына шөкер, күз яше төшәрдәй берәүне дә җәберләмәскә тырышам.

Тукай. Тырышып кына да калма.

Шәмәт. Үзем дә шул уйда. Шуңа күрә сиңа кердем дә. Иөрәк януларын басар өчен зәмзәм суы алырлык бер унбиш тиен биреп торсаң... күтәргә дим.

Тукай. Ай, Шәмәт дус, бүген акча ягым такыррак шул. Китап басучы бай абзыйлар вак-төяк алаңагымны да бирми.

Шәмәт. Барысы да жулик алар. Иске плутатор. Эшләгәндә эшләтә, түләгәндә тияр тиеннәреңне басып кала.

Тукай. Шул-шул. *(Кесәләреннән акча*

эзли. Өстәл тартмасын ачып, портмонетыннан бер сумны ала.) Үземә яшәрлек бер сум бар барын да...

Ш ә м ә т. Унбиш тиен житә. Давай, Тукай дус, калганын китерермен.

Т у к а й. Үткән юлы да шулай дигән идең...

Ш ә м ә т *(акчаны алып)*. Беләм, ул чак ни... иптәшләр бит... Сиңа бирәчәк бурычым бер сум утыз тиен җыйнала. Барын да тулы килеш түләячәкмен. Пәйгамбәрдән дә артык күргән шагыйрь абыем гөнаһысына кереп, тәмугта янасым юк.

Т у к а й. Ышанам.

Ш ә м ә т. Ышан, Гаптулла дус. Шадра Шәмәт утка керер, кәтр китәр, но сине падвадит итмәс. *(Акчаны чөеп алып.)* Бер сум көмеш, ә! Ух-х!! Чыңлый. *(Көйләп.)*

Әйли, әйли, әлләри,
Әлләриннең мәйләри,
Шул мәйләрне әмәлләсәң,
Дөньялары әллә ни! *(Биеп ала.)*

Эх, мать честная, Маруся начная, яшә, Тукай абый! *(Китә.)*

Т у к а й. Әй, Шәмәт, Шәмәт. Дөнья басмаса, үзең шагыйрь була торган кеше син. *(Кесәсеннән язу алып укый.)* Зәйтүнә!.. Тукта, нигә әле куркам аңардан? Болгар бабамнар гайрәте юкмы әллә миндә?

Ш ә м ә т *(аргта)*. Әйдә, бабай. Шушында инде. *(Ишекне ачып.)* Давай, кер, кер. Менә сиңа, Тукай абый, яна кунак. *(Ишекне яба.)*

**Сакал-мыеклары чалланган, начар гына киенгән, бер аягы, бер кулы зәгыйфь, нык аксап йөри торган авыл крестьяны Рәхмәй керә. Кулында төенчек.**

Р ә х м ә й *(кыюсыз гына)*. Әссәләмегаләйкем!

Т у к а й. Вагаләйкем әссәлам.

Р ә х м ә й *(ышаныр-ышанмас карангалап)*. Бу егет дөрес әйттеме соң... Миңа шагыйрь Гаптулла әфәнде Тукаев кирәк не.

Т у к а й. Әйе, Тукаев мин булам.

Р ә х м ә й. Шигырьләр язып, китап чыгара торган Тукаевмы?

Т у к а й. Әйе, йомышыгыз миндә булса, рәхим итегез. *(Урындык куя.)*

Р ә х м ә й. Юк, юк, туганым. Тукаев үзе булгач, басып торам инде... Рәхәтләнеп басып торам. *(Аптырабрак торган Тукайга.)* Кем икән дисең инде син бу тинтәк чатан картны?

Т у к а й. Юк, нигә...

Р ә х м ә й. Үзем гарип-гораба булсам да, ниятләрем изге. Арча якларыннан мин. Иске Мәңгәр авылыннан.

Т у к а й. Якташ болай булгач. Мин — Кушлавычтан.

Р ә х м ә й. Һи-и, тәгаен дөрес икән... Шигырь чыгаручы Тукаев безнең якларда туып үскән дигәч, ышанып бетмәгән идем... Ну малай, Тукай туганым, шигырьләрең шигырь генәме... Барысы да йөрәккә май булып ята. Ә инде чалмалы ишан, акча өчен жансатарлар йөрәгенә тоз сибеп язган җырларыңны телдән-телгә йөртеп укыйбыз. Әчебез катып көлә-көлә. Инде дә китереп балаларга атап язганнарың балаларыбызны сандугачтай сайрата. Укып та укыйлар, көйләп тә җибәрәләр. Бер көн шулай нәни кызым Наилә мәктәптән кайтты да, алдыбызга килеп, шундый көйләп җибәрде: и туган тел, әткәм-әнкәмнең теле!.. дип. Әнкәсе белән без бер-беребезгә карап елаштык хәтта. Шулай булмыйча соң, байлыгыбызның иң зуры шул тел бит инде. Югыйсә, береннең хәлен берең ничек белер иең, ә? *(Утыра.)* Үзем мин, Тукай туганым, япун сугышы солдаты. Бер аягым, бер кулым шунда калды. Бер күзем дә зәгыйфьләнде. Җырның, моңның кадерен бик беләм. Ипекәй белән җыр — солдатка иң кирәге. Мылтык кебек үк. Харбин тирәләрендә ранин булдым. Ярый әле, шөкер аллага, Порт Артурда булмадым. Анда бит, һи-и, кырып кына салды япун безнең халыкны. Ватты, җимерде... Солдатын, әфисәрен, крипесен. Көлен күккә очырды. Әй, без күргәннәр... Ходай күрсәтмәсен, дим, сугышны әйтәм... *(Кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгара да, кулында әйләндергәләп, кире куя.)* Миңа менә кырык бер яшь...

Т у к а й. Нибары кырык бер?!

Р ә х м ә й. Тулып та җитмәгән. Үзем җитмеш яшьлек бабайлар кебек, кәкре дә бөкре. Бары шул тынгысыз йөрәк кенә йөртә. Мулла кушкан исемем Рәхмәтулла. Алланың рәхмәте, янәсе. Һи-и, кая инде ул рәхмәте. Карачкы бер... Аксап-туксап йөри торган Чатан Рәхмәй... Хи-хи-хи!

Т у к а й. Юк, Рәхмәтулла абзый, аягың чатан булса да, күңелең чатан түгел синең. Йөрәгең дә дөрес тибә, белеп йөртә.

Р ә х м ә й. Анысы, аллага шөкер, жансатар хаҗилар тирәсенә түгел, менә синең янга алып килде. *(Караньш алып.)* Болай булгач, дөресен әйтим инде. Авылда, тирәякта да шомлы хәбәр таралган. Изге күңелле иң якын кешебез ниндидер авыруга дучар булган, дип, сине атап сөйлиләр шулай. Алайса, мин әйтәм, барып кайтыйм әле.

дим, Казанга, хәлен белеп, дим. Андыймондый ярдәм кирәк булса, мин әйтәм, җыелырбыз да, бөтен илебез белән берләшеп ярдәм итәрбез, дим. Казанга, Тукайны күрергә барам дигәч, кызым үрле-кырлы сикерә. Әтием, ди, Тукай абзыйны күргәч, миннән дә, безнең бөтен балалар исеменнән дә күп итеп сәлам әйт, ди. Менә шул. Монда килеп керүемнең сәбәбе шулар, Гаптулла туганым.

Тукай *(нык әсәрләнеп)*. Чыннан да ниятләрең изге икән шул. Барысы өчен дә рәхмәтем зур, күңелемә алар шифалы дәва. Инде хәлем ничек дип сорасаң, үзең күреп торасың, сау-сәламәт... Ә инде байлыгым чутына килгәндә, анысы да әлегә мең шөкер. *(Портмонетны суккалап.)* Димәк, акчага да мохтаҗлыгым юк. Шулай булгач, борчылмагыз, Рәхмәтулла абзый.

Рәхмәй. Син дөресен генә сөйлә, Тукай туганым.

Тукай. Дөресе шулай. Әлегә кадәр һичкемнән бурычка акча алмадым, моннан соң да...

Рәхмәй. Безнең бит, Тукай туганым, бурычка түгел, болай, пруста ярдәм, сәдака сыман...

Тукай. Сәдака?! Миңамы?

Рәхмәй. Юк ла, Тукай туганым, үпкәли күрмә тагын, сәдака сүзе... Тфу! Җен алгыры, авызымнан ялгыш ычкынды. Түлке шул... Халык ярдәме сәдака түгел, туганым! Береңә берең ярдәм, брат, Иван солдат әйтмешли, святуй дело.

Тукай. Аңладым, Рәхмәтулла абзый! Ярдәмгә мохтаҗлыгым төшсә, үзем барырмын сезгә. Өчиледә туганнарым да бар. Авылдашларым, барысы да, рәхмәтләр яусын, киң күңелле...

Рәхмәй. Вәт, шулай дисәң, күңелем булды, ичмасам. Рәхмәт! Инде тынычланып китәм.

Тукай. Сыйларга сыем гына булмады. Ялгыз кеше булгач, хәл шулайрак инде ул. *(Пауза.)* Ә менә кызың Наиләгә... Сабыр! *(Өстәл тартмасыннан китабын ала да, берничә сүз язып, Рәхмәйгә суза.)* Бу яңарак басылган китабым — «Балалар күңеле». Монда «Туган тел» дә, башка шигырьләр дә бар. Язып та куйдым: «Наилә сеңлемә! Тукай абыеңнан». Минем бүләгем итеп бирерсең.

Рәхмәй *(китапны күкрәгенә кыса)*. Әй, Тукай туганым... *(Күз яшьләрен җиңе белән сөртеп.)* Мең алтыннан да кадерле бүләгеңнең әҗерен ничек кенә кайтарырбыз икән.

Тукай. Кызың Наилә яратып укыса, әнисе белән әтисе дә яратып тыңласа, шуннан да кадерлесе юк миңа, Рәхмәтулла абзый.

Рәхмәй. Алай булса инде, туганым, күптин-күп рәхмәтләребез, изгедән-изге теләкләребез сиңа. Бернинди сырхау да кагылмасын. Вакытыңны күп алдым, зинһар өчен ачулана күрмә! *(Китапны түенчегенә урнаштыра.)*

Тукай. Якташларыма сәламемне тапшыр.

Рәхмәй. Тапшырам, алла боерса, тапшырам. Ярый хуш. *(Күрешә.)*.

Тукай. Килгәндә тагын кер. Сый-хөрмәтем булмаса да...

Рәхмәй. Һи-и, ачык чыраең үзе зур хөрмәт, Тукай туганым, хуш булып тор. *(Ишектән килеп керүче Рәмигә бәрелә.)* Извиняюсь, пожалыста.

Рәми. Карабрак йөриләр аны, бабай. Сукыр түгелсеңдер!

Рәхмәй. Аллага шөкер, сукыр түгел, мүкләк сыер белән адәм баласын яхшы аерам... *(Тукайга.)* Хуш, туганым. *(Китә.)*

Рәми. Чатан булса да, нинди телчән.

Тукай. Минем якташ.

Рәми. Шулайдыр, күренеп тора... Ну, җаным, ничек түзәсең шундый үтем-сүтемгә? Кайчан килмә, бүлмәң тулы кеше. Бер керсәң — шагыйрь-шогыр, икенче керсәң — мужиклар.

Тукай. Өченче керсәң, шигъриятебезнең синең кебек даһилары... Алар да кайчак тавафкыла шушы хөҗрәмне.

Рәми. Эч пошканда киләсең инде, телең төерле булса да, үзең как-никак ничава кеше. Якын иптәш! *(Җилкәсенә суга.)*

Тукай. Ну, кулың...

Рәми. Милләтебезнең шөһрәтле шагыйренә хөрмәт белдерүем.

Тукай. Җавап кайтарыр идем дә пумала башыңны кызганам.

Рәми. Чыны шулай, Тукай. Кайсыбыз соң синең кадәре татар милләте өчен яна, көя? Минме, Дәрдмәндме? Думавимы? Бәшириме? Сүнчәләйме? Берсе дә! Бары тик син ул милләтебезнең милли рыцаре!

Тукай. Милли? Тел төбеңнән сизеп торам, кайбер тырнаклы әдипләр кебек син дә миңа тар милләтче — националист дигән ярлык тагарга исәп тотасың.

Рәми. Нигә, милләтче булу хурлыкмыни?

Тукай. Хурлык! Милләтчеләр татар халкын бары тик алдый, баш очында укый аңа үлем аяте ясин, ясин гына. Ә мин чын күңелдән яратам милләтемне.

Рэми *(мыскыл белән)*. Татар бит мин, татармын, татар бәхете өчен җан атармын, дисең инде.

Тукай. Дөрес! Әгәр миңа хәят биргән, ана теле, моң-җыр биргән төрки-болгар татарымны яратмасам, аның яхшылыкка нигезләнгән гореф-гадәтләрен оныта калсам, яшен атар иде мине! Тарихчылар әйткәнчә, безнең илбасар Батый-хан белән бер уртаклыгыбыз да юк. Батый-хан рус шәһәрләрен генә түгел, безнең бабаларыбызның туган илен — Болгар дәүләтен дә тар-мар иткән. Шәһәрләребез, авылларыбызны яндырып, хәрабә хәленә китергән. Бабаларыбызның башын кискән, кырган, таптаган... Без — болгарлар! Милләтемнән ваз кичәргә, шулай ук татар исеменнән качарга да җыенмыйм. Карагруһ мулла, хаҗи, ишаннарны җенем сөйми. Ләкин Шиһаб хәзрәт Мәрҗани миңа иң кадерле кеше. Бабаларыбызның кыю, намуслы халык, болгарлар булуын фәнни нигездә аңлатып биргән галим.

Рәми. Әйе... Әйе!..

Тукай. Ләкин мин татармын дип, бер генә халыкны да чит күрмим. Руслар — якын дустыбыз. Башкортлар — ут күршебез. Кыргыз, үзбәк — тел кардәшләребез, белорус, грузин — берсе дә чит түгел миңа.

Рәми. Шулай ук карсак япуннар да диген.

Тукай. Япун, кытай, һинд һәм монгол, әйе, безгә татар исемен тагып калдырган Чыңгыз ханның бүгенге оныклары — монголлар да ят түгел миңа. Бары да үз, туган, кардәш, һәркайсының үз моңы, үз җыры, якты өмете, хыялы... Минем өчен бер генә зур дошман бар. Илбасар-сугыш чукмарлары. Халыкларның иркен, бәхетен талаучылар.

Рәми. Яздың. Сугыш һәм Дума турындагы язмаң нәкъ шул турыда иде.

Тукай. Әйе, алтынчы елның язында, канлы фаҗигалар булып үткәч, патша манифестына ышанып Дәүләт Думасына өмет баглаган көннәребездә яздым, дөресрәге, социал-демократ Памирцев мәкаләсен тәрҗемә иттем. Уйланып, шатланып...

Рәми. Балаларча кул чәбәкәйләп... Имештер, бөтен Әрәчәй күләмендә мир җыены. Крестьяннар, эшчеләр, галим-голәмә җыйнала да дәүләтне ничек идарә итәргә икәнлеге турында акыл бирә. Патша аны кабул итә, беркайчан да сугыш булдырмаска дигән фәрман чыгара, ха-ха-ха! Я, әйт, синнән дә ахмак кем бар бу дөньяда?

Тукай. Бар!!! Миннән мең кат ахмаграклары, мин диеп масаеп, патшалар минем алда чүп кенә, дип кычкыручы «даһилар» булмадымыни ул чак?.. Алар ахмаграк түгел идемени?

Рәми *(зәһәр белән)*. Түгел!!!

Тукай. Соңыннан патша алдына барып тез чүктең!

Рәми. Этләшәсең, Тукай.

Тукай. Нишләмәк кирәк! *(Пауза.)*

**Сәгыйть папирос кабыза. Тукай бер як читкә китә.**

Шәмәт *(керә. Кызмача)*. Булды! Кәеф! Шәмәт күкнең иң югары катында бүген, фәрештәләр янында. *(Акча биреп.)* Сдачасы нәкъ сиксән биш тиен. Әйттем бит:

Әлләрине бер мәйләсәң,
Дөньялары әллә ни!..

*(Рәмигә.)* Шулай түгелме, дәү абый?.. Үркәчле тәвә абый, ә?

Рәми. Бу нинди маймыл?

Шәмәт. Миние маймыл? *(Өстенә килә.)*

Тукай. Минем дустым Шаһиәхмәт.

Шәмәт. Пунятно?.. *(Тукайга, көйләп.)*

Рәхмәт яусын кулларыңа,
Гөл үссен юлларыңа...

Ә сиңа, тәвә абый... кик... *(хәрәкәтләр ясап)* кик-ри-күк! *(Китә.)*

Рәми. Исерек баш...

Тукай. Изге җан ул. *(Пауза.)* Әле дә хәтерлим ул мәкаләдәге юлларымны: *(һәр сүзенә басым ясап)*. Әгәр мәмләкәтебез, патша манифестыннан аңлашылганча, халык тарафыннан идарә ителсә, халык сугышның кабатлануына юл куймас, үткән сугыштан калган җәрәхәтләрен бәйли белер...

Рәми. Менә бит, бичара адәм баласы нинди генә хыяллар белән хыялланмый.

Тукай. Ләкин шул юллардан соң ук: бу ышану, бу өметләр белән куану урынлымы? — дип күрсәтү... Думага фабрикант, банкир, алпавытлар кереп тулачак, ярлы халыкка Думадан бәхет көтү, эт авызыннан сөяк алу белән бер, дип кисәтеп кую... Сез ул мәкаләмә бәя бирмәдегез. Ә ул көннәрдә иң кирәге халыкка шуны аңлату иде. Нигезле итеп, кемнәр өчен ул сугыш? Нәрсә ул Дума? Дәүләт? Власть? Хакимият...

Рәми. Власть?.. Ташла! Аракың бармы?

Тукай. Юк! Беркайчан да бүлмәмдә аракы тотмыйм.

Рәми. Власть... Әгәр бер могҗиза булып синең кулыңа власть бирсәләр, ә? Нишләр идең?

Тукай. Гомәр Хәйям хыялланган сыман —

Бу дөньяны сүтәр идем, җимерер идем,

һәм адәмнәр мәңге рәхәт яшь торган
Бүтән дөнья иҗат итеп бирер идем.

Бөтен милләтләр үзара тату, дус яши торган, беркайчан да сугыш булмый торган яңа дөнья!..

Р ә м и. Ох-хо-хо! Хыялларың...

Т у к а й. Әйе, мең еллар буе чын кешеләр күңелендә яшәгән изге хыял... Менә бер шагыйрь ничек хыялланган: барлык сугыш коралларын җыеп эретсәң иде дә, сука-тырмалар ясатып, игеннәр иксәң иде.

Акмас иде каннар ул чак,
Таммас иде кешеләр күз яше.

Р ә м и. Кем ул шундый акыллы баш? Инглизме? Немецмы?

Т у к а й. Юк, Гомәр Хәйям шикелле үк ул да бер азиат... Мең ике йөз ел элек яшәгән кытай шагыйре Ду-Фу.

Р ә м и. Каян чокып чыгардың шундый ерак дөнья шагыйрен.

Т у к а й. Якындагы тарихыбыз өчен җаның әрнегәч, чокынасың икән шул. Порт-Артур фаҗигасын исеңә төшер. Инглиз белән немец түрәләре өстереп тора. Дүрт йөз мең кешебез кырыла япун сугышында. Яраланып кайткан гарип-гораба ничә миллион... Харап булган байлык, җимерелгән шәһәр, авыллар... Әле генә син сукыр, чатан мужик, дип хурлаган минем якташ та бит япун сугышында кул-аягын, бер күзен югалткан гарип...

Р ә м и. Кызганыч, белмәдем.

Т у к а й. Иң элек шундыйларны күрә белү кирәк түгел микән?

Р ә м и. Мине сукырлыкта гаеплисең?

Т у к а й. Синнән битәр үземне гаеплим! Дөньямның ямьсез яклары булган әнә шундый фаҗигалардан котылу... Кешелекнең якты язмышы... Кая минем шулар турындагы иҗатым?.. Мин дә бит кайчан да булса бар дәүләтләр һәм халыкларның үзара тату яши торган көннәре киләренә ышанам.

Р ә м и. Кемнәр китерер икән аны? Бармы дөньяда шундый көч?

Т у к а й. Бар! Синең белән мин ул. Барыбыз да, Ямашев һәм...

Р ә м и. Ямашев?! Белмим... Мин ул партиядә тормыйм. Аның үзен дә сирәк очратам. *(Пауза.)* Син еш очраткач, күбрәк беләсеңдер, билгеле. Ярата бит ул сине.

Т у к а й. Ул барыбызны да хөрмәт итә.

**Ишек шакымыйча Акбирдин керә дә, Рәмине күреп, ишек төбендә тукталып кала.**

Р ә м и. Анысы шулай, ләкин сине хөрмәт итүе башкачарак.

А к б и р д и н *(түргә уза)*. У-у!.. Синдә кунак бар икән ич. Милләтебезнең мактаулы шагыйрьләренә *(реверанс ясап)* дан һәм хөрмәт!

Р ә м и. Маймылланма, Рәфыйк! Монда маймыллар юк!

А к б и р д и н. Бигайбә! Белмәдем. Заманында бергә эшләгән танышлар да булгач... күрсәсең, ялгышканмын.

Р ә м и. Бик нык ялгышкансың.

А к б и р д и н. Алайса, зинһар, гафу әйлә. Йомышым Тукайда.

Т у к а й. Сөйлә. Сер түгелдер ич.

А к б и р д и н. Юк, нинди сер булсын. Шулай да бүген сезне тынычлыкта калдырам. Иртәгә керермен. *(Рәмигә.)* Ләкин юкка дулыйсың, Рәми агаем! Үзең зур, талантың зур, әмма ләкин дөнья хәлләре... Сизенәсеңдер, дүрт дәүләт берләшеп, Дарданелл һәм Босфорны буып, төрек бабаңны бугазыннан алмакчы. Балкан әле ул— җәнҗалның башы гына. Ә инде диңгезләр котырынып, акула-дәүләтләр беренә каршы бере һөҗүм башласа, җил-давыл барыбызга да кагылачак. Япун сугышыннан соң безне бөтереп алып киткән бу җил-давыл баласы гына булмады микән әле? Антанта,— минемчә, дәһшәтле һәм көчле йодрык.

Р ә м и. Йодрык?

А к б и р д и н. Борчылмагыз, безнең башка төшмәс ул, ходай кушса. Ярый, Тукай, иртәгә керермен... *(Ишек янында туктап.)* Бу арада Хөсәен килеп чыкмагандыр?

Т у к а й. Аның биредә бер ел инде булганы юк.

А к б и р д и н. Ярый, хәерле булсын! *(Китә.)*

Р ә м и. Акулалар турында нәрсә каркылдады бу козгын?

Т у к а й. Өстебезгә килә торган зур фаҗиганы сиздерде...

Р ә м и. Зур фаҗига дигәнең сугышмы? Шушы йомран башмы ул турыда хәбәр китерүче? Ха-ха!

Т у к а й. Әрлән белән йомран кебек җанварлар галимнәргә караганда җир тетрәячәген күп алда белә диләр бит хәзер.

Р ә м и. Әкият! Ә инде сугыш һәм аның ни белән бетәчәк икәне сиңа — сугыш гыйлеме белгеченә, үзең әйтмешли, дипломат һәм общественный деятельгә күбрәк кагыла.

Т у к а й. Көлмә, Сәгыйть, фаҗиганы булдырмау, шагыйрь хыялланганча, сугыш коралларын тынычлык кораллары итеп кою

турында уйлау барыбызның да бурычы, минемчә.

Рәми. И-и, Тукай-җан, әнә нинди хыяллар бит изге күңелеңдә. Һич кенә аерыласым килми синнән. Шулай да карарым кискен хәзер. Әстерханга китәм. «Идел» газетасына сәркатип булып. Менә редакторның чакыру хаты ун көн инде кесәмдә таушала *(күрсәтә)*.

Тукай. Казанны ташлап, ә?

Рәми. Моңарчы икеләнеп йөрдем. Ә бүген, сиңа кинәшкә дип килгәч, хәл иттем. Китәм!!!

Тукай. Күзләреңдә шундый шом, әйтерсең, миндә гаеп?

Рәми. Ялгышмадың! Китүемнең сәбәбе синдер, мөгаен.

Тукай. Сәгыйть! Мондый сүзне шаяртып та әйтмә!

Рәми. Кашки шаяру булса икән.

Тукай. Нәрсә?! Син шундый сәер бүген...

Рәми. Башым чатный... *(Папирос кабыза.)*

**Ашыгып Камал керә. Тәрәзәгә карый.**

Камал. Фу! Ләгънәт! Кара шайтан, мунча пәрие!

Рәми. Сабыр әйлә, Галиәсгар, кем чуалтты мыегыңны?

Камал *(мыекларын сыпырып куеп)*. Син дә мондамыни әле, әтәч Фәхри! *(Тукайга.)* Ну, мин ул чучканы бугазыннан алып акыртмасаммы! Үрле-кырлы сикертәсикертә.

Тукай. Уитер Камали төрмәгә яба аның өчен.

Камал. Үзен генә дә түгел, бөтен карагруһ мөритләре белән бергә. Әйләндереп салмасаммы...

Рәми. Ул чакны Салсал батыр Галиәсгар да булмыйм, диген.

Камал. Шулай-й...

Тукай. Аңлатыбрак сөйлә әле, ни булды?

Рәми. Кем кыстырды нишатырны арт ягыңа?

Камал. Нишатыр?! Ха-ха-ха! *(Көләләр.)* Алла боерса, нишатырны үзем кыстырам әле аларга.

Рәми. Булыр, булыр, башың йомры, түбәтәең кыңгыр... «Беренче театр»ыңнан соң бөтен Казан тетрәп тора синнән.

Камал. Бик тетрәми икән шул. Хурлык, валлаһи! Урамнан үтәр хәл юк. Беркайчан да өрми калганы юк собаканың.

Тукай. Аңлашылды. Кәфер почмагының эте Мөхәммәтҗан дисең...

Камал. Бөтен өере ырлап ябышты. Һау да һау! «Яшен»егезне сүндергән идек, патша хәзрәтләренең күзен буяп «Ялт-йолт» килеп маташасыз, ди. Абайлагыз, имеш, куркыта, ипкә-сапка килмәсәгез, барыгызны берьюлы, иң башлап Шүрәле дигәнегезне, сине янәсе *(Тукайга күрсәтә)*, аннан мине, берәм-берәм башкаларыгызны да тәүбәгә китерәчәкбез, ди. Башыма әле шундый уй, илһам килде. Әнә шул кара йөрәк Мөхәммәтҗан кебек ләңкә, әкәм-төкәмнәрнең бөтен серләрен фаш итеп, сатира язачакмын.

Тукай. Шәп!

Камал. Сугыш! Барысына каршы аяусыз сугыш ачам!

Рәми. Афәрин!.. Гали батырга — ур-ра!

Камал. Көлмә, Рәми.

Тукай. Син сугыш дисең дә бит, без әле дөньядагы бөтен төр сугышны бетереп, барлык милләтләр, бөтен кеше тату яши торган дөнья турында хыялланабыз.

Камал *(сарказм белән)*. Сезме?.. Барлык милләт, ә?.. Үзара тату? Сәгадәте инсаният, ә? Ха-ха-ха! Әй җаннарым, бөтен кеше түгел, иң әлек өчәү, юк — икәү, бербәрегез белән тату яшәү турында хыяллагыз!

Тукай. Көлмә, көлмә! Ике кеше тату яши алган җирдә ике мең дә, меңнәр генә түгел, миллионнар да тату яши ала! Яши ала! *(Пауза.)* Мин кешенең акыл көченә ышанам. Әгәр кешеләрнең башында социаль тигезлек, үзара тату яшәү турында фикер, хыял туган икән, димәк, ул күктән төшмәгән, җирнең, кешелек җәмгыятенең үзендә туган. Бу инде табигать, җәмгыять үсешенең үз кануны бар һәм ул синең белән минем ихтыярга да, падишаһлар ихтыярына да буйсынмый торган көчле кануны дигән сүз.

Камал. Шулай булгач, Тукай дус, кеше акылы дигәнең чүп булып чыга түгелме соң?

**Рәми шаркылдап көлеп җибәрә.**

Тукай *(зәһәр белән)*. Юк, түгел! Әгәр акыл шул кануннарның төп серенә төшеп, аны идарә итәргә өйрәнә икән, тату җәмгыять төзү генә түгел, атылган ядрәне авызлыклау гына да түгел (анысы аның җиңел), айга күтәрелеп, кояшта чибәр кызны да коча ала, дигән сүз.

Рәми *(кул чабып)*. Афәрин! Акылың алтын синең, Тукай-җан!

**Картина.**

## VI

**Кечкенә бакча. Эскәмия. Эчтәрәк парадный ишек.**

Тукай *(ялгыз)*. Уфф! Үзем сөям, ә Зәйтүнә күрсәсә, бетәм, югалам... *(Сәгатенә карап.)* Килмәве яхшырактыр да бәлки. Ай! Үзе! *(Пауза.)* Үзды! Мең шөкер! И-и, шагыйрь дус! Үзең гашыйк, үзең күрми китте, дип куанасың!.. Чү, кирс борылды. Бире килә!..

Зәйтүнә *(керәп)*. Тукай әфәнде!

Тукай. Зәйтүнә туташ?!

Зәйтүнә *(эскәмиягә утыра)*. Уф!.. Сез кемнедер көтәсез?

Тукай. Юк, сезне, бары тик сезне. Исәнмесез!

Зәйтүнә. Исәнмесез! *(Пауза.)*

Тукай *(утырып)*. Сезне инде, Зәйтүнә туташ, яңа шигырьләр китабым кызыксындырадыр?

Зәйтүнә. Әйе, кызыксындыра. Шулай да китап... дөньямның яртысы гына...

Тукай. Ә калган яртысы?..

Зәйтүнә. Сезнең «Яшен», яшен уты иде... сүнде, ахры?

Тукай. Сүнмәде! Без аны «Ялт-Йолт» журналы итеп яңадан дөрләтеп җибәрдек.

**Артта шау-шу.**

Сәләхи. Бар, кадалып кит! *(Ишектән яшь кенә кыз — Җәмиләне этеп чыгара.)* Күземә күренмә!

Җәмилә. Сәләхи абый, кызган! Яшьлегемне, намусымны...

Сәләхи. Сиңа тагын намус! Себерке!

Җәмилә. Себерке?! *(Тора, чайкала. Зәһәр белән.)* Шулаймыни? Мыскыл иттең... намусымны таптадың да хәзер инде эткә тинләп куасыңмы? *(Өстенә килә.)*

Сәләхи. Бар дим, кит! Югыйсә... Менә! *(Яңаклый.)* Менә!

Тукай *(йөгереп килеп, Сәләхинең кулын тота)*. Туктагыз!

Сәләхи. Ә-ә, син... ач әрвах. Сүнгән яшен. Бар, сыпырт! Югыйсә, күрәсеңме, кишмиш түгел, кукиш диләр моны. *(Кыткылдап көлә.)* Кех-х-х-хи-хи-хи. Тфү!

Тукай. Кыз баланы җәберләргә хакыгыз юк.

Сәләхи. Асравым ул. Телим икән, эшемне эшләтәм, телим икән... Кххх... хи-хи... тф-тф!

Тукай. Намусын таптыйсың?

Сәләхи. Бар-бар! Әнә, ябалагың көтә... Калай этәч! *(Утыра.)* Кикри-кү. Кү-кү. Яшен аткан булып маташкан идең дә, сүңдердек яшенегезне. Потамушта без ул — без. Имән багана. Ә син — шаталак... Марҗа сарафаны. Бар, барр!

Тукай. Барча кошның да үзенчә
сайравы бар, шигъре бар.
Карга мескен җырлый белми,
Кычкыра тик: «кар» да «кар».

Сәләхи. Син үзең карга!! К-й-кы-кыхх! Хи-хи! Юк-к, моннан соң, алла бирсә, ялтйолтыгыз да... *(Яшен яшьни, күк күкри.)* Лә хәүле вә лә куатә...

Тукай. Укып бетер. Илла биллаһи галиелгазыйм, диген, югыйсә Корьәндәгечә булмый...

Сәләхи. Ә? Ә-ә-ә. *(Кулларын селтәп.)* Кит. Иблис ләгыйн! Тфү, тфү! Бисмиллаһи! *(Мукәйләп өенә кереп китә.)*

Зәйтүнә. Нинди тупас, мәрхәмәтсез кеше.

Тукай. Байлыгы зур, кесә калын. *(Җәмиләгә.)* Туташ! *(Җәмилә дәшми.)*

Зәйтүнә. Нинди коточкыч дөнья бу!

Тукай. Туташ! Битегездә кан... Менә чиста кулъяулык, сөртегез, туташ.

Җәмилә. Туташ, имеш, көләсез? *(Ярсып, ыргыта, елый.)*

Зәйтүнә *(юатып)*. Туташ!..

Җәмилә. Сез дә? *(Өзгәләнеп елый.)*

Тукай. Сеңелем! Әгәр... Әгәр...

Зәйтүнә. Тукай әфәнде, тынычлансын ул... әйдәгез китик.

Җәмилә *(тетрәнеп)*. Тукай? Шагыйрь Тукай? Ярабби! Кичерегез мине, Тукай абый! *(Аягына егыла.)*

Тукай. Кирәкми, сеңелем! Кимсетмә үзеңне! *(Кызны аягына бастыра.)* Беркем алдында да кимсетмә!

**Картина.**

## VII

**«Ялт-Йолт» журналы редакциясе.**

Тукай *(Нургали белән кереп)*. Әйдә, курыкма. Кәҗәләргә любой бакчага керергә ярый. Монда — мин хуҗа.

Нургали. Ну?!

Тукай *(кузналарны урнаштырып)*. Кузналарны яшерәм дә...

Нургали *(бер кузна алып).* Ну малай, Апуш, саллы да бу кузнаң. Шуңа отасың да миңе. Югыйсә, бу якын тирәдә кузна каруле мин идем. Каян өйрәндең шулай оста сугарга?

Тукай. Җаекта. Кыргыз малайларыннан.

Нургали. Алар остамыни шулай?

Тукай. И-и, кырып кына сала кузнаны.

Нургали. Ну-у?

Тукай. Мондыйлар миндә икәү. Мә, монысы сиңа булсын.

Нургали. Давай. Мин дә сиңа бирәр нәмә бирермен.

Тукай. Кирәкми. Кашыкларыңны суга-суга жырласаң...

Нургали. Шушындамы?

Тукай. Монда да ярый. Ташаяк базары тирәсенә барсак яхшырак. Халык арасы. Әүвәл карусельдә әйләнербез, яме?

Нургали. Анысы кирәкми, Апуш, бала-чагамыни без, я сакаллы сабый, диярләр.

Тукай. Дисә? Безнең мондагы абзыйлар берсе дә минем белән кузна уйнамый. Карусель дә әйләнми. Кешеләрдән тартына.

Нургали. Мөгаен, алар зур акыл иясе-дер.

Тукай. У-у, нинди генә әле. Безгә синең белән, Нургали дус, кечерәк акыллы булсак та ярый, ә?

Нургали. Знамо, ярый. Булган кадәресе бик житкән, имә? Главный, тәүфыйк булсын кешедә. Үзен генә түгел, кешене дә кеше итеп санасын. Комсыз булмасын. Безнең нибары бер кәҗәбез бар. Аллага шөкер, житә сөте. Әни сөт белән мине дә сыйлый, күршедәге авыру апага да өлеш чыгара. Әгәр күкрәгең-мазар авыртса, син әйт миңа, Апуш, тартынып торма. Сиңа да китергәләрмен кәҗә сөте. Кымыз кебек ул, шифалы диләр аны.

Тукай. Рәхмәт, Нургали дус.

Нургали. «Кәҗә» дип, кушаматым белән генә әйт. Беләсеңме, каян килде миңа бу кушамат?.. Барысына да әнә шул сакаллы кәҗә гаепле. Мин аны көн саен үзебезнең Тегәрҗеп урамыннан ике бистә арасындагы күл буена, үлән ашарга алып барам. Шул чак Аккомасты малайлары мыскыл итеп кычкырып кала. Әнә, Кәҗә Гали килә диләр. Үзебезнең Тегәрҗеп урамындагы малайлар Галиең дә әйтеп тормый. Кәҗә генә, ди. Әйтсә тагын. Дөньяда кушаматсыз кеше буламыни. Апуш! Әйт әле, малай, синең кушамат ничек?

Тукай. Шүрәле.

Нургали. Кит! Ха-ха-ха! Бөтенләй коточкыч. Шүрәле.

Тукай. Коточкыч булуы әйбәт тә. Кешеләрне озын бармаклары белән кытыклап үтерә торган Шүрәле. Кети-кети уйнап.

Нургали. Кем бирде сиңа шундый кушаматны?

Тукай. Үзем.

Нургали. Үзең? Дүрәк! Үзенә үзең шундый кушамат... Карале, Апуш, әллә кайчаннан бирле сорыйсы килгән бер соравым бар.

Тукай. Сорап кара?

Нургали. Адәм әйтеп, адәм ышанмаслык инде ул.

Тукай. Сора, сора.

Нургали. Теге матур жырлар, шигырьләр яза торган кешене син, имеш, дип сөйлиләр.

Тукай. Син ышанасыңмы шуңа?

Нургали. Ышанырга бит, дүрәк, минем белән кузна уйный торган малай Тукай үзе булып чыкса, дөньяның асты өскә килер.

Тукай. Мин Шүрәле дидем бит сиңа үземне.

Нургали. Тукта, аның Шүрәле дигәне дә шул Тукай үзе диләр бит әле. Шүр... Шүрәле? Син! Тукта?! Тукай-й... Апуш, жаным, дустым! Кирәкми! Тукай булма! Син Апуш кына булганда, без шундый дуслар... Ә шагыйрь Тукай булсаң...

Тукай. Барыбер дус булырбыз.

Нургали. Я хода! Кая алып кердең мине?

Тукай. Хода түгел, мин алып кердем. «Ялт-Йолт» редакциясе бу. Элек без «Яшен» журналы чыгара идек.

Нургали. Байларның котын алган «Яшен»ме? Хәтта патшаның үзен дә... Син шуны чыгаручы Тукаймы?

Тукай. Әйе.

Нургали. Малай!.. Юк, Тукай абый! Зинһар, ачуланма, минем белән кузна уйнагач, үзем белән тиңгә куеп, килеп йөрдем монда. Ә син, баксаң-күрсәң, әнә кем икән!

Тукай. Кәҗә Галигә дус булуны үзем өчен бәхет саныйм.

Нургали. Тукай абый, беләсеңме, син бит изгеләргә охшаган.

Тукай. Бәлки җеннәргәдер?

Нургали. Күңеле изге кешенең җенгә охшавы мөмкин түгел.

Тукай. Мин бөтен кешегә дә изге түгел, Нургали дус.

Н у р г а л и. Анысы капкорсак байлар, ишаннарны мин дә яратмыйм.

Т у к а й. Ә попларны?

Н у р г а л и. Кит, попларны яратсаң, дүрәк, алла сугар.

Т у к а й. Кулы булса.

Н у р г а л и. Тәүбә диген, исәр. Алла турында шулай әйтәләрмени?

Т у к а й. Курыкмаганнар әйтә...

Н у р г а л и. Әйтүен әйтә, ә соңыннан үкенәдер дә мужыт. Тел очыннан ычкындымы сүз, оча инде ул. Әнә бит Яңа бистәнең хәзрәт улы Фатих мәхзүм алланың үзенә дә түгел, фәрештәләренә генә тел тидергән икән дә, суккан да еккан, ди, моны алла. Хәзер ята, ди, түшәк өстендә. Инде аллаһе тәгалә кәмитче Камалны сугачак, имеш, диләр.

Т у к а й. Ә Тукайны? Мине диюем?

Н у р г а л и. Син беренче булгансың да бит... Күрәсең, аллаһе тәгалә, изге яклярыңны искә алып, чиратны үзгәрткәндер.

Т у к а й. Кем сөйләде сиңа мондый сүзләрне?

Н у р г а л и. И Тукай абый. Мәзәк кеше син. Печән базарының теле бер генәмени... Мең аның теле. Йөз мең! Бер Мөхәммәтҗан Хафизда гына җитмеш җылан теле бар.

Т у к а й. Җитмеш җылан теле? Ха-ха-ха! Ну, шәп әйттең. Карале малай, Кәҗә! Син бит үзең шагыйрь. Чын, чын! Менә дигән сатирик. Кил безгә эшләргә. Кеше талаучы байларның да, карагруһ ишаннарның да тетәбез тетмәләрен. Патша хәзрәтенең үзен дә читтә калдырмабыз.

Н у р г а л и. Патша?! Ярабби! Менә син нинди кузначы малай икән, Апуш... Юк, Гаптулла абый, мин абайламый гына килеп кергәнмен монда. Зинһар, мине патшага, аллага каршы котыртма. Политсә ишетсә...

Т у к а й. Юкка куркасың. Синең белән без — бергә булганда — полициядән дә, патшаның үзеннән дә көчлерәк. Менә кара әле безнең «Ялт-Йолт»ны. *(Өстәлдәге нөсхәләрнең берсен бирә.)*

Н у р г а л и. Политсә күрсә... *(Куркып кына ала.)*

Т у к а й. Күрсен! Без моны цензор рөхсәте белән чыгарабыз. Димәк, патша рөхсәте белән. Дөресен әйтим, без патшадан рөхсәт алу өчен... тәүбә кылган булдык. Хәйләсез дөнья — файдасыз.

Камал керә.

К а м а л. Сәлам, Тукай. Урманчы юкмы әллә?

Т у к а й. Бәлки, бүген булмас та...

К а м а л. Димәк, бөтен йөкне сиңа ташлады.

Т у к а й. Йөк тартырга мин өйрәнгән. *(Нургалиге күрсәтеп.)* Таныш бул: минем дус — Нургали. Иске бистә белән Яңа бистә кузначыларының короле. Ә бу инде, Нургали дус, Галиәсгар абзаң Камал була. Кәмитче Камал. «Яшен»не дә, хәзерге «Ялт-Йолт»ны да яшьнәтүче...

К а м а л. ...ләрнең беренчесе синең дус Тукай булса, икенчесе *(кул биреп)* мин булам. Тукайның дусты булгач, димәк, ышанычлы. Тукай дусларны белеп сайлый ул.

Н у р г а л и. Мин кузначы малай Апушның гына дусты.

К а м а л. Апуш барыбер Тукай инде ул. Тукта! Мин таныйм бит сине. Базарда кашык сугып җырлаучы бит син.

Н у р г а л и. Әйе шул.

К а м а л. Ха-а! Коеп куйган артист! Сине Карига да әйттем. Артист итеп театрга ал, дидем.

Н у р г а л и. Театрга? Аллам сакласын! Әле җырлаган өчен дә шундый итеп кыйнадылар... Борынымнан каннар китте. Әгәр базарга аяк бассаң, башыңны өзәбез диләр.

К а м а л. Син курыктыңмы шуннан?

Н у р г а л и. Курыкмыйча, башсыз нишли алам мин... Хәзер поездларда гына җырлап йөрим. Арча белән Казан арасында.

К а м а л. Әйтәм без эзләп таба алмадык. Хәер, үкенечле булмаган. Куркаклар артист була алмый. Борынны канаттылар дип качып китсә инде ул... Булмый! Артист икәнсең, Нургали дус, борынны канатты дип кенә качма инде син. Башыңны өзәбез дисәләр дә, качма! Нык тор! Җырыңны җырла. Егылсаң, торып бас. Тагын җырла! Бигрәк тә Тукайның дусты булгач...

Т у к а й. Һәм минем дә диген.

К а м а л. Әйе, минем дә дус булгач, сугышырга өйрән! Берәү борыныңны канатса... Син аның авызын канат!

Н у р г а л и. А! Сез бит моны шаяртып кына әйтәсез...

Т у к а й. Юк, бик чынлап әйтәбез, Нургали дус.

К а м а л. Менә яңа номерга дигән материалны укып китердем. *(Язу бирә.)* «Доносчы колагына» дигән баш астына. «Прости, мамаша» көенә, дип өстәдем.

Т у к а й. Бик шәп! Менә дигән булып чыга. Нургалидән шикләнмә. Үз кешебез.

К а м а л *(укый)*.

Ташдыйн битәр катысың!
Үләксәдән сасысың!

Һәркөн донос ясыйсың!
Вөҗдансызың тидия!
Һәр фетнәнең башысың!
Иблиснең юлдашысың!
Милләт башын ашыйсың!
Хәрам корсак тидия!
Бер көн череп ауларың,
Өзелеп чыгар бауларың!
Файда бирмәс дауларың!..

Т у к а й. Әйбәт әйтелгән. Әгәр Ишми ишан белән Сәләхи бай укыса, күзләре шар була. Имзасы ничек?

К а м а л. Бичура. Ягъни өй парие.

Н у р г а л и. Өй парие? Ой?!

Т у к а й. Доносчыларның да, полицмейстерның да котын алабыз. Ха-ха-ха, синеңчә ничек, Нургали дус?

Н у р г а л и. Әйбәт тә бит, тик политсәмастер булгач...

Т у к а й. Әллә безнең белән дуслашканга үкенәсезме?

Н у р г а л и. Юк... Тик мин сезнең кебек була алмам, мөгаен.

К а м а л. Син тырыш! Беләгең таза. Йөрәгең дә ярыйсы кебек.

Н у р г а л и. Ярыйсы гына шул. Ә монда... Ай-яй. Йөз арыслан йөрәге кирәк... Ярый, абыйлар. Эшегез күптер. Мин китим.

Т у к а й. Нургали дус, «Ялт-Йолт»ны ал. Бу сиңа.

Н у р г а л и. Үземә үкме?

Т у к а й. Әйе.

Н у р г а л и *(алып)*. И Тукай абый, рәхмәт инде. Сиңа да рәхмәт, Камал абый. *(Китә. Шунда ук әйләнеп керә.)* Әлеге мөнәҗәтне «Печән базары»нда җырласам, ачуланмассызмы?

Т у к а й. Чәйдәш байдан курыкмасаң.

Н у р г а л и. Кагылып кына карасын. Без — Бисто малайлары җыелып алсакмы... Кая керер урын тапмас Чәйдәш бай. *(Китә.)*

К а м а л. Шәп егет бу.

Т у к а й. Тукай дусларны сайлый белә дип үзең әйттең ич.

**Акбирдин керә.**

А к б и р д и н. Сәламе галәйкем, дуслар!

К а м а л. Вә галәйкем, Ак пәри!

А к б и р д и н *(эшләпәсен салып, югары күтәрә)*. Милләтебезнең халыкчан вәкилләренә дан һәм хөрмәт!

К а м а л. Халыкчан булмаганы кемнәр инде?

А к б и р д и н. Аның бары байларын, хаҗиларын гына милләт дип санаучылар. Ә безгә — үз көннәрен үзләре күргән фәкыйрь-фокырә, эшче һәм игенче... Менә кем ул милләт.

К а м а л. Дөрес сукалыйсың.

А к б и р д и н. Минем өчен, Тукай һәм сез, Галиәсгар ага, үрнәк кешеләр. Реакция шаукымы бәреп аударган җирдән сәламәтләнеп, «Ялт-Йолт» булып аякка баскан яшенчеләр.

К а м а л. Үзеңдә дә ялкын ярыйсы хәзер. Аеруча соңгы мәкаләң...

А к б и р д и н. Мин дә сынатмаска тырышам. Бергәләшеп барган җирдән абынып калсам, оят булыр иде. Тукай һәм аның тормыш юлы, киләчәге турында, уй һәм хыяллары хакында бер рисалә язып чыгара алсам...

Т у к а й. Әй, Рәфыйк, дус син, әмма рисалә дигән сүзең...

А к б и р д и н. Син үзеңә-үзең кыйммәт түгел икән, милләт өчен кыйммәт, халкыбыз өчен. Минемчә, Галиәсгар ага да хуплый моны. Бу турыда Ямашев белән дә сөйләшкәнем бар. Тагын да сөйләшәчәкмен. Син, Тукай дус, тылсымлы иҗатыңны дәвам ит. Яз да яз. Аеруча үзебезнең сул канат кешеләре фикерен куәтләп җырла. Юк, юк! Патшага, династиягә каршы дигән сүзем түгел. Киресенчә, Романовлар нәселнәсәбенә кайнар мәхәббәт күрсәт.

Т у к а й. Ничек, ничек?! Кайнар мәхәббәт?

А к б и р д и н. Күз буяу өчен. Падиша яраннары сөенсен, мактансын хәтта. Ә икенче җырыңда халык өчен үз фикереңне әйт. Халык күңеленә хуш килерлек шигырь яз. Милләтебез әһелләре, мулла-мунтагай тел тидермәсен өчен, динебезне дә яманлап ташлама. Кирәкми. Әнә бит «Васыятем» шигыреңне муллалар, олы хәзрәтләр нинди яратты. Бәрәкалла диде күбесе, Габдулла әфәнде саф иманлы ходан зат икән ич, дип үзеңне күккә күтәрделәр.

К а м а л *(шаркылдап көлеп)*. Күтәрмичә бит. Миңрәү сарык сыман миңрәү булгач... Әгәр ул муллалар Габдулла абзыйның «Васыятем» шигыре үткен сатира, үзләреннән көлү өчен язылганын белсәләр идеме... Һи-и...

А к б и р д и н. Юк, Галиәсгар ага, син мине нәрсәнең сатира, нәрсәнең сатира түгел икәнен аңламый торган бер ахмакка санама!

К а м а л *(көлеп)*. Соң инде, акыллы баш булсаң, уйлап кара, егерме өч яше тулыртулмас сап-сау егет, үз җанына үзе мөрәҗәгать итеп: И нәфесле җаным, бар, юнәл,

кит таңрецә, диме? Ха-ха-ха! Ну, акыл үзендә...

Акбирдин. Бу, бу... бу инде, Галиәсгар ага, гәрчә үзең мәшһүр мәзәкче булсаң да, «Васыятем»гә шундый аңлатма бирү, бигрәк тә Тукайның үзе алдында...

Камал *(елмаеп торган Тукайга карап)*. Мин үземчә аңлыйм. Юл асты мәгънәләрен дә аңлый алам. Әйе, әйе, җаннарым, коеп куйган һөҗү — сатира бу. Мулла-мунтагай һәм ябалак баш агайларның ахмаклыгыннан көлү. И моны «Яшен яшьнәгәндә» шигыре бик яхшы ачыклый.

Акбирдин. Яшен яшьнәгәндә? *(Тукайга карый.)*

Тукай. Ул әле дөньяга чыкмаган. Бары тик Камалга укыдым.

Акбирдин. Бәлки мине дә таныштырырсың?

Тукай. Сине?! *(Уйланып тора.)*

Акбирдин. Сер булмаса, билгеле?

Тукай. Синнән яшерен бер серем дә юк, Рәфыйк.

Камал. Тукай рөхсәт итсә, үзем укып күрсәтәм. Гаҗәпләнмә, Тукайҗан, дүрт юлны да хәтердә саклый алмасам, нинди мөһәррир булыр идем мин.

Тукай. Я, я, укып кара әле.

Камал *(тамак кырып)*. Эһем!

Куркытма син, алла, яшен белән,—
Барыбер мин курыкмыйм, яши белəм.
Куркытсаң да — курыкмыйм, аязымны
Сатып алдым аһым, яшем белән!

Акбирдин *(нык тәэсирләнеп, бер Тукайга, бер Камалга карый)*. Бу инде чынчыннан гыйсьян! Бунт! Аллага каршы. Юк, аллага гына да түгел...

Камал. Ә син «Васыятем»не чын васыять дисең.

Акбирдин *(Тукайга карап)*. Боларны дөрес аңлатучы — Тукай, бары тик Тукай үзе, минемчә.

Тукай. Барысы да шунда... язылган.

Акбирдин *(паузадан соң)*. Хи-хи-хи! Яшә, Тукайҗан! Дөресен әйткәндә, мин үзем дә ярым дәһри, динсез. Аллага да ышанмыйм, патшага да!

Камал. Чү, чү, Рәфыйк. Алла ишетмәсә, патша ишетүе бар.

Акбирдин. Икесе дә нипочем!

Тукай. Oho!.. Ярый, Галиәсгар, озын сүзебезнең кыскасы шул булсын, бөтен әңгәмәне бер читкә куеп, укыйк әле шушы язманы. Рәфыйк дустыбыз бәя бирсен. *(Донос турындагы шигырьне Акбирдинга бирә.)* Менә «Ялт-Йолт»ның алдагы саны өчен әзерләнгән мөнәҗәт. Синә да ошаса, бер төзәтмәсез редакторга бирәм.

Акбирдин *(укый)*. Доносчыга. «Прости, мамаша» көенә. *(Сикереп тора.)* Ха-ха-ха! Кызык.

Тукай. Укы, укы!..

Акбирдин *(укый)*.

Ташдыйн битәр катысың!
Үләксәдәй сасысың!
Һәр көн донос ясыйсың!
Вөҗдансызсың...

Камал. Укы, укы!

Акбирдин. Бер көн череп... өзелеп
чыгар бауларың...

Файда бирмәс дауларың... Шәп! Ха-ха-ха! Ну кирәген биргәнсез Ишми ишанның.

Тукай. Ишми ишаннан мәкерлерәкләренә дә өлеш бар.

Акбирдин. Бар, бар, сизелә.

Камал. Без әле һәркайсының исем шәрифләрен атап, баганага ябыштырып куячакбыз. Халык, милләтебез үз «дусларын», үз араларында нинди хәшәрәтләр барлыгын белеп торсын.

Акбирдин. Ш-шәп! Әйтәм бит милләтебез каһарманнары сез, дип. Сүз бирәм: Габдулла турында рисаләне уңышлы тәмамласам, икенчесе сезнең турында булачак, Галиәсгар ага!

Камал. Рәхмәт! Тәшәккердән гаҗизмен! Иншалла, мин дә бурычлы булып калмам.

Акбирдин. Билгеле инде, дуслар ашы — кара каршы. Ярый, очтым! Мин әле үтеп барышлый. Габдулла дусны күреп чыгыйм дип кенә кергән идем. *(Китә.)*

Камал. Сәер кешегә әверелде кебек хәзер синең дус.

Тукай. Уртак дустыбыз дип сөйлә.

Камал. Ярый, калдырыйк аны. *(Әкрен.)* Кичә Хөсәенне күрдем. Ул «Ялт-Йолт»ның соңгы номерын мактады.

Тукай. Журналның әһәмиятен ул аңлый. Бу мөнәҗәт ярыйсы гына килеп чыкты. Ә алдагы көнгә бөтен шарлатаннарны көйдереп ала торган бернича куплет бәет үзең дә яз.

Камал. Чамалармын.

Тукай. Шәһәребезнең серләрен ачу ни хәлдәрәк?

Камал. Ярыйсы бара. Мөртәт Мөхәммәтҗанның сыртын ярыйсы каезладым. Үткезеп! Сәхнәдә Кариев дус та уйнаса...

Тукай. Роле булса, үкертеп уйный... Димәк, театрга язык?

Камал. Шулай дип өмет итәм.

Театр — мөкатдәс ул, бөек ул, гали зат ул;

Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул!

Акбирдин ишекне ача да тукталып кала. Аннан соң әкрен генә яртылаш ябып куя.

Тукай.

Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,
Әгәр һиммәт агачыннан өзелсә!

Камал *(әкрен)*. Хөсәен иртәгә безне кунакка чакырды. Кариев белән Сакайны да. Башкаларга сиздереп торма. Кызлардан качып Бакалтайга барам дисәң, барысы да ышаначак.

Акбирдин *(ишекне киң итеп ачып керә)*. Бигайбә, дусларым, сезнең турыда рисалә ди-ди эшләпәмне онытып калдырганмын.

Камал. Ярый әле башыңны онытып калдырмагансың.

Акбирдин. Алла саклый анысын. Акыллы башым һәрвакыт үзем белән *(эшләпәсен тотып, реверанс ясап)*. Бигайбә, тагын бер кат бигайбә, дусларым. *(Китә.)*

**Тукай белән Камал аптырашта калалар.**

**Картина.**

**VIII**

**Дубасов кабинеты.**

Дубасов *(ачулы, кискен хәрәкәт ясап)*. Иртәгә Алафузовтан — Сидоровны, Пороховойдан — Буторинны минем янга! Әгәр шушы атна эчендә кайда, кемнәр һәм нинди кораллар туплавын фаш итеп, Питерга хәбәр итә алмасак, нәрсә көткәнен аңлыйсыздыр...

Быков. Аңлыйм...

Дубасов. Питердан килгән кешенең кем булуы һәм кемнәр белән эш итүе дә томан эчендә.

Быков. Ачыклыйбыз.

Дубасов. Тик озак... *(Папирос кабыза.)*

Быков. Сезне Акбүре көтә.

Дубасов. Керсен.

**Быков папкаларны алып чыга.**

Акбирдин *(керә. Кәгазь бирә)*. Ямашев турында координатлар.

Дубасов. Ямаш бездән котыла алмас. Күбрәк ул айкый кешеләр йөрәген. *(«Ялт-Йолт» журналын алып.)* Нәрсә бу?

Акбирдин. «Ялт-Йолт».

Дубасов. Барыбер яшен! Яшен! Ә цензор йоклый.

Акбирдин. Алдагы номер тагын да зәһәр булачак. «Прости, мамаша» дигән булып сездән дә шундый усал көлә. Патшадан да көлү бу, минемчә.

Дубасов. Башын өзәчәкмен мин аның! Башын!..

Акбирдин. Шулай да бөтен бәла — Ямашта.

Дубасов. Беләм. Астан торып казый безгә каберне. Ә Тукайлар өстә — легаль, ачыктан-ачык. Патшаның үз рөхсәте белән яндыра, айкый дөньяны... Һаман шул Дума бәласе... Эх-хе хе!.. Ямашевны кулга алу — әле анардан котылу түгел. Рәшәткә аша да ул Тукайларга план корып бирәчәк. Шуңа күрә иң яхшысы... *(Мәгънәле хәрәкәт ясый.)*

Акбирдин. Юк!.. Ямашевның дуслары күп, сизгер. Шау-шу күтәрүләре мөмкин. Аның партиясендәге кешеләр барыбер исән-сау кала. Ачулары кабарып, актив рәвештә корал туплап...

Дубасов. Ко-корал?.. Бәлки бу турыда хәбәрең бардыр?

Акбирдин. Төгәл үк түгел. Шулай да кайбер җеп очлары...

Дубасов. Во-во-вот... Шул җеп очын табып, барын да актарып чыгарырга. Кайда, кемнәрдә яшерелгән ул...

Акбирдин. Аларны Ямашев эзеннән барып кына табып була. Коралларны янында, җинаять өстендә фаш итеп...

Дубасов. Во-во-вот, бөтен шайкасы белән! *(Пауза.)* Утыр әле. Бу көннәрдә Тукайның хәле, сәламәтлеге ничегрәк?

Акбирдин. Шәптән түгел. Һаман ютәлли. Шулай да Әстерханга китәргә җыена. Рәмиев янына. Рәмиев үзе чакырган аны.

Дубасов. Менә ничек? Бу — кызыклы хәбәр. Ул барып, әйләнеп кайту белән барын да белешеп безгә хәбәр итәрсең.

Акбирдин. Сәгате-минуты белән үк, Николай Николаевич.

Дубасов. Кариев белән Сакаевны да күздән ычкындырма.

Акбирдин. Минемчә, Ямашев белән бер шайка алар.

Дубасов. Фа-фа-факт кирәк. Кайда, кайчан очрашалар? Сунчаләйләр, теге елны

прокламация тараткан Шәриф, Сәгыйть кайда?

Акбирдин. Авылда, укытучы алар.

Дубасов. Кичә авылда, бүген мо-монда булулары мөмкин.

Акбирдин. Шәриф — прокламация таратучы гына түгел, бишенче ел якшәмбе вакыйгасын сылтау итеп, Әхтәриев белән семинария залындагы падишаһ портретын, төн уртасында кереп, ерткалап ташлаган кеше.

Дубасов. Подлец! Һәм ул үз вакытында ачылмыйча җәзасыз калды. Тукай белән Сәгыйть Сүнчәләй — якын дуслар. Бәлки бергә-бергә Ямашев белән очрашалардыр, ә? Казанга килгән арада? Тагын шул: сиңа социал-демократ-большевиклар партиясенә керергә кирәк!

Акбирдин. Большевиклар?

Дубасов. Курыкма! Сиңа хәвеф-хәтәр булмас.

Акбирдин. Хәвеф-хәтәр Ямашевлар ягыннан булачак. Ул минем элекке эсер икәнемне яхшы белә.

Дубасов. Син — күптән эсерлыктан киткән кеше. Тәүбә итеп, төрмәдән чыгарылдың...

Акбирдин. Сезгә турылыклы хезмәт итү бәрабәренә. Ямашев моны белми, билгеле. Әмма шикләнә, дип уйлыйм.

Дубасов. Революцион мәкаләләрне син житәрлек яздың.

Акбирдин. Аларның да задание белән язылганын сизенүләре мөмкин. Конспирациянең нечкә серләрен үзләштергән «Урал»чы ул. Шулай да тырышып карармын.

Дубасов. Во-во-вот! Башта ышаныч казан. Тик кара, ялагайланма! Ялагайдан шикләнә алар. Уңыш телим.

Акбирдин. Хушыгыз, Николай Николаевич! *(Китә.)*

Дубасов *(уйланып, ишекле-түрле йөренә).* А годы проходят, лучшие годы...

Быков *(кереп).* Господин полковник... Первой гильдии купец Сәләхи Гимранович Сезне күрергә тели. Ялгызыгызны.

Дубасов. Ну что ж! Тик кара аны. *(Ымлап күрсәтә.)*

Быков. Аңлыйм. *(Китә.)*

**(Сәләхи керә. Кулында саквояж.)**

Дубасов *(каршы алып).* О-у, Сәләхи Гимранович.

Сәләхи. Здоровья жилаю, гуспадин палкаүник. *(Як-ягына карана.)*

Дубасов. Үзебез генә. *(Урын күрсәтеп.)* Утыр, Гимранич.

Сәләхи. Иң элек бүләкне рәхим ит. Кхх, тф, тф.

Дубасов *(саквояжны ачып).* О-у! Бик юмарт син, Гимранич.

Сәләхи. Татар баеның күңеле киң.

Дубасов. Беләм, беләм, күңел киң, кесә калын...

Сәләхи. Шөкер анысы. Тик, тагын бәла килде башка. Кхх-тф.

Дубасов. Бәла? Нинди бәла?

Сәләхи. Һаман шул, Тукай ләгыйн. *(«Ялт-Йолт» журналын күрсәтә.)* Тагын яшьнәтә яшенен. Телен генә киссәгез икән шул афәтнең. Кул-аягын бәйләп, кхх тф, тф, төрмәгә утыртсагыз, бераз хәл алыр идек. Шул Тукай дигән ата шайтаннары булмаса, башкасының койрык кысыла. Кысыла. Хи-хи-хи, тф, тф!.. Шул җылан телдә төп бәла.

Дубасов. Ләкин Тукайның, аның дусларын да патшага, байларга каршы котыртучы кеше — большевик Ямаш...

Сәләхи. Бәлшәүник?! Ишеткәнем юк андый кешене.

Дубасов. Хөсәен Ямашевны ишеткәнең юкмы?

Сәләхи. Минһаҗетдин малае Хөсәенмеме? Һи! Аны бала чагыннан ук беләм. «Мөхәммәдия»дә укыганда әйбәт шәкерт ие, субака. Тәүфыйклы, диндар. Учительскигә кучкач, бозылды.

Дубасов. Стало быть, яхшы беләсең?

Сәләхи. Һи-и, белмичә. Минем дус Бадамшинның кызы Хәдичәгә өйләнде. Ну шәп тә кыз ие, ефәктәй шома, сылу. Әрәм генә итте шуны, динсез сусиялис! Йөри хәзер качып-посып.

Дубасов. Дусыңның кияве булгач, сиңа да киләдер...

Сәләхи. Миңа?! Аллам сакласын! Әллә мин сусиялисмы?

Дубасов. Үзеңне яратмаса, кызың... я...

Сәләхи. Кызларым кияүдә. Хатыным янына дисәң, тешсез әби ул. Асравым янына гына килмәсә. Кх-х-хи-хи, тф, тф!

Дубасов. Асравың янына да килүе мөмкин.

Сәләхи. Юк! Асрауларыма үзем күзколак.

Дубасов. Анысы шулайдыр. Син ышанычлы кеше...

Сәләхи. Патша хәзрәтләре өчен җаным фида.

Дубасов. Утыр, утыр, Гимраныч. Моннан соң Ямашевка да күз-колак булсаң...

Сәләхи. Булам, алла бирсә, дусым кияве дип тормам...

Дубасов. Во-во-вот...

Сәләхи. Тик син, господин пәлкәүник, Тукай мәлгуньне авызлыкла, телен кис. Яшен булып яшьнәү түгел, дөньяда ук яши алмасын. *(Акча чыгарып.)* Менә, бисмилла-һи, шул күрсәтәчәк изгелегең өчен ал әле тагын йөз сум, юк, ике йөз...

Дубасов. Что сез...

Сәләхи. Алыгыз, ал... Сәдака булыр... Алла өчен.

Дубасов. Шу-шулай дисәң генә... *(Ала.)* Рәхмәт! Юмарт, юмарт сез, татар байлары.

Сәләхи. Урыс байларыннан калышмаска тырышабыз.

**Пәрдә**

## Икенче бүлек

### IX

### Тукай бүлмәсе

Тукай. Нинди зур талант безнең халыкта *(көйләп)*.

Бик сагынсам, айга карыйм,
Ай да ялгыз минем күк.
Җәүһәр жыр. Ә нинди мәгънә.

**Ишек шакыйлар. Тукай ишетми. Уйлый, яза, Сәгыйть Сүнчәләй керә.**

Сәгыйть. Дөньясын оныткан... Тукай, шаштыңмы әллә?

Тукай. Ә?.. Шаштым, Сәгыйть. Нинди көч, нинди дәрт, тапкырлык! Кешене кеше иткән бөек көч — аның теле, сөйләшә белүе генә түгел, жыры, моңы, әкияте, гореф-гадәтләре. Милләтләрне милләт иткән сәләтләр дә шулар. Дөресен әйткәндә, әдип ул безнең халык, бөек шагыйрь... Лекциямне нәкъ шул турыда сөйләячәкмен.

Сәгыйть. Лекция?..

Тукай. Халык әдәбияты турында лекция сөйләргә җыенам. Чү! Син бит күптән инде авылыңда — Сараштa идең.

Сәгыйть. Сараштa идем дә... Синең хатны алу белән юлга чыктым. Синең янга.

Тукай. Тукай түгел, басылып ята торган китабың — «Шильон мәхбүсе» тарткан сине.

Сәгыйть. Анысы да бар.

Тукай. «Шильон» — яхшы ук уңышың синең. Дөрес, кайбер тәгъбир һәм кафияләрең[1] тирәсендә каләм йөрттем бераз. Ләкин килергә ашыккансыз.

Сәгыйть. Матбагага кереп белештем. Ике айсыз чыкмас, диделәр. Басылгач бер үк данәсен үзең җибәрерсең, шәт?

Тукай. Җибәрәм, билгеле. Кайчан китәсең?

Сәгыйть. Бүген өлгермәсәм, иртәгә. Кибетләрдә йөреп, Фәридәнең йомышларын йомышлыйм да...

Тукай. Күптән шулай жанкәшем йомышлары китерде дисәң...

Сәгыйть. Бәбәебез бар!

Тукай. У-у, бәрәкалла! Котлыйм! Өлгер син, Сәгыйть, шигырьгә дә, бәбәйгә дә.

Сәгыйть. Анысы, аллага шөкер. Ә син һаман ялгыз. Зәйтүнә белән арагыз ничек соң?

Тукай. Син генә ичмасам бирмә бу сәвальне.

Сәгыйть. Ярый, монысы калсын. Минем борчыганы — хатыңда язган «Өзелгән өмет»ең синең.

Тукай. Ул турыда да сөйләшмик... Үзең турында сөйлә. Нәрсәләр язасың?

Сәгыйть. Вак-төяк шигырьләр... Ә житдирәге — «Әлмансур»ны тәрҗемә итә башладым.

Тукай. Генрих Гейне? Шундый катлаулы әсәрне! Юк, бу инде шигырьгә, тәрҗемәгә житди караш түгел, Сәгыйть!

Сәгыйть. Димәк, минем көчемә ышанмыйсың?

Тукай. Ышанмыйм да түгел... Син бит татар шагыйре, иҗатыңда Байрон, Надсон, Гейне...

Сәгыйть. Аларны тәкъдир[1] итмисең?

Тукай. Гейне белән Байронны тәкъдир итмәсәм, җир йотар иде. Әш анда түгел, кайда синең үз тормышың? Үз халкың?

Сәгыйть. Ай, кояш һәм нурлы йолдызлар сүнәрләр сүнсәләр.

Тик татар бетмәс, татар сүнмәс... Яшәр! Бу юллар халкыма мәхәббәт турында сөйләмимени?

---

[1] Кафия — рифма.

[1] Тәкъдир — (бу очракта) тану, бәя бирү.

**Тукай.** Татар-татар дип кенә кычкыру ул халкын тормышын язу түгел әле. Аның көнкүреше, халәте рухиясе кайда?

**Сәгыйть.** Шүрәлесе, Мияубикәсеме?

**Тукай.** Әйе! Әллүкие, җыры, моңы, әйтемнәре, табышмагы...

**Сәгыйть.** Димәк, шигырьләремне шигырьгә санамыйсың?

**Тукай.** Алай димим. Синең «Җыен», «Татар хатыны» дигән шигырьләрең турында яхшы ук югары фикердә мин.

**Сәгыйть.** Шулай булгач?

**Тукай.** Болар гына аз. Син барыбыздан да яшьрәк. Дәртле!

**Сәгыйть.** Үз халкыңны инглиз, немец, шагыйрьләре иҗаты белән таныштыру аның рухи байлыгына хәзинә өстәү түгелмени?

**Тукай.** Гейненың алтын поэзиясен үз телебездә дә алтын итеп бирә алсаң, яхшы, бик яхшы. Тик шулай да тәрҗемәне, безнең белән аралашып яшәгән рус шагыйрьләре, әдипләре — Пушкин, Толстой, Тургенев, Горькийлардан башласак, халкыбыз меңмең рәхмәт әйтер иде. Ни әйтсәң дә, инглиз, немец әсәрләре синең белән миңа — тәрҗемәдән тәрҗемә. Рус теле безнең өчен икенче ана теле.

**Сәгыйть.** «Шильон мәхбүсе»н яхшы дидең бит.

**Тукай.** Һәр яктан мөкәммәл дисәм, шигърияткә дә, шулай ук үз-үземә дә монафыйк[1] булган булыр идем.

**Сәгыйть.** Димәк, «Шильон»ны бастырып чыгаруың мине кызганып кына иде? Ә мин җүләр, дивана, шатланам тагы. *(Кулындагы кәгазьне кисәсенә сала.)*

**Тукай.** Кызма, Сәгыйть, борчылма да! Беренче тәҗрибә мөкәммәл булып бетми. Үзем тәрҗемә иткән Лермонтов «Пәйгамбәр»ен дә камил тәрҗемә дигән фикердән ерак торам. Тукта, миңа бирергә җыенган кәгазеңне нигә кесәңә салдың?

**Сәгыйть.** Әлегә үземдә торсын.

**Тукай.** Дуслыгыбызга хыянәт итмә, Сәгыйть! Миңа бирергә теләгәнсең икән, бир! Хәзер үк!

**Сәгыйть.** «Әлмансур» тәрҗемәсенең беренче юлларын күрсәтеп киңәшим дигән идем дә...

**Тукай.** Алайса бигрәк тә. Бәлки файдалы киңәш бирермен.

**Сәгыйть.** Ярый инде, мә, укы!

**Тукай.** Үзең генә укы. Син бит бераз артист та, музыкант та кеше. «Әлмансур»— башлыча сәхнә өчен язылган әсәр.

[1] Монафыйк — ике йөзле, икейөзле кеше.

**Сәгыйть** *(укый).*

Я бабайларның сарае, син әлек
нинди идең,
Иске булсаң да хәзер, җаңга сөекле
һәр җирен.
Бу менә изге бабайлар таптаган
хәтфә палас,
Мескенем, кискән көя, беткән нәфис
рәсмен синең.

**Тукай.** Укы, укы!

**Сәгыйть.** Бары шул.

**Тукай.** Минемчә, бу... чын шигырь, Сәгыйть. Чын шигърият! Саф үзебезчә. Юк, бу инде «Шильон мәхбүсе» түгел. Тәҗрибәле кул эше. Тәрҗемәне дәвам иттер, Сәгыйть. Мин догада!

**Сәгыйть.** Рәхмәт.

**Тукай.** Тагын әле ачу белдереп әйтәсе зур сүзем бар.

**Сәгыйть.** Ачу белдереп?!

**Тукай.** Балалар өчен кыйраат[1] дәреслеге төзим дип язуыма каршы — нигә шундый вак-төяк эш белән вакыт әрәм итәсен, дип яздың.

**Сәгыйть.** Әйе, яздым, әле дә әйтәм.

**Тукай.** Әле дә?! *(Кулындагы кәгазьне йомарлап ыргыта.)* Шагыйрь сүзе, укытучы сүзе түгел бу, Сәгыйть! Кешеләр үз балаларын тәрбия итмәсә, йөрергә, сөйләшергә, җырга, моңга, хезмәткә өйрәтмәсә, үсә төшкәч, укытмаса (кыза барып), кеше түгел, хайван булып үсәр иде алар. Бүреләр арасында үссә — бүре, дүрт аяклы ерткыч бүре булып. Бу турыда укыганың булмадымыни?

**Сәгыйть.** Укыдым... Әллә Һиндстандамы булган хәл...

**Тукай.** Алай булгач, нигә шундый ахмак сүзләр? *(Бүлеп озак йөткерә. Су эчә. Дару каба. Хәлсезләнеп, урындыкка утыра.)*

**Сәгыйть.** Син авырыйсың, Тукай.

**Тукай.** Утыр әле янымә. Әлеккечә тын гына утырыйк бераз. *(Тын гына утыралар.)* Бәлки җырларбыз, ә?

**Сәгыйть.** Җырга син оста.

**Тукай** *(әкрен генә җырлый).* И мөкатдәс, моңлы сазым...

**Сәгыйть** *(туктатып).* Башка җыр җырлыйк, Тукай.

**Тукай.** Дәртле җыр дисең? Анысы да була. *(Дәрт белән җырлый.)*

Бидрәсе бизәкле лә, көянтәсе үзәкле,
Баскан саен борылып карый, шунысы
өзә үзәкне.
Өй түбәсе дранча ла, әйләнә дә җил ача,

[1] Кыйраат — ятлау.

Безнең болай утырулар

боек күңелне ача.

*(Бармакларын шартлатып.)* Их-их-их! Боек күңелне ача. *(Сәгыйтьнең җилкәсен кочып.)* Борчылма, иптәшкәем! Яшибез әле без, яшибез!

Сәгыйть *(шундый ук дәрт белән).* Гөрләп яшибез!...

**Пауза.**

Тукай. Шулай да мин үз хәлемне үзем беләм, Сәгыйть. Хәлем шәптән түгел. *(Нык ышаныч белән.)* Шулай да бирешергә уйламыйм. Быел Питерга да барып кайту ниятем. Кәбир Бәкерне күреп, кайбер татар студентларын һәм... *(сарказм белән)* күз кырые белән генә булса да падишаһ сараен...

Сәгыйть. Күр, күр, һичшиксез күр!

Тукай. Аннан берәр тәҗрибәле докторга да күренсәм...

Сәгыйть. Менә, менә... монысы инде иң мөһиме...

Тукай. Шуннан Уфа, Троицкий тирәләренә барып кымыз эчү, дәваланy... Әгәр аннан биш-ун еллык көч, илһам алып кайтсам *(көлеп)*, ары таба тагын бераз чамаласам...

Сәгыйть. Әй, Тукай... *(кочаклый)* бер түгел, йөз кеше гомере бирер идем мин сиңа!

Тукай. Кирәкми! Берәгәйле бер гомер бик житкән. *(Пауза.)* Утыр әле яныма һәм тыңла! *(Сәгыйть Тукай янына килеп утыра.)* Сиңа бик яшерен серем бар. Тик бер шарт: аны берәүгә дә сөйләмисең, язмыйсың... Беркайчан да!

Сәгыйть. Димәк, үзем белән кабергә алып китәргә?

Тукай. Бары шулай гына. Чөнки ялгышуым мөмкин. Үлем куркытмый. Фаҗига куркыта.

Сәгыйть *(сагаеп).* Фаҗига?!

Тукай. Сүз Рәмиев турында...

Сәгыйть. Ул рәхәтләнеп эшли, яши дип беләм.

Тукай. Әстерханга аның өчен бардым. Үзе чакырды.

Сәгыйть. Беләм... яздың миңа.

Тукай. Пычакка пычак килгән чакларыбыз булса да, шатланып каршы алды. Нариман Нариманов, артист Зәйни Солтанов, укытучы Шаһит Гайфи белән таныштырды.

Сәгыйть. Серең нәрсәдә?

Тукай. Сер һәм фаҗига шунда... Шагыйрь Рәмиев юк... хәзер дөньяда. Үлгән! Аның урынына дөньяда күләгә йөри. Ашый, эчә, сөйли, мәкаләләр яза, шигырьләр дә яза кайчак. Гәүдәгә дә таза... Ләкин җан, ялкын, өмет, ышану юк. Берсе дә!

Сәгыйть. Илебездәге реакциянең ана да кагылуы табигый.

Тукай. Реакция барыбызның да канатын каерды. Рухыбызны төшерде. Мин дә элекке мин түгел, син дә син түгел хәзер. Прокламацияләр таратып йөрүче бишенче ел Сүнчәләйләре юк бүген дөньяда. Юк! Ләкин Рәминең бөтенләй башка. Үз күңеленә аваздаш булганга, күрәсең, Толстойның «Тере мәет» драмасын тәрҗемә итеп, газетада бастырган.

Сәгыйть. Гаҗәп хәл.

Акбирдин *(кереп).* Һи-и, кемне күрәм! Мелла Сәгыйть! Ике якын дус янына мине дә өстәсәк, өч дус — теләсә нинди крепостьны алырлык көч булабыз! Ә? Шулай түгелмени?

Тукай. Шулаен шулай да... *(Уңайсыз пауза.)*

Акбирдин. Таракан булдым, ахры. Үзара серегез бар икән, туп-туры әйтегез. Үпкәсез-нисез китәм дә барам. Чын, чын! Аңлыйм ла мин, егет белән егет арасында нинди сер булмас!

Сәгыйть. Бер төрле серебез дә юк, Рәфыйк.

Тукай. Бигрәк тә синнән, икебез өчен дә үз кешедән.

Сәгыйть. Дөрес!

Тукай *(паузадан соң).* Якын дусларга гына сыя торган серебез Рәми турында. Әгәр бу серемне кемгә дә булса ачсагыз, иң явыз дошманым булачаксыз. Мәңгегә!

Акбирдин. Аңлыйм. *(Сәгыйтькә карый. Ул да баш ия.)*

Тукай. Алайса шул: Әстерханда очрашкач, ачык итеп үзе әйтте: элекке Рәминең мин бары күләгәсе хәзер, мөгаен, гомерем буе шулай булып калырмын да, ди. Ул гынамы, кешеләр барысы да подлец, сатлык, аларның берсенә дә ышанма, хәтта якын дусларга да, ди. Тетрәттe мине бу сүзләре. Син дә бит кеше, дустым минем, сиңа да ышанмаскамы, дим. Әйе, ышанма! диде бу башта, соңыннан каһкаһәләп көлде дә,— юк, миңа ышан, сине дә, берәүне дә сатмаячакмын, ди. Шулай да миннән ераграк йөр, миндә махау зәхмәте кебегрәк беркайчан да терелеп булмый торган куркыныч зәхмәт, ди.

Сәгыйть. Махау кебек булса, шулай билгеле.

Тукай. Телем, өметем киселгәч, уйларым, хисләрем теткаләнгән, ди. Нәрсә икәнен үзе әйтмәде. Ләкин мин тетрәнеп, уй-

ланып калдым. Әйтерсең, газраил күктән төшкән дә: «Я идеалың, шигырең, дусларың,— я жаның!» — дип, бугазыннан алган, һәм ул аптырап калган.

Акбирдин. Коточкыч! Шундый көч, революцион рух иде бит аларда.

Сәгыйть. Тыңлап бетерик, Рәфыйк.

Тукай. Шиккә төштем. Тыным кысылды. Буыла башлагач, һавага чыктым. Жан тетрәткеч хәл. Якын дустың туганың булып күренә, ә ул — газраил сине үтерү өчен алладан әмер алган. Мине, сезне, Хөсәенне...

Сәгыйть. Син боларны Ямашка әйтергә тиешсең! Мондый зәхмәт күбрәк аның өчен хәтәр.

Тукай. Ул барыбыз өчен дә хәтәр. Мин Рәмигә ышанам. Ул безгә зыян китермәячәк. Ямашка да, берәүгә дә.

Сәгыйть. Мәетләр исәннәрнең бугазыннан ала.

Тукай. Рәми куркыныч түгел. Ә менә башкалар... Әйтәм ич, авыру да, үлем дә куркыныч түгел. Ә менә бер-береңә, хәтта дусларыңа да ышанмый яшәү... Фажига бу! *(Чайкалып китә.)*

Сәгыйть *(куркынып)*. Тукай... *(Пауза.)*

Тукай. Хөсәен — минем өчен бөек зат. Хөсәен кебек була алмаганыма кайчак көнләшәм дә.

Сәгыйть. Халкының моң-зарын, шатлыгын жырлаучы шагыйрь булу — үзе дә илаһи эш. Өч мең еллар элек үк әле Вавилон, юк, Мисыр шагыйре әйткән: патшалар, хакимнәр үләләр, алтын сарай, мәрмәр йортлар жимерелә, уала... Әмма шагыйрь, аның язганнары үзенә һәйкәл булып мәңге кала.

Тукай. Бу — Пушкин, даһи шагыйрь. Аның «һәйкәл»е.

Сәгыйть. Син мәшһүр, Тукай.

Тукай. Житте! Житте! *(Читкә борыла.)*

Сәгыйть. Шөһрәт ул — бәхет, дәрәҗә, яшәү стимулы.

Тукай. Һәм адәм баласының хурлыгы, көчсезлеге дә!

Сәгыйть. Түгел! Ул иҗат әһеленә шундый көч, илһам бирә, полководецка — гайрәт. Шул илаһи көч булмаса, Пушкин да Пушкин була алмас иде. Македонский, Тимерлан кебек бөек полководецлар да...

Тукай *(зәһәр белән)*. Адәм башларын кисеп тау өя алмаслар иде. Бабаларыбызның туган иле Болгарны, Россияне хәрабә хәленә китереп, халыкларны канга батырып...

Сәгыйть. Тарих күзлегеннән караганда, ул шәхесләрнең эше...

Тукай. Коточкыч! Кан коеп, халыкны коллыкка дучар иткән икән, Батыйханмы ул, әллә дәһшәтле Иоанмы — барыбер. Изге көч дигәнең халык бәхете өчен түгел икән, димәк, изге түгел. Сәнгать дөньясына да үз даны, үз мәнфәгате өчен генә тырышу — хурлыклы хәл. Югыйсә, тарихка кереп калу өчен Герострат нәфис храмны яндыра. Ә безнең Геростратлар... Берсе әллә ниләр яза. Әй, агу йоткан көчек!.. Синдәме ул Тукайны егарлык көч... Әнчек! Калдырыйк! Ләм-мим алар турында.

Сәгыйть. Ярый, ләм-мим икән, ләм-мим!

Акбирдин. Ләм-мим! *(Тынлык. Бераздан Сәгыйтькә.)* Авылга киткән идең, с приездом, дип әйтимме соң?

Сәгыйть. С отъездом, дисәң дә була.

Акбирдин. Казан шул Тукай белән миңа гына Казан. Авыл, билгеле, ожмах. Кайткач Шәрифкә сәлам әйт. Хөрмәтем зур аңа. *(Як-ягына карангалап.)* Бишенче, алтынчы елның утлы айларында зур эшләр эшләдек аның белән, ышанам, ул әле дә безнең уртак изге эшебезне дәвам иттерәдер?

Сәгыйть. Хәзер бары тик балалар укыта.

Акбирдин. Аңлыйм. Чор башка хәзер. Саклык кирәк. *(Әкрен.)* Яңа тактика кирәк бүген. Патша сурәтен ертырга түгел, хөр мәмләкәт, дип чаң да сукмаска, киресенчә, мактарга патшаны, нәсел-нәсәбен, династиясен... Кыскасы, уяулыгын томаларга охранканың, милләтебез хакы өчен...

Сәгыйть. Тез чүгәргә?

Тукай. Аягын үбәргәме патшаның?

Акбирдин. Юк, киресенчә... Мактарга һәм... *(Ым белән күрсәтә.)*

Сәгыйть. Нәрсә?! Провокациямe бу?

Акбирдин. Тссс... *(Пауза.)* Акыл һәм хәрәкәт! Жаена карап, хәл-әхвал ни куша... *(Пауза.)* Бу сүзләр шушында калыр дип ышанам.

Сәгыйть. Анысы өчен борчылма.

Акбирдин *(Тукайга)*. Бу юлы менә сиңа килүем. *(Төргәк чыгара.)* Иң шифалы дәва сиңа — алоэ гөле. Күкрәк авыруыннан.

Тукай. Күкрәк?! *(Кызып.)* Миндә бер авыру да юк! Үпкәм дә, йөрәгем дә сәламәт. Акылым да, шөкер аллага. Мә, ал!

Акбирдин. Тукай, мин бит күрәм, белеп торам, дустың синең.

Тукай. Дус булсаң, миңа бер авыру да такма. Үлем дә юрама! Ал алоэнны!

Акбирдин. Аш белән аткан дусыңа таш белән ату... Ярдәм итәргә теләвемә шулай карыйсың икән... *(Китәргә җыена.)*

**Тукай.** Кыздым бераз. Үпкәләмә! Икенче вакытка кил. Аңлашырбыз.

**Акбирдин.** Бу сүзләреңә рәхмәт, Габдулла. Ышан. Мин изге ният белән килгән кеше. Ярый, хуш! Сиңа да хәерле юл, Сәгыйть. Шәрифкә сәламемне онытма.

**Сәгыйть.** Онытмам. Хуш! *(Акбирдин китә.)* Аңламадым сине. Миңа гына сөйләргә җыенган серенне дә яшермәдең аннан.

**Тукай.** Нәкъ менә шикләнгәнем өчен сөйләдем дә. Патша охранкасыннан булса да, курыкмыйм! *(Пауза.)* Рәми турында әйтеп бетермәдем!.. Хөсәенгә карата Рәми бик яхшы фикердә. Рәми үлсә үләр, әмма Хөсәенгә карата әшәкелек эшләмәс! Менә сиңа берничә юл шигырь. *(Өстәл тартмасыннан кәгазь ала.)* Якын бер иптәшем, син аны беләсең, җырчы Солтан...

**Сәгыйть.** Рахманкулов?

**Тукай.** Әйе. Бер ахмаклык эшләде. Шул инде, тахил шәраб[1] баласе. Тәфсиленә кереп тормыйм. Хатасы иде бу аның. Дөнья бит! Шулай да кешеләр аңардан йөз чөерде. Якын дуслары да. Барысы да. Шул уңай белән шигырь яза башладым. Менә аерым юллары *(укый)*:

Сине ташлап бөтен дөнья, үзең фәкать
ялгыз калсаң,—
Белеп тор: мин чыгармын таш күңелләләр
арасыннан.
Күлеп тормам карап читтән, синең
бәхетең карасыннан...

Менә шул. Рәмигә карата да нәкъ шулай язар идем.

**Сәгыйть** *(тәэсирләнеп)*. Гали рух синдә, Тукай.

**Тукай.** Бик гади рух. *(Ютәлли. Күкрәген тотып тын гына утыра.)*

**Сәгыйть.** Тукай җаным, якын дустың булып үтенәм, әйдә авылга — Сарашка китәбез. Саф һава бездә, урман, зур елга... Май, сөт, катык... Кымыз да табарбыз. Сиңа тынычланырга һәм дәваланырга кирәк.

**Тукай.** Бөтен эшемне ташлапмы? Юк, Сәгыйть, булмый. Рәхмәт. Кулыма каләм тота алган чагымда мин язарга, әгәр алар әз генә булса да халкыбызның дәртен күтәрү, монархияне җимерү өчен ярдәм итә икән, язарга тиешмен! Соңгы сулышыма кадәр. Шуннан да яхшырак дәва, шатлык, бәхет юк миңа. Ә менә Ямашев белән сөйләшәчәкмен. Юк, Рәмиевне әләкләп түгел. Аңа ничек ярдәм итү турында киңәш сорап. *(Кесә сәгатен алып Сәгыйтькә бирә.)* Мә, Сәгыйть! Бүләгем бу сиңа!

**Сәгыйть** *(алып)*. Бу бит синең үзеңә кирәк.

**Тукай.** Мин янасын алырмын. Сиңа дуслык истәлегем булсын.

**Сәгыйть.** Тукай! *(Кочаклый. Үксеп җылый.)*

**Картина.**

## X

**Урам. Гафур Колахметовлар өе. Капка төбендә эскәмия. Суфия йөгереп керә дә, тукталып, артына борылып карый. Кул болгый.**

**Суфия** *(әсәрләнгән. Күзләрендә ялкын)*. Хуш! Хуш, Хөсәен абый! Ак юл сиңа! *(Эскәмиягә килеп утыра.)* И-и, Хөсәен абыем, йөрәгемнең уттай янганын беләсеңме? Белә! Белә! Үзе дә шундый ярата бит ул мине... Тик... Олы мәхәббәт өчен нигә шундый каршылыклар?.. Ул әле мине һаман яшүсмер кыз балага саный. Ә мин инде югары белем алган кыз. Доктор. Барлык җаваплы эшләрен миннән яшерә. Ул да, Гафур абый да. Ышанмыйлар. Ә мин күбесен беләм. Хөсәен гомеренең һәр минуты кыл өстендә, ди, абый. Аңлыйм, һәр адымын жандарм эзләре сагалый. Шулай да аның белән бергә булсам... Көчем бар... Кем ул килә? Кызу-кызу? Җәй көне башына шәл ябынып? Төнгә каршы? *(Шикләнебрәк алга уза.)*

**Мәрфуга** *(әкрен)*. Миңа Суфия духтыр кирәк не.

**Суфия.** Мин булам Суфия доктор.

**Мәрфуга** *(шәлен ачып)*. Шулай икән шул.

**Суфия.** Мәрфуга апа?!

**Мәрфуга** *(каранып)*. Мин бу, Суфия сеңелем, мин. Хөсәен кирәк иде, ул булмаса, Гафур абыең...

**Суфия.** Гафур абый өйдә юк. Хөсәен дисәң...

**Мәрфуга.** Кадыйр абзаң җибәргән не, бик ашыктырып.

**Суфия.** Әллә бер-бер хәл бармы? Син миннән шикләнмә, Мәрфуга апа.

**Мәрфуга.** Кадыйрны жандармнар алкитте. Яшергән корал таптыралар. Ызбаны тентеделәр, базларны, сарайны. Берни дә

[1] Тахил шәраб — аракы.

тапмадылар. Шулай да Кадыйрны апкиттеләр.

Суфия. Төрмәгәме?

Мәрфуга. Анысын әйтә алмыйм. Үзе болай борчылмады. Кайтарырлар, диде. Шыпырт кына шуны әйтте: тиз генә Хөсәенгә иреште, жандармнар, төрле шикле адәмнәр күп чуала башлады, бу араны безнең тирәдә күренмирәк торсын, диде. Тагын шуны әйтте... Йозагыбыз нык, борчылмасын, диде.

Суфия. Йозагыбыз нык? Анысы нәрсә?

Мәрфуга. Анысын инде, духтыр туганым, үзләре беләләрдер. *(Акбирдин керә, сәхнәдәгеләрне күреп яшеренә.)* Әгәр бүген Хөсәенне күрә алсаң, мин әйткәннәрне Гафур абыеңа иреште. Бүген үк.

Суфия. Аңладым, Мәрфуга апа.

Мәрфуга. Хөсәен — барыбыз өчен дә кадерле кеше.

Суфия. Әйе, әйе, бик кадерле.

Мәрфуга. Синең өчен аеруча, дим.

Суфия. Нигә аеруча?

Мәрфуга. Сизәм ич мин, Суфия туганым, Хөсәенгә синдә кызлар мәхәббәте барын.

Суфия. Кызлар мәхәббәте?

Мәрфуга. Әйе, хатыны барлыгын белсәң дә, дим.

Суфия. И, Мәрфуга апа жаным, олы мәхәббәт өчен киртә бармыни соң? *(Пауза.)* Шулай да мин аның гаиләсен җимермәм! Аны уйлый-уйлый янып үлсәм дә. Өлешемә төшкән көмешем табылыр әле.

Мәрфуга. Һи-и, табылмыймы соң, үзең алтын, йөрәгең алтын... Инде тагы сүзем Тукай турында. Дәвага житәрлек акчаны табарбыз дигәннәр, Кадыйр абыең дуслары.

Суфия. Монысы өчен аеруча зур рәхмәт, Мәрфуга апа.

Мәрфуга. Аңлыйм, духтыр туганым. Ярый, исән-сау бул.

Суфия *(озата барып)*. Исән бул, Мәрфуга апа!

Акбирдин *(чыгып)*. Суфия туташ!.. Бу сез?..

Суфия *(сискәнеп)*. Әйе, мин... Рәфыйк әфәнде.

Акбирдин. Гафур әфәнде өйдәме?

Суфия. Өйдә юк шул.

Акбирдин. Яңарак Хөсәен әфәнде дә килеп чыкмадымы? Ул да бик кирәк иде.

Суфия. Хөсәен?! Юк... Күптән инде бездә булганы юк аның. Соңгы вакытта күбрәк университетта була, ахры. Гафур абый шулайрак сөйләп торды.

Акбирдин. Университет? Сез миңа шикләнеп карыйсыз ахры, Суфия туташ.

Суфия. Һич! Шикләнергә нинди хакым бар? Аннан миндә, гади доктор кешедә, яшерер сер дә юк. Бигрәк тә сездән...

Акбирдин. Үзем дә шулай уйлыйм. Хөсәен, Гафур, мин... барыбыз да бер идеал кешеләре. Ярый, Суфия туташ! Хушыгыз! Хәерле кичләр, матур төшләр телим сезгә! *(Нәзакәтле хәрәкәтләр ясап, баш иеп чыгып китә.)*

Суфия *(баш иеп)*. Рәхмәт!..

**Картина.**

## XI

**«Амур» номерында Тукай булмәсе.**

Тукай *(ялгыз)*. Авыр иде бала чагым, шулай да сагынам аны...

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән
сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән
яшел яфрак чагы!
Юк гамең бернәрсәдән дә,
барча эшләр ал да гөл...

**Утырып уйга кала. Тынлык. Хыялындагы күренеш. Сәхнәгә моңсу гына алсу яктылык сирпелә. Арттан бик нәфис итеп киенгән Тукайның әнисе килеп чыга. Елмая, шагыйрьнең башыннан сөя.**

Ана. Балам! Догалар укып, теләкләр телим сиңа. Ярабби ходаем! Сау булсын дим аяк-кулларың. Якты булсын дим, барыр юлларың. Кешеләргә шәфкать булсын йөрәгеңдә... Беркайчан да сырхауны белмә, балам... *(Пауза.)* Алды мине салкын кабер сиңа өч яшь тулган чакта.

*(Янында нәни Тукай күренә.)*

Тукай. Бирегез! Кайтарыгыз әниемне, дип жылый-жылый чаптым артыңнан! Ләкин юк, кайтармадылар.

Ана. Нишлисең бит, һичкем кире кайта алмый ул дөньядан.

Тукай. Сагынам сине, әни... Сагынам бала чакларымны...

*(Музыка. Хыялның дәвамы.)*

**Ана нәни Тукайны җитәкләп алып китә. Тирә-ягы урман белән чолганган авыл. Бүрәнәгә утырган ак сакаллы бабай курайда борынгы татар халык көе «Карурман»ны уйный. Әнисе алдында утырган нәни Тукай йокыга тала. Ана әкрен генә бишек җыры көйли:**

**Әллә-бәлли итәр бу, мәдрәсәгә китәр бу,**
**Тырышып сабак укыгач, галим булып**
**җитәр бу.**
**Әлли-бәлли көйләрем, хикәяләр сөйләрмен,**
**Сиңа теләк теләрем, бәхетле бул диярмен.**

Тукай *(аңына килеп)*. Әни! *(Тора, карана.)* Ах, бу хыяллар... Беләм, бу миңа ерак дөньядан шомлы хәбәр. Ләкин... Мин бит әле бик аз яшәдем. Күпме генә язган җырларым? *(Тукайның уйлары микрофонда яңгырый.)*

Дөрес түгел! Үзеңне юкка битәрләмә!
Авырлык төшсә, түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми?
Бу тормыш кем белән туктар талаштан?
Сугыш син, һич тә армас-талмастан.
Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан.

Җәмилә. Рөхсәт итегез!..

**Ак, пөхтә киемнән Җәмилә керә. Битләре алсу, күзләре нурлы. Чәчләрен үреп куйган. Башында энҗеле калфак.**

Тукай *(таныр-танымас)*. Сез?!

Җәмилә. Хурлыктан коткарып, сез аякка бастырган кыз. Шуннан соң артык егылмадым. Өемә кайттым. Уйландым. Кешеләрдән дә, дөньядан да бизгән идем. Яңадан яши башладым. Бер апа үзенә ярдәмче итеп алды. Җөйче итеп. Хәзер инде аз булса да кешечә яшим. Миңа сез ярдәм иттегез, Тукай абый.

Тукай. Мин?..

Җәмилә. Сез, Тукай абый,— фәкыйрьләргә рәхмәт фәрештәсе, явыз байлар өчен газраил икәнсез.

Тукай. Ха-ха-ха! Димәк, җаннарын алам?

Җәмилә. Аларга шул кирәк тә, Тукай абый, мәгез... теге вакыттагы кулъяулыгыгыз, мин юләрлегем аркасында...

Тукай. Онытыгыз, сез гаепсез...

**Нургали керә.**

Нургали. Рөхсәттер, Тукай абый?

Тукай. О, Нургали дус! Әйдә, әйдә!..

Нургали. Кәҗә сөте алып килдем, Тукай абый. Беркөн ютәллисең кебек иде. Әнием җибәрде.

Тукай. Рәхмәт... Тик мин исән-сау бит, Нургали дус. Авырмыйм. Үзеңдә нихәлләр? Кузна, кузна ничек?

Нургали. Син уйнамагач, мин дә хәзер уйнамыйм диярлек. Күп чакны малайлар, кызлар бергә җыйналабыз да күмәкләшеп җырлыйбыз. Синең «Туган тел»не, Тукай абый. Җәмилә апа?! *(Тукайга.)* Кайчак Җәмилә апа да кушыла. Ул күрше урамда, Заводскойда яши. Бер усал карчыкта. Әтисе машинага кысылып, әнисе сырхаулап үлгәч...

Җәмилә. Җитте сиңа, Тукай абый аны әйтмәсәң дә белә.

Нургали. Җәмилә апа — әйбәт кыз. Кояштыр! Тукай абый, син аңа да бирәр китабыңны бүләк ит. «Күңел җимешләре»н.

Җәмилә. Җитте сиңа, Кәҗә! Тукай абый синең акылыңа мохтаҗ түгел. Аннан «Күңел җимешләре» үземдә бар. Тукай абыйның бөтен китабы бар.

Тукай. Бөтен китабы?

Җәмилә. Нургали усал карчык дигән әбекәй, китап укыганымны күрсә, гел ачулана иде. Бер көнне аңа «Көзге җилләр» шигырен укыдым. Башта, тыңламыйм дигән иде, укый башлагач, тыңлады. Һи-и, ничек кенә әле! Соңгы юлны тәмамлагач, карыйм, әбием үксеп җылый. Хәзер инде үзе укыта Тукай абый шигырен.

Тукай. Кара-а!..

Нургали. Тукай абый! Вакытың булса, кил кырый урамдагы күл буена. Без күмәкләшеп җырлап күрсәтербез... Әллә малайлар, кызлар җыйналып, үзебез килик микән?

Җәмилә. Шул гына җитмәгән иде, шау-шу килеп, бимазалап...

Нургали. Без мыштым гына, Тукай абыйның «Миңубикә»се кебек.

Тукай. Килегез соң! Кунагым булырсыз.

Нургали. Анысы кирәкми. Без тамакны туйдырып киләчәкбез.

Тукай. Мин сезне аш белән түгел, шигырь белән сыйлармын.

Нургали. Алай дисәң, була. Син ачуланма түлке. Бу безнең малайлар өчен пулный бәйрәм булачак...

Җәмилә. Кызлар өчен дә.

Нургали. Анысы инде сама сабуй. Киттек, Җәмилә апа!

Җәмилә. Хушыгыз, Тукай абый. Сез

инде үпкәләмәгез. Безнең Кәҗә шундый ул. Кузна дисәң, кузыдай сикерә, телгә дисәң...

Н у р г а л и. Ярар, ярар. Тукай абый үзе дә яхшы белә мине. Киттек! *(Китәләр.)*

Т у к а й. Хушыгыз, дуслар!.. *(Пауза.)*

**Шәмәт керә. Өсте-башы рәтләнгән, кырынган, чәчләре дә таралган. Башында эшләпә.**

Ш ә м ә т. Исәнме, Тукай җаный?..

Т у к а й. Шаһиәхмәт?! Синме соң бу?!.

Ш ә м ә т. Мин, Тукай абый. Әлеге дә баягы өтек Шәмәт.

Т у к а й. Бу арада күренмисең...

Ш ә м ә т. Көн саен пристенда хәзер. Баржадан икмәк бушатабыз. Бурычка алган акчаларымны китердем. Әзләп-әзләп ала торгач, төгәл биш сум җыелган.

Т у к а й. Биш сум?! Кит, каян ул кадәр булсын...

Ш ә м ә т. Артыграктыр да әле... Мужет биш-ун тиен кимрәктер дә. Ну инде мин тиеннәр чутлап, сине дә, үземне дә ваксындырасым килмәде. *(Биш сумлык сузып.)* Мә рәхим ит! Шытырдап торган биш сум. Шикләнмә! Көч куеп, тир түгеп алган хәләл акчам.

Т у к а й. Бу арада мохтаҗлыгым юк, Шәмәт дус. Үзеңдә калсын.

Ш ә м ә т. Синең хакыңны өстемдә калдырып, ахирәттә тәмугъда янасым юк. Ахирәте чурт с ним. Шушы дөньябызда сиңа бурычлы булып йөрүләр — үзе бер газап. Какуй чурт бер генә, мең газап. Дөнья уты, Тукай җаный, йөрәк уты дигәнем, тәмугъ утына караганда да көчлерәктер.

Т у к а й. Шулай дисәң генә, Шәмәт дус. Әмма кара, алай-болай акча кирәк булса, туры үземә кер. Миндә хәзер акча бер букча.

Ш ә м ә т. Беләм, Тукай җаный, беләм. Казанда юк, какуй Казан, бөтен Әрәчәйдә юк синнән бай кеше.

Т у к а й. Монысын менә дөрес әйттең, Шәмәт дус, рәхмәт!..

Ш ә м ә т. Каләм очындагы байлыгың гына да мең алтын!..

Т у к а й. А-а-а! Син әйтерсең...

Ш ә м ә т. Дөресе шулай. Үз байлыгыңны үзең белеп яшә! Ярый, Тукай җаный. Иомышым хәзергә шул гына ие. Исән бул! *(Китә.)*

Т у к а й. Сау бул, Шәмәт дус. *(Озата килә.)* Ха-ха! Әрәчәйдә иң бай кеше син, ди, Шәмәт. Нигә? Бәлки чыны шулайдыр. Нәрсә соң ул байлык?.. Нинди үлчәүләр белән үлчәнә ул хәзинә?

К а м а л *(кереп.)* Әссәләмегаләйкем, дамелла!

Т у к а й. Вәгаләйкем, мелла Галиәсгар! Авыз нишләп ерык әле синең бу кадәр?

К а м а л. Как же! *(Кулындагы журналын күрсәтеп.)* Яңа номер «Ялт-Йолт!» Көлеп тора бит тышы.

Т у к а й. Димәк, шәп художник син.

К а м а л. Шуны әйт, дим, шул.

Т у к а й. Ә эче? Эче ничек?

К а м а л. Эче шәп булганга тышы шәп. Әмма да чирттек, малай, саламторханнар борынына. Синең шигырь, минем рәсем.

Т у к а й. Мактанырлык рәтебез бар дисең, алайса?

К а м а л. У-у, ничек кенә әле!..

**Суфия керә.**

Т у к а й. Суфия туташ?! Хуш килдегез?

К а м а л. Нинди җилләр ташлады сезне бу якларга?

С у ф и я *(ярсып)*. Хөс... Хөсәен абый...

Т у к а й. Ни булды Хөсәенгә? Әллә...

С у ф и я. Дөньяда юк инде хәзер Хөсәен абый. Вафат ул. Вафат ул.

Т у к а й.<br>К а м а л. } Вафат?!

К а м а л. Ничек? Кайда булды бу хәл?

С у ф и я. «Гасыр» көтепханәсендә. Шундый серле фаҗига... Мин барып күрүдән бары ун минут элек...

Т у к а й. Я алла! Нигә үлем аңа килгән? Нигә миңа түгел?

К а м а л. Тукай, тынычлан! *(Суфияга.)* Бәлки агулап үтергәннәрдер?

С у ф и я. Мин дә шулай түгелме дип шикләнәм. Доктор буларак, полицмейстердан тикшерү таләп итәчәкмен! Җинаятьчене тапканга кадәр.

Т у к а й. Җинаятьче мәгълүм. Мәрхәмәтле падишаһыбыз безнең. Падишаһ һәм...

С у ф и я. Кем?

Т у к а й. Аның ялчылары...

**Картина алмашына. Музыка.**

**Тукай булмасе. Ул ялгыз. Нык борчулы. Шашынып йөри.**

Тукай. Дәртләнеп яшәдем. Күкрәдем, яшьнәдем... Ә бүген?.. Фаҗига. Нишләргә? Бөтен җирдә үлем. Үлем алып килүче дөньяга каршы сугыш, сугыш кирәк бүген!.. Афәт килә! Бәлки әле зур фаҗиганың башы гынадыр бу... Сабыр! Кем авызыннан чыкты бу шомлы хәбәр?.. Акбирдин?! Балкан сугышы турында язам дип, Камал Истамбулга китте. Ярый ла анда башын югалтмаса!.. Ул булганда эчмасам эчне бушатырга кеше бар иде... *(Пауза.)* Их, Хөсәен! Әллә нигә бер генә күренсәң дә, айлар буена җитәрлек җан азыгы биреп китә идең. *(Басым белән.)*

Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,
Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.

ХӨСӘЕН. Әйе! Җимертергә кирәк патшалыкны! Халыклар зинданын! Романовлар династиясен! Хөр Россия рухына иң кадерле бүләк булачак. Җимерергә!.. Ә аңа бәйрәм тантанасы әзерлиләр. Бүген иң кирәге — сугышчан шигырь, утлы җыр... Ә минекеләрдә җылау, моң, зар... Гомергә сөймәдем җылакларны, димәк, мичкә аларны! *(Өстәл тартмасын актара, кайбер кәгазьләрне йомарлап кәрзингә ыргыта. Берничә бит кәгазь тотып, уйга кала. Укый.)*

Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм...

Кемгә кирәк хасталыгым? Бераүгә дә! *(Кәгазьләрне атып бәрә.)* Кемгә барып егылыйм киңәш сорап? Хөсәен үлде. Сүнчәләй авылда. Фатих авырый. Күршедә генә яши. Тик ничек борчыйсың аны. Яшен булып яшьнәдем... Хәзер инде «Ялт-йолт» килеп сүнимме?.. Ай бу дуслар! Әгәр алар юмалау-юатуның кеше булган кеше өчен никадәр чиркаңыч икәнен аңласалар... Юк шул, юк! Әнә бит ап-акыллы Кәбир Бәкер, Питердә, докторны озаткач, сайрапмы сайрый. Имеш, миндә куркыныч бер авыру да юк, әз-мәз ютәл, шуңа әллә ни дару-фәлән дә биреп тормады, бары тик яхшы һава суларга, сөт, май ашарга, кымыз эчәргә киңәш бирде. Мин бит шагыйрь, психолог. Кешеләрнең күзенә, ничек елмаюларына карап, барын да күрәм, аңлыйм. Димәк, гомерем санаулы минем... Ә менә Уфада Мәҗит Гафури. Аңа рәхмәтләр төшсен, чынлап та шагыйрь йөрәкле кеше икән. Аңлады мине. Мондагы дус-ишләрем кебек хәләхвәлемне сорашып җанымны кыймады. Саубуллашканда да рәхимле булды. Син әле озак яшәячәксең дип юмаламады. Берберебезне кочакладык та басып тордык тып-тын гына. Бу соңгы күрешүебез икәнен икебез дә яхшы белдек... Ә менә бүген... *(Дәһшәтле музыка яңгырый.)*

И мөкатдәс, моңлы сазым!
Уйнадың син ник бик аз?..

*(Музыка туктый. Авыр тынлык.)*

**Ишек ачыла, Фатих, коляскасын тәгәрәтеп килеп, Тукай каршысында туктый. Чәчләре тузган, йөзе агарган.**

Фатих. Тукай? Ыңгырашуың булмәмә ишетелде, ышанмадым.

Тукай. Бер дә юкка чабып кергәнсең.

Фатих. Юкка түгел. Яңа бахбаем белән мактанасым килде... Кара. Ха-ха-ха!

Тукай. Ха-ха-ха... *(Кинәт аңына килеп, туктала.)*

Фатих. Мин әле яңа әсәр башладым. Исеме «Кадерле минутлар» булачак.

Тукай. Матур исем...

Фатих. Болайрак башлап китәргә уйлыйм. *(Кәгазьдән укый.)* Елаклар сез! Бөтен гомерегезне елап, сыкрап үткәрәсез!— ди Рәшат, әсәрнең баш герое. *(Укый.)*— Үзегез дөньяда тора белмисез, үзегез тереклегегезгә мәгънә, тормышыгызга кызык бирә белмисез дә, мәгънәсез, кызыксыз дип елыйсыз. Юк! Минем мәртәбә юк! Мәгънә дә бар, кызык та бар, ләкин аларны таба белергә кирәк.

Тукай. Әйбәт башлана... Менә нинди могҗиза тудыручы кеше син, Фатих.

Фатих. Әсәр язу өчен аяк кирәкми, кул исән булсын! Йөрәк! Хыял! Акыл! Ә синең, Тукай дус, барысы да үз урынында. Главное — аягың. Аяк кирәкми дисәм дә, аның кирәк яклары бар. Тегендә барасың, монда чабасың. Кыз-кыркын да ир-атның житезрәк йөргәнен ярата. Ул яктан, сер итеп кенә әйткәндә, мин отышта хәзер. Свиданиега барасы юк. Кызлар үзләре килә. Тик менә биеп булмый. Җырга дисәң, үзең беләсең, синдәге моң да, тавыш та юк миндә. Ә сөйләргә, аллага шөкер, телем ярыйсы тарта тегермәнне... Дус итеп кенә тагын бер сер әйтим үзеңә.

Тукай. Әйт, әйт.

Фатих. Өченче көн Хәлимә килгән дә

әйтә миңа: Фатих абый, җаным, ди, бәгърем, ди, аягың булмаса да, ал мине үзеңә гомерлек яр итеп, ди. Күзләрендә яшь. Әтиәниләрең ризамы соң?— дип сорыйм.— Юк шул, риза түгелләр, ди, бу. Синең белән күрешмәскә дә кушалар, ди. Эх, алып кына качар идем дә, аякларым юк шул, дигән идем, кычкырып җылап ук җибәрде. Мин көлдем. Әрнеп көлдем, Тукайҗан. Аңардан түгел, үземнең шундый язмышымнан көлдем. Ләкин көлүем барыбер көлке булып чыкмады. Шулай да мәхәббәтебез дәвам итә. Олы мәхәббәт, күңелле дә, кызыклы да, газаплы да. Нишлисең бит. Үз бәхетеңнән качып котылып булмый. Беркая да! Качарга түгел, ямь, кызык табып яшиселергә кирәк. Аяклы кешечә җиргә нык басып, башны горур күтәреп. Җырлыйҗырлый. Мәхәббәт ул, Тукайҗан, илаһи хәзинә. Ә син кадерен белмисең. Теге «Кызык гыйшык» исемле шигыреңне укыгач, Зәйтүнәң Казанга килеп өч көн буе әйләнеп йөргән, сине күзләп. Очраткан. Син аны күреп тә күрмәмешкә салынгансың.

Тукай. Киресенчә, ул үзе мине күрмәмешкә салышты.

Фатих. Ә син, егет булсаң, йөгереп барып идең дә, алдына төшеп, туктатыр идең. Стоп, кызый, шаярма, дияр идең.

Тукай. Аллам сакласын!..

Фатих. Вәт шул шул. Котың оча. Ә ул кыз бала, үзе сөя, үзе тартына. Болай булгач, Чистайга үзем барам да, Зәйтүнәңне алып кайтып, тоттырам кулыңа.

Тукай. Ну?.. *(Көләләр.)* Ләкин сиңа күп йөрү ярамый.

Фатих. Хәрәкәт — хәят ул, дигән Әбугалисина. Сиңа кыз урлап кайтсам, савабы гына да ни тора. Әйе, әйе, калган ягын үзең карарсың. *(Коляска рычагына тотынып.)* Әйдә, бахбай, киттек! На! *(Кул изәп.)* Адье! *(Коляска тәгәрәтеп, китеп бара.)*

Тукай. Синең белән без яшен уты атабыз әле болай булгач. Яшьнәсен яшен! Яшен минем яшәвем, шатлыгым ул!

*(Ут сүнә. Паузадан соң тагын кабына.)*
**Акбирдин керә.**

Тукай. Тагын шул турыдамы?

Акбирдин. Уйлашыйк әле, Габдулла әфәнде. «Йолдыз» газетасы һәм «Мәгариф» журналы өчен түгел, милләт өчен, бигрәк тә аның ярлылары өчен патшага бер дипломатик жест ясасак...

Тукай. Патшалар таҗына дан җырлапмы, ә?

Акбирдин. Патша өчен түгел, милләтебез өчен. Ишеткәнсеңдер, династиянең өч йөз еллыгы уңае белән патша манифест чыгарырга әзерләнә, диләр. Әлегә кадәр кимсетелеп яшәгән милләтләргә ирек, хокук бирү, мәктәп, шифаханәләр ачу...

Тукай. Патшаны мактап шигырь, ә?

Акбирдин. Шигырь ул, Тукай җаным, дөресен әйткәндә, хәйләи шәргый, политика! Патша күзенә төтен... Дипломатия!

Тукай. Дипломатия, дипломатия... Утыр әле.

Акбирдин *(утырып).* Утырдым.

Тукай. Тыңла. *(Укый.)*

И бадә сәт, и мәйке минаи,
Чындан ки хурм и турашум шидаи...
Гомәр Хәйям бу, аңлыйсыңмы?

Акбирдин. Бик үк аңлап җитмим...

Тукай. Кызганыч. Алайса Сәгъдине укырга кала?

Акбирдин. Алай яхшырак.

Тукай.

Бу дөньяда якты акыл иясенә
Килсен иде гомер юлы ике кабат,
Берсе аның туплар өчен акыл, тәҗрибә,
Икенчесе яшәү өчен шуңа карап...[1]

Акбирдин. Әйбәт әйткән Сәгъди.

Тукай. Шул, шул. Безгә дә ярый аның акылы.

Акбирдин. Бик ярый.

Тукай. Инде менә үз шигыремне тыңла.

Ачтым басу капкасын,
Утырдым бүкән башына.
Кызыл перчатка бирер идем,
Әтиеңә әйтерсең дип куркам.

Акбирдин. һе-һе... һи-һи... *(Көлгәндәй итә.)*

Тукай. Көл, көл. Пешми калган шигырь бу.

Акбирдин. Ә-ә!

Тукай. Патша турында сүз барганда, мондый шигырь ярамыйдыр, мөгаен. Пешкән шигырь кирәктер, ә?

Акбирдин. Тукай! Мин синең белән чын күңелдән сөйләшергә дип килдем.

Тукай. Аңладым. Шуңа чынлап сөйләшәм дә. Уйланып, акыл җыеп. *(Пауза.)* Династияне мактап, чын шигырь язачакмын. Һич дипломатиясез! Ике-өч көннән менә дигән шигырь булачак! Мин инде бу турыда күптән уйлап йөрим...

Акбирдин. Илһамыңа алла куәт бирсен!

Тукай. Амин. Теләкләрең кабул булсын.

Акбирдин. Хуш, Габдулла әфәнде, уңыш телим.

[1] Мостафа Ногман тәрҗемәсе.

**Тукай.** Хуш, хуш, Рәфыйк...

**Акбирдин китә.**

**Тукай** *(зәһәр белән).* Романовларны мактап шундый язармын! Әйе, шундый шигырь... Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак... Падишаһ, ха-ха-ха! Аннан...

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук.

Патшаны, аның нәсел-нәсәбен мактатып, миннән шигырь яздырмаячаксың... Явыз дошман икәнең инде ачык миңа. Дошман! Хөсәение үтерүче дә син түгелме икән әле? А-а... *(Пауза.)* Их, Тукай, Казан диден, дусларым диден, дусларыңнан күбрәк хәзер дошманың... Дошманның да куркынычы, мәкерлесе, сизәсең ич үзең дә... Сөлек сыман суыра канынны, суыра үпкәнне! *(Ютәлли. Яулыгында кан.)* Кан?! Кан тәкерәсең! Яшер тизрәк! Дошманың күрмәсен, күрмәсен дусларың да, сөйгән ярың да. Сөйгән яр? Хакым бармы сөяргә? Ярымйорты үпкәм белән, бик санаулы калган гомерем белән, гөл чәчәге кебек Зәйтүнәгә, хатыным бул минем диярга? Юк!!! Хакым юк моңа. *(Пауза.)*

**Зәйтүнә керә дә ишек янында туктый. Күренми тора.**

**Тукай** *(әкрен генә).*
Зәйтүнәм!.. Күз нурым!
Илһамым син, моңым син,
Йөрәктәге җырым син!
Тик дошманнар!..
Дусларымнан күбрәк дошманым.

**Зәйтүнә** *(Тукай янына килә).* Ялгышасың, Тукай. Дусларың мең тапкыр күбрәк синең.

**Тукай** *(шатланып сикереп тора).* Зәйтүнә?!

**Зәйтүнә.** Халкыбызның телендә, күнелендә син. Минем дә...

**Тукай.** Зәйтүнә!! *(Кулыннан ала, ләкин шунда ук кире җибәрә.)*

**Зәйтүнә.** Син оныттың мине.

**Тукай.**
Җир яшәрмәс, гөл ачылмас, төшми
                    яңгыр тамчысы,
Кайдан алсын шигъре шагыйрь,
                    булмаса илһамчысы?

Зәйтүнәм! *(Дәрт белән кулыннан ала.)*

**Зәйтүнә.** Сез инде мине күрергә теләмисез, бары тик шигырьләрегез белән генә яшисез, дип уйлый башлаган идем.

**Тукай.** Сез дә шигырьләрем кебек, димәк, җаным кебек үк кадерле миңа.

**Зәйтүнә.** Күзләреңдә яшь?

**Тукай.** Гомеремдә беренче тапкыр шундый бәхет! Тик ул үкенечкә генә булмасын!

**Зәйтүнә.** Мин дә аның гомерле булуын телим.

**Тукай.** Гомерле? *(Тетрәнеп.)* Ах, Зәйтүнә, белсәгез икән...

**Зәйтүнә** *(башыннан сыйпап).* Авырыйсың, ахры?..

**Тукай.** Мин?! Юк! Юк, юк!..

**Зәйтүнә.** Йөрәгегез дә, үзегез дә шундый кайнар... *(Дәрт белән җырлый.)*

Балкып янган миллион йолдыздан мин
Сайладым бары берсен генә.
Уйчан йолдыз, моңлы йолдыз дидем,
Ул да булса бары син генә.
Синнән яктырак йолдызны
Күзләдем, табалмадым.
Белмим,
Әллә җырың, әллә үзең,
Йөрәгемне аулады?
Күлдә йөзгән аккош гел моңая,
Янында аның пары булмаса.
Кызлар да нәкъ ялгыз аккош сыман,
Җаны сөйгән яры булмаса.
Син аккош булсаң иде дә,
Мин парың булсам иде...

**Тукай** *(кискен).* Юк, бу мөмкин түгел!!!

**Зәйтүнә** *(тетрәнеп).* Мөмкин түгел?! Ни өчен?

**Тукай.** Күңелемдә башка йолдыз.

**Зәйтүнә.** Башка йолдыз? *(Көлеп.)* Шаяртасың, хөрмәтлем! Ерактагы йолдызым дип миңа атап җырлаучы син түгелмени?

**Коляскада Фатих керә, ишек янында туктала.**

**Тукай.** Сиңа карап җырласам да, күңелемдә...

**Зәйтүнә.** Юк! Ышанмыйм.

**Тукай.** Ышаныгыз һәм... онытыгыз мине!

**Зәйтүнә.** Ярабби!

**Тукай.** Онытыгыз! Бөтенләй! Мәңге! Мәңгегә!

**Зәйтүнә.** Мәңгегә? Нинди рәхимсез сез, Тукай!

**Тукай.** Әйе, рәхимсез мин! Рәхимсез! *(Зәйтүнә йөгереп чыгып китә.)* Рәхимсез! *(Диванга каплана. Үкси.)*

**Фатих.** Зәйтүнә! *(Тукайга.)* Туктат аны! Бу ни дигән сүз? Зәйтүнә бит синеке бердәнберең.

**Тукай.** Әйе, бердәнберем. Иң кадерле, иң сөекле кешем Зәйтүнә... Бердәнберем!..

**Фатих.** Шулай булгач?!

**Тукай.** Ул лаеклы олы бәхеткә, ә мин... *(Буылып ютәлли.)*

**Картина.**

## XIII

**Дубасов кабинеты. Сәхнәдә Дубасов, Быков, Акбирдин.**

Дубасов *(кулында Тукай шигыре).* Ярый, укып карыйк. Ниләр язган икән бөек династияне котлап. *(Укый.)*

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «мөнафис» нам канат.
Җыела халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

Яхшы! Яхшы! Вот так, то-то-товарищ революционерлар! Артык котырынмый торыгыз әле! Атаклы шагыйрь үзе мактый императорны! Так, так... Ә дальше как? *(Укый.)*

Рус җирендә без әсәрле, әзле без,
Та-тарихында, бер дә тапсыз көзге без.

Нәрсә, нәрсә?!

Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып.

**Микрофонда Тукай тавышы. Үзе артта, прожектор яктысында күренә.**

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек,—
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

**Микрофонда күмәк тавыш: Хөр мәмләкәт! Хөр Россия!**

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез...

Нинди белеберда бу? Синнән сорыйм, Быков?

Быков. Әйтә алмыйм, ваше высблагородие!

Дубасов. Бәлки син әйтерсең, Акбүре?

Акбирдин. Ми... ми... ми... дәвамын укыгыз!

Дубасов. *(Шигырьнең дәвамың күз йөртеп укый, укыган саен йөзе үзгәрә бара.)* Нәрсә, нәрсә? *(Кычкырып укый.)*

Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук.

**Микрофонда күмәк тавыш: Хөр мәмләкәт! Хөр Россия!**

Дубасов. Ха-ха! Хокук? Ха-халыкка? Бу бит р-ре-революциягә чакыру! Патшалыкны җимерергә! Изге династияне... *(Өстәлгә суга.)* Болваннар! Нәрсә китердегез? Әрәм тамаклар. Йолкыш шагыйрь! Мо-мо... Морда! Хокукмы сиңа?!.. Татарва?

Акбирдин. Татар гына түгел, үзбәк, кыргыз, чуваш... барысына да, ди. Русны да мактый.

Дубасов. Русның үркәчлесен, имгәген!

Акбирдин. Тукай белән Ямашевны үз йогынтысына алган икән, үркәчендә димәк көч аның.

Дубасов. Көч?! Бәлки үзең дә шул шайка яклыдыр?

Акбирдин. Ту-ту... Тукай — Тукай бит ул...

Дубасов. Морда! Менә сиңа Тукай. *(Яңагына чаба.)* Менә сиңа Ахиллес үкчәсе. *(Икенче яңагына чаба.)*

**Ут сүнә. Картина.**

## XIV

**Тукай бүлмәсе.**

Тукай *(ак күлмәк, кара чалбардан. Тәрәзә янында табигатьнең уянуына, яз килүенә шатланып карап тора. Өстәле янына килеп кызу-кызу яза да, башын күтәреп).* Лев Толстой! Үзе граф... Ә үзе нинди әүлия, нинди даһи шәхес. Нинди даһи фикер иясе. Могҗиза бер. *(Пауза.)* Ә Хөсәен аның бар ягын да мактап бетерми иде. *(Ютәлли.)*

И Казан, нурлы Казан!
Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман
кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр
сайлый Казан.

Әгәр дә Сәгыйть Рәми... Каян килеп кердетелемә Рәми? Сүнчәләй салды шөбһә... Шом!.. Әгәр дә ул Ямашевка хыянәт итсә, имеш. Шөкер! Рәми андый булып чыкмады! *(Кызу-кызу килеп, өстәл тартмасыннан газета ала.)* «Идел» газетасында менә бит нәрсә яза: «Хөсәен Ямашев һәрвакыт изге һәм гади максатларга гына күз төбәп яшәде. Аның бар уе халык сәгадәте юлына хезмәт итү иде. Без киләчәктә бик зур файдалары тиячәге күренеп торган бер кешебезне югалттык... Ул, яшьләр арасында иң сөекле, иң игътибарлы бер яшь буын булып, үзенең вөҗүде, хәрәкәтләре вә киңәшләре белән яшьләр хәрәкәтенә рух биреп

тора иде. Аның белән утырганда, кеше үзенең барлык кайгысын оныта, киләчәккә өмет баглап бөтенләй җанлана иде. Сәгыйть Рәми *(газетаны карап)* 20 март, 1912 ел.»

Хөсәенгә карата иң дөрес, иң самими сүзләр. Тукта, бу газетаны Сүнчәләйгә җибәрергә кирәк. Сарашка. Мөгаен, ул укымагандыр. Укысын! Рәми турында начар уйда йөрмәсен! *(Газетаны конвертка салып, адрес яза.)* Оса, Сараши, Сюнчели. *(Тәрәзә янына килә.)* Яз килә! Тиздән ямьле, җылы көннәр башланачак. Ә мин...

**Фатих, коляскасына тотынып, аксый-аксый керә дә тукталып кала.**

*(Тукай ютәлли.)* Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым... эттән күбәйде дошманым, чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым. Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш... *(Креслога тотына.)* Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьлый алмадым.

Фатих. Үзеңә үзең яла якма, Тукай. Меңнәр, йөз меңнәрчә кешенең пакьландырдың рухи дөньясын. Бәхет тапсын өчен юлында, кабыздың син өмет кояшы. Бәхет кояшы!

Явыз җаннар өчен тапкыр сүзләрең дә
табылды,
Биргән аклың барып җитмәгәндә,
яшен уты булып кабындың.

Тукай. Өченче көн патшаларны мактап шигырь яздым.

Фатих. Шигырь дип... ха-ха-ха! Ут, ак ефәккә төреп ут җибәргәнсең ич син. Яшен уты! Нәкъ менә шул шаштырган да акылдан... Кемне? Беләсеңме кемне? Охранка башлыгы Дубасовны. Ә Рәфыйк Акбирдин бүген төнлә үзен-үзе асып үтергән.

Тукай. Үзен-үзе? Чынмы бу хәбәр?

Фатих. Ул кабәхәт охранка белән бәйле булган. Җасус. Провокатор.

Тукай. Провокатор?! Эх, подлец! Минем турыда рисалә, имеш. Ак, кабәхәт!.. Хәер, мин аны күптән үк сизенгән идем...

Димәк, шигырь пәтша охранкасын шулай тетрәткән икән...

Фатих. Тарих битенә алтын хәреф белән язарлык ул шигырь. Халык сукыр түгел. Энҗе бөртекләрен чүп-чардан аера белә... Менә башка нәрсә тетрәндерде: кайчан гына якты идеаллар белән яшәгән журналист, акыллы, сөйкемле генә кеше, нишләп шулкадәр үзгәрде, үзе һаман шаяра, көлә дә кебек иде, ә үзе...

Тукай. Охранка кулында уенчык булган, димәк.

Фатих. Куркыныч уенчык. Битендә — көләч маска, эчендә — зәһәр агу. Тукай ни дә, милләт, ватан ни аңа. Барын да агуларга әзер. Үләр алдыннан калдырган язуы гына ни тора.

Тукай. Язу?! Кемгә язган?

Фатих. Барыбызга да. Күрше хатын укыган.

Тукай. Я, я? Ниләр язган?

Фатих. Бары тик өч сүз: «Үзегезгә булсын дөньягыз».

Тукай. Үзегезгә булсын дөньягыз? Димәк, дөньяда аның бер идеалы да булмаган...

Фатих. Башта булгандыр ул... Якты да булгандыр бәлки... Ләкин охранка... Охранка...

Тукай. Барыбер сатлык җан. Көчсез мәхлук. Хәшәрәт!

Фатих. Менә иң нык газаплаганы, Тукайҗан, кеше булган кешенең әнә шул хәлгә төшүе. Фаҗига бу!

Тукай. Их, Хөсәен белән Камал да исән-сау булсалар...

Фатих. Хөсәен инде кайтмас, ә Истамбулдан кайтып егылган Камалны озакламый аякка басар, диләр.

Тукай. Шулай гына була күрсен! *(Ютәлли.)*

Фатих *(дару биреп)*. Мә, даруыңны эч әле, Тукай дус!

Тукай. Эх, Фатих дускаем! Әйдә ичмасам, барын да онытып, җырлыйк әле минем җырны.

**Пәрдә.**

## Рафис Гыйззәтуллин

# ЧИТЛЕК

хикәя



Ул ике катлы итеп эшләнгән. Ишегенең берсе — тышка, икенчесе эчкә таба ачыла. Һәркайсының үз йозагы бар. Тиз генә ачармын димә. Читлекнең башка өлешләре дә корыч челтәрле. Тышкы якка караган агач өлешләре сырлап, бизәкләп ясалган. Хуҗа кешенең күңел биреп, тәфсилләп эшләгәне әллә каян күренеп тора. Хәер, читлек кеше күзенә чалынырлык урында түгел. Таш сарай ышыгына — күләгәле җиргә яшерелгән ул. Янәшәдәге сарайның да ишеге ышанычлы тимердән. Йозаклары да байтак бугай. Күпме икәнлеге читлек эченнән күренми генә. Бикләрнең күплеген читлектәге Вега үз хуҗасының тимер ишекне бик озаклап ачып ябуыннан гына сизенә. Әлеге таш пулатта хуҗаның машинасы саклана. Арырак — аның өе. Анысының да ишеге күренми. Урам капканың кай якка ачылуы да әлегә кадәр Вегага сер булып кала бирә. Корыч ятьмә аркылы бары тик таш җәелгән киң ишегалды, сикереп тә чыга алмаслык биек койма гына күренә. Веганың аларга караганы да юк диярлек. Әллә бар, әллә юк алар аның өчен. Чөнки читлектән чыккан очракта да ишегалдыннан ары китә алмасын ул яхшы белә. Ишегалды да шундый ук читлек кебек тоела.

Тоткындагы эт, йомры башын алгы аяклары арасына салган килеш, тын гына ята бирә. Хуҗа кеше читлек янына килеп, ашарына салып киткәндә дә кымшаный ул.

Дөрес, хуҗа күренүгә Вега элегрәк өзгәләнеп өрергә, ишекне тырнарга, корыч ятьмәне чәйнәргә керешә, ирекккә чыгарга омтыла иде. Мондый чакларда хуҗа кесәсеннән тәмәке ала, аны авыз кырыена эләктерә дә озаклап суыра; аксыл төтенен пыф-пуф итеп өрә-өрә, читлек каршында басып тора, Веганың тынычлануын көтә. Дәшми. Сукмый да, какмый да үзе...

Хуҗа, тәмәкесен тартып бетергәч, беравык аны ташларгамы-юкмы дигәндәй, уйланып тора һәм тәмам тартылып беткәненә, сүнгәненә ышангач кына төпчекне бармак очларына куя да чиертеп җибәрә.

Әнә, ул бүген дә күренде. Аның таш пулат янына таба килүен Вега сыңар күзе белән күреп алды. Чалтыр-чолтыр ачкыч тавышы ишетелде. Бераздан ишек ачылды, кызыл төстәге җиңел машина ишегалдына чыгып туктады. Башына киез эшләпә кигән хуҗа, тагын бер кат өй ишегенең, читлекнең биген тарткалап караганнан соң, машинасына утырып, каядыр китеп барды.

Вега, читлек почмагына җәелгән палас өстендә яткан килеш, аны озатып калды. Әчкелтем төтен исе, корыч ятьмәдән кереп, аның дымлы борынын кытыклады. Ул күзен йомды.

...Күпме вакыт үткәндер — Вега абайламый да калды. Капканың кабат ачылып ябылганына уянып китте. Өй почмагыннан хуҗаның гәүдәсе күренде. Ялгызы гына түгел иде ул бу юлы, ниндидер ят этне җитәкләгән иде. Бу эт Вегага караганда киңрәк күкрәкле, озын торыклы, койрыгы да кыскарак.

Вега үзе дә сизмәстән сикереп торды, бәргәләнә-бәргәләнә читлек буйлап йөренергә кереште. Әмма кай якка гына барса да, борыны белән корыч ятьмәгә килеп төртелде. Ачуыннан үзе яткан паласны чәйнәргә кереште.

Киң күкрәкле ят эт кара нәфис сыртын кояшта елкылдатып утыра бирде. Бары үрә торган колаклары, кан баскан күзләре генә аның сәерсенүе, әчке ярсуы турында сөйли иде.

Ниһаять, хуҗа тәмәкесен тартып бетерде. Ул арада Вега да тынычлангандай булды, инде өзгәләнеп өрми, йөренми иде. Тукталды да тыштагыларны күзәтергә кереште.

Иң башлап хуҗа хәрәкәткә килде. Ул бизәкле читлек янына якынайды. Кулындагы бер бәйләм ачкычлар бер-берсенә бәрелеп зыңлашты. Ишекләр ачылды. Баядан бирле тыныч кына утырган киң күкрәкле эт ачык ишектән ояга керүгә, ишекләр кабат ябылды.

Читлеккә аяк басуга, кыска койрык ырылдап алды һәм башын иеп басып торучы Вега янына атлады...

Иртәгәсен Вега тагын ялгызы калды. Таң атуга, читлек каршына хуҗа килде. Читлектән чыкмаска тартышкан киң күкрәкне өстерәп диярлек чыгарды да урам якка атлады.

Веганың корыч ятьмә аша моңсу гына карап калуын ул күрмәмешкә салышты шикелле. Хуҗасы әлеге этне тагын иртәп кайтыр дип өметләнгән иде Вега, әмма ялгышты... Ә берничә көннән Вега киң күкрәкне онытырга да өлгерде. Хуҗа да үзгәрде. Эт алдына ашамлыкларны күбрәк куя башлады. Вега үзе дә үзгәрде. Үзгәреш аңа акрынлап, сиздермичә генә килде. Йөреше салмакланды, гәүдәсе авырайды. Күзен авыр йокы басты, һәм ул читлек почмагындагы ерткаланган паласта йокларга әвәсләнеп китте. Хуҗа кеше дә этнең холкы үзгәрә баруын сизде бугай. Читлек янына ешрак килә башлады, үрелә-үрелә читлек эчен күзәтә торган булды. Мондый чакларда Вега иренеп кенә күзен ачып карый да янә татлы йокыга тала. Соңгы вакытта еш кына төш күрә башлады ул. Гел бер үк төш керә.

...Күз күреме җир ямь-яшел, имеш. Әллә урман аланы шунда, әллә бакчаның тын бер почмагы — белмәссең. Тирә-юньдәге аллы-гөлле чәчәкләрне исни-исни, бихисап күбәләкләр оча. Кеп-кечкенә көчекләр әүмәкләшә-әүмәкләшә күбәләк куалар. Әнкәләре исә сузылып яткан да кояшта сыртын кыздыра. Рәхәт, тыныч.

Чү! Әнкәләре сикереп торды түгелме соң?! Әнә, һау-һаулап өрә дә башлады. Нәниләрен үз янына чакыруы иде бу аның.

Төрлесе төрле якка сибелгән көчекләр, туп кебек тәгәрәшеп, әнкәләре янына ашыктылар. Вегага әллә ни булды шулчак. Абынып егылды, ниндидер җепкә уралды. Күз алдында ярсый-ярсый өрүче әнкәсе, куркышып берсе өстенә берсе өелгән көчек туганнары гына торып калды...

Мондый чакларда Вега сискәнеп уяна. Күзләре зур булып ачыла, йөрәге, күкрәк читлегеннән чыгарга теләгәндәй, дөп-дөп тибә, сулыш алуы кыенлаша...

Әлеге төш аңа бик еракта, томан эчендә калган әнкәсен, көчек туганнарын искә төшерә. Мондый чакларда аның дүрт стенага җаны сыймый, тыгызлана иде.

Ишегалдында авызына затлы сигарет капкан хуҗаның арлы-бирле йөренүен күргәч кенә ул гадәти хәленә кайта.

Бүген кич Веганың көчекләре туды. Моны күргәч, хуҗаның йөзе яктырып китте. Менә ул читлек ишеген ачты да яртылаш гәүдәсен тыкты, көчекләрне санарга кереште.

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Ул, ялгышмадыммы икән дигәндәй, аларны тагын бер кат санап чыкты. Юк, ялгышмаган икән.

— Шул гынамы?! — диде хуҗа. Аның кәефе кырылды, йөзе каралды. Вега хуҗасының сүзләрен аңламады, көчекләрен имезергә дип җайлап ятты. Көчекләр зәгыйфьләр иде. Көчсез борыннарын төртә-төртә, имәргә эзләнделәр.

Хуҗа көчекләрне берәм-берәм әниләренең күкрәгенә тезеп чыкты.

— Кара аны, сак кылан. Имгәтәсе булма. Болай да аз...— дип, Вегага бармак янады.

Көчекләр тернәкләнделәр. Әнкәләре тирәсендә уйный-шаяра торган булдылар. Күзләре ачылды — елтыр-елтыр килеп яналар.

Хуҗа абыйлары көчекләрнең һәркайсын аерым-аерым тотып карый. Аякларын, гәүдәләрен капшый...

Бер көнне көчекләрнең берсе юкка чыкты. Хуҗа алар белән уйнап торган иде. Читлек ишегенә тыштан йозак элгәнгәч кенә сизде моны Вега. Өреп караган иде дә, әмма бушка. Хуҗа борылып та карамады, капка ягына таба китеп, юкка чыкты...

Икенче көнне дә, өченче көнне дә шулай булды. Хуҗа ашамлык салынган савытны алга куя да көчекләрнең әле берсен, әле икенчесен тотып карый, әйтерсең, кибеттә товар сайлый. Күңеленә ошаганын куенына кыстыра да Веганың борын төбендә үк ишекне ябып куя. Әнкә этнең капка ягына атлаучы гәүдәгә, киң җилкәгә текәлеп караудан башка чарасы калмый.

Хуҗаның көчекләрне ала торган гадәтен белгәч, Вега, ул күренүгә үк, ярсып өрә башлады. Хуҗа кешенең генә аңа исе китми, хәтта күтәрелеп тә карамый, машинасы тирәсендә кайнаша бирә.

Бер-ике көн тыныч үтте. Ә өченче көнне, кичке якта хуҗа янына таныш булмаган хатын килде. Озак кына ни турындадыр сөйләшеп тордылар. Хуҗа тәмәке төтәтте. Хатынның карашы гел читлек ягында иде. Ниһаять, алар Вега каршысына ук килеп бастылар.

— Ай! Бигрәк матур,— диде хатын, озын тырнаклы бармак очлары белән генә читлеккә кагылып-кагылып алды.

— Шушы инде,— диде хуҗа, Веганың аяк арасына сыенган көчеккә күрсәтеп.— Соңгысы. Сирәк очрый торган нәселдән...

Ул берөзлексез өргән Веганы читлек почмагына этеп-төртеп җибәрде һәм шул арада соңгы маэмайны читлектән тартып та чыгарды.

Хатын, әллә инде Веганың карашыннан курыкты, читкә борылды, кабаланып сумкасын ачты. Аннан бер төргәк чыгарды.

— Менә, сөйләшкәнчә...

Төргәк хуҗа кулына күчте. Ул аны ашыкмый гына санады да көчекләрне яшереп алып китәргә гадәтләнгән куенына салып куйды, аннан соң көчекне хатынга сузды...

Вега ни эшләргә дә белмәде. Арт аякларына утырган килеш өнсез торды һәм башын югарыга күтәрде дә акрын гына уларга-шыңшырга тотынды. Төнозын көчекләрен чакырды ул. Ә күз алдыннан төшләренә кереп йөдәткән яшел мәйдан, андагы бихисап чәчәкләр, йомгак кебек тәгәрәүче көчекләр китмәде...

Иртәгесен хуҗа тагын аның янына килде. Бу юлы да ялгыз түгел иде ул. Вегага таныш булган киң күкрәкле, озын торыклы көяз этне җитәкләгән иде...

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты.
**Касыйм Тәхау,**
журналистларның Х. Ямашев исемендәге
республика премиясе лауреаты.

# ФРОНТОВИК ӘДИПЛӘР

*Бөек Ватан сугышы елларында илебез азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәштә күп язучылар катнашты. Алар мәкерле дошманга каршы автомат һәм каләм тотып сугыштылар. Бөек Ватан сугышы елларында Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Әхмәт Ерикәй, Гадел Кутуй, Нур Баян, Габдрахман Әпсәләмов, Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Әхмәт Исхак, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗи, Абдулла Әхмәт, Мирсәй Әмир, Кави Нәҗми, Фатих Хөсни — барлыгы кырыктан артык әдип үз әсәрләре белән «Кызыл Татарстан» газетасында һәм «Совет әдәбияты» журналында катнашканнар. Аларның әсәрләрендә совет солдатының туган партиягә һәм Ватанга тугрылыгы, гитлерчы юлбасарларга каршы көрәштә күрсәткән тиңсез батырлыгы, халкыбызның тылдагы фидакарьлеге гәүдәләнә. Бу авторларның күбесе фронт газеталарында эшләгән.*

*Әлеге язмада Риза Ишморат, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Госман Бакиров, Зәйни Шаһиморатов, Афзал Шамов, Әхмәт Ерикәй, Әхмәт Исхак, Абдулла Әхмәт, Шәрәф Мөдәррис һәм башкаларның фронттагы иҗатларына кыскача күзәтү ясалачак.*

* * *

Без «Ватан намусы өчен» («За честь Родины») газетасының саргаеп беткән битләрен актарабыз. Бу фронт газетасы рус, татар, казах, украин һәм үзбәк телләрендә чыгарыла. Анда Беренче Украина фронтының фашист козгыннарына каршы аяусыз көрәше, ташкындай алга — көнбатышка, дошман өненә ярсулы омтылышы — җиңүләр белән данга күмелгән сугышчан юлы гәүдәләнә.

«Ватан намусы өчен» газетасының татарча беренче саны 1942 елның 19 декабрендә чыга башлый. Ул 1943 елның 10 июненә кадәр — редактор урынбасары капитан Әхмәт Ерикәй, аннан соң редактор урынбасары өлкән лейтенант Риза Ишморатов җитәкчелегендә басыла.

Фронт газетасы редакциясендә хезмәт иткән елларны искә төшереп, Риза Ишморат болай сөйли:

«Фронтта, хәтәр шартларда, сугышчыларны канәгатьләндерерлек газета чыгару

авыр һәм катлаулы вазифа булды, билгеле. Ләкин редакциябездә сугышка кадәр үк газетада эшләгән тәҗрибәле журналист-шагыйрь Гали Хуҗиев, журналист Әнвәр Ямангулов, соңрак, дошманны эзәрлекли барып, Украина территориясенә җиткәч, редакциябездә эшли башлаган кыю, тәҗрибәле, утта чыныккан сугышчылар — капитан Мөхәммәт Садри, өлкән сержант Госман Бакиров иптәшләрнең сугышчан заданиеләрне намус белән һәм төгәл үти барулары аркасында «Ватан намусы өчен» газетасын уңышлы чыгарып, аны вакытында сугышчыларыбызга җиткерә килдек...

Курск дугасында чагыбызда госпитальдән чыгып, авыр ярасы төзәлер-төзәлмәс, газетабызда берничә ай эшләп, аннан соң икенче фронтка киткән кече лейтенант Мостай Кәрим дә үзенең очерклары һәм шигырьләре белән газетабызны җанландыручыларның берсе булды».

Газета төпләмәсенең битләрен ачкан саен аларда М. Кәрим, Р. Ишморат, Г. Хуҗи, М. Садри, Г. Шәрипов, Ә. Ямангулов, Г. Бакир, З. Шәһиморатов кебек язучыларның фашист ауларына каршы бил алышкан һәм батырлык үрнәкләре күрсәткән сугышучыларыбыз турындагы окоп-блиндажларда язган мәкаләләрен һәм очеркларын очратасың, аларны дулкынланып укыйсың.

Р. Ишморатның сугыш елларында фронт газетасында «Изге хис», «Ленин ордены», «Гвардия майоры Бәдретдинов», «Берлинда» очерклары, «Рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар», «Владимир Маяковский» һ. б. мәкаләләре басыла. «Берлинда» исемле очерктан берничә юл китерик.

«Менә ул, фашист еланнар оясы, мең кәррә ләгънәтләнгән Берлин.

Берлин бүген бездә. Без әле Ватаныбыз иң дәһшәтле минутлар кичергәндә, немецлар Москва янында торган чагында да Берлин турында уйлый һәм дошманны бер вакытта да Москвага аяк бастырмавыбызга, ә үзебез Берлинда булачагыбызга ышана идек...

Менә без бүген Берлинда. Берлин өстендә безнең Җиңү байрагыбыз җилферди...» («Ватан намусы өчен», 1945 ел, 30 сан.)

Газетаның һәр санында диярлек шагыйрь Гали Хуҗиның шигырьләре, очерк һәм мәкаләләре урын алган. Автор «Яу күрке» поэмасында Советлар Союзы Герое гвардия сержанты Нурми Шәриповның тиңдәшсез батырлыгын сурәтли, соңгы сулышына кадәр дошман алдында тез чүкмәвен калку рәвештә тасвирлый. Поэма газетаның 1945 елгы 4—5 саннарында басылып чыга.

**«...Ауды җиргә...**
**Бөтен тирә-якны**
**Ялкын белән тимер көйдерде.**
**Үлеме дә совет солдатының**
**Дошманнарга үлем китерде...»**

Фронт газетасы битләрендә Мөхәммәт Садриның да шигырьләре, мәкалә һәм очерклары еш очрый. «Атлы батыр алга ашкына», «Хафиз батыр» исемле шигырьләрендә, Александр Матросовка багышланган «Каһарман дус» исемле поэмасында, «Сугыш осталары» кебек очеркларында әдип совет солдатлары һәм офицерларының онытылмас образларын тудырган. Бу җәһәттән газетабызның 1944 елгы 95 санында басылган «Сугыш осталары» дигән очеркы аерылып тора.

Фронт газетасы редакциясендә кече лейтенант Мостай Кәрим дә берничә ай эшли. Башта ул газетаның актив хәбәрчесе була. Менә М. Кәримнең «Мин синең ягымлы анаңны күрдем» дигән парчасы. Ул газетаның 1943 ел, 4 май санында басылган.

«Әнкәң синең өйгә кайтуыңны көтә, димәк, синең җиңүеңне көтә. Аның улының җиңмәве мөмкин түгел. Ул дошманны җиңмичә кайтмаячак. Әнкәң йөрәгендә синең җиңүеңә никадәр ышаныч һәм сиңа никадәр мәхәббәт, сугышчы иптәш!..

Мин синең әнкәңне Башкортстанның зәңгәр күге астында да күрдем...

Мин синең әнкәңне гүзәл Татарстанның алма бакчаларында күрдем...

Сугышчан иптәш! Мин синең әнкәңне туган илебезнең барлык почмакларында да очраттым.

Ул синең җиңүеңне көтә».

Фронтовик әдипнең «Идел кызы» шигырендә яу кырында батырлыклар күрсәтеп, яралыларны үлем тырнагыннан коткарган совет кызы образы гәүдәләнә:

> «Яуда ауган егетләрнең
> Бәйли күңелы ярасын,
> Гөлнәзирә ялкын аша
> Суза шәфкать карашын.
> Батырларның гомре өчен
> Утлар эченә керә,
> Идел кызы, илем кызы
> Санитарка Нәзирә».

(Газетаның 1944 елгы 26 саны).

М. Кәрим «Дан ордены», «Син кайтканда» кебек шигырьләрендә дә җиңү артыннан җиңү яулаган, дошманны үз өненә куып барган сугышчыларыбызның образларын җылы һәм тәэсирле сурәтли.

Кече лейтенант Зәйни Шәһиморатов та, редакция сотрудникгы буларак, газетаны чыгаруда зур тырышлык куя, мәкаләләре, шигырь һәм скетчлары белән газетаны баета. Аның «Сакта булган мажара» скетчы, «Мин ант итәм» (1944 елгы 42 һәм 44 саннар) «Туган илемә» дигән шигырьләре, «Имән әкияте» (1945 елгы 53 һәм 62 саннар) балладасы — шундыйлардан.

1946 елда Татгосиздат тарафыннан «Җиңү юлы» исемле китап чыгарыла. Анда фронтовик әдипләрнең, журналистларның 1 нче Украина фронты сугышчылары турындагы шигырьләре, поэмалары һәм очерклары тупланган. Бу әсәрләрнең күбесе башта «Ватан намусы өчен» һәм «Кызыл Татарстан» газеталарында басылган. Җыентыкны майор Р. Ишморатов, капитан Г. Хуҗиев, Г. Иделле һәм Г. Бакиров төзегән. Анда Госман Бакировның «Сугышчы көндәлегеннән» исемле зур күләмле очеркы да бар. Автор бу язмасында үзенең беренче империалистик сугышта да катнашуын, Тернополь шәһәрен дошманнан ике кат азат итүен искә төшереп, очеркын болай тәмамлый:

«...Мин ул вакытта яшь идем әле. Дошманга каршы көрәшнең дә ни икәнен аңлап бетерми идем, 1917 нче елгы революция дулкыннары мине алга алып киттеләр... Совет власте шартларында минем бөтен теләкләремә ишекләр ачылды.

28 елдан соң немецлар белән мин тагын очраштым. 28 елдан соң, Тернополь, мин тагын да синең капкаңны кагарга, сине дошманнан азат итәргә килдем. Бу юлы мин коралымның үткенрәгән сайлап, чукмарларымның зуррагын күтәреп килдем».

Бу китапка «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына җавап хаты», «Н-че часть сугышчыларына, сержантларына һәм офицерларына Татарстан хезмәт ияләре хаты» (1944 ел), «Батыр сугышчыларыбызга Татарстанның Дөбъяз районы комсомол һәм яшьләренең җавап хаты», «Татарстанның «Кызыл юл районы», «Алмалы» колхозы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары хаты» урнаштырылган, кайбер каһарманнарның рәсемнәре һәм алар турында белешмәләр бирелгән.

«Җиңү юлы» китабында Р. Ишморатның «Татарстан улы», «Висла буенда», Г. Хуҗиның «Хатип Хәсәнов, Советлар Союзы Герое», Г. Иделленең «Минзәлә егете», «Татарстан тәрбияләп үстергән большевик», «Якташыбыз Гәрәевнең батырлыклары», М. Садриның «Алтын Йолдызлы егет», «Беренче эскадрон», «Арыслан баласы», Г. Бакировның «Парторг», Г. Шәриповның «Лачын», Г. Рәмазановның «Зур тормыш», М. Әмирнең «Мидхәт» очерклары һәм мәкаләләре урын алган.

Р. Ишморат, М. Садри, Г. Хуҗи һәм Г. Иделле Бөек Ватан сугышы елларында — «Кызыл Татарстан» газетасы белән тыгыз элемтәдә торалар, укучыларны яңа әсәрләре белән шатландыралар, фронт батырлары белән таныштыралар.

«Ватан намусы өчен» газетасының үз тирәсенә зур төркем сугышчы-хәбәрчеләрне туплавы да игътибарга лаек. Солдатлар, сержант-старшиналар, офицерлар һәм генераллар газетага яу кырында батырлыклар күрсәткән хезмәттәшләре турында язалар, дошманга каршы сугышта тупланган тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Мәсә-

лән, Башкортстан егетләре капитан Зиннәт Фәтхуллин, старшина Гыйлемдар Рамазанов (хәзер ул шагыйрь һәм галим), сержант Гали Ибраһимов (хәзер язучы), отставкадагы полковник Сәлмән Таһиров (Казан), солдат Шәриф Сайкин, лейтенант Нургали Монасыйпов һәм башка бик күпләр фронт газетасында хәбәрләре, мәкаләләре һәм очерклары, хикәяләре һәм шигырьләре белән катнашалар. Г. Рамазанов үзен шагыйрь һәм оста очеркист буларак таныта. Ул, «Җиңү мае» шигырендә совет солдатының дошманны үз җирендә тар-мар итүен тасвирлап, Европа күгендә азатлык кояшы балкуы, җиргә тынычлык язы килүе турында җырлый («Ватан намусы өчен», 1945, 28 сан).

**«Висла аша, Одер, Шпрее аша**
**Җиңеп узды совет солдаты.**
**Бу майда соң ничек шатлык ташмас,**
**Бәреп кердек Берлин капкасын!»**

«Ватан намусы өчен» газетасында һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, М. Әмир, Г. Бәширов кебек әдипләрнең әсәрләре дә еш басыла. Фронт сугышчылары татар совет язучыларының иҗатлары белән вакытында танышып баралар, ул әсәрләрдән дошманга карата рәхимсез булырга өйрәнәләр.

Бөек Ватан сугышы елларында, совет кешеләрендә патриотизм хисе тәрбияләү максатыннан, пропаганда һәм агитациянең миллионнарча массаны колачлаган яңа бер формасы барлыкка килә. Ул — төрле фронтларда фашистларга каршы көрәшкән татар сугышчыларына Татарстан хезмәт ияләренең хат-мөрәҗәгате. «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хат» 1943 елның 5 мартында «Правда», «Известия», аннары 6 мартта «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарында басылып чыга. Бу хат фронт газеталарына да урнаштырыла. Аны язуда К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Кашшаф, Х. Хәйри, Х. Ярми, К. Федин, Б. Зернит зур тырышлык куялар. Татар халкының фронтовик улларына һәм кызларына язган хат-мөрәҗәгатенә төрле фронтлардагы татар сугышчыларыннан җаваплар килә. «Кызыл Татарстан»ның 1943 елның 3 апрель санында — «Ленинград фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына хаты», 1944 елның 19 август санында — «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына җавап хаты», 1945 елның 17 июль санында «Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хаты» игълан ителә.

«Ватан намусы өчен» газетасы редакциясендә эшләгән Риза Ишморат, Гали Хуҗи һәм Мөхәммәт Садри «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты»н язуга зур өлеш кертәләр.

Шәрәф Мөдәррис «Икенче Белоруссия фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына хаты»н иҗат итүдә актив катнаша.

Хәрби журналистлар татар халкына язылган хаттагы һәр сүзне сугышчыларга җиткерәләр. һәм алар тәкъдиме белән Бөек Ватан сугышы мәйданында батырлык күрсәткән геройлар исеменнән халкыбызга фронттан җавап хаты язу оештырыла. Җавап хаты Беренче Украина фронты политидарәсе начальнигы генерал-майор С. Шатилов тарафыннан яхшы дип табыла һәм раслана.

Сугышчыларның үз халыкларына язган хатларның әһәмияте турында элекке Беренче Украина фронтының Хәрби советы члены генерал-полковник К. В. Крайнюков «Үзенчәлекле корал» исемле китабында (ул «Хәрби мемуарлар» сериясендә 1978 елда Мәскәүдә СССР Оборона министрлыгының «Воениздат» нәшриятында чыккан) менә нәрсә ди:

«Беренче Украина фронтында сугышучы сигез мең үзбәк, казах һәм татар сугышчылары республикалар хезмәт ияләренә адресланган коллектив хатларга кул куйдылар. Советлар Союзы Геройлары А. Х. Вәлиев, В. Б. Әлбетков, Н. Х. Шәрипов, Ә. Кәлиев, С. Х. Хәсәнов һәм башкаларның даны эшләре турында сөйләгән безнең татар сугышчылары хаты Казанда брошюра итеп чыгарылды. Аның тиражы 15 000 данәдән артты. Шуннан соң безнең фронтка Татарстаннан өзлексез ташкындай патриотик хатлар агылды».

Татар сугышчылары җавап хатына тирән дулкынлану кичереп кул куялар. Хаттагы: «Ватан сугышы елларында Сез хезмәттә гаять зур батырлыклар күрсәттегез,

Без Сезнең фронтка, илгә биргән хезмәт җимешләрегезнең тагын да күбрәк, тагын да мулрак булуын телибез. Хак эшебезнең җиңүе хакында, үз-үзегезне аямыйча, тагын да яхшырак эшләгез. Кызыл Армиягә коралларны, сугыш кирәк-яракларын, азык-төлекне, промышленность өчен чималны күбрәк һәм күбрәк бирегез...

Немец-фашист басып алучыларны тәмам җиңеп чыгар өчен каннарыбызны һәм җаннарыбызны да кызганмабыз, бөек азатлык көрәшендә ару-талуны белмәбез, бу көрәш тәмамланмый торып, безнең йөрәкләребез тынгы белмәс.

Шаһит бул, туган җир!

Шаһит бул, якты кояш!» — дигән сүзләр һәркемнең үз күңеле түреннән чыккандай тоела.

Икенче Белоруссия фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына шигъри хатны язуда «Фронт хакыйкате» газетасы хәрби журналистлары, аеруча Шәрәф Мөдәррис актив катнаша. Мәгълүм булганча, «Икенче Белоруссия фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына хаты» 1945 елның июлендә «Кызыл Татарстан» газетасында басыла.

«Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хаты»н фронт газетасында пропагандалауга һәм аңа җавап язуны оештыруга «Ватан намусы өчен» газетасының хәрби журналистлары зур өлеш кертәләр. Алар 1944 елда, партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре З. Муратов ярдәме белән, «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына җавап хаты»н брошюра итеп татар һәм рус телләрендә бастырып чыгаруга ирешәләр.

1943—1945 елларда «Ватан намусы өчен» газетасы битләрендә «Татар егете! Үз халкыңның наказын син ничек үтисең, син ничә фашистны юк иттең?», «Антыңны син ничек үтисең?», «Хәрби антыңны һәм халкыңның наказын син ничек үтисең?» кебек рубрикалар, алар астында сугышчыларның хәбәрләре, язмалары тупланып бирелә.

«Ватан намусы өчен» һәм «Кызыл Татарстан» газеталары үзара да тыгыз элемтәдә торалар. Беренчесе республика газетасы өчен фронттан сугышчылар батырлыгы турында сөйләгән материаллар җибәрсә, икенчесе фронт газетасы өчен Татарстанның тылдагы фидакарьлеген күрсәткән мәкаләләр, әдәбият-сәнгать һәм культура эшлеклеләренең әсәрләрен оештырып җибәргән. Ике газета арасындагы элемтәне ныгытуда Беренче Украина фронты политидарәсенең дә роле зур була. Фронт политидарәсе начальнигы генерал-майор С. Шатилов 1944 елның 23 апрелендә партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре В. Никитинга болай дип яза:

«Беренче Украина фронтының татар сугышчылары, үзләренең туган республикасы тормышын һәм эшчәнлеген газета битләрендә даими яктыртуны сорап, татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» фронт газетасы редакциясенә мөрәҗәгать итәләр...

Сездән Ватан сугышы чорында Татарстан республикасының тормышын һәм эшен яктырткан материалларны җибәрү эшендә тиешле органнарга һәм учреждениеләргә безгә ярдәм итүләре кирәклеге турында күрсәтмә бирүегезне сорыйм (Хат ТАССРның Үзәк дәүләт архивында саклана.)

В. Никитин «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә тиешле күрсәтмә җибәрә.

Мөхәммәт Садри белән Гали Хуҗиның 1944 елның 12 сентябрендә «Кызыл Татарстан» газетасы редакторына язган хатында әлеге элемтәнең ныклыгы аеруча калку күренә.

«Кадерле иптәш Узбеков!

Сезгә һәм «Кызыл Татарстан»ның бөтен коллективына бик күп итеп фронтовой коммунистик сәламнәребез белән бергә, газетагыз өчен материаллар җибәрәбез. Аларны урнаштырырсыз, дип ышанабыз. Җавап хаты Сезнең газетада басылып чыгу бик яхшы булды. Хәзер бик күп иптәшләр Татарстанның төрле районнарыннан хатлар алалар. Без, аларны сайлап, якын көннәрдә газетабызда файдаланачакбыз. Сезгә җибәрербез. Бу материаллар хезмәт ияләренең хатларына җавап төсендә урнаштырылса, бигрәк тә яхшы булыр иде.

Ком. сәлам белән

М. Садри, Гали Хуҗи.

12. IX. 44 ел.»

Беренче Украина фронты гаскәрләренең сугышчан данлы юлы фашист җирләренең үз оясына — Берлингача барып җитә. Бу җиңүгә фронт газетасы журналистлары да үзләреннән зур өлеш кертәләр. Фронтның Хәрби совет члены генерал-полковник К. В. Крайнюковның «Үзенчәлекле корал» китабындагы түбәндәге юллары игътибарга лаек.

«Хәрби корреспондентлар — штыкка тиң булган большевистик сүз, каләм белән көрәшүче алгы сызык солдатлары алар. Әгәр хәл таләп итсә, илбасарларга каршы сугышка кергәндә, алар кулларына автомат алдылар. Урам сугышлары вакытында, геройларны сурәткә төшергәндә, «Ватан намусы өчен» газетасының фотохәбәрчесе Николай Ксенофонтов Бреслауда дошман снайперы пулясыннан һәлак булды. Оператив задание буенча ПО-2 самолетында очканда шул ук газета хезмәткәрләре капитан И. Станевский һәм өлкән лейтенант Н. Скоробогатов гитлерчылар тарафыннан һәлак ителделәр. Майор С. Вовк сугышчан постта үлде. Татарча чыгарылыш буенча фронт газетасы редакторы урынбасары Р. Ишморатов һәм аның бригадасының кайбер членнары Берлин юнәлешендә снаряд кыйпылчыгыннан яраландылар». (К. В. Крайнюков. «Үзенчәлекле корал», Мәскәү, «Воениздат», 1978 ел.)

Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Р. Ишморатов һәм Г. Бакиров — Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр, Г. Хуҗиев һәм М. Садретдинов Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивында редактор урынбасары майор Р. Ишморатовны II дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итү турында «Бүләкләү листы» саклана. Анда «За честь Родины» («Ватан намусы өчен») фронт газетасының җаваплы редакторы полковник С. Жуков олы бүләккә лаек булучы коллегасына мондый характеристика бирә:

«...Иптәш Ишморатов хәрәкәттәге частьларга еш чыга, подразделениеләрдә, алгы позицияләрдә сугышчылар арасында эш алып бара. Аның тырышлыгы белән татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасы тирәсендә ныклы авторлар коллективы тупланды...

Иптәш Ишмуратов үзен ихтыярлы һәм кыю офицер итеп күрсәтте. Политидарә һәм Хәрби совет заданиесе буенча соңгы чорда иптәш Ишморатов Беренче Украина фронтындагы сугышчы татар геройлары турында җыентык оештыру һәм язу эшенә җитәкчелек итте»...

Шул ук архивта шагыйрь Гали Хуҗины «Бүләкләү листы»да саклана. Ул «Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим ителә, аңа түбәндәгечә характеристика бирелә:

«Өлкән лейтенант Г. Хуҗиев — шагыйрь, журналист, тәрҗемәче — әдәби сотрудник сыйфатында татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасында аның оешу көненнән, ягъни 1942 елның ноябреннән алып эшли. Иптәш Хуҗиев, квалификацияле журналист буларак, иң җаваплы материалларны тәрҗемә итә, шулай ук оригиналь материалларны, очерклар, шигырьләр, мәкаләләр иҗат итә.

Иптәш Хуҗиев шигырьләре укучылар арасында зур популярлык казанды...»

Өлкән техник-лейтенант Мөхәммәт Садретдиновны Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим иткәндә, аңа мондый характеристика язылган:

«Иптәш М. Садретдинов корреспондент-оештыручы буларак эшләп, һәрвакыт алгы сызыкта йөри һәм редакцияне системалы рәвештә оператив материаллар белән тәэмин итә...

Иптәш Садретдинов, Бөек Ватан сугышы башыннан ук фронтларда катнашып, төрле дәрәҗәләрдә һәм һәрвакыт алгы сызыкта булган хәлдә, үзен Совет Ватанының лаеклы сакчысы итеп танытты.

Аның шигырьләре һәм очерклары бик популяр һәм алар татар сугышчыларын яңа батырлыкларга рухландыралар. Редакциягә килгән күп санлы хатлар шул хакта сөйли.

«За честь Родины» фронт газетасының җаваплы редакторы полковник (С. Жуков)».

Бу документлардан күренгәнчә, Бөек Ватан сугышы еллары журналистикасын баетуга лаеклы өлеш кертүннәре һәм батыр булганнары өчен, фронтовик әдипләр иҗатына югары бәя бирелә.

*
* *

Бөек Ватан сугышы елларында дошманнарга каршы көрәшкән, фронт газеталарында хезмәт иткән Ибрай Гази, Әхмәт Ерикәй, Абдулла Әхмәт, Афзал Шамов, Хатип Госман һәм Әхмәт Исхак кебек әдипләребез шулай ук сугыш еллары әдәбияты һәм журналистикасының һөҗүмчәнлеген арттыруга күп көч куялар. Дәһшәтле елларда аларның әдәби әсәрләре, мәкалә һәм очерклары, публицистик язмалары «Кызыл Татарстан» газетасында, «Совет әдәбияты» журналында, үзләре эшләгән фронт газеталарында бер-бер артлы дөнья күрә. Бу әдипләр халкыбызның гитлерчы илбасарларга каршы изге көрәшен һәм сугышчыларыбызның батырлыгын гәүдәләндергән язмалары белән солдатлар һәм офицерларның зур ихтирамын казаналар. Түбәндәге документлар да шуны раслый.

Менә Ибраһим Газиның «Бүләкләү листы». Анда мондый юллар бар:

«Лейтенант Ибраһим Зарифович Мингазиев — Совет Язучылары союзы члены, моннан ике ел ярым элек үзе теләп, Кызыл Армия сафларына баса һәм Ватанны саклау өчен фронтка китә.

Ул, вакыты һәм авырлыклар белән исәпләшмичә, үзенең бөтен энергиясен газетага бирә. Ватан сугышы геройлары турындагы хикәяләр һәм очерклар китаплары белән иптәш Мингазиев үзен татар теленең иң яхшы белүче итеп күрсәтте. Аның тарафыннан Ватан сугышының иң җаваплы документлары — иптәш Сталин докладлары һәм приказлары, фронт политидарәсенең листовкалары һәм башка материаллар татар теленә тәрҗемә ителделәр...

Ул безнең фронтның башлап язучы сугышчы-авторлар белән элемтәдә тора, аларга консультация бирә, матбугатта чыгарлык әсәрләр язарга ярдәм күрсәтә...

«Красная Армия» газетасының җаваплы редакторы полковник (Потапов).

30 май, 1945 ел».

Беренче Белоруссия фронтының «Красная Армия» газетасы «Кызыл Армия» исеме белән татар телендә дә чыгарыла.

Бу документ СССР Оборона министрлыгының үзәк архивында саклана. Шунда ук язучы Абдулла Әхмәтне «Бүләкләү листы» да бар.

«Кече лейтенант А. С. Әхмәтов 1943 елның мартыннан татар телендә чыга торган «Алга, дошман өстенә» газетасы редакциясендә эшли. Башта корреспондент, 1944 елның гыйнвареннан — оештыручы корреспондент. Алгы сызыктагы подразделениеләрдә еш була. 1944 ел дәвамында һәм 1945 ел башында һөҗүм итүче подразделениеләр сафларында булып, редакцияне безнең фронт сугышчыларының, бигрәк тә татар сугышчыларының батырлыклары турындагы оператив, яңа материаллар белән тәэмин итеп торды...

Редакциянең сугышчан заданиеләрен бик яхшы үтәгәне өчен кече лейтенант А. С. Әхмәтовны хөкүмәт бүләгенә — Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим итәм.

Җаваплы редактор

подполковник (М. Рамзин)».

Язучы һәм журналист Абдулла Әхмәт Бөек Ватан сугышы елларында очерклары һәм мәкаләләре белән киң масса укучыларга яхшы танылды. Аның бу елларда «Алга, дошман өстенә» газетасында дистәләгән язмалары чыкты. Фронтовик әдип үзенең әсәрләрендә якташларыбызның яу кырында күрсәткән батырлыкларын калку тасвирлый. Күренекле шагыйрь Әхмәт Ерикәй дә үзенең иҗат эшчәнлеген журналистика белән оста бәйләде. Бу җәһәттән түбәндәге документларга игътибар итик.

«19 декабрь, 41 ел.

ВКП(б) Үзәк Комитеты.

Пропаганда һәм агитация Идарәсе начальнигы

иптәш Александровка.

Татар язучылары Ерикиев, Фәйзи һәм Маннур иптәшләр хәрәкәттәге армиягә барырга теләк белдерделәр.

СССР Язучылары союзы Президиумы сездән шушы язучыларны хәрби матбугат работниклары сыйфатында фронтка җибәрүдә ярдәм итүегезне сорый.

Моңардан тыш, СССР Язучылары союзы Президиумы Эшче-крестьян Кызыл Армиясенең Политик идарәсеннән, талантлы татар язучысы Максудовны, аның соравы

буенча, Мәскәү хәрби округы элемтә полкының (Чабаксар шәһәре) беренче бүлекчәсеннән (ул Мәскәү шәһәренең Первомайский район хәрби комитетыннан мобилизация буенча шунда җибәрелгән иде) фронт газеталарының берсенә күчерүгә ярдәм итүегезне үтенә, анда ул, сугышчы, язучы-коммунист буларак зур файда китерәчәк:

ӨСТӘМӘ: 1) Ш. Ф. Маннуров гаризасы һәм характеристика;
2) Ә. Ф. Ерикиев гаризасы һәм характеристика;
3) Ә. С. Фәйзи гаризасы һәм характеристика һәм
4) иптәш Максудовка характеристика.

СССР Язучылар Союзы Президиумы секретаре
(А. Фадеев)».

Бу документ СССР Оборона министрлыгының үзәк архивыннан алынды. Шуннан ук тагын бер документ. Ул — Мәскәү хәрби округының «Красный воин» газетасы («Кызыл сугышчы» исемендә татарча да чыккан) редакциясеннән шагыйрь Ә. Ерикәйгә бирелгән отзыв.

«ОТЗЫВ

Бу отзыв капитан Ә. Ф. Ерикиевка бирелә, ул 1943 елның августыннан декабрьга кадәр Мәскәүдә булды, Мәскәү хәрби округының татарча чыга торган «Кызыл сугышчы» газетасы эшендә актив катнашты.

Бу вакыт эчендә иптәш Ерикиев газетада шактый шигырьләр, мәкаләләр, очерклар һәм «Бәти» исемле хикәя бастырды.

Бу отзыв аңа офицерлар бригадасының 53 нче полкына бару өчен бирелде.

Татар телендә чыгарылыш буенча газета редакторы урынбасары өлкән лейтенант (Ярмәкиев).

27 декабрь, 1943 ел».

Бөек Ватан сугышы башланып, берничә ай үткәннән соң, Әхмәт Фәйзи үзе теләп фронтка китә. Ул анда «Фронт хакыйкате», «Ватан өчен» һәм «Совет сугышчысы» газеталарында эшли. Күренекле шагыйрь һәм драматург, проза остасы һәм ялкынлы публицист, тәнкыйтьче, опера һәм балет либреттолары авторы Әхмәт Фәйзи фронт газеталарында һәм республикабыз матбугатында күп санлы шигырьләрен, очерк һәм мәкаләләрен бастыра. «Һәркем үзенең көчен барласын», «Бүре походы» исемле шигырьләрен, «Москва очерклары», «Тәпәреш егете», «Кимпреков алдынгы сугышчы булды» дигән очерклары, әсәрләре — шундыйларның үрнәкләре.

Яшь шагыйрь Шәрәф Мөдәррис Бөек Ватан сугышы чорында «Ватан өчен», «Фронт өчен», «Фронт хакыйкате» һәм «Җиңү байрагы» гзаеталарында әдәби сотрудник һәм корректор булып эшли. Әдип дәһшәтле елларда дошманга каршы батырларча сугыша, үзен актив журналист һәм талантлы язучы итеп таныта. Аның, мәсәлән, «Кызыл Татарстан» газетасындагы «Очкыннар», «Татарстан чәчәкләре», «Баш врач Минһаҗев» кебек очерклары җылы һәм тәэсирле итеп язылган.

Шәрәф Мөдәррисне «Бүләкләү листы»нда (шул ук архивта саклана) мондый юллар бар:

«Кызылармеец Ш. Х. Мөдәррисов Ватан сугышында беренче көннәрдән үк катнаша. Ул Ватан өчен сугышларда яраланды һәм контузия алды. Госпитальдә дәваланганнан соң фронтка кабат килде һәм 1942 елның сентябреннән татар телендә чыга торган фронт газетасы редакциясенә штаттан тыш шагыйрь сыйфатында эшкә кабул ителде... Аның «Командир» «Артиллерист Ваһап» поэмалары, «Фронтовик татарлар» очеркы укучылар арасында югары бәя алды, аларны фашист илбасарларга каршы көрәшкә туплады. 1943—1944 елларда Татгосиздат тарафыннан иптәш Мөдәррисовның Ватан сугышы чорында язылган әсәрләреннән ике җыентык чыгарылды. Иптәш Мөдәррисов күп кенә башлап язучыларны да газетага тартты.

Иптәш Мөдәррисов — яшь, талантлы татар шагыйре, Татарстан Язучылар союзы члены.

Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүгә лаек.

Җаваплы редактор
полковник (Т. Миронов).

18 май, 1945 ел».

Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары ветераны, талантлы язучы, иҗат эшчәнлеген гражданнар сугышы елларында башлап, шушы көннәргә кадәр уңышлы дәвам иттергән һәм укучыларны күпләгән җыентыклары белән шатландырган Афзал Шамов та, гитлерчыларга каршы көрәш чорында хәрби журналист буларак, «Алга, дошман өстенә», «Суворовча кысрыклау» исемле газеталарда эшли. Ул алгы сызыкта, окоп-блиндажларда сугышчылар белән очраша, очеркларында аларның каһарманлыгын сурәтләп, батырларның калку образларын тудыра.

Хәрби журналист фронт шартларында төрле хәлләр кичергән, ул дошманның кургаш яңгыры ява дип тормаган, сугышчыларыбыз янында булырга, аларның батырлыгын үз күзләре белән күрергә омтылган. Афзал Шамов та алгы сызыктан редакциягә кайтып килгәндә бер төркем фашистларга юлыга. Ул югалып калмый, тәвәккәллек һәм кыюлык күрсәтеп, җиде фрицны әсир итә. Аның эшчәнлеге һәм күрсәткән батырлыклары югары бәяләнә — ул Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

А. Шамовны «Бүләкләү листы»ндагы характеристика шул хакта сөйли:

«Капитан Афзал Шиһабетдинович Шамов — татар телендә чыга торган фронт газетасының корреспондент-оештыручысы, безнең фронтның һөҗүм сугышлары вакытында газета өчен материаллар оештырганда каһарманлык, батырлык һәм инициатива күрсәтте. Иптәш Шамов һөҗүм итүче алгы подразделениеләрдә айдан артык булды, аларның тәҗрибәләрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, подразделениеләр белән бергә алга барды. Һөҗүм сугышлары вакытында, хәрби корреспондент буларак, бик яхшы эше өчен, редакция заданиеләрен үтәгәндә күрсәткән шәхси каһарманлыгы һәм батырлыгы өчен, капитан Шамовны хөкүмәт бүләгенә — Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим итәм.

«Алга, дошман өстенә» газетасының җаваплы редакторы
полковник (М. Рамзин)».

Калинин фронтының «Алга, дошман өстенә» газетасы хезмәткәре Җ. Хәсәнов «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә җибәргән хатында болай яза:

«Бөек Ватан сугышының авыр елларында мин, Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Абдулла Әхмәт белән Калинин фронтында чыгарыла торган «Алга, дошман өстенә» газетасында кулга-кул тотынып, бик тату һәм бик якын дуслар булып хезмәт иттек.

Инде үзем турында бер-ике сүз. Мин — Хәсәнов Җәмил Кыямович Куйбышев районы, Әҗмәр авылында яшим. КПСС сафларында булуыма 40 ел тула. Дүрт ел сугышта булдым, ике мәртәбә авыр яраландым. 40 ел укытучы, завуч һәм мәктәп директоры булып эшләдем. Хәзер лаеклы ялда».

Татар совет поэзиясенә зур өлеш керткән өлкән шагыйрь Әхмәт Исхак та — фронтовик әдипләрнең берсе. Ул бик яшьли республикабыз матбугатында шигырьләрен бастыра башлый. Аның иҗатына Муса Җәлил югары бәя бирә. Ә. Исхак менә алтмыш еллап инде татар совет поэзиясенә хезмәт итә. Әдип Бөек Ватан сугышы елларында командир булган, аннары рус телендә чыгучы «Ватан чакыра» исемле дивизия газетасы редакциясенә әдәби сотрудник итеп күчерелгән.

«Взвод командиры кече лейтенант Әхмәт Абдуллович Исхаковка

ПОЛИТХАРАКТЕРИСТИКА

Кече лейтенант Әхмәт Абдуллович Исхаков 1905 елда туган. Татар. Урта техник белемле. 1 нче укчы батальонның 3 нче ротасында взвод командиры булып эшли. Эшен намус белән башкара. Дисциплиналы, эшне үтәүчән командир. Политик яктан үскән, тотнаклы, ротада үткәрелә торган политмасса эшендә һәм стена матбугатында актив катнаша, үзенең идея-политик белемен күтәрү өстендә өзлексез эшли. Үзенә һәм үз карамагындагы кешеләргә таләпчән.

1 нче укчы батальон командиры урынбасары
лейтенант (Дубровский)

...11, 43 ел».

Документ СССР Оборона министрлыгының үзәк архивыннан алынды.

Бөек Ватан сугышында катнашкан фронтовик әдипләр сугыштан соңгы елларда да татар совет әдәбиятын яңадан-яңа әсәрләр белән баеттылар. Аларның кайберләре арабызда юк инде. Әмма аларның әдәбиятка һәм журналистикага керткән өлешләре, халкыбызның бәхете хакына кылган изге эшләре беркайчан да онытылмас.

## Мирхәт Хөснимәрдәнов

# СЕБЕР БЕЛӘН ПАРИЖ АРАСЫ

ОЧЕРК

*КПССның XXVI съездында «1981—1985 елларга һәм 1990 елга кадәрге чорга СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре» расланды. Анда әйтелгәнчә, унберенче бишьеллыкта газ чыгаруны тизләтү иң мөһим бурычлардан санала. Билгеле булганча, РСФСРдагы газ чыганакларының иң әһәмиятлесе — Көнбатыш Себердәге ятмалар.*

*Шул байлыкны, җир астыннан чыгарып, халык хуҗалыгын үстерүгә бирү унберенче һәм уникенче бишьеллыкларның төп бурычларыннан берсенә әверелде. Моның өчен югары дәрәҗәдәге автоматлаштырылган һәм файдалану өчен ышанычлы булган куәтле магистраль газүткәргечләр төзелә.*

*Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргече төзелеше шундыйларның берсе. Ул Көнбатыш Себердән Европага кадәр сузылачак. Көнбатыш Европа илләре Советлар Союзы белән ике арада төзелгән «Газ—торбалар» контракты нигезендә Уренгой газын 1984 елда алачаклар. Түбәндә урнаштырылган очерк шушы магистраль экспорт газүткәргечен салуда катнашучы Татарстан төзүчеләре турында.*

## Илсур егетләре



ичәдә кузгалабыз? — дип сораулы караш ташлады шофер егет, ишектән керә-кергә.— Тышта тагын яңгыр...

Илсур Шәйхетдинов дәшмәде, өстәл өстендәге блокнотларының берсен алып, аның соңгы битләренә нидер язып куйды да урыныннан кузгалды, чөйдәге фуражкасына үрелде.

— Путевканы — Казангамы? — Шофер кабатлап сорады.

— Кирәкми. Мине станциягә генә илтеп куярсың. Поезд белән китәм.

«Мондый чакта юньле хуҗа этен дә урамга чыгармыйдыр».— дип, мыгырданырга яратса да, үзенең начальнигын — технологик агым җитәкчесе Социалистик Хезмәт Герое Илсур Гарәфиевич Шәйхетдиновны тәүлекнең теләсә кайсы минутында теләсә кая илтеп җиткерергә риза. Әгәр «әйдә» дисә, бүген дә карышмас иде. Исең киткән: Арча — Казан, ике-өч сәгатьлек юл. Әмма начальнигы: «Вокзалга!» — диде.

Була бит кешенең ялгыз гына калырга теләгән минутлары, була... Ул бушрак күренгән вагонга кереп утырды. Аның гаиләсе: яраткан хатыны, үсеп җиткән балалары — Марат белән Гөлчәчәге Казанда яши. Кайткан саен сагынып кайтасың.

Кызык бу дөнья: тормыш юлыннан алга барып кына була, кире кайту юк. Үткәннәрне искә төшерергә генә мөмкин.

...Илсур армиядән кайткач, аны «Татнефтепроводстрой» трестының 3 нче төзүмонтаж идарәсенә чүкечче итеп алганнар иде. Кадрлар бүлегендә саклана торган бланкка аның тормыш юлы турындагы саран гына мәгълүматлар теркәлде: Биектау районының Мүлмә авылында 1936 елда туган, аннары Арча районындагы Орнашка күчкәннәр; сигез балалы гаиләнең башлыгы — укытучы. Илсур — иң олы бала. Арча педучилищесын тәмамлаган. Механизатор һөнәренә һәвәслеге барлыгын белеп, бераздан тракторга утырттылар. Махсус курска да җибәреп кайтардылар. Шуннан соң ул торба салу колоннасының бригадиры булды. Бу хәл моннан егерме өч еллар элек иде.

Ул чакта Илсур бу хезмәтнең нинди авыр сынаулар алып киләчәген уйламаган иде. Аңа дан китерәчәге исә башына да кереп чыкмады. Дан өчен эшләми бит кеше.

Торба салучының хезмәт юлы бик гади ысул белән, чакрым санына карап үлчәнә. Чакрымнары исә тигез җирдән генә үтми, биек-биек таулар, төпсез сазлыклар, киң елгалар, калын урманнар, тирән чокырлар да очрый аңа. Өстәвенә, җир астыннан үтә торган бу торбаларны геометрия китабындагы сызыклар кебек турыга гына да салып булмый. Аларны сыек тал чыбыгы кебек теләсә кайсы якка бөгә дә алмыйсың. Шуңа күрә нокталар барлыкка килә. Берсеннән икенчесенә турыга, иң-иң кыска юлдан үтәргә кирәк. Аннан тагын борылыш. Тагын яңа нокта. Торба салучының хезмәт юлы да әнә шундый нокталардан җыела сыман.

Себер нефтен һәм газын үзләштерүчеләрнең меңләгән армиясе сафына ул үзе теләп кушылды. Бу вакытта инде ул чорнап җир куенына торба салу эшенең нечкәлекләренә тәмам төшенгән колонна башлыгы иде. Себер нәкъ шундый кыюларны, романтик рухлыларны таләп итте. Чөнки илебезнең бу районнарында әлегәчә файдаланылмый яткан җир асты байлыкларын, бигрәк тә нефтьне һәм газны күпләп чыгара башлау вакыты җитте. Атаклы нефтьчеләр, төзүчеләр, бораулаучылар һәм газ чыгару осталары Себер киңлекләре куеныннан алып биргән байлыкны арзанлы ысул белән озату өчен куәтле нефть һәм газүткәргечләр корырга, җыю һәм компрессор станцияләре, эшкәртү заводлары төзергә тиеш иде. Мондагы газ чыганаклары чит илләрне дә кызыксындыра башлагач, бу хезмәтнең әһәмияте тагын да арта төште.

Себердәге «кара алтын» һәм зәңгәр ягулык өчен барган хәлиткеч көрәшнең елъязмасына Татарстан егетләренең дә, шул исәптән Илсур Шәйхетдиновның да исеме теркәлеп бара. Газета-журнал битләреннән аның тулы көләч йөзе балкый. Алар колоннасы сузган торбалар башта Әлмәт белән Горький шәһәрен тоташтырган иде. Хәзер инде Шаим-Төмән-Әлмәт трассасында да ничә еллардан бирле шаулап нефть ага. Миңлебай — Казан арасындагы этан үткәргеч торба республикабызның зур химиясен алга җибәрүдә нык этәргеч булды. Түбән Кама һәм Брежнев шәһәрләре, андагы куәтле нефть химиясе комбинаты, «КамАЗ» автогиганты, Зәй ГРЭСы — һәммәсенә нефть һәм газ кирәк иде. Һәм алар кыйммәтле чимал белән вакытында тәэмин ителде.

Зур бүләкнең беренчесен — Ленин орденын Илсур Шәйхетдинов Шаим-Төмән нефть үткәргечен нормада каралган вакытны ике тапкыр кыскартып сафка бастырганы өчен алган иде. Һәм менә тагын яңа Указ: «Төмән өлкәсенең төньяк районнарында Урал — Идел буе — Үзәк газүткәргечен төзү вакытында ирешкән уңышлары өчен СССР Верховный Советы Президиумының 1975 ел, 20 февраль Указы нигезендә «Татнефтепроводстрой» трестының механикалаштырылган колонна бригадиры Илсур Гарәфи улы Шәйхетдиновка Социалистик Хезмәт Герое дигән исем бирелә, аңа Ленин ордены, «Урак һәм Чүкеч» алтын медале тапшырыла...»

Указ чыккан көнне Илсур Татарстаннан еракта иде. Ял иткән җиреннән коштай очып Казанга кайтып төште. Хатыны, бала-чагалары әтиләрен сый әзерләп

көтеп торганнар. Икенче көнне иртән үк Илсур колоннасына, коллективына ашыкты. Аның егетләре бу көннәрдә Төмән өлкәсендә Нижневартовск — Курган — Куйбышев трассасын салалар иде. Бу юлы алар 66 километрны үтәргә тиешләр. Шуның иң авыр өлешен — 26 километрын май аенда, Себер язының актарыла башлаган вакытына кадәр төгәлләргә кирәк. Ничек икән хәлләре? Илсурның уенда — шул гына.

Илсур самолетта Көнбатыш Себер тайгасы өстеннән оча. Күзләре — җир өстен күзәтә. Әнә шундагы бер төбәккә кайчандыр алар вертолетка төянеп күчеп килделәр. Январында яшь балалары да бар. Вертолет җиргә төшеп утыру белән, ашыгып төзү материаллары бушата башладылар. Аяктан егардай көчле җил исә. Хатыны юрганга төрелгән яшь баласын кар өстенә куя да, йорт әйберләрен алу өчен вертолетка кире менә. Баскычтан борылып караса, җил кар өстендәге баланы тәгәрәтеп алып китеп бара.

— Илсу-у-у-р!

Илсур бала артыннан чаба, җилне куып җитеп, төргәкне күтәреп ала. Үзе көлә: «Шулай чыныксын Себер табигатенә!» — дип, Даниясен үрти. Хатыны килеп аны битәрли башлый: «Синең арттан йөреп, баланы харап итә яздым инде!» — ди.

Соңгы елларда гына Илсур Шәйхетдинов гаиләсе Казанга төпләнде, аларга бөтен уңайлыклары булган зур квартира бирделәр. Дания шунда эшкә дә урнашты. Карда тәгәрәгән Марат — хәзер төзелеш инженерлары институтында, Гөлчәчәк техникумда укый.

Аталары Илсур — үз юлында, үзе хәтәр, үзе мавыктыргыч юлда ул. Берчак шулай сазлыкка килеп төртелделәр. Киңлеге биш йөз метрлап бар. Торбаларны шуның аша сузарга кирәк иде.

— Торбаларны коры җирдә ябыштырып, чорнарга, сазлыкка шудырып кертергә уйладык,— дип сөйли Илсур. Агач киртәләр тезеп, сазлыкка өслек ясадык. Төнлә коеп яңгыр яуды. Иртән карасак, өслек бүрәнәләребез йөзеп йөриләр. Нишләргә? Киртәләрне җыю өчен муеннан суга керергә кирәк. Моңарчы бернинди кыенлык алдында да югалып калмаган егетләрнең дә каушар чагы бар икән! Мин «суга кереп эшләргә кирәк булыр», дигәч, шикләнә калдылар. Сазлык бәлки, ул төпсездер, төбе булса да, суырадыр. Карашлары: «Башта үзең кереп күрсәт» дип әйтәдер кебек. Башлап үземә эшләп күрсәтергә туры килде шул. Киртәләрне яңадан бастырдык, яңадан тездек. Бу участокта да торбалар салу тоткарланмады. Безнең эш шундый инде: урын уңайсыз, дип, уратып үтеп булмый. Торбаларны гел турыга сузарга кирәк.

Илсурның үз тормыш юлы да әнә шул торбалар кебек, читкә тайпылмыйча, гел турыдан, гел алга бара.

Менә тагын яңа магистраль. Чакрымнарга сузылган лычкылдап торган сазлык. Ялгыш атладыңмы, чумасың. Трасса үз юлында Обь һәм Иртыш елгаларын да аркылы кичеп үтә. Әлегә кадәр кырыс Себернең төрле җирен — тайгасын да, күлләрен-елгаларын да, сазлык-баткагын да күрделәр. Тик мондыйны...

Илсур Гарәфиевич егетләрне яңа трасса үтәчәк урынга алып чыкты. Җитәкче аһ-зар ишетергә әзерләнеп торган иде дә, егетләрнең әллә ни исе китмәде. Үз көчләренә ышану идеме бу, әллә алдагы бурычның бөтен катлаулылыгын тоеп җиткермәү булдымы — әйтүе кыен. Шулай да яңа имтиханның җиңел түгеллеген һәркайсы төшенде. Егетләрнең мондый чакта һәрнәрсәне уен-көлкегә бора торган гадәтләре барлыгын белә иде начальник. Алай җиңелрәк.

Барлык трассаны уникე айда файдаланууга тапшырырга! Норма буенча 36 ай каралган. Елның өченче кварталында өлгертү өчен, һәр колоннадан, һәр торбачыдан эш темпын өчләтә арттыру таләп ителә. Ә ничек итеп? Бусын инде үзең уйла, үзең тап. Технологик агым начальнигы буларак, Илсурга аеруча җитди эзләнергә туры килә. Элек торбаларны траншея төбенә ныгытканда тимер-бетон батырмадан файдаланалар иде. Бу бик кыйммәткә төшә. Ә хәзер тиз дә, арзан да кирәк. Унынчы бишьеллык бурычлары торба салучылардан эчке резервлар табуны таләп итә. Себер газы Көнбатыш Европа илләренә дә — Франция, ГФРга кадәр барып җитәргә тиеш, дигән сүзләр дә йөри...

Егетләргә социалистик ярыш ярдәмгә килде. Шәйхетдиновныкылар ярыша беләләр инде! Алар газүткәргеч салуда катнашучы барлык арадаш оешмаларны «Эшче эстафетасы» дигән комплекслы ярышка кушылырга чакырдылар. Мөрәҗәгатьне һәркайда күтәреп алдылар.

Илсурныкылар, эшне вакытында үтәп чыгу өчен, ике сменага бүленделәр, кайчак өченче сменада эшләүдән дә баш тартмадылар. Субподрядчылар да моны хуп күрде. Тәүлек дәвамында башкарылган эш күләме сизелерлек артты: торба тоташтыручылар бригадасы да нормадагы 500—600 метр урынына 1000 метр ялгый башладылар. Җир казучыларның да, чорнап торба салучыларның да темпы үсә барды.

Илсур егетләре эштәге алымнарны гел яңартып, камилләштереп торалар. Соңгы вакытта алар торба салганда тимер-бетон батырмалардан баш тартырга уйладылар. «Алмашка нәрсә тәкъдим итәсез?» — дип сорадылар алардан. «Анкерлар кулланырга, ягъни бастырыклау ысулыннан файдаланырга кирәк»,— диделәр. Бу, әлбәттә, бөтенләй яңа эш иде. Тиз генә өйрәнеп тә, күнегеп тә китә алмадылар. Көнгә нибары 15—20 анкер бораулап керттеләр. Мондый акрын темп белән эшләгәндә, барлык сроклар чәлпәрәмә киләчәк иде. Өйрәнеп җиткәч, югалган вакытны куып үтәрбез, дип чын күңелдән ышанды Илсур һәм хезмәтне төгәл оештырырга тырышты.

Ул ялгышмады. Яңалыкны үзләштерү оешкан төстә барды. Бастырыклау процессы өч этапка бүленә. Анкерларны җыю һәм трассага китерү белән Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Г. Бесчастнов җитәкчелек итте. Ул, пенсия яшендә булуына карамастан, тагын корыч магистральләр коруны ташлый алмый иде әле. Бу бригада составында Илсурның Совет Армиясе сафыннан кайткан иң кече энесе Азат та бар иде. Шулай итеп Шәйхетдиновлар трассада абыйлы-энеле дүртәү булдылар.

Икенче һәм өченче этапларда, анкерны җиргә бораулап кертеп торбаларны бастырыклап куюда Илсурның тагын бер энесе — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Зөфәр хезмәттәшләре Р. Гыйсмаев, Шамил һәм Әбүзәр Җамалиевлар белән аеручa дәртләнеп эшләделәр. Бастырыклар 10—11 тонна авырлыгындагы торбаларны, өскә калкып чыкмаслык итеп, траншея төбенә беркетеп торырга тиеш.

Татарстанның торба салу осталары уйлап тапкан камил эш алымнары һәр трассада файдаланыла.

Пермь — Казан — Горький газүткәргечендә Илсур Шәйхетдинов җитәкләгән агым коллективы 116 километр торба сузды. Аннан Төмән газы илебезнең үзәк районнарына килә башлады. Шул елдагы «Молния»ләрнең берсендә шундый юллар бар: «Технологик агым коллективлары арасында беренче урынны И. Шәйхетдинов җитәкчелегендәге комплекслы технологик агым коллективы яулады. Алар Илеть елгасы култыгында үткәргеч торбаларны салуда яңа технология — шлюз аша йөздерү алымы кулландылар...»

Торбаларны саzлык төбендә тотып торучы, кыйммәтле тимер-бетон батырмалардан баш тартып, анкерлар белән бастырыклау ысулына күчү хезмәт чыгымнарын 2,7 тапкыр киметергә мөмкинлек бирде.

Хәер, бер Шәйхетдиновныкылар гына түгел, торба салучыларның һәр коллективы хезмәткә иҗади мөнәсәбәттә тора, мөгаен, шуңадыр — аларның һәр чакрымын уңыш бизи бара.

## Уренгой урамы

Тугандаш Мари республикасының Звенигово шәһәренә килгәч, «Су астында эшләүчеләр кайда яши?» — дип кемнән генә сорасаң да, төгәл юнәлеш күрсәтерләр, Иделгә таба ишарә ясарлар. «Шәһәрчек» бер катлы такта йортлардан тора. Төгәл тәртип белән төзелгән бердәнбер урам. Кырый йортка «Уренгой урамы» дип язып куелган. Беренче йорт — кафе. Каршыда — контора. Безне су асты техник эшләр идарәсе начальнигы Владимир Пелипенко каршылады.

— Тиздән Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргеченең шушы тө-

бәгендә бик катлаулы эш башланачак,— дип сөйләп китте ул.— СССРның Европа өлешендәге иң зур су юлы — Идел елгасы төбенә зур диаметрлы газүткәргеч торбалар салыначак. Бу эшне суднолар йөрешенә комачаулык китермичә, 9—10 көн эчендә башкарырга кирәк...

План буенча бу эш биш-алты ай соңрак вакытка билгеләнгән иде. Әмма аны 1982 елның октябрь аенда, СССРның 60 еллыгына бүләк төсендә, алдан башкарырга уйладылар. «Востокподводтрубопроводстрой» трестының Казандагы 4 нче идарәсе начальнигы Владимир Георгиевич Пелипенко үз эшләренең хикмәтен аңлатырга тырыша.

— Траншея казып, торба салу җир өстендә дә катлаулы эшләрдән санала. Шулай да монда ялгыш җибәрсәң, үз күзең белән күреп торасың, тиз арада төзәтергә була. Әлеге юан торбаларны су астына төшерүнең ни дәрәҗәдә четерекле икәнен аңлатып та булмый. Монда ялгышырга һич ярамый, бик зур тәгәллек кирәк. Су төбендәге траншеяга урнаштырганда, торба салучыдан аеруча ипләп эш итү сорала. Без шул имтихан алдында торабыз. Өч көннән траншеялар әзер булачак. Елга төбеннән 700 мең кубометрлап балчык алынды...

Владимир Георгиевич сөйләвеннән туктады да елга төбен күрсәткән картага карады.

— Менә шушы төштә,— диде ул бер ноктага тукталып,— каты үзле балчыкка килеп төртелдек. Бу кыска гына араны үтү өчен тагын да куәтлерәк икенче земснарядны да шунда юнәлтергә туры килде. Су төбендәге траншеяның тирәнлеге урыны белән 4—12 метрга җиткереп казыла. Ә биредә суның тирәнлеге дә 20 метрлап бар. Иделнең аръягында — текә кыя.

Елга кичү ничек кенә катлаулы булмасын, 4 нче су асты техник эшләр идарәсе коллективы аны уңышлы башкарып чыгачагына алдан ук ышанган иде. Чөнки, елга төбенә торба төшерүнең бөтен технологиясе җентекләп өйрәнелгән. Бу җаваплы бурыч иң оста егетләргә йөкләнгән. Шулай да эшкә турыдан-туры катнашучы, аның өчен барыннан да элек җаваплы кешеләрнең йөзеннән борчылу галәмәтләре төсмерләргә була. Коллектив Иделне рекордлы срокта үтәргә җыена. Аның аша салыначак торбалар (су төбенә салына торган торбаларны дюкер дип йөртәләр) озын итеп әзерләнгәннәр. Ком өстенә аларны суга таба тартырга уңай итеп җайлап урнаштырганнар. Югарыдан караганда, алар пенал эчендәге карандашларны хәтерләтәләр. Һәр бәйләмдәге торба такта белән тышланган, аларга берничә метр саен чуен кыршау кидерелгән. Шунсыз ул елга төбендә ятмаячак, өскә калкып чыгачак. Бәйләмнәрне Казанда ук әзерләгәннәр, рентген нурлары белән тикшереп, 100 атмосфера басымы астында сынаганнан соң гына Идел буйлап су юлы белән Звениговога китергәннәр.



Командирлары А. Хәсәнов һәм В. Искәндәров булган земснаряд экипажларының эше аеруча җаваплы булган. Торба ятачак траншеяның тирәнлеге, турылыгы, ныклыгы алар осталыгына бәйле. Водолазлар станциясе старшинасы Фәргать Шәйдуллин да, торба салу механизмы машинисты, дюкерны яр буенда суга төшерү өчен әзерләүчеләр бригадиры В. Чернявский да, бульдозерчы-машинист А. Сорокин да, торбаларны эретеп ябыштыручы аталы-уллы Богуновлар да — иң катлаулы операцияне ышанып тапшырырдай белгечләр.

Уренгой урамы әллә ни киң түгел, әмма озынлыгы... Көнбатыш Себердән Европа үзәгенә кадәр сузыла. Ул — хезмәттәшлек урамы. Иң мөһиме һәм кадерлесе — тыныч хезмәт урамы. Ул илебезнең күп кенә республикалары һәм өлкәләре аша үтә. Ул Социалистик дуслык илләренә барып җитә. Европадагы ГФР, Франция, Италия, Австрия кебек капиталистик илләр дә Уренгой «урамы» аша сузылган торбалардан Себер газын алачаклар. Экспорт газүткәргеченең беренче мең километры 1982 елның октябрь аенда сафка басты. Уренгой урамы айдан-айга, елдан-елга озыная барачак.

Ә биредә — Идел буенда водолазлар көн саен су төбенә төшәләр. Траншеяның тирәнлеген, киңлеген үлчәп торалар, торышын тикшерәләр. Уренгой — Помары — Ужгород газүткәргечен салганда, күп урында су киртәсе үтеләчәк. Бөтенесен бергә җыйсаң, су төбе траншеяларына салыначак торбалар озынлыгы 40 километрга җитә. Идел — шуларның берсе һәм шактый катлаулысы. Идарәнең су асты хезмәте батырларын ул бу юлы кырыгыйчы тапкыр сыный.

## Кырыгынчы имтихан

Барысы да әзер. Һәммәсе «башларга» дип күккә чөеләчәк яшел ракетаны көтәләр. Әмма 4 нче су асты техник эшләр идарәсенең Идел төбеннән газүткәргеч торбалар сузарга алынган кешеләре ашыкмыйлар. Аларга һавалану хас түгел. Бригадир В. Чернявскийның В. Воронцов, П. Сапожников кебек монтажчылары су төбенә беренче төшәчәк 200 метрлы бәйләмне тагын бер тапкыр тикшереп-күзәтеп чыктылар. Сварщиклар Николай һәм Александр Богуновлар махсус киемнәрен кигәннәр. Водолазлар суга чумарга әзер. Торба салучы алты машина бәйләм — торба буенча тигез ара калдырып тезелгәннәр. Кабина ишекләреннән машинистларның җитди йөзләре күренә.

Аръяктагы лебедка хуҗалары белән рация аша элемтә өзелеп тормый. Белгечләр, әзерлекне тикшерү өчен, катерга утырып ул якка чыгып та керделәр.

Яр тулы кеше. Һөнәрнең төп иясләреннән тыш, Татарстан, Мари, Чуваш автономияле республикаларының матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре, Мәскәү хәбәрчеләре, операторлар, режиссерлар, кинохроникачылар да җыелган — санап бетергесез. Һәммәбез көтәбез. Көндезге сәгать өч. Юан корыч аркан акрын гына тартыла башлады. Миңа ул скрипка кылы кебек киерелде, нечкәрә төшкәндәй булды. Башланды!

Без катлаулы операцияне башкарудагы җаваплы кешеләрнең кайберләреннән аяк өсте генә интервью алдык.

Иван Яковлевич Захаров, «Востокподводтрубопроводстрой» трестының баш инженеры:

— Бу минутларда тросны урнаштыру тәгәлләнеп килә. Уңъяк ярдагы лебедка дюкер бәйләмнәрен тартачак. Һәр бәйләм — 400 тонна. Су төбенә төшкәндә, җиңеләйтү өчен понтоннар куела. Алар торба белән бергә су төбендәге траншеяга кадәр төшә. Аннан соң водолазлар аны ычкындыралар, понтон өскә калкып чыга.

Елга төбе траншеясыннан чыккан балчык, дюкерны траншеяга салгач, үз урынына тутырыла...

Владимир Грызунов, электросварщик, «Почет билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, СССР Нефть һәм газ промышленносте төзелеше министрлыгы отличнигы:

— Мин бу системада егерме ике ел эшлим инде. Кама аша — 10, Идел аша 20 тапкыр торба сузуда катнаштым. Миңа тагын — Идел. Безнең өчен бу гадәти эшкә әйләнде. Торба салу процессы бөтен ваклыкларына кадәр төгәл исәпләнгән.

Николай Исайков, торба салу машинисты:

— Идел безне: «Тагын килдегезме?!» — дип сәламли төсле. Эшне вакытыннан алда башладык. Шулай кирәк иде. Бөтен ил күзәтә. Бөтен дөнья игътибары шушы магистральдә хәзер...

...Моторлы көймә уңъяк ярга кабат томырылды. Аннан, бирге якка чыгып, хәзерлек барышын үз кулына алган идарә начальнигы Владимир Пелипенко суга

беренче булып төшәчәк торба бәйләме янындагы икенче звено өстенә менеп басты. Кулында — ак һәм кызыл төстәге ике флаг. Бәйләмнең теге башында да шундый ук сигналчы баскан. Владимир Георгиевич муенына эленгән рация аша һәр ике яктагы эш барышы белән командалык итә. Диспетчерлык пунктында — берләшмә начальнигы урынбасары В. Мальцев. Сәгать кичке биш. Караңгылана башлаган күк йөзен яшел ракета яктылыгы кисеп үтә. 18 торбаны бергә тоташтырып ясалган 200 метрлы бәйләм җирдән акрын гына күтәрелә. Уңъяк ярдагы лебедка аны үзенә таба тарта башлый...

Идел аша торба сузучылар өчен кырыгынчы имтихан булган бу эш 9—10 көн дәвам итте. Иделдән зур-зур теплоходлар, җитез метеорлар узып тора, йөк төягән баржалар үтә. Эш башланган көнне елгачылар Звенигово шәһәре каршында Идел төбенә юан диаметрлы газүткәргеч торба салына башлануын белмиләр иде әле. Алар арасында иң тәҗрибәле водолазлардан саналган якташыбыз старшина Фәргать Шәйдуллин да бар.

Безне яңа очрашулар көтә иде.

## Уңъяк ярда

Идел аша торбалар суза башлауның җиденче көне. Текә ярны уеп ясалган тигез мәйданда мәһабәт лебедка тора. Аннан тартылган трос Идел төбенә юнәлгән. Фәргать яр башындагы такта шалашта рация аша сөйләшә. Водолазлар телендә. Торбалар бәйләменең җиденчесен төп линиягә ябыштырганнар икән.

Сигнал! Лебедка хәрәкәткә килде. Трос тартыла башлады. Аны берләшмәнең үзәк лабораториясе начальнигы урынбасары Михаил Алексеевич Клименко бик игътибар белән күзәтеп тора. Бу лебедканы алар баш конструктор Н. Уваров белән бергә иҗат иткәннәр. Әлеге эштә лебедка беренче сынавын үтә.

— Бу — уникаль лебедка,— дип аңлатты Михаил Алексеевич.— Бөтен ил күләмендә нибары уникe генә данә ясалды.

Трос хәрәкәтләнүеннән тукталды. Теге якта чираттагы понтонны беркетәләр икән. Тәнәфестән файдаланып, без водолазлар белән танышабыз. Фәргать биографиясеннән кыска гына юллар: 28 яшьтә. Армиягә хәтле ун класс бетергән. ДОСААФта водолазлыкка өйрәнгән. Менә сигез ел инде шушы идарәдә эшли. Су төбендә барлыгы 3 мең 500 сәгать булган. Тәүлеккә әйләндерсәң, 146 га җыела. Фәргать үз һөнәре турында болай ди:

— Беренче тапкыр су төбенә Казанка елгасында төштем. Тирәнлек дүрт метр иде. Куркыныч. Тын кысылган кебек. Нибары 20 минут булдым, әллә никадәр вакыт үткән кебек. Әмма иң мөһиме — курку хисен җиңәргә кирәк, шунсыз водолаз була алмыйсың...

Траншея казыганда да, дюкерларны төшерә башлагач та водолазлар су астында була, эшне тикшереп торалар. Алар куллар белән капшап кына тикшерәләр, чөнки 20 метр тирәнлектә дөм караңгы.

Биредә мондый романтик һөнәр ияләре алтау иде: Александр Симбиров, Касыйм Сәгъдиев, Әнәс Хәйруллин, Анатолий Простак, Александр Воропаев һәм старшина Фәргать үзе.

Сулъяк ярда безне водолаз Касыйм Сәгъдиев каршылады. Әнә ул суга шуыша торган торба өстенә баскан да әкрен генә атлап килә. Чөнки ул интервью бирә, ә без бер урында басып торабыз.

— Алты ай водолазлар мәктәбендә укыдым. Балтик диңгезендә десантчылар сафында хезмәт иттем. Минем бүтән һөнәрләрем дә бар. Тәзүче дә мин, киномеханиклыкка да укыган идем. Бусы — ошый. Менә унбер ел инде — водолаз. Утызынчы дюкерны сузуым. Күңелемә ятмаган булса, китәр идем. Беркем дә тотып тормый. Трассада семьям белән җиде ел буе күчеп йөрдем. Улым да шунда үсте, чыныкты. Гомумән, водолазлыктан китүчеләр сирәк. Беренче тапкыр су төбенә төшкәндә, миңа унтугыз яшь иде. Биш кенә минут торасы иде. Ә мин шул кадәр мавыкканмын, тарталар, чыкмыйм икән. Унбиш минут үткән. Чыктым. Инструктор әрли. Шелтә эләкте үземә. Гафу итегез...

Аны каядыр чакырып алдылар.

Диспетчер тагын ак флаг болгады. Һәм дюкер, комлыкта тирән эз калдырып, Идел эченә керү юлын дәвам иттерде. Монтажчылар чираттагы бәйләмне әзерлиләр. Сигезенчесен...

1982 елның 19 октябрена каршы төндә водолазлар уникаль операция башкарганнар. Алар төнлә, су төбенә төшеп, дюкер башындагы блокка тагын бер трос ялгаганнар. Эш темпын киметмәс өчен алар моны көндез эшләмәгән. Икенче трос лебедканың тарту көчен икеләтә арттырган. Дюкер ике мәртәбә тизрәк шуыша башлаган. Ул көнгә сузылырга тиешле эш сигез көндә тәмамланган. Бу җиңү СССРның 60 еллык юбилеена багышланган. Су асты хезмәте кешеләре кырыгынчы имтиханны уңышлы үттеләр.

Алда дюкерны гидравлик сынаулар көтә иде. Ул 103 атмосфера басымы астында үткәреләчәк. Монда, барыннан да элек, сварщиклар эше сынала.

## «Утлы көлтә» бәйләүчеләр

Биредә бер генә эш тә икенче дәрәҗәдәге дип каралмый. Һәркем үз урынында мөһим вазифа башкара. Исемлекне болай дәвам итәргә булыр иде: торба ташучы шофер, траншея казучы, изоляцияләүче, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы, торба салучы машинист, монтажчылар, су асты хезмәте кешеләре...

Күргәнегезчә, сварщиклар — иң үзәктә. Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргече төзелешендә юан дюкерларны елга аша сузу башланган иде инде. Кыска гына тәнәфескә туктаган арада, экскурсиягә килгән Балык Бистәсе районының яшь укытучылары трассачыларга тантаналы шартларда ипи-тоз тоттырдылар. Кабарып пешкән бодай күмәчен ике яшь егет — электросварщик Александр Богунов һәм водолаз Касыйм Сәгъдиев кабул итте. Кыска гына әйтелгән: «Армый эшләгез!», «Зур рәхмәт!» сүзләре озын речьләрдән көчлерәк тәэсир ясады. Мәскәү кинооператорлары бу матур күренешне кинотасмага алып калырга ашыктылар.

Бодай күмәчен кабул итүчеләрнең берсе сварщик Александр Богунов булуы һич тә очраклы түгел иде. Ул юан-юан торбаларны Идел аша сузуга әзерләүдә төп эшне башкара. Якыннанрак танышабыз: әтисе Николай Богунов 22 ел инде торбаларны эретеп ябыштыручы булып эшли. Соңгы дүрт елы Александр белән бергә узган.

Александр бала вакытыннан ук әтисенең эшенә соклана. Әти кеше 8 классны тәмамлаган улына остаз булды. Егет 19 яшендә инде 5 нче разрядлы сварщик иде. 200 метрлы торба бәйләмен дюкер башына китереп терәр алдыннан ул торба эченә кереп кала. Тыштан әтисе, Владимир Грызунов яки Сергей Стенин тоташтырылачак ике торбаны бергә каптырып тиз генә берничә урыннан эләктереп куялар. Бусы — ныклык өчен. Аннан төп сварка башлана. Иң соңыннан җөйне рентген нурларын үткәрә торган махсус прибор белән тикшерәләр. Аннан соң торбаларны су астында 100—103 атмосфера басымы белән кабат сыныйлар. Ә магистраль эшли башлагач, Себер газы аннан 75 атмосфера басымы белән генә куылачак...

...Кичке кояш Мари урманнары өстенә кунып бара. Трасса бушап калды. Су асты хезмәте кешеләре поселокка кайта. Александр Богунов та — алар арасында. Ул кулына көндез күчтәнәч итеп бирелгән бодай күмәчен тоткан. Йөзе дә шул күмәчтәй балкып тора. Димәк, бүген дә эшләре уңышлы барып чыккан. Каршысына очраган яшь кызлар: «Саша, әллә туйга әзерләнәсеңме?» — дип, шаяртып үтәләр. Ул, уенын-чынын бергә кушып: «Туй бара бит инде»,— дип, мәгънәле җавап кайтара.

Әйе, трассада туй. Хезмәт туе. Берничә көннән ул, 2 километрдан артык юл үтеп, Иделнең аръягында төгәлләнде.

# Тагын Шәйхетдиновлар янында

Көнбатыш Себердә эшләгәндә, ул Казанга сирәк кайта иде. Кайткан саен без аның белән очрашмый калмыйбыз. Һәр очрашуда ул Себер якларының кырыслыгы, кышкы салкыннары, язгы, көзге баткаклыгы, җәйге интектергеч чебен-черки болытлары турында түгел, андагы хезмәт кешеләренең фидакарь эшләре, батырлыгы турында кайнарланып сөйли.

Соңгы очрашу вакытында мин аннан: «Сез салган торбалар ничә километр булды икән?» — дип сораган идем. Ул, уйлап та тормыйча:

— 1500 километр чамасы,— диде.— Әле тагын күпме саласы...

Илсур Гарәфиевич хаклы. Унберенче бишьеллык ахырына һәм уникенче бишьеллыкта Көнбатыш Себердән, аерым алганда, Түбән өлкәсеннән — Уралга, Идел буена, Үзәккә һәм илебезнең көнбатыш чикләренә гигант газүткәргеч торбалар сузылачак. Помары станциясе быел файдалануга тапшырыла. Шуңа күрә дә Уренгой — Ужгород дип әйткәндә уртага бүтән бер исем дә түгел, нәкъ менә «Помары» дигән Мари авылы исеме өстәлә: Уренгой — Помары — Ужгород. Помары станциясе — трассаның нәкъ уртасында. Аны да безнең Татарстан төзүчеләре сала. Җиһазларны Италия фирмалары җибәргән. Бу төзелештә Япония машиналарын, Франция, ГФР маркасы сугылган юан корыч торбаларны еш очратасың. Себер газы, задвижканы ачканнан соң, 3—4 сәгать эчендә Парижга барып җитәчәк.

Бу вакыйганың политик һәм экономик яктан тирән әһәмияте бар. Беренчедән, Уренгой газы — ул тынычлык ялкыны, илләр арасындагы ышанычлы дуслык, хезмәттәшлек хәбәрчесе. Икенчедән, «Газ — торбалар» дип даны чыккан гасыр контрактына кушылган һәр ил өчен аның экономик файдасы зур. Шуңа күрә дә ул илләрнең күбесе АКШ президенты санкцияләрен хупламады. Газүткәргеч магистраль кору өчен кирәк булган машина, җиһаз, зур диаметрлы торбаларны үз вакытында җибәрә торды. Тормыш АКШ президенты Рейганны үз санкцияләрен үзенә үк кире алырга мәҗбүр итте. Чөнки совет кешеләре экспорт газүткәргече, берниндн каршылыкларга карамастан, үз вакытында сафка басар, дип катгый рәвештә белдерделәр.


«Татнефтепроводстрой» тресты коллективы газүткәргечләр сузуда иң актив предприятиеләрдән санала. Куәтле трансконтиненталь магистраль РСФСР, Украина, Белоруссия республикаларының 27 өлкәсе һәм автономияле республикалары аша узачак. Көнбатыш чиккә кадәр сузылачак Уренгой — Помары — Ужгород трассасының 216 километрын безнең «Татнефтепроводстрой» һәм «Татнефтестрой» тресты коллективлары башкара. Трассага кирәкле заводта ук изоляцияләнгән торбалар Франция һәм Германия Федератив Республикасыннан алына. Торбалар мәсьәләсендә әлегә тоткарлык булганы юк.

«1981—1985 елларга һәм 1990 елга кадәрге чорга СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре»ндә табигать шартлары катлаулы районнарда үткәргеч торбаларны ел буена салу технологиясен булдыру бурычы куелган иде. Аны тормышка ашыруда «Татнефтепроводстрой» трестының күп кенә коллективлары, аларның Илсур Шәйхетдинов кебек тәҗрибәле җитәкчеләре төп таяныч булып тора. Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргеченең Вяткадан алып Иделгә кадәр булган участогындагы эш — алар карамагында. Арча һәм Шәмәрдән янында трассачыларның вагоннардан корылган шәһәрчекләре бар.

— Эш темпын тагын да арттыру өчен без соңгы вакытта торба салу хезмәтен башкача оештырдык,— диде трестның производство-техник бүлеге начальнигы Анатолий Михайлович Калинин. Генподрядчы да, субподрядчы да, башка иярчен подразделениеләр дә бетерелде. Барысына да бер кеше — комплекслы агым начальнигы җавап бирә. Бу яңалыкны да һәрвакыттагыча, Шәйхетдинов һәм Сабитов җитәкләгән коллективларда сынап карадык.

Кыенлыкның берсе — күчеп йөрү иде. Уникe айның дүртесе юлда югала килде. Бер коллективның җиһазларын, техникасын башка урынга күчерү өчен генә дә йөздән артык вагон кирәк. Бу бишьеллыкта күчеп йөрүләрне бик нык киметергә

тырышабыз. Мәсәлән, Шәйхетдиновныкылар бу якларга биш-алты ел эшләргә дип урнаштылар. Чөнки Татарстан аша 6 линия газүткәргеч трасса үтәчәк, икесе — экспорт өчен...




...Кичә Казанга алып кайткан электричка бүген аны яңадан Арчага алып бара. Бер атна яуган яңгырдан соң ялындырып кына чыккан кояш «әле мин дә бар бит» дигән сыман сүрән күзге нурлары белән тимер юлы буйлап сузылган урмандагы шәрәләнгән агач ботакларын сыйпап үтә. Коелмый калган миләшләр уттай җемелди. Илсур иртүк хатыны Дания белән балалар уянмасын дип пышылдап кына сөйләшүләрен искә төшереп елмаеп куйды. Хатыны аны кайткан саен битәрли.

— Үзең турында да уйла! Өч елдан бирле ял алганың да юк. Себере ерак иде, хәзер Казан янында гына бит инде: көн саен кайтып йөрергә була. Балалар сагынып беттеләр үзеңне.

— Түз инде, әнкәсе, түз. Менә бетерик тә...

Илсур хатынын юатыр өчен генә әйтә. Эшнең бетәсе юк аның. Хәер, бетә күрмәсен! Газүткәргеч трассалардагы бөтен җаныңны биләп торган эштән башка ничек яшәр идең!?

Тау башында Арча күренде. Әнә болынлык уртасында олы «П» хәрефенә охшатып вагоннар тезелгән. Анда трассачылар яши. Шәһәрчектә медпункт та, кибет тә, берьюлы ике йөз кешене тукландырырлык «Березинка» исемле ашханә дә бар. Ерак түгел Зур Бирәзә авылы урнашкан, ашханә исемен шуннан алганнар.

Һәвәскәр рәссам шәһәрчекне бизәргә һич иренмәгән. Үзәк бер урында Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргеченең карта-схемасы эленеп тора. Аңа эш барышы турындагы күрсәткечләр дә теркәлгән: Бөек Октябрьның 65 еллыгына трассаның илле километрында 1420 миллиметрлы юан торбалар җир куенына төшерелгән. Социалистик Хезмәт Герое Илсур Шәйхетдинов җитәкчелегендәге коллектив СССР төзелүгә алтмыш ел тулу хөрмәтенә алган социалистик йөкләмәләрен вакытыннан алда төгәлләгән. 1983 елда да эш темпын төшерергә уйламаган бурычлар шул хакта сөйли.

Коллективта Арчадан килеп эшләүчеләр дә бар. Әмма алар да торба салучылар шәһәрчегендә яшәүне хуп күрәләр. Монда вакыт бик кадерле. Агым коллективы үзенә төшкән бурычны алдан үтәргә өйрәнгән. Себер җирләрендә эшләгәндә бервакытта да әйткән сүзләрен үтәми калмадылар, бу яңа трассада сынатырга бигрәк тә ярамый.

«Уренгой — Помары — Ужгород» сүзләре хәзер телдән төшми. Еллар үтәр, магистраль торбалар җир куенында булыр. Алар кеше күзенә күренмиләр. Әмма торба салучы каһарманнар, тарихка кереп калачак Уренгой — Помары — Ужгород экспорт газүткәргече турында сүз чыкканда, җир куенына безнең йөрәк җылыбыз да салынган, дип, урынлы горурлык хисләре кичерерләр.




## Илдар Низамов

# КҮҢЕЛ УРТАЛЫГЫННАН...

## Ипи тарихчыга да кирәк



Туган авылга кайткан көнне үк күңелгә ике вакыйга кереп утырды. Беренчесе: дәүләткә ашлык сатуда районда алга чыкканы өчен безнең колхозга Кызыл Байрак тапшырылрга килгәннәр. «Адашканнардыр, янәшә колхозга, Фәйзи абыйга диган байрактыр»,— дип шаярткан булдым. Күрше Хаҗи абый сүземне кабул итмәде. «Көлмә! Безгә дә вакыт»,— диде.

Икенчесе: төнлә дә уралар икән. Сеңелемнең улы Булат туган-тумача арасында кичен дә күренмәгәч, сорадым. «Басуда, кичә дә төнге бердә генә кайтты»,— диделәр. «Нәрсә, хәзер кызлар белән тау астында түгел, басуда очрашалармыни?» — дим. Шаярту бу юлы да барып чыкмады. «Төнлә дә уралар быел»,— дип җитди җавап бирделәр.

Төнлә дә уралар диген! Безнең колхозда мондый хәлне хәтерләмим. Бәлки бу юлы да кабынып алу гынадыр?

Түгел! Менә өченче төн инде язудан туктап-туктап калам. Уралар! Ерактан йомшак кына мотор гүләүләре килеп җитә, күк гөмбәзендә сыек кына балкышлар бөркелеп куя.

Бөтен илдә диярлек ду кубып, тирләп-пешеп ашлык җыя торган көннәр иде. Басуларны төнлә дә колонна-колонна комбайннарның юл-юл нурлары телгәли, газеталарда да ике сүзнең берсе — «көнне төнгә ялгап».

Бу манзараларны кайда гына күрсәң дә, дулкынланасың, әмма үз ягыңда тагын да көчлерәк тәэсир итә икән. Сизәм, төнге уру серле бер тылсым булып, күңелне тарта бара, били бара.

Ләкин, тукта әле, боларны төпле уйлау, нидер эшләү быелгы планнарымда һич тә каралмаган ласа.

Мин бу юлы нәкъ алтмыш дүрт елга чигенеп, ягъни тарихи уисигезенчегә кире кайтып, бүгенге дөньяны ничек тә онытып, шул дәһшәтле көннәрдә яшәргә тиеш идем. Тарихи әсәр язам. Ләкин...

1982 елның май аенда партия Үзәк Комитетының Пленумы булды. Анда илебез өчен 1990 елларга чаклы Азык-төлек программасы кабул ителде. Программаның үзәге — икмәк. Илдә, озакка сузмыйча, икмәк, азык-төлек муллыгына ирешергә кирәк. Сүз, димәк, киләсе көнебезнең язмышы турында бара. Икмәк — ул ирнең дә, илнең дә егәре, дан-шөһрәте. Шунлыктан, партия, Программаны үтәү — бөтен халык бурычы, дип билгеләде.

Авыл темасы минем күңелдә дә, чал тарихны әдәп белән генә этә-этә, үзенә урын ала барды: кызыксыну артты, авылдашлар, якташлар белән очрашулар,

Этнә, Арча якларына кайтып-китүләр ешайды. Ниһаять менә, чираттагы ялны, урак өстенә туры китереп, авылда үткәрергә булдым.

Бу юлы кайтканда, күңел дә сизгеррәк иде. Бөтен илне аякка бастырган Программа таләпләреннән күзәткәндә (бүгенге авылны өйрәнү, анализлау, бәяләү бары тик шушы биеклектән генә була ала), икмәк язмышын уйлап төпченгәндә, безнең колхоз, безнең авыл нindирәк хәлдә соң?

Чынын яшермичә әйткәндә, үзебездән канәгатьсезлек хисе һаман бетми икән. Колхозыбыз — урта кул хуҗалык. Ул һаман урталыкта. Дөрес, бу — өметсезлек түгел. Күрәбез, аңлыйбыз: урталык ул колхозның алга киткәннәр белән чагыштыргандагы хәле. Әгәр аны ун-унбиш ел элеккеге үз хәле белән чагыштырсаң, башны ташка бәрерлек үк түгел. Колхоз соңгы чакта шактый алга китте. Ашлык җыеми акрын булса да арта, терлек саны ишәя, терлекчелек продуктларының тулай күләме дә арта. Трактор, комбайн, автомашина дисеңме, бүтән ярдәмче техникасымы — ишәйде, төрләнде. Ашламасы да җиргә кереп тора. Хәзер колхоз авылларын күтәрелгән туры дамбалы юллар тоташтыра. Тирә-якта шифер түбәле таза фермалар, зур ындыр табаклары, ашлама складлары, машина паркы... Колхоз үзәгендә Культура йорты, идарә бинасы, әйбәт өйләрдән торган, кунак йорты булган поселок үсеп чыкты. Элек атлы юлчы гына түгел, шоферлар да котлары алынып, баш кашып торган тирән ермаклар, тимер-бетон плотиналар белән буылып, күл-бөяләр булып ялтырап ята, алардан насос-торба системалары басу, печәнлекләргә су сибә. Ярларында чыршы-нарат буй урманнары калкып килә. Яшеллек, сафлык.

Боларга карап сөенәсең. Һәм... уйланасың да. Алдынгы колхозларда мондый үзгәрешләр күптән булып, алар бу мөлкәтнең игелеген күрәләр: ашлыкны, итне, сөтне дәүләткә күп саталар, шул исәпкә яңа, яхшырак техника, мөлкәт булдыралар, экономикаларын тагын да ныгыталар. «Искра», мәсәлән, гектардан 20 центнер уңыш ала. Без исә иң кулай елны да 15 тән уздыра алган юк. Кайчан соң без кеше аркасына карап барудан туктарбыз?

Әлбәттә, омтылыш белән генә дә булмый. Безнең җирләр көлсу, сабанны аз гына батырсаң да, каерылып кызыл балчык чыга. Үзе Татарстанның иң төньяк читенә урнашкан, олы юлларга ерак. Техниканың еш ватылуы, ашламаның нәкъ кирәкле вакытка җиргә керә алмавы, ашлык, бәрәңге, ит, сөтнең тапшырганда сыйфаты төшүе, белгеч, кадрлар кытлыгы — болар олы юлга турыдан-туры килеп тоташкан мәсьәләләр.

Инде шулар белән үзебезне юатып, хәлебез белән мәңге разый булып утырыйкмы? Аклану сәбәпләрен эзләүдән битәр урталыктан чыгу юлларын эзләү — изгерәк, кирәклерәк эштер. Сүз бит бер безнең колхоз турында гына бармый. Андый хуҗалыклар республикада, илдә бик күп. Шуңа күрә бу язмалар да гомумиләштерелгән саналырга хаклы, аларда колхоз, кеше исемнәре шартлы. Урта кул хуҗалыкларны алга чыгару — бүген бөтен ил күләмендәге әһәмиятле эш.

Ә моны кем белми? Беләләр, әмма... без, кирәк тирәкне ега, дияргә яратсак та, бу кирәкнең тирәге, күрәсең, алай ансат кына егып була торганнардан түгел.

## Кирәк тирәкне ничек егар?

Ул көннәрдә әчендә җаны булган бер генә кеше дә үзенә бикләнеп утыра алмаган булыр иде. Сиксән икенче ел урагы иде бит ул! Җитмәсә, әйткәнемчә, кайта-кайтышка күңелгә тегә ике вакыйга килеп тиде.

Байрак, чыннан да, безнең колхозга бирелгән икән. Колхоз басуында моңарчы күрелмәгән уңыш үстерелгән. Һәм безнекеләр, уракка оешкан рәвештә, бердәм төшеп, уңышны тизрәк җыярга ябырылганнар. Байрак тырышлыкның беренче нәтиҗәсе өчен иде.

Ялуымнан туктаган араларда тизрәк шул басуларны, анда эшләгән кешеләрне күрергә ашыгам. Кемнең кемлеген беләсең килсә, урак өстендә аның эшенә кара икән. Гәпләшеп торулар өчен исә көн саен иртә-кич «капка төбен» калдырмаска

тырышам. «Капка төбе» ике тапкыр: иртән аз гына минутларда — көтү куганда, ә кичен бер сәгать чамасы көтү каршылаганда булып ала. Монда кешеләр бер-берсенең хәлен белешә, яңалыкларын уртаклаша.

Бу көннәрдә капка төбе хәбәрләренең иң яңалары, иң саллылары урак хәбәрләре иде: ничә комбайн эшли, күпмесе ватылган, запас частька кайсы якка чыгып чапканнар; ындыр табагыннан күпме ашлык озатылган, шефлардан ничә машина килгән, кем, нигә эшкә чыкмаган, председатель ничек-ничек дулаган... һ. б., һ. б.

Халык мактанырга, лаф орырга яратмый. Капка төбе хәбәрләре дә, асылда, эшлекле, кайгыртучан, күбесенчә, борчулы, тәнкыйтьчел була. Шулай да урак вакытындагы капка төбе хәбәрләре гел өметле, алга омтылышлы булды. Мондый кәеф, мондый өмет мул уңыштан, аның исән-имин дәүләт келәтләренә, колхозчыларның үз бураларына керә башлавыннан да иде. Көннәре дә, тулаем алганда, матур тора. Гомумән, бу җәйдә табигатькә үпкәләрлек булмады. Казан артында тагы да «табигать шартларының авыр килүенә карамастан...» дип акланучы булса, теле корыр.

Шулай да колхозыбызның беренче мондый уңышын табигать мәрхәмәте белән генә аңлатсак, һич дөрес булмас. Бу — без әле генә санап киткән мөлкәтләрнең — хөкүмәт ярдәме һәм колхозчылар тырышлыгы белән еллар буе бөртекләп тупланып, корылып килгән абзар-кураларның, ашлама, машиналарның, агротехник чараларның, шулай ук авыл кешеләрендә бөртекләп җыелып килгән белем, осталык, тәҗрибәнең әкренләп гамәлгә аша башлавы түгелмени?!

Тукта әле! Үзебез колхоз турында, ул җитештерә торган ашлык, ит, сөт турында, экономик артталыктан, урталыктан чыгу турында, ягъни матди нәрсәләр турында сөйләшәбез, ә үзебез ике сүзнең берендә к ә е ф, к ү ң е л, ө м е т, р у х и х ә л ә т, дибез. Очраклы хәл түгел бу. Икмәк һәм кеше күңеле, аның рухи халәте бер-берсеннән мәңге аерылгысыз. Без «егарга тиешле тирәкнең тамырларын» ачыклаганда, урталыктан котылу юлын эзләгәндә, кешеләрдәге т е л ә к, о м т ы л ы ш, и х т ы я р к ө ч е бигрәк тә әһәмиятле. Бөтен шартлар булып та, моңа күңел омтылышың, рухи әзерлегең, ихтыяр көчең җитмәсә? Алдынгы булу ул к а м и л л е к, г о р у р л ы к, д а н-ш ө һ р ә т, ү з-ү з е ң ә т а л ә п ч ә н л е к кебек рухи төшенчәләрдән һич аерылмый. Алга да чыгарсың, ә кире чигенмәскә, беренчелекне кулыңда тотарга рухи көчең җитәрме?

Төнге уруга игътибар итү дә шул уйлардан килеп чыкты, ахрысы. Шикләнүем юкка булган, төнге уру бер кабынып алу гына түгел иде, озак балкыды. Төнге басу игенченең рухи халәте турында уйлануны куәтләп, күңелне үзенә тарта торды, әйди башлады.

Урак очланып вакыт җиткәч, августның соңгы көне тәмамланган сәгатьләрдә без басуга чыктык. Без дигәнем — очынган күңелгә канат та табылды — күптәнге юлдашым велосипед иде.

## Нихәл, бөртек!

Сәгать төнге уннар иде инде. Дөм караңгы. Менә авылны калдырдык, урман ягына да каердык. Бераздан күз дә ияләшә төште ахрысы, бәрәңге басуының бетүен чамаладык. Велосипедны юлдан читкәрәк тайпылдырып карыйм. Көпшәк бишинәләре келтер-келтер итә — камыл, урылган басу.

Борынга таныш ис — урылган басу исе бәрелде. Басу исе ялт кына яшьлеккә кайтара. Тау астында ашлык киптергеч бар иде, сушилка. Тауны кисеп кенә ясаган зур авызлы җир мич. Өсте — бура. Арыш шунда киба. Мичкә ат белән зирек агачы ташыйм. Утынны бушатып, атны тугармыйча гына су буена үләнгә җибәрәсең дә, бурага кереп, җылы арыш өстенә менеп ятасың. Ачы таңнан торылган, әле ныгып та җитмәгән куллар белән юан-юан зирекләрне кисеп тәялгән, арык атны әйди-әйди күпме юл үтелгән. И арышның җылы кочагы...

Әз генә черем итеп алу да яшь тәнгә көч-хәл бирә, җанга рух өсти. Мич эчендә калайда кыздырылган арышны капкалап, барып чишмә суы эчсәң дә янә урманга икенче олауга төшеп китәсең..

Алда якты нокталар җемелди башлады. Алар күзгә күренеп зураялар. Дистәләгән ут көлтәләре балкый. Урман ягыннан басу иңләп комбайннар менә. Тоташ гөрелте... Сәер шәфәкъ ачыла — кара битъяулык астыннан яктырып алган караш сыман серле, сихри бер балкыш.

Киләләр! Җир дөңгердәтеп, тирә-юньне балкытып, комбайннар ашлык урып килә! Кораб дигән чагыштыру аларга төнлә дә ябыша икән. Көндез ул дулкындулкын иген басуын киң диңгезгә охшатканга — кораб. Ә төнлә ул, дөньядан аерылып, караңгыдан курыкмыйча, һаман алга баручы кодрәтле җанга охшатылганга — кораб.

Ялгыз кораб та тәэсирләндерә. Әмма күбәү булганда, алар сокландыра. Иңгәиң куеп, бер-берсенең сулышыннан көч-ышаныч алып, теләсә кайсы минутта берберсен яклаячакларын тоюдан нык басып атлаучы матросларны хәтерләтәләр.

Комбайнкарга сокланган арада, өскә прожектор утлары бөркелде, ялт кына читкә тайпылып, ашлык төягән автомашинага юл бирдем. Аннан янә аска, урман буена җилдерәбез. Ул арада сул кул якта тәбәнәк кенә койма пәйда булды — урылмаган җир. «Юл читендә кырын ятып, ял итеп ал, велосипед дус, ә мин башаклар белән сөйләшеп чыгыйм». Башаклар, әкрен генә кыштырдыйлар. Иелеп, биткә тидерәм. Берсен өзеп алам. Юан, тук, коры. Учка җылысы бәреләкебек. Башакны көндез карау белән төнлә тою арасында аерма бар икән. Бөртекләрен кабып карыйм. Тешкә тере, сәламәт катылыгы тия. Бармаклар да аларның тирелеген, көч-куәтен тоя кебек.

Бөртек, бөртек! Нинди могҗиза бит син: бөтен кешелеккә дә җан өрүче, үлгәнче аны хәрәкәттә тотучы. Галиҗәнап бөртекләрне туплаган башак дәүләт гербларына алтыннан, якуттан коела, ефәк белән уратыла!

Бер бөртек мең, миллион бөртекләрнең вәкиле була ала. Бөртек дибез, ә күз алдына бөтен бер капчык ашлык, бөтен бер келәт, элеватор ашлык килеп баса. Бөртек ул — бөтен Татарстан икмәге, бөтен ил ашлыгы. Менә нәрсә ул бер Бөртек.

...Җылы башакны велосипедка атланганда да ташлыйсы килми. Уй да Бөртектән тиз генә аерылырга теләми. Нишләп соң без аңа ешрак сәлам бирмибез, нишләп хәлен ешрак сорашмыйбыз, сөйләшеп тормыйбыз? Игътибарлырак булсак, комбайннардан сугылып бетмичә төшкән башаклар, автомашиналардан юлга коелган бөртекләр, шәһәрдә чүплеккә ташланган ипи сыныклары очрамас иде!

Бөртек белән «сөйләшкән» кешеләр хәтергә уелып-уелып кала. Менә председатель, яңгыр туктап, озак та үтмәстән, басуга ашыкты. Машинадан төште дә, йөгерә-атлый, арыш эченә кереп китте. Башакка иелде! «Кибәсеңме инде, хәлең ничек, Башак?» — диде микән. Ындыр табагында эшләгән хатын-кыз, төшке ялга туктап, авылга кузгалды. Шактый киткәч, бер хатын кинәт туктап, сызганган җиң сырларыннан бөртекләрне учына алды да, аларны көшелгә илтеп салды. Ашлыкка шәһәрдән килгән автомашина белән юлга чыктык. Җил иде, бәреп-бәреп яңгыр ява. Каршыга шундый ук машина кайта. Аның шоферы безгә туктарга ымлады, сәлам биреп: «Брезентың җилферди»,— диде. Үзе, әрҗәгә менеп, яшь шоферга булышты. Бөртекләрне учына алып сыйпады да: «Ярый, чыланмаганнар әле»,— диде.

Ул минутта бу кешеләрнең якты йөзләренә җан олылыгы, күңел кечелеге чыккан, карашлары мөлаем, мәрхәмәтле иде.

## Салам күче яисә күңел күзе

Тоюның да күзе бар инде әллә, юлдан тайпылмыйча барабыз. Юлны тоеп барабыз. Шома, йомшак. Әйдәле, очыйк, велосипедым!

Шунда капылт күз алды караңгыланып китә, әһ дигәнче, сәер йомшаклык велосипедның алгы көпчәген суырып та ала, һәм без икебез ике якка каерылып

та төшәбез. Салам күче икән. Велосипедтан моңарчы төрлечә егылып төшкән бар иде, тик болай, циркач кебек мәтәлчек ату беренче тапкыр. Шөкер, икебез дә сау-сәламәт.

Берничә ел инде терлек азыгы кытлыгы кичереп, мең бәясенә төшкән саламны күрше өлкәләрдән ташыганлыктан, әлеге байлык җанны җылыта. Бер көнне бер председатель телевизордан, быел без салам эскертләрен озын итеп өябез, ди. Яңалык сиңа! Күп булгач, озайтмый хәлең юк. Югыйсә, ут-күздән, бозылу-күгәрүдән, тычкан-бөҗәк һөҗүменнән саклыйм дисәң, урта кул үлчәмне бозмау хәерле.

Кыскасы, салам бик кирәк, кадерле. Нишләп бу күч юл өстендә соң? Аны бит машинадыр, атлы, җәяүледер таптарга мәҗбүр булачак. Гомумән, рәтләр туры, егетләрнең карашы үткен, яхшы салганнар.

Әмма берәүнең, юлны шәйләп алып, саламны ике генә метр я алдан, я узып китеп салу өчен маңгай күзе генә җитмәгән, күрәсең.

Күңел күзе! Икмәк тирәсендәгеләргә иң элек менә нәрсә кирәк! Кешеләргә бер төсле бирелми икән бу күңел күзе дигәннәре. Бөртекне җир шарын тотып торырдай Галиҗәнап Баһадир дип күрә алмаучылар да бар. Димәк ки, күңелнең күзе хәрәкәттә, алга омтылганда гына ачыла, инерциядән, күңел урталыгыннан чыгарга ыргылмаган кешедә маңгай күзе — ботак тишеге.

Күңел урталыгы? Анысы ни тагы?

Хәрәкәтсез ятып, тынчый башлаган сазлык ул. Кешедә дә була андый халәт: биргәненә шөкер, ди, алтын урталыгым, ди. Җанын бимазаламас өчен тирә-ягын күрмәскә маташа. Күңел урталыгы ул — ялкаулыкка бирелү, хыял канатларының сәлперәюе. Күңелең шундый рухи халәттә, шундый урталыкта булса, колхозыңның экономик урталыкта булуы белән дә ризалашасың.

Без егарга тиешле «тирәк»нең төп тамырларының берсе менә шушы түгел микән әле. Азык-төлек программасы таләп итә торган борылышны күңел күзе күрүчән, хыял канатлары нык булганнар гына ясый ала.

Басуның читенә җиттек. Юл, кара пар җиренә кереп, урманга бара. Ә безгә басуның марилар белән кушылган ызаннан менәсе. Комбайннар, мөгаен, шул яктан төшәр. Тик кайда әле алар? Басуның авыл очында матур бер манзара ачылган ласа: тулган ай күтәрелеп килә, офыкка да, күккә дә аксыл томан бөркелгән. Ай астында саргылт йолдызлар җемел-җемел килә. Алар барысы да бер якка хәрәкәтләнә. Аңлашылды: комбайннар. Барысы бер булып, авылга таба каерганнар икән.

Иртәрәк түгелме? Авылга кайтып җиткәнче, комбайнны карап, өйгә кайтып кергәнче, юынганчы, чәйләр эчкәнче, ярты төн үтә дә китә. Алтыда гына тотынган булсалар да, эш көне унҗиде-унсигез сәгатькә җыела. Иртәгә дә — бәйрәм түгел, иртүк торасы. Сукранырлыкмыни — рәхмәт әйтергә кирәк.

Үргә менәбез. Авыррак икән. Әллә уйлар бик үк канатлы булмагангамы? Башаклар кыштырдап кала. Алар: «Яңгыр юк, чык, томан юк. Урырга да урырга иде! Санаулы була мондый сәгатьләр, үкенмәгәегез»,— диләр кебек. Күңел алар белән бәхәскә керә: «Бөтен колхоз белән ярты төн эшләү — зур казаныш, батырлык инде ул, әлек монысын да оештыра алмый идек...»

Башаклар исә барыбер: «Үкенерсез, үкенерсез,— дип кыштырдый кебек.— Ике ай миең кайнамаса, ун ай казаның кайнамас».

Күңелең урталыкта тынчымаса, уйлар өзлексез кайный. Биш комбайн авылга кайтып бара. Колхозда хәрәкәттә дип исәпләнгән комбайннарның саны уникe бит. Калганнары кайда? Ватык, төзәтергә запас частьлар юк. Көндез машиналар паркында булган идем. Комбайнчы, еларга житешеп, таралган подшипникны актарып азаплана. Паркта бернинди җайланма юк. Хәтта верстак та — юан-юан ике бүрәнә. Бу бит — колхозның иң зур бер бригадасы. Күчмә ремонт мастерскойлары бар, диярләр. Юллары начар хуҗалыкларга ул бик үк кулай түгел икән.

Күңел күзе ачык булса, комбайнчы сорауны икенче башыннан бирергә тиеш: ни өчен ватыла соң техника? Быел безнең якларда да ипатовлылар ысулын чынлап торып искә төшерделәр. Муллык үзе мәҗбүр итте. Мондый тәртип исә аерым комбайнчыларның үз-үзләренә таләпчәнлеген, җаваплылыгын бермә-бер арттыра. Ике бүрәнәне верстак итеп азапланган комбайнчы иптәшне мин яхшы беләм. Бул-

дыклы, уңган белгеч санала иде, тәҗрибәсе дә бар. Күмәк хезмәткә шундыйлар кирәк. Үзе дә яңача эшләүне башта чынлап торып хуплады: тәртелеп калсаң, өлкән иптәшләр килеп җитә, җитәкчеләр дә гел янда, элек унлап комбайнның кайсына барырга да белмиләр иде; аш-чәй дә вакытында килә, бергә-бергә ашаулары ук күңелле.

Әмма оешканлык күктән төшми, ул һәр комбайнчының асыл сыйфатларыннан җыела. Тәртип, ярдәм ошый икән, үзең дә тәртипле, ярдәмчел булырга тиешсең. Ләкин әлеге иптәш башкаларга караганда ешрак сафтан чыга икән. Менә кайчан китереп суга китап укымау, белем арттырмау. Осталык чамалы икән, күмәк темпка чыдап булмый. Аерым эшләгәндә, болар сизелми, күмәк эштә исә моны яшереп булмый. Иптәшләре аңа теләсә кайчан ярдәмгә атлыгып тора, ә ул ялны кадерлерәк күрә. Менә кайчан беленә кешенең күңел күзе бик үк үткер булмавы.

Сизгер карашны хәзер тоеп аласың. Беркөнне Нургали абыйны очраттым. Олыгая инде ветеран. Гомер буе комбайнда эшләде, күп яшьләрне җитәкләп диярлек басу түренә алып чыкты. Күрәм: гәүдә бераз бөкрәйгән моның. Гомер йөгеннән генә түгел — кулбашына, әбәт сумкасына салып, детальләр аскан. «Запасны үзең белән йөртмичә булмый, ватылганын төнгә алып кайтасың да, иртәнгә, менә, рәтләп алып чыгасың, янында булгач, ышанычлы»,— ди...

Барлык комбайннарның басуда була алмавының икенче сәбәбе — алмаш сменага кеше җитмәү. Кадрларны авылда калдыру — көн үзәгендәге катлаулы проблема. Катлаулылык һәм экономик, һәм социаль, һәм рухи-әхлакый якларга бәйле. Мәсьәләнең ике ягы хакында хәзер күп сөйләнелә, ә менә әхлакый ягына килгәндә... Уйланыр өчен, бер-ике мисал китерим.

Бригадир колхозчыларны кайгыртмый, дип берәү бер сүз әйтә алмас. Әнә ул бер шоферга мәктәп балаларын күрше авылга утыртып барырга кушты. Укытучы апа шул арада аңа: «Энем, өлешкә тигән печәнне иртәгә кайтарып булмасмы икән?» — дип мөрәҗәгать итте. «Башта колхозчыларныкын ташыйбыз...» — диде бригадир. Ул укучылар алдында колхозчының дәрәҗәсен күтәрдем, дип уйлагандыр, бәлки. Ләкин шушы балаларда җиргә, туган колхозга мәхәббәт тәрбияләргә тиешле иң җаваплы кешеләрнең — укытучыларның дәрәҗәсен төшерүнең киләчәктә нәрсәгә китерәсен күңел күзе күреп җиткермәде.

Авылга кайтыр алдыннан Казанда бер колхоздашны очраттым. Элекке комбайнчы. Яхшы исәптә иде. Авылны ярата. Урак хәлләрен сөйләштек.

— Абый комбайнда. Төнлә дә ура, алмаш җитми, ди.

— Үзең кайтыр идең.

— Чакырмыйлар ич. Ялны да шул вакытка көйләп булыр иде, кул да кычыта. Болай гына кайтып-китеп йөрергә автобусы да юк...

Күңел күзе булганда, мондый егетләрне, әйтик, Сабан туенда чәйгә дәшеп алып, урак турында гаплəшү, теләге булганнары белән үзенә күрә килешү дә төзеп кую, хат-хәбәр алышу авыл җитәкчеләренә бер дә кыен эш түгел. Араларыннан китмәскә кайтучылары да килеп чыгар иде әле...

## Кызыл китапка—Кешене.
## Яшел китапка—Җирне.

Бу мәлдә басудагы тынлык шундый тыгызланган, шундый авырайган иде ки, ирексездән туктап ук калдым. Сәер, шомлы гына түгел, хәтәр үк тынлык түгелме соң бу? Тургай, бытбылдыклары да сайрамасын ди, торна, төлкеләрен дә комбайннар өркетсен ди, ләкин тычканыдыр, бөҗәге, күбәләге бетәмени җирнең? Сагаеп калдым: аммиак исе!

«Җир ашкарткәндә керткәннәрме, әллә түгелгәнме?..» Юк, башыма килгән бе-

ренче уй бу түгел иде, мин агулы истән качу ягын чамаладым. Җәһәт бул, велосипед! Иңкүлектән ерагайгач, сулыш тигезләнеп, йөрәк үз эзенә төшкәч кенә әлеге уйлар килде. Адәм баласы үз гомере өчен курка, үлемнән кача. Дөрес эшли. Ул үзен-үзе сакларга тиеш. Югыйсә, аны кем саклар-сын.

Аммиак таралган төштә бүтән җан ияләре калды бит. Аларда да үлемнән котылу инстинкты бар барын, тик барысы да читкә кача белми. Минераль ашламалар, агулы химикатлар игенчегә бик кирәк, аларсыз югары уңыш үстерү мөмкин түгел. Ләкин алар, кешегә дарулар ничек бирелсә, җиргә шулай ук фәнни нигездә, индивидуаль кертелергә тиеш. Туфракны сәламәт, уңдырышлы тотыйм дисәң, андагы бөҗәкләрнең һәркайсын истә тотарга тиешсең. Җиргә, тереклекне яраткан, үз эшен яхшы белгән, олы җанлы, кешелекле белгечләр кирәк. Агулы ашламадан көйгән чирәмлекләр, тирә-якны корытып яткан химикат калдыклары — агрономнарның ак төшкән, сукырайган күңел күзләредер ул.

Белгечләр генәмени?! Җәйнең бер көнендә Шура елгасын иңләп, агуланган балык акканын күреп, хәйран калдык. Чабак, кызылканат, кушбаш, алабуга... Кайсылары инде чалкан ук яткан, күбесе, хәлсез дерелди-дерелди, авыз белән һава йота, соңгы сулышларын алалар, үлемнән качып, үзләре ярга ташланалар, комга, ләмгә тәртеләләр. Болар — күзгә күренгәне, ә аста, су эчендә нинди мәхшәрдер.

Соңыннан белдек: көчле яңгыр мари республикасы «Передовик» колхозының аммиаклы тирес буасын агызган.

Чын сукырларны җәзалап та була, ә менә күңел күзе сукырайганнарны нишләтергә? Ул көнне җанны иң каты кыйганы да шул булды: без бу коточкыч хәлдән котылу чаралары эзләп йөргәндә, көтүче егетләр, ятмә белән суга ташланып, балык сөзәргә тотындылар.

Советча яшәү әхлагы буенча, көтүче ул — табигать баласы, ул — басу-болынны, инеш-суларны, агач-үләнне кәтелмәгән афәтләрдән саклаучы, һәр тереклек иясенең докторы, кайгыртучысы. Табигатьне газаплаучы миһербансызларга иң беренче булып көтүчеләр каршы чыгарга тиеш.

Мондый «сукырлыклар» эзсез калмый. Бүген без җир-суга карата саксызлык таягы белән кизәнәбез икән, ул таякның икенче башы үзебезгә килеп төшүен онытмыйк! Кызыл китапны Кеше булдырды. Үлемгә хөкем ителгән җан ияләрен саклап калу өчен. Соклангыч, мөкатдәс эш! Кешенең үзен исә ул китапка бер генә җан иясе дә язып куймас. Кеше үзен үзе сакларга тиеш. Ә моңа бер генә юл: табигатьне, бөтен башка тереклекне саклап калу...

Һоп-лә! Тагын барып төштем. Бу юлы велосипедым да, каты ук бәрелеп, зыңлап-ухылдап куйды. Тез капкачының авыртуына түзә алмыйча, тынсыз утырдым. Каян килгән монда чокыр?

Ай инде шактый күтәрелгән, чокырның басу эченә таба уелып кергәне ачык чамалана иде. Биттәге яра җөе диярсең. Аксый-аксый «җөй» буйлап атлыйм. Ермак әлегә тирән түгел, әмма читләре ишелергә генә тора. Шушы кечкенә генә яра да басуны шактый зарарлап өлгергән: ике яклап та әллә ничә адым җирдә бодай бөтенләй кәрлә, ә беткән төшендә — зур бер пеләш мәйдан.

Ермак, ярый, озын булмады, тиз борылдым. Хәлең ничек, велосипед, атларлык җаең бармы? Бар икән. «Юлда уяу булырга, карап йөрергә кирәк шул!» Юлда ватылып кайткан шофер, тракторчыларга колхоз җитәкчеләре гел шулай диләр. Нишләптер, юлны, басуны тигезләргә кирәк, димиләр. Шуның аркасында күпме техника эштән чыга.

Хәер, Ханнан абый белән Сәлим бу чокырга алай ырҗаеп китәргә ирек бирмәсләр. Алар — аталы-уллы агрономнар — җирне яраталар, элекке ермакларны тигезләү, яңаларын булдырмау өчен тырышалар. Күпме еллардан бирле Шура суы буенда колхозның байтак җире төп-түмгәкләрдән арчылмыйча әрәм булып ята иде. Быел, ниһаять, хәрәкәт башланды. Чирәм күтәргән җирдә мин дә булдым. Куәтле ике трактор түмгәкләрне, ком чокырларын актарып-актарып, җир тигезләп киләләр. Абыйлы-энеле Хабил белән Рәхмәтулла икән. Шундый җаваплы эшне

кемгә тапшырырга белә Ханнан абый. Икесе дә — колхозның төпле, ышанычлы осталары.

Мондый кешеләр җирнең кадерен белә! Икмәккә мәдхия укыйбыз икән, ул мәдхия — җиргә дә! Бөтен байлык — җирдән. Биләмәләре булган һәр хуҗалыкта Яшел китап булдырырга, ермак, чокырлардан интеккән һәр басу, болынны, юлларны исәпкә алырга, аларны савыктырырга кирәк! Булдырыйк шундый китапны!

Күптән күзәтәм: иң каралмаган җирләр чик буенда була. Район, республика чигендә. Басу эченә керә барган шыксыз чокырлар, гадәттә, чикләрдән башлана. Ышанмасагыз, Казан артының Мари АССР белән чиктәш «Алга», Азин исемендәге һәм башка хуҗалык басуларына килегез. Моннан егерме ел элек тип-тигез булган болыннарда — коточкыч ермаклар. Яңа башланганнары да җитәрлек.

Җир гамьсезләрне, күңел күзе сукырларны гафу итми. Дөрес, ул кычкырмый, кизәнми, бары... икмәк бирүдән генә туктый.

## Колхозның хуҗалары

Комбайннар калдырып киткән соңгы чүмәләләргә җиттек. Велосипедымны иң читтәгесенә сөйим дә эченә чумам. Дөньяда моннан да йомшак, моннан да тәмле бишек юктыр! Мөгаен, шушында гына йокларгадыр, өйдән чыкканда да: «Төнне, бәлки, басуда үткәрермен»,— дигән идем.

Буыннарны язып җибәрдем. Карасана, баягы башак һаман учта икән! И Бөртек, Бөртек! Басуны әйләнеп чыкканчы, синең хакта күпме уй уйлап алганмын, күңел күзе, күңел урталыгы дөньясына бөтен бер сәяхәт кылганмын. Безгә хәзер игенченең рухи халәте турында да өшрәк, җитдирәк уйларга вакыт. Безгә, рухи урталыктан котылып, рухи камиллеккә ирешү өчен күп тырышасы бар бит әле. Моны тану гына җитми. Чарасын да күрергә кирәк. Кем җаваплы авылда әхлакый тәрбия өчен? Гаиләдә кем җаваплы булса, колхозда да шул, колхоз бит ул — бер гаилә. Димәк, председатель? Әлбәттә. Гаилә башы бит — ул, хуҗа — ул. Ә нигә соң алайса без хуҗалык җитәкчеләреннән икмәк, ит, сөт кебек нәрсәләрне күпләп сорыйбыз да авыл кешеләренең рухи халәте белән сирәгрәк кызыксынабыз?

Уйлый китсәң, бер закончалык ачыла: урта кул колхозларда председательләр еш алмашынган була. Бу, бәлки, колхозның урталыкта таптану сәбәпләренең дә берседер.

Без, гадәттә, соңгы председатель турында язарга яратабыз. Сүзне «...ул фәләненче председатель булып килде», дип башларга күнеккәнбез. Бәлки үнөченче председательне мактарга ашыкмыйча, теге уникенең нинди рәк кешеләр булуын, ник китүләрен төпченергәдер, моның файдасы күбрәк булмас иде микән?!

Безнең хәзерге председатель унөченче үк түгел. Без аның нинди дер сан гына булуын теләмибез, гел шул урынында булыр, дип өметләнәбез. Бөртек белән ихластан сөйләшә белгән кешенең күңел күзе дә дөньяга, кешеләргә һәрвакыт ачыктыр. Ул сайланган елны мин, авылга кайтып, бер ай язып утырдым. Ай буе көн саен биштә торып, алтынчы яртыда эшкә тотына идем. Шул вакыт тәрәзә каршыннан председатель машинасы үтеп китә. Ул үз авылыннан колхоз үзәгенә килә, аннары — безгә. Аның ничәдә торуын чамалап буладыр. Ай буе шулай кабатланды. Кешегә өмет баглар өчен дә, аңардан өмет өзәр өчен дә күп кирәк түгел.

Дөрес, председатель эшне буш җирдә башламаган, колхозның бүгенге уңышлары, әйткәнебезчә, моңа кадәр ирешелгәннәргә таяна. Әлбәттә, аның үз холкы, үз фигыле булсын, үз юлын тотсын, шулай ук үзенә кадәргеләрне дә исенә төшергәләсен: яхшылыгын да, халык гайрәтен чигергән якларын да.

Халык элекке председательнең радиодан күп сөйләвен, гадәти генә эшне дә зурдан кубып, радио аша кушуын өнәмәде. Ата кеше, тәрбияче кеше сүзен йөзгә туры карап, тәэсиренең нинди буласын күреп әйтергә тиеш иде кебек. Рәхмәтне дә, кулны кысып, сүзен ихластан әйтеп җиткерү хәерле түгелмени? Шундый сүз генә җанга барып җитәчәк.

Ә аннан да алдагы председатель турында: «Аның бер аягы гына җирдә»,— диләр иде. Кешеләр белән сөйләшкәндә, машинасыннан төшеп бетми, бер аягы, хәзер кереп китәм, дип машина басмасында тора икән.

Кешеләр җиргә нык басып торганнарны ныграк хөрмәт итә.

Председательнең бөртек сыйпап торган кулларын, игътибарлы карашын бер көнне аеруча еш искә төшердем. Уңыш өләшкән көн иде ул. Яшьләр, капчык тулы машиналар белән килеп туктап, җор сүзләрне юмарт әйтә-әйтә, килен-кызларның шаян җавапларыннан көлә-көлә, өлешегезгә тигән көмешегез, дип, ишегалларына арыш ташыдылар. Чирәм өсләре, төзтүбәләр сап-сары палас җәелгәндәй булды — арышны кибәргә тараттылар. Җир баласы, нинди генә муллыкка чумып, тамагы ничек кенә туймасын, икмәкне олылаудан, аны хәстәрләүдән беркайчан да туймас, мөгаен. Кешеләрнең күңеле күзгә күренеп күтәрелеп китте, горурлыклары артты.

Тагын берничә көннән ишегалларына машина-машина коры салам кайтты. Малына ашарга булса, крестьянның йөзе тулган айдан ким яктырмый. Күңелләр тагын да күтәрелде, эшкә тагын да дәртләнебрәк йөри башладылар.

Председателебез кешеләрне, беренче чиратта, менә шулай, матди муллык көче белән тәрбияли икән! Икмәк, терлек азыгы, ягулык белән авыл кешеләре вакытында, җитәрлек тәэмин ителсә, көнкүреш, транспорт ихтыяҗлары җайланса, тәртип бозулар, урлашу, ялагайлык, ришвәтчелек кебек яман сыйфатлар күпкә кимер иде. Председательнең тәрбия чаралары арсеналында үгет-нәсихәт тә, шәхси үрнәк тә, кирәк чагында, каты кул, власть та бар. Урынына, вакытына, кешесенә карап куллана гына бел. Һәм башка белгечләрне, урта звено җитәкчеләрен дә тәрбия һөнәренә председатель өйрәтергә тиеш. Шунда гаиләдә ихтирамлы, хөрмәтле чын ата буласың.

Колхозның экономик хәле, перспективасы өчен, аның бүгенге ихтыяҗлары өчен председатель белән бер үк дәрәҗәдә кайгыртa, борчыла, җавап бирә торган тагын бер җитәкчесе бар — ул партоешма секретаре. Ул хуҗалык хакында, кешеләр турында уйлап, аларның рухи халәтенә бәйләп кайгырта.

КПСС Үзәк Комитетының май Пленумында башлангыч партия оешмалары хакында аерып әйтелде: «Коллективлардагы әхлакый-психологик климат, оешканлык һәм дисциплина дәрәҗәсе, хезмәтнең нәтиҗәлелеге, димәк, ахыргы нәтиҗәләр хәлиткеч дәрәҗәдә аларның эшчәнлегенә бәйләнгән. Партия оешмаларының үз тырышлыкларын төп нәрсәгә туплавы бик мөһим. Ә ул төп нәрсә — кешеләр белән эшләү»,— диелде.

Иң башта, секретарь сайлауга өстән төшсенгә генә башкарыла торган эш дип карамаска иде. Бу — оешма коммунистларының да, райкомның да киләчәккә, кешеләр язмышына туп-туры кагылган үтә җаваплы эше. Хаталану бик кыйбатка төшә. Безнең колхозда янгын сакчысы булып өлкән генә абзый эшли. Ул үз вазифасын әйбәт үти, ул — үз урынында. Яшьрәк чагында тракторчы иде. Тырыш, булдыклы. Ул вакытта да агай үз урынында иде. Тик аны үз урыныннан аердылар — шушы ике эш арасында ул партоешма секретаре булып торды. Ул елларда заманалар нык үзгәрде, бу вазифага таләпләр артты. Хәзерге секретарь белемле, киң эрудицияле, кеше күңеленә үтеп керердәй итеп язарга да, сөйләргә дә сәләтле, ә иң мөһиме, кешеләрне чиксез яратучы гадел, принципиаль, намуслы коммунист булырга тиеш.

Заман таләпләренә туры килерлек үзгәрә алмасын сизеп, абзый башта баш тартып та караган иде, аны тыңламадылар. Нәтиҗәдә ул партия эшенә бөтенләй ят булырга тиешле өч кизүнең корбанына әйләнде: формализмның, волюнтаризмның, принципсызлыкның. Аның белән бергә, бәлки, колхозның урталыктан чыгу мөмкинлеге дә берничә елга артка чигенгәндер.

Колхоз-совхозлардагы партия оешмалары бүгенге авыл кешеләрендә күренә башлаган шәхси мәнфәгатьне җәмәгатьнекеннән өстен кую, җиңел юллар белән яшәргә маташу, эчүчелек кебек яман чирләргә каршы нык көрәшергә тиешләр. Колхозда, гомуми чараларга өстәп, үз чаралары, үз «дарулары» (бу чирләр һәр урында индивидуаль чаралар белән профилактика ясаганда, дәвалаганда гына

бетерелергә мөмкин, ә партия эше — ул нәкъ менә индивидуаль эш) табылса, бу — секретарьның дөрес эшләвенә дәлил.

Эчүчелек аеруча хәтәр бәлага әйләнде. Эчәр өчен урлыйлар, алдашалар, башка намуссызлыклар кылалар. Әдәпсез сүз, олыны олы дип, кечене кече дип белмәү, кешегә кул күтәрү — болары да шул яман шеш тармаклары. Эчүчелек эт әчәгесе кебек әрсез, бер тамырдан яңа өч-дүрт тамыр, яңа сабаклар чәчри дә чыга. Быел яңа бер тамырын күзәтергә туры килде. «Өмет итүчеләр». Газчы, тегермәнче, электрик, пилорамчы, тимерче кебек һәр йортның йомышы төшә торган һөнәр ияләре эш урыннарыннан явыз нияттә файдаланалар. Иртән килеп керер шундый бәндә, хәл белешкән булып, элек эшләгән «яхшылыгына» ым кагар, әмма тоныкы карашыннан ул синең хәлеңдә түгеллеге, үз хәленең хәл икәнлеге аңлашыла. «Өмет итеп» кергән.

Аларга, «гүр төзәтер», дип, кул селтәргә ярамый. Монда партия оешмасының индивидуаль эше аеруча кирәк. Башка чаралар рәтендә «капка төбен» дә куллану булыр иде.

Гомумән дә, парторг һәм аның булышчылары «капка төбе» кебек җирле информация-агитация каналын акыллы файдалана алырлар иде. Әйтик, менә бу айда «капка төбендә» сүз ни хакында барды, халыкны нәрсә күбрәк борчыды? Миңа ике мәсьәлә игътибарга лаек кебек тоелды.

Беренчесе. Бер ай элек безнең авылда почта бүлекчәсе ябылды. Хәер, колхоз идарәсе булган күрше авылда шундый бүлекчә ачылды. Яңа бүлекчә ачылуы бик яхшы, димәк, май Пленумы карарлары — үтәлештә. Ә менә Совет власте чыкканнан бирле эшләп килгән бүлекчәнең, авылда яшәүчеләр саны елдан-ел арта барганда, бу бүлекчә хезмәтеннән хәтта Мари АССР авыллары да файдаланганда, ябылуы бер ничек тә аңлашылмый. Халыкка сәбәбен дә төшендерүче булмаган. Ә имеш-мимеш, кешеләрне пошындырып, йөри дә йөри.

Икенчесе. Авыл халкын, безнең колхозга автобус кайчан йөри башлар? — дигән сорау борчый. Җитмәсә, гомер буе эшләгән Казан — Әтнә маршрутын да ул айларда ябып куйдылар. Кайчанга чаклы, ни сәбәптән? Беркем, бернәрсә аңлатмый. Моны, идеология эшендәге минус димичә, нәрсә дисең. Чөнки ул зур политикага турыдан-туры килеп бәйләнә. КПСС Үзәк Комитетының май Пленумында болай дип билгеләп үтелде: «Авылда торак, культура-көнкүреш, юл төзелеше белән никадәр тырышыбрак һәм тизрәк шөгыльләнсәк, крестьян хезмәтенең шулкадәр җитештерүчәнрәк булачагын исбатлап торуның кирәге юк... Ул — шәһәр белән авыл арасындагы социаль аермаларны бетерүгә юнәлдерелгән зур политика».

## Кояшны каршылау

Уянып китсәм, яктыра башлаган. Кызык, авыл урак өстендә таңны ничек каршылый икән? Мин кабат салам бишектә килеш күзәтеп ятам. Һе! Күзәтче, имеш. Авыл әллә кайчан уянган инде. Гомумән дә, авылдан элек торып була микән әле. Никадәр генә иртә күтәрелмә, аңарчы барыбер инде кемдер кузгалган була. Урам буйлап велосипедта ике килен үтеп китте. Алар югары очтан көненә өч мәртәбә сыер саварга йөриләр. Килен булып авылга бергә төштеләр, бергә фермада эшли башладылар, дуслашып киттеләр, фермада да, өйдә дә эш-тормышлары әйбәт бара.

Савымчылар фермага киткәч, озак та үтми, авылга ышанычлы, салмак бер моң-гүләү тарала. Фермаларда сөт, ит конвейеры ел әйләнәсенә шулай эшләп тора. Әйләнеп тора, әгәр маллар алдыннан азык өзелеп тормаса... Димәк, бу конвейерның да һәм, һич арттыру түгел, илдәге бүтән конвейерларның да сулышы, ямьлы басуда, урак өстендә хәл ителә.

Комбайннар күренми әле. Көнне төнгә ялгаулар җиңел түгел күрәсең. Тынлык. Күңелгә тия торган авыр тынлык. Каян болай? Хәтта әтәчләр дә, каргалар да өнсез калган. Ярый әле кисәк кенә биткә салкынча җил бәрелеп, тәнне чиркан-

дырды, камыл, саламнар кыштырдап куйды. Юкка пошынганмын. Бу — олы тантана көткәндә була торган тынсыз калу икән. Табигатьнең тантана мизгеле.

Кояш чыга!

Онҗы үре өстендә зур кызыл шарның чите күренә башлады. Ул арта, зурая бара. Исәнме, кояш!

Авыл тәмам җанланды.

Ниһаять, бу як юлда да тузан болыты күпереп чыкты. Комбайннар, ашлык ташый торган автомашиналар! Әйдә, велосипедым, без дә кузгалыйк, аларны хөрәкәттә каршы алыйк.

Атлыйбыз. Басу буйлап төнлә үткән юлны гына түгел, хис-тойгыларны, уйларны да кабат хәтердән кичерәм. Алар төн караңгылыгында туган иде, әмма берсе дә томанлы да, караңгы да түгел. Тормышчан, кирәкле, якты уйлар. Урак өстендә, һәр минут кайнар хезмәттә үткән көннәрдә, җитди генә бер уйланып алу начар нәрсә түгелдер. Төнлә уйлаганнарың көндез гамәлгә ашырылса — бигрәк тә.

Тормышка ашыру исә игенченең үз кулында. Ул теләгәненә, уйлаганнарына ирешер дип, партия нык ышаныч белдерә. Үзәк Комитетның май Пленумы фәрманы белән. Халык исеменнән. Ышаныч белдерә һәм шартлар тудыра. Әйтик, озаклатмас, ел ничек килүенә карамастан, җирне уңдырышлы итә торган ашламалар, вакытында эшкәртә, сугара торган машиналар, тәүлек әйләнәсенә туктаусыз эшли торган комбайннар булыр.

Булыр! Тик без шуңа рухи яктан әзерме? Әзер булу — ул игенченең шул үзгәрешне ихластан теләве, шуңа омтылышы, күңелен гамьсезлектән, ваемсызлыктан чыгарырга тырышуы, гел алгысынып яшәве дигән сүз. Аның рухи дөньясы бүген үк киң офыклы, нурлы, илһамлы дигән сүз. Шунсыз алга бару, партия ышанычын аклау мөмкин түгел. Бер генә машина да безгә Бөртекне үзе үстереп, үзе җыеп бирә алмас. Бу — Игенче кулыннан гына килә торган эш. Бөртекнең юлы бары тик Игенче кулы, Игенче күңеле аша гына үтә.

*1982 ел*

# ЯҢА АВЫЛ ҖЫРЧЫСЫ



Татар совет әдәбияты үсешенә шактый өлеш керткән, әсәрләре укучылар тарафыннан бүген дә яратып укыла торган язучылар арасында прозаик һәм журналист Гариф Галиев тә бар. 20 нче елларда ук матбугатка килгән бу язучының иҗаты нигездә авыл, крестьян тормышы белән бәйләнгән. Авыл тормышыннан башка Г. Галиев иҗатын күз алдына да китерү мөмкин түгел. Татар авылының үзенчәлеген, халык рухын, табигатен якыннан хис итүче, аңлаучы язучыларыбызның берсе ул.

Язучының иҗади эшчәнлеге, гадәттә, аның тормыш юлыннан аерылгысыз була. Бу Гариф Галиев өчен дә характерлы. Бер әсәрендә: «Мин гомеремне Татарстан районнарында, колхоз басуларында үткәрдем»,— дип юкка гына әйтмәгән күрәсең ул...

Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10 маенда Азнакай районы Урманай авылында туган. Ул Бәйрәкә мәдрәсәсендә укый, аннары Бөгелмә шәһәрендә семинария тәмамлап, үзе дә укытучы булып китә. Яшьтән үк әдәбият белән кызыксына, халык иҗатына игътибар бирә, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, авыл тормышындагы яңалыклар турында газеталарга хәбәрләр язып тора. «1923 елның көзеннән мин «Крестьян газетасы»на языша башладым һәм бу хәбәрчелек эшемне 1925 елның җәенә кадәр дәвам иттердем»,— ди ул үзенең истәлекләрендә. Әйе, гади авыл хәбәрчесеннән сәләтле язучы һәм журналист үсеп чыга. Башта ул Бөгелмәдә чыга торган «Сабанчы» газетасында эшли, 1930 нчы елдан инде ул — республикабызның «Колхоз газетасы» редакциясендә җаваплы секретарь, аннары — «Колхоз бригадиры» журналында җаваплы секретарь. Күрәсез, Г. Галиевнең бөтен эшчәнлеге авыл хуҗалыгыннан аерылгысыз, һәм бу аның иҗатына да уңай йогынты ясый. Авыл хуҗалыгына караган басмаларда булсын, «Социалистик Татарстан»ның махсус хәбәрчесе булып эшләгән вакытларында булсын, Г. Галиевнең колхоз авылы үзгәрүен, яңа кешеләр үсүен чагылдырган хикәяләре һәм әдәби очерклары дөньяга чыгып торды. Без инде ул чакта ук аның бу активлыгын, саф халык теле белән язылган матур парчаларын күреп соклана торган идек. Г. Галиевне Язучылар союзы 1939 елны үз сафына кабул итә. Союзга член булып керергә аңа Муса Җәлил рекомендация бирә. «Ул җанлы тормышны күрә белә, шуннан иң кирәклесен, халык тормышының сулышын якыннан тоеп тасвирлый белә»,— дип бәя биргән Муса Җәлил үзенең язма рекомендациясендә.

Бөек Ватан сугышы елларында Гариф Галиев — солдат, фронт газетасы эшчесе. Башта ул Мәскәүдә чыга торган «Кызыл сугышчы» исемле татар газетасында хезмәт итә, аннары 1 Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасына җаваплы секретарь итеп җибәрелә. Бу газетада ул И. Гази, Г. Кутуй кебек күренекле әдипләр белән бергә эшли, күпләгән очерк һәм хикәяләрендә совет кешеләренең батырлыгын, явыз дошманны җиңәчәгебезгә ышану хисләрен дулкынланып сурәтли. Г. Галиев бөек җиңү көннәрен фронтовик язучы буларак каршы алды. ВКП(б) сафына да ул сугыш елларында кабул ителде. Фронттагы батыр хезмәтләре өчен ул Кызыл

Йолдыз ордены һәм «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен», «1941—1945 елгы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнде. Совет әдәбияты өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен «Почет билгесе» орденына лаек булды.

Хөрмәтле язучы һәм журналистыбыз Гариф Галиевкә хәзер инде сиксән яшь тулды, шушы гомернең илле җиде елы әдәбият мәйданында, мәшәкатьле журналист юлларында үткән. Ләкин язучы хәзер дә безнең сафта, аның каләме кулыннан төшми, ул яңа хикәяләр белән укучыларны шатландырып тора. Үткән ел басылып чыккан «Истә, һаман да истә» дигән хикәясен генә алыйк. («Казан утлары», № 12, 1982 ел). Монда Г. Галиевкә хас табигый тасвир, күңел сафлыгы, олы җанлы авыл кешеләренең образлары, үзенчәлекле характерлар. Ак күңелле, чибәр кыз Гөлсем — чын мәгънәсендә шигъри образ. Гомумән, Г. Галиев хикәяләре гади авыл карчыклары, олы җанлы хатын-кыз образларына бик бай.

1980 елда Г. Галиевнең «Җир турында җыр» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыкты. Китапның исеме үк уйга калдыра һәм авторның нинди җырчы икәнлегенә бик мәгънәле итеп ишарә ясый. Җир турында җырлый, уйлана, изге җиребезнең кадерен, кыйммәтен онытмаска өнди автор. Менә шушы җыентыгы кебек Г. Галиевнең элекке елларда дөнья күргән китаплары да асылда бер тойгы, бер теләк белән сугарылганнар: караңгылык, фәкыйрьлек эчендә газапланып яшәгән крестьяннар, җир кешеләре Бөек Октябрь кояшының якты нурлары астында яңадан тудылар, ирекле, бәхетле тормыш төзүгә ирештеләр. Колхозлашкан яңа авылда яңа кешеләр, социализм байрагын югары күтәргән яңа буыннар җитлекте, һәм алар да олы юлдан баралар.

Г. Галиевнең басылып чыккан 42 китабына тупланган хикәя һәм очерклары язучының иҗади активлыгын бик ачык күз алдына китерәләр. Аларда 212 хикәя, 320 очерк, балалар өчен йөздән артык кыска хикәя тупланган. Әле тагын, колхоз-совхоз сәхнәләрендә уннан артык кечкенә пьесалары уйналган. «Хаттан башланды» пьесасы Мәскәүдә русча басылган һәм 1956 елда немец теленә тәрҗемә ителгән.

Г. Галиев иҗаты турында язган иптәшләр аны: яңа авыл, колхоз тормышы җырчысы, аның әсәрләре — колхозлашу тарихының бер көзгесе, дип атыйлар. Чынлап та шулай. Бу гомуми бәя аның 20—40 нчы еллардагы хикәяләренә дә, сугыштан соңгы бик күп очерк һәм хикәяләренә дә туры килә.

Шушы уңайдан бер искәрмә дә ясап үтәсе килә. Очерк һәм публицистика өлкәсендә зур тәҗрибәсе булган Г. Галиев кебек язучыларның стилендә еш кына публицистик алым, хәл-әхвәлләрне сөйләп бирү белән мавыгу сизелгәли. Ә бу исә кайчак образларның психологик тирәнлеген ачуга тискәре йогынты ясый. Г. Галиевнең кайбер хикәяләре дә моннан азат түгел. Бу бигрәк тә элегрәк язылган әсәрләрдә сизелә. Әмма тел байлыгы, халыкчан сурәт, тәгъбирләр, сәнгатьчә гадилек кебек уңай сыйфатлары әлеге йомшаклыкны еш кына «күмеп тә» китәләр.

Гомумән, Г. Галиев безнең әдәбиятта хикәя һәм очерк остасы булып танылды. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Бәширов, Ф. Хөсни кебек хикәя осталарының матур традициясенә Г. Галиев исеме дә бик табигый рәвештә килеп тоташа.

Г. Галиев мәктәп балалары, пионерлар өчен бик матур, гаять эчтәлекле, киң мәгънәле, мавыктыргыч әсәрләр иҗат итте. Аның 1982 елда дөнья күргән китабы да балаларга адресланган һәм «Без авылныкылар» дип атала. Язучы балалар дөньясын, алар яшәгән тирәлекне үткен күз белән күрә белә, бала психологиясенең, үсмерләрнең матур омтылышларын тирәнтен аңлап сурәтли.

Аның бу җыентыгына кергән «Штурвал безнең кулда», «Курайлы елга», «Борчаклар борчылалар», «Аю агачлар белән сөйләшә», «Кошлар җыелышы», «Безнең Сафуаныбыз», «Почтальон кызы», «Сине эзлим», «Чын хуҗа» хикәяләре, минемчә, балалар әдәбияты хәзинәсенә керәчәкләр.

Сиксән яшь тулган көннәрендә язучының хисләр белән януы, каләменең көче кимемәве безне сокландыра! Совет әдәбияты һәм сәнгате алдында яңа бурычлар торганда, барыбыз да яңа үсеш дәрте белән янып яшәгәндә без Гариф Галиевкә иҗади уңышлар телибез!

**ХӘСӘН ХӘЙРИ.**

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Туфан Миңнуллин

# «КҮКТӘ НИ БУЛМАС...»

Яратам бәхәсләшүне: нәрсәнедер яклап, нәрсәнедер кире кагу гадәте канымда бар. Хәер, дөньяга нидер әйтергә теләп, кулына каләм алган, язучылык һөнәрен үзенең профессиясе итеп сайлаган һәркемдә дә бардыр ул гадәт. Битараф кешедән язучы чыкмый,— бусы бик күптәнге хакыйкать.

«Казан утлары» бүгенге проза турында сөйләшү дип шомартыбрак әйтсә дә, ул сөйләшүнең төбендә бәхәс ятадыр. Бәхәс булмаса, барлык язучылар һәм укучылар бер сүзне тәкърарласалар, нигә сөйләшеп торырга?! Димәк, бәхәс? Әйдә алышабыз! Ләкин бу очракта кем белән алышырга, кем белән бәхәсләшергә? Каләмдәшләр белән без аерым-аерым да, җыелышларга җыелып та әдәбиятыбыз турында сөйләшәбез, бәхәсләшәбез түгелме соң? Нигә аны журнал битләренә чыгарырга? Әллә киң масса укучыларга кирәкме икән безнең бәхәсебез? Шулайдыр, мөгаен. Дөресен әйткәндә, минем үземнең дә бүгенге укучы белән сөйләшәсем, бәхәсләшәсем килә. Без язганнарның кайсылары ошый яки ошамый аларга? Ни өчен ошый һәм ни өчен ошамый? Безнең әдәбиятыбыз бөтенсоюз әдәбиятыннан кай ягы белән ким, яисә кайсы мәсьәләләрдә тиңләшә? Укучыны нинди геройлар, кайсы проблемалар күбрәк кызыксындыра?

Әлбәттә, әдәбият турында сөйләшү профессиональ дәрәҗәдә булырга тиеш. Шуңа күрә, бу дискуссияне профессионал язучыларның башлап җибәрүе бик табигый. Мин прозаиклар, тәнкыйтьчеләр янәшәсенә басып белдекләләнергә җыенмыйм. Алар проза әсәрләренең бөтен нечкәлекләрен белеп сөйлиләрдер, дөнья, бөтенсоюз прозасы белән миңа караганда күбрәк танышлардыр. Әмма драматургия дә — әдәбият жанры, без бер үк материал белән эш итәбез, максатларыбызның да, борчыган мәсьәләләрнең дә күбесе уртак.

Кыскасы, мин проза турында аны актив укып баручы буларак һәм драматург буларак кына сөйләшергә алынам. Субъектив фикерләрнең булуы һәм алаҗның ялгыш булуы да бик ихтимал. Кем әйтмешли, ялгышларын тапсагыз, төзәтеп укыгыз.

Баштан ук әйтеп куям: мин әдәбиятыбыз турында, аерым алганда прозабыз мәсьәләсендә оптимистик караштa торам. Бар иде безнең чын проза әсәрләребез, хәзер дә бар алар һәм киләчәктә дә булачаклар. Болай әйтүем шуның өчен: күп вакытта һәм бу сөйләшүдә дә, үзәк журналларда басылуны төп критерий итеп алып, без үзебезнең әсәрләргә кимсетебрәк карыйбыз, мескенләнәбез. Янәсе, дөньякүләм һәм бөтенсоюз аренасында дан алган әсәрләрдән безнекеләр түбәннәр, шуңа күрә, аларны санга сукмыйлар, съездларда телгә алмыйлар. Җитешмәгән якларыбызны күрик, аларны тәнкыйтьлик, әмма да ләкин шул чаклы ук мескенләнмик әле, егетләр. Мин үзебездә чыккан һәр проза әсәрен укып барам, көчемнән килгәнчә, дөнья һәм бөтенсоюз прозасын да күзәтеп барырга тырышам. Үзебезнекеләрне укып, аһ дип куанганым да, эх дип көенгәнем дә бар. Үзәк журналларда басылган әсәрләрнең дә кайберләре таң калдыра, кайберләре ташка үлчим. Бөтенсоюз әдәбияты турында сүз бара икән, ни өчен әле безнең аһ дигән әсәрләребезнең шактые үзәк журналларда үз вакытында дөнья күрми? Шушы сорауга җавап эзләгәндә:

Безнең дә бар мәчебез,
Сезнең дә бар мачыгыз;
Безнең мәче сезгә барса,
Зинһар ишек ачыгыз,

— дип җырлап җибәрәсе килә. Ишек ачылган очракларда «безнең мачыбыз» йолкынган, таушалган кыяфәттә барып керә икән, моңарга мачыларның хуҗасы гына гаепләме?

Төп сәбәп, минемчә, яхшы әсәрләребезнең вакытында һәм яхшы сыйфатлы итеп тәрҗемә ителмәвендә. Тәнкыйтьнең яхшы әсәрләрне үз вакытында күтәреп алмавында. Аларның чыннан да югары художествога ия икәнлекләренә оста һәм танылган тәрҗемәчеләрне ышандыра алмауда. Ни өчен Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы бөтенсоюз күләмендә яңгыраш тапты? Беренчедән, ул әсәр чын әсәр иде, икенчедән, аны танылган рус язучысы В. Чивилихин тәрҗемә итте. Әгәр дә мәгәр М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә»сен — В. Солоухин, А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән»ен В. Белов тәрҗемә итсә, ничек булыр иде?! Ә. Еникинең хикәя, повестьлары вакытында авторның үзе кебек үк талантлы язучыга эләксә?! Яки Н. Фәттах романы? Яки...?

Бар бит әсәрләребез. Бүтән әдәбиятларда да мондый әсәрләр һәм мондый язучылар унлап-егермеләп түгел ләбаса. Бу турыда безнең күп тапкырлар сөйләшкәнебез бар. Кабатлап та тормас идем, ләкин Р. Мостафин һәм А. Гыйләҗев мәкаләләрендә, үзәк журналларда чыкмауның сәбәпләрен ачып тормыйча, прозабызны мескенләтү чалымы сизелә. Мәсьәләгә ничек карыйсың бит ул. Журналистлар арасында шундый мәзәк йөри. Имеш, бер журналист ниндидер җыелыштан кайткан да зал яртылаш буш иде дип информация язган. Редакторга буш дигән сүз ошамаган. Ләкин фактны да үзгәртергә ярамый. Нишләргә? Редактор буш сүзен тулы дигән сүз белән генә алыштырып, зал яртылаш тулы иде дип төзәтә. Факт шул ук, әмма яңгырашы бүтән. Шуның сыман, яхшы товарың булу гына җитми, аны яхшылап сата да белергә кирәк. Әдәбият турында сүз барганда, сәүдәгәрләр термины кулланганга гафу үтенәм, ләкин без, чыннан да, товарыбызны бөтен матурлыгы белән күрсәтә белмибез. Яхшыларын өйдә калдырып, үтмәс товар белән дә дөнья базарына чыккалыйбыз. Алмасалар, ачуланып йөрибез, уптым илаһи әдәбиятыбызны гаеплибез. Кабатлап әйтәм: бар иде безнең чын проза әсәрләребез, хәзер дә бар, киләчәктә дә булачак.

Ни өчен мин моны кабатлап әйтәм? Укучыларыбызның күңелендә булдыксызлар икән безнең язучыларыбыз, юкка кәгазь әрәм итеп яталар икән дигән фикер калмасын. Монысы — бер. Икенчесе — һәрвакыт үзен-үзе кимсетеп, мескенләнеп, үз кадерен белмичә яшәүче кешенең бер заман чып-чын мокыткә әйләнүе ихтимал. Мокыттан манкортлыкка да ара ерак түгел. Шуңардан сакланыйк.

Әдәбиятыбызның сафлыгы өчен янып-көеп йөргән, артык борчылудан максималист булып киткәләгән Аяз Гыйләҗевкә минем кирәгеннән артык оптимистлыгым бәлки ошап бетмәс. Ләкин мин, яз көне ишегалдыннан чыгып ычкынган бозау шикелле, алны-артны, уңны-сулны белештермичә әдәбият урамы буйлап койрык чәнчеп чабарга җыенмыйм. Аязны аңлап, аңа кушылып: урта кул әсәрләребез дә җитәрлек дим. Сүз уңаенда әйтеп китим: үзәк журналларда да урта кул әсәрләрнең күплеге турында еш язалар. Мисаллар китерәләр. Ул мисаллар арасында безнең әсәрләребез юк — монысына да игътибар итәргә кирәктер.

Димәк, әдәбияттагы урта куллык — бөтенсоюз әдәбияты алдында торган уртак проблема икән. Монда инде кайбер урта кул татар язучыларының тетмәләрен тетү белән генә чикләнмичә, проблемага тирәнрәк карау сораладыр. «Литературная газета»да берәү урта кул әдәбияттан котылып булмый, ул һәрвакыт булды һәм булачак диебрәк язган иде бервакыт. Шулай диюче бүтәннәр, әлбәттә, тәнкыйтьләде. Мин үзем урта кул язучыларны бетереп булмый дип әйтүчеләр ягында. Әдәбият тулы бер дөнья ул. Тукай әйтмешли:

Күктә ни булмас дисең,—
Очсыз-кырыйсыз күк бит ул.

Урта кул әсәрләр күп дип никадәр бәргәләнсәк тә, алар бетмәячәктер. Ни өченме? Чөнки андый әсәрләрне дөньяга тудырган сәбәпләр күп төрле. Беренчедән,

язучылар да әллә кем түгел, нигә миңа да язмаска дип, белемле, мәгълүматлы, дөнья күргән, ләкин иҗат оеткысы салынмаган берәүнең әдәби әсәр язарга алынуы. Алтай халкында бер риваять йөри. Тәңре аргамакны яратып җир өстенә җибәргәч, аның матурлыгына сокланмаган зат калмаган. Тәңренең осталыгыннан көнләшүче дә табылган. Шуларның берсе — җир асты патшалыгының Эрлик исемле хуҗасы икән. Тәңредән калышмаска теләп, ул да аргамак яратмакчы булган. һәм эшкә тотынган. Аргамакныкы шикелле дугаланып торган муен ясаган. Ул муенга кылдан ял тезеп чыккан. Ләкин гәүдәгә ябыштырганда муенның дугаланып торган ягын аска каратып куеп ялгышкан. Нәтиҗәдә дөньяга дөя пәйда булган. Гыйбрәтле риваять бу. Аргамак ясыйм дип, дөньяга дөя ясап җибәрүчеләр — шул урта кул язучылардыр инде ул. Әлбәттә, дөя дә хайван, әмма аргамак түгел.

Урта кул әсәрләрне дөньяга тудырган сәбәпләрнең икенчесе, минемчә — бүген фәлән темага фәлән әсәр кирәк дип, ашыгу, кабалану. Чын язучылар уйлаган, фикер туплаган арада житез куллы, елгыр күзле, практик акыллы берәү редакциянең өстәленә роман яки повестьны китереп тә ыргыта. Тема бар, купшы сүз җитәрлек — тагын ни кирәк? Шулай итеп дөньяга тагын бер урта кул әсәр өстәлә.

Өченчедән, безнең мактаулы, чын әдәби әсәрләр язып әдәбиятта исем алган язучыларыбыз да вакыт-вакыт урта кул әйберләр язгалап бастыргалыйлар. Әйдәгез, яшермик — синдә дә бар андый бер көнлекләр, миндә дә бар. Нидән килә ул?

Болайдыр: язучы иң изге ниятләр белән, шәп әйбер язачагына инанып, өстәл артына утырадыр. Әсәрен язып төгәлләгәч, укып чыгадыр да, язганының бик шәп үк түгеллеген, аңа нәрсәдер җитеп бетмәгәнен тоядыр. Шул вакыт язганны өстәл тартмасына салып куярга яки ертып ук ташларга кирәктер дә, җәлке, мур кыргырысы. Әйдә инде, бу юлга ярар, икенче тапкыр болай эшләмәм дип язганын кая да булса төртә каләм иясе. Кызганычка каршы, «әсәр» басылып та чыгадыр. «Әсәр»е өчен оялып йөрүен йөридер соңыннан агаебыз, тик эш узган буладыр.

Әйе, нишлисең, чыга дөньяга урта кул әсәрләр. Бу бик ямьсез күренеш булса да, минемчә әле ул иң куркынычы түгел. Иң куркынычы: ниндидер максат, ният белән шул урта кул әсәрләрне мактаудан, аларны әдәбиятның өлгесе итебрәк күрсәтергә тырышудан башлана. Монда инде критерийлар бутала. Мондый очракларда эш безнең тәнкыйтьчеләребезнең намусына, аларның профессиональ хәзерлегенә кайтып кала. Объектив бәяне алар биреп, дөрес юлны алар билгеләргә тиеш. Язучы ничек кенә талантлы булмасын, башкаларның иҗатына ул үз зәвыгыннан чыгып карый, аңа объектив булу шактый читен. Тәнкыйтьчегә исә Бикмөхәммәт тә, Биктимер дә бер. Аның бәяләү эталоны — бары тик галиҗәнаб әдәбият. Язучының ялгышырга хакы бар, тәнкыйтьченең — юк, дип саныйм мин. Тәнкыйтьче — әдәбиятның табибы, аның ялгышуы әдәбиятка шактый кыйммәткә төшә. Авыруны күреп тә дәшми калу — монысы йомшак итеп әйткәндә, намуссызлык.

Мәсәлән, бер автор шәп кенә роман бастырып чыгарды да, икенчесен язды. Анысы да роман дип атала. Унбиш битле хикәя материалыннан автор роман ясаган. Көчәнә-көчәнә язганы сизелеп тора. Шунысына рәхмәт — ярый әле, хәле бетеп, туктарга мәҗбүр булган. Югыйсә, болай язганда, унбиш том язып та очына чыкмаска мөмкин. Бу очракта мин авторны аңлыйм, язган икән — сәбәбе булгандыр. Беренче романы макталгач, икенчесен язу җиңелрәк булыр дип санагандыр, бәлки беренче роман күләгәсендә монысы үтеп китәр әле дип уйлагандыр. Иң кызыгы шунда — үтеп китте бит, тәки.

Мин авторның фамилиясен махсус язмыйм. Чөнки аның:

— Нәрсә аңлыйсың син роман масьәләсендә, һәм, гомумән, минем нәрсә язганымда синең ни эшең бар? Син язучылар союзы члены, мин язучылар союзы члены — тыгылма минем эшемә,— дип әйтүе мөмкин. һәм ул күпмедер дәрәҗәдә хаклы да булачак. Ә менә инде әдәбият фәненең бөтен нечкәлекләрен белгән профессиональ тәнкыйтьче саллы гына итеп, дәлилләп, ах-вах килмичә генә романны сүтеп күрсәтсә, автор ул романын яңадан җыя алмас иде. Бүтәннәр өчен дә бу зур сабак булыр иде. Роман язуның бик үк җиңел түгел икәнлеген аңлар иде ялгышучылар, хәйләкәрләр дә аз-маз шикләнерләр иде.

Фәнни тәнкыйть дигәннән, «Казан утлары» журналында басылган әсәрләрне

тикшерүгә багышланган җыелыш искә төште. Анда бер яшь прозаик ялгышып (бары тик ялгышып кына) Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романына тел тидерде. Шуннан трибунага күренекле тарихчыбыз Миркасыйм Госманов менде дә яшь прозаикның ялгышларын төзәтте. Фән теле белән һәр сүзен аргументлап сабыр гына сөйләде ул анда. Нәтиҗәдә, яшь прозаик тарихчыбызга рәхмәт үк әйтте шикелле. Һәрхәлдә романның зурлыгын хис белән тойган кешеләр аның чыннан зур икәнен акыл белән аңладылар ул көнне.

Кыскасы, әгәр урта кул әйберләрнең дөньяга чыккалап торуы котылгысыз бер стихия икән, аларга бәя бирү эше стихияле булмаска тиеш. Аларны эт итеп сүгәргә тартынсак та, авторларына гуманлык күрсәтсәк тә, ичмасам, үтереп мактамыйк. Ә инде чын әдәбият әсәрләре дөньяга килгәндә, аны күтәрә белергә өйрәник, беркие рецензия белән генә чикләнмичә, туктаусыз пропагандалыйк. Пропагандалау да, әлбәттә, әсәр югарылыгында булырга тиеш. Яхшы әсәрне һәм аның авторын мактый белеп мактау — куркыныч түгел. Талантлы кеше мактаудан бозылмый. Бозыла торган булса, бүгенге заманның зур әдибе Чыңгыз Айтматов әллә кайчан юкка чыгар иде инде. Ә ул макталган саен үргә менә, һәр яңа әсәре белән безне таң калдырып тора.

Инде килеп, роман, повесть, хикәяләребезнең геройлары турында берничә сүз. Әдәби әсәрләрнең герое кем булырга тиеш дигән сорауга җавап эзләп тору кирәкмәстер. Бу очракта журнал замандашларыбызның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алырлык үрнәк, ягъни мәсәлән уңай герой мәсьәләсен күтәрәдер. Бу хакта да күп сөйләнелде һәм сөйләнелә. Шул турыда берзаман үзем дә фикеремне әйтеп караган идем. Әллә әйтә белеп әйтмәдем, әллә аңламадылар — Т. Миңнуллин тискәре геройларны якларга маташа дигәнрәк тамга суга яздылар. Бактың исә, минем сүзем болайрак иде. «Ни өчен безнең уңай геройларыбыз җансыз, тәссез, примитив килеп чыккалый?» дигән сорау куеп, чөнки безнең тискәре геройларыбыз кирәгеннән артык вак, дип әйткән идем. Тискәре герой дигәндә мин кеше кыяфәтендәге адәм актыкларын да, уңай герой алдында торган киртә-каршылыкларны да, уңай герой чишәргә тиешле проблемаларны да күз алдында тоткан идем. Әле дә шул фикеремдә калам. Чөнки күп вакыт әсәрләребездә уңай итеп күрсәтергә тырышкан героебыз чәнчә бармак белән сытарлык, мескен, йолкыш затлар белән көрәшеп маташкан була. Яки уңай героебыз сикереп үтәргә тиешле киртәнең биеклеге бик тәбәнәк була. Ярты метр биеклегендәге киртә аркылы сикертәбез дә героебызны, вәт маладис, вәт маладис, дип кул чәбәклибез. Яки героебыз чишәргә тиешле проблема итеп вак мәсьәләне алабыз. Безнең «героебыз» юлдан өч тиен акча таба да, милициягә илтеп бирергәме, юкмы бу акчаны дип баш вата, төн йокысын йокламый газаплана. Менә шуннан ваклана да инде уңай героебыз.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгына ни өчен сокланабыз без? Нигә Мусаны әсәрләребезнең герое итәргә омтылабыз? Чөнки Муса каршында Гитлер, Геббельс, Розенберглары белән Германия империясенең коточкыч куәтле машинасы торган. Муса үлем дигән җан өшеткеч нәрсә белән күзгә-күз очрашкан. Һәм аның рухы, шуларга баш имичә, шуларны җиңеп, киләчәккә юнәлгән. Бүгенге заманның үрнәк герое каршында Мусалар алдындагы киртәне куеп булмыйдыр, әлбәттә. Шартлар бүтән, дөнья үзгәргән. Әмма ләкин, намус, вөҗдан көрәше барыбер исән кала. Әгәр уңай героебыз, вөҗданы кушканча гына яшәсә, бүген дә шактый зур каршылыкларга очрар иде. Хәтта аңа үз-үзе белән дә көрәшергә туры килер иде. Бүген безнең күп кенә проза әсәрләребезгә әнә шундый үрнәк геройлар җитешми. Бар алар, ләкин тагын да күбәйтәсе иде, тагын да үстерәсе иде.

Бүгенге заманның үрнәк героен тудыру — авыр мәсьәлә, ул бик күп эзләнүләр таләп итә. Ә менә тормыш безгә үзе биргән, фамилияләрен, исемнәрен дә үзгәртмичә роман, повестьларыбызның үзәгенә куярлык геройларыбыз әллә ни чаклы бит. Шуларны күрмичә яшәвебез мине нык борчый. Ярый әле Гариф Ахунов «Ардуан батыр» повестен язып, беренче бишьеллыклар герое Мирсәет Ардуанов образын тудырды. Ә азмы андый геройларыбыз? Алар — тормыш сынавын намус, вөҗдан белән үткән фидакарьләр. Безнең әсәрләребездә нигә аларга урын аз бирелә? Без язмасак, алар турында кем язар? Күп санлы укучыларның язучыларга бу сорауны бирергә тулы хаклары бар.

Соңгы сүзем әдәби осталык турында. Ул хакта да әледән-әле сүз кузгатылып тора. Ләкин күбрәк абстракт рәвештә әйтелә, конкрет әсәргә бәя биргәндә, әдәби осталык мәсьәләсе соңгы елларда сирәк телгә алына. Әдәби әсәр иң беренче чиратта укылырга тиеш. Әгәр романның ун битен укыганнан соң йокы килә башлый икән, аның актуаль темага язылган булуыннан яки халкыбызның берәр каһарманына багышлануыннан ни мәгънә? Хәтта акыллы-акыллы фикерләре булса да, алар барыбер укылмыйча кала түгелме соң?

Кайвакытларда әдәбиятның кайсы жанрында эшләү авыррак диган темага сүз башлана. Классиклардан цитаталар китерә-китерә, кемдер поэзияне әдәбиятның алиһәсе итеп исбатлый, кемдер драматургияне иң катлаулы жанр формасында авансценага чыгарып бастыра, кем өчендер прозадан да катлаулырак жанр юк. Мин жанрларның берсен чөеп, икенчесен тәю ягында түгел. Чөнки алар барысы да авыр, катлаулы.

Әмма да ләкин проза үзенең «мәкерлелеге» белән бүтәннәрдән бераз аерыла шикелле. Карап торырга гади генә кебек — утырасың да белгәннәреңне-күргәннәреңне язасың да язасың. Шигырьдә ритм, рифма дигән нәрсәләр куркыта, драматургиядә — сәхнә законнары, ә монда карап торырга берниндн закон юк. Менә шулай дип уйлап, шактый гына сәләтсез кешеләр проза теле белән теләсә нәрсә язарга алына. Яза-яза бераз шомара да. Ләкин әдәбиятның (бу очракта прозаның) сәләтле кешеләр генә аңлый, тоя алган закончалыкларын белми, сизми ул. Сызгалый да сызгалый, ә без укымыйбыз, укый алмыйбыз, укып булмый. Әгәр дә без: карале, абзый (агайэне, энекәш), укып булмый бит сезнең романны дисәң, ул: «Минем романым эшчеләр, (я колхозчылар, я революционерлар) турында язылган» — дип авызны томалый.

Өстәвенә тагын бер нәрсә бар: роман, повестьларның укылмавы тиз генә беленми, сизелми, ә драматургиядә инде качып котыла алмыйсың. Шәп спектакль карарга дип килгән тамашачы, алданганын аңлап, кайта да китә һәм пьеса, ике-өч уйналгач, төшеп кала. Анда инде: «Мин бөек төзелеш турында яздым бит, китмәгез»,— дип ялынып та, янап та булмый. Соңыннан гына тамашачыны наданлыкта, артта калганлыкта гаепләп сөйләргә мөмкин. Иң уңай сылтау. Яза белмим шул дип берсе дә әйтми. Билгеле, язган кеше үзе әйтмәс инде ул, аның өчен бер кулына гөрзи, икенче кулына май канаты тоткан гадел тәнкыйтьче торырга тиеш. Ул инде тема дип аталган саламга тотынучыларның хәйләсен тиз фаш итәргә, әдәби осталыкның нинди компонентлардан торганын шәп белергә тиеш...

Әдәби осталык турында язам дип, тагын урта кул әсәрләр мәсьәләсенә килеп төртелгәнмен икән! Әйттем бит: алардан котылып булмый... Димәк, бүгенге әдәбиятыбызның иң төп проблемасы да — урта кул әсәрләр икән. Шулар басып китмәсен иде!

## Солтан Шәмси

# ВАКЫЙГА АРТЫНДА НИ ЯТА?..

Кызык кына башланып китте әле бу сөйләшү һәм шулай сүрелмичә дәвам итә дә. Әлбәттә, бәхәс бәхәс инде ул... Анда максимализм һәм арттырып җибәрүләр дә, субъективлыктан куркып, читтәрәк йөрүләр, хәтәр урыннарны әйләнеберәк узулар да, салкын акыл белән үлчәп карап, бүгенге прозабызның хәлен аңларга тырышулар да — барысы да бар. Булсын, бары тик битарафлык кына булмасын!

Минем үземә, мәсәлән, кискенрәк булса да, А. Гыйләҗев белән Т. Миңнуллинның кайнарлыгы ошый. Алар үзәккә үткән нәрсәләр турында борчылып язалар. Р. Мостафин белән Ф. Зөлкарнәев мәсьәләнең асылын ачыкларга тырышалар, көн тәртибенә байтак сораулар куеп, шуларга җавап эзлиләр, кайберләрен ачык килеш калдырып, башкаларны да бәхәскә, сөйләшүгә тарталар.

Афоризмнар остасы Козьма Прутков әйтмешли, колачка сыймас әйберне барыбер колачлап булмаячак. Шуңа күрә бер мәкаләгә барысын да сыйдырып булмаслыгын аңлап һәм Т. Галиуллинның «сөйләшү конкрет һәм предметлы булсын иде» дигән теләген дә искә алган хәлдә, мин үземне дулкынландырган, уйланырга мәҗбүр иткән бер-ике әсәргә генә тукталып үтәргә уйлыйм.

Әсәрләрнең берсе — Гомәр ага Бәшировның 1981 елда «Казан утлары»нда басылып чыккан «Сарут» хикәясе. Икенчесе — Аяз Гыйләҗевның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән повестьлар җыентыгына кергән «Өч аршын җир» повесте.

Нәрсәсе белән кадерле соң безгә бу ике әсәр? Ни өчен укып чыккач та аларны оныта алмыйсың, геройлары күз алдыннан китми.

Беренче чиратта, ике әсәрнең дә бер үк чорга — сыйнфый бәрелешләр, иске дөньяның җимерелү һәм зур кыенлыклар, югалтулар, тетрәндергеч вакыйгалар аша яңасының туу чорына — каравы игътибарны җәлеп итә. Икенчедән, геройларның аваздаш булуы, охшаш характерлы ике кешенең («Сарут»тагы Мифтах белән «Өч аршын җир»дәге Мирвәлинең) фаҗигасе, гыйбрәтле язмышы уйландыра.

Аларның икесен дә гаярь егетләр дип атар идем мин. Икесенә дә көчле рух, физик тазалык, ныклык, үз-үзенә артык ышану, үҗәтлеккә әверелгән үзсүзлелек, кеше сүзен санга сукмау, һәр нәрсәне, акыл үлчәвенә салып тормастан, кызу кан белән хәл итеп кую хас. Бу ике кеше бер-берсеннән санап үтелгән сыйфатларның берсендә күбрәк яки азрак булуы белән генә аерыла. Революцион көрәш барган чорда шушы характерның заманга, кешеләргә булган мөнәсәбәте, яшәү рәвеше һәм гыйбрәтле язмышы безне беренче чиратта кызыксындыра.

Әүвәл Г. Бәшировның Мифтахын аңларга тырышып карыйк. Ул яшь ягыннан да А. Гыйләҗев героеннан яшьрәк, яшәгән чоры да Мирвәлинеке кебек колхозлашу һәм аннан соңгы елларга түгел, ә совет власте беренче адымнарын ясаган вакытка туры килә. Бераз алга китеп булса да әйтим: охшаш характерлар буларак, Мифтах белән Мирвәлинең кендекләре бергә береккән. һәм, төгәлрәк итеп әйтсәк, Мирвәли образы тегє чакта исән калган Мифтахның икенче язмышы кебек кабул ителә.

Шулай да, кем соң ул Мифтах Шәмгунов? Автор хәрби трибуналга шаһит булып килгән агай сүзләре аша заманны төгәл билгели: «Патша пичәте чуттан чыкты, ә советский пичәт каладан кайтып җитмәде әле»,— ди агай. Димәк, аклар басып алмаган төбәкләрдә совет органнары эшне инде җайлап җибәргән. Сугыш вакыты булганлыктан, хәрби трибунал да эшли һәм фронтны ташлап туган авылына кайткан унтугыз яшьлек дезертир Мифтах аның каршысында басып тора. Ни өчен? Фронттан качкан өченме, әллә башка гаепләре дә бармы егетнең? Бар икән шул!

Трибуналның карары кыска: «Югарыда саналганнарны һәм Ямбыз авылы халкының аны зарарсызландыруны үтенүен искә алып, Мифтах Шәмгуновны атып үтерергә хөкем итәргә... Фронт якынлашып килүне истә тотып, карарны кичекмәстән гамәлгә

ашырырга». Менә шулай... Авыл халкының моңа ничек кулы күтәрелгән? «Әгәренки үзәк бәгырьләренә үтми икән, халык диганең үз баласы өстеннән беркайчан да мондый пригавар җыймый! Рәнҗү ташып аккан, түземе төкәнгән!»

Трибунал рәисе Мифтах турында төпчена. «Юк! — диләр аңа. — Гомеренә ат җикмәде, сыер саумады... Элек-электән бизбашка булып үсте инде ул. Умарта басып та тотылды, базларда сөт-каймактан авыз иткәндә дә эләккәләде, кыен ашады».

Димәк, Мифтахның солдатка киткәнче дә авылда яманаты чыккан булган. Солдаттан инде егет бөтенләй зураеп, әллә кемләнеп кайтып керә. Качып кайтса да!

«— Ну соңгы айларда бөтенләй дә чыдар әмәл калмады, гупчи дә азынды, кызыл әрмегә ихтыярыйлар җыя башлагач, бигрәк тә,— ди шул шаһит.

— Ачыграк: нәрсә, ничек?

— Барып теркәлә дәгән, өр-яңа солдат киеме киеп кайта бу. Анысын сатып эчә дәгән, янәдән барып теркәлә бу! Алып кайта дагын, сата бу, сата дагын, эчә бу, янәдән барып теркәлә бу!»

Шушылары өстенә башка җинаятьләре дә өстәлә: ул ошатып йөргән кызы Гөлҗиһанны көчләргә тотына; аннан соң Гайфи мөгаллимне аулакта кыйнап ташлый; үзе турында «пригавар» чыгарганны ишетеп, авыл советы йортына граната ыргыта, ике кешене яралый. Каршы бер чара да күрелмәгәнгә узынып, Мифтах авыл халкын өркетә, чын мәгънәсендә террор урнаштыра.

Хикәяне укый башлагач та Мифтахның характерын ача торган бер урынга игътибар итәсең. Кыйналган Гайфи мөгаллим турында сүз чыккач, трибунал рәисе:

— Нигә шулай рәхимсез кыландыгыз,— дип сорый.

— Ә нишкә минем белән Гөлҗиһан арасына кысыла? Ул кем дә мин кем?

Бик тә үзенчәлекле, егетнең чын йөзен, кешеләргә булган мөнәсәбәтен, үзе турында ничек уйлавын ача торган сүзләр. «Ул кем дә мин кем?» Егет үзен бүтәннәрдән өстен санап кына калмый, аларга җирәнеп тә карый икән ләбаса. Ни өчен? Хикәя барышында егет бу сорауга үзе ук җавап бирәчәк.

Әйтеп үтелгән явызлыклар хөкем карары чыгарылганчы кылынган, ягъни Мифтахка әле бернинди куркыныч та янамаганда, ул үзенең «табигый» хәлендә яшәгәндә. Атарга алып барганда да шундыйрак уйлар: «Ул узганда, бүтәннәр дер калтырап торсын, җаннары табан астына төшсен! Ник дигәндә, ул — Мифтах, ул — алар шикелле селәгәй түгел, ул бер генә...»

Хикәянең кайсыдыр бер төшендә Мифтах образы явызлык гение булып кабул ителә башлый. Кайдан килгән егеткә бу кадәр дә усаллык, бу кадәр дә кансызлык, дисең. Автор арттырып җибәрмәде микән дип тә куясың. Әмма ашыкмыйк әле...

Атылудан качып котылгач, Мифтах инде бер бокрадан чыгып, икенчесенә килеп керә. Аның яңа җинаятьләре тезелеп китә. Ул иң элек сакчыны имгәтә, киемен алыштыра, коралланa, аннан үзен утыртып кайткан агайның атын талап ала, кияүдән үч ала, авылына ут төртергә җыена. Аның хәзер икенче гомере башланды. Ул үз тәвәккәллеге аркасында үлемнән котылды. Тере калуын берәү дә белми, кием башка, ялган документ кесәдә, хәзер җир йөзендә Мифтах Шәмгунов урынына Битал Басуркин йөри. Берәү булса, шушы документлары белән, бәладән баш-аяк дип, читкә китеп югалыр иде. Юк шул, Мифтах әле үч алырга тиеш. Үч! Үч алырга тиеш ул! Моннан соңгы эшләре аның шушы байрак астында эшләнә.

Егетнең «тыныч» вакытта да әллә ниләр кылганын искә төшерсәк, соңгылары инде гаҗәпләндерми. Аның явызлыкларына күнегеп тә киләбез кебек. Тик шунысы борчый: нилектән егет шул кадәр дә явыз? Сәбәбе нәрсәдә? Нигезендә ни ята?

Әгәр язучы Мифтахның кыңгыр эшләрен генә күрсәтеп, характерны җентекләп тикшермичә, соңгы ноктаны куйса, ул үз максатының я р т ы с ы н а гына ирешкән булыр иде. Хикмәт шунда ки, Г. Бәширов җинаятьченең психологиясен тикшерә, явызлыкның сәбәбен эзли. Чын әдәбиятка, җитди әдипкә хас сыйфат! Ә без үз әсәрләребездә максатның менә шул б е р е н ч е я р т ы с ы н а гына ирешәбез түгелме соң?

«Гаярь» егетнең бүгенге эшләрен аңлау өчен, хәзерге көнен күрсәтү генә җитми икән. Аның нинди шартларда үсүен, формалашуын күрсәтергә кирәк.

Шушы урында без хикәянең мәгънәви һәм фәлсәфи үзәгенә килеп җитәбез. Моңа хәтле ниндидер супермен рәвешендә кабул ителгән Мифтахны аңлый башлыйсың. Безне баштан ук изалап килгән күп кенә сорауларга бер-бер артлы җаваплар

табыла. Язучы, йомгак сүткәндәй, характерның эчке логикасын ача башлый. «Аның (Мифтахның) күңелендә бу авылга бармак башы тикле генә дә җылы тойгы юк иде»,— ди автор. Аннан соңгы битләрдә әле генә унтугызны тутырган Мифтахның язмыш ачысын инде күп татуын, ул сабый чакта ук әнисенең, аларны ташлап, яшь ирга кияүгә чыгуын, әтисенең исә малай белән күрше Ямбыз авылының Хөмәйрә исемле усал хатынга йортка керүен яза. Малай кечкенәдән үги ана кулында кыен ашап, типкедә үсә. Үз анасы малайны күрергә килгәндә дә, үги ана аны, мунчага ябып куеп, әнисенә күрсәтми җибәрә. Мифтах үсә төшкәч, үги ана, иреннән үч аласы булса, моны малайдан эшләткән. Ә үзе: «Яле, уңлы-суңлы чалтырат әле шул бозауның яңагына! Кизәнебрәк, ныграк! Менә шулай!» — дип азындырып торган. Тыңламаса, үзен кыйнаган. Шул вакыт малай күңелендә нык кына ир була торып үзен шушы хатыннан мыскыл иттергән әтисенә нәфрәт уяна. Мәми авыз булганы өчен ул аны күрә алмый башлый. Шул кыерсытуларның үчен урамга чыккач башкалардан ала. «Кечкенәдән үк явызлыкның зәһәре белән агуланып, аның «түмен татып», шуннан рәхәт табып үсә», — ди язучы, Мифтахның фаҗигале һәм тетрәндергеч язмышын ачып салып.

Аның артыннан без дә, кем соң ул Мифтах Шәмгунов, дигән сорауга җавап алабыз, тик җавап безгә куаныч китерми. Күз алдына бөтен акылсызлыгы, гамәлгә сыймаган эшләре, күңел катылыгы, кансызлыгы белән япь-яшь егет Мифтах килеп баса. Их, дисең, заяга үткән гомер! Әгәр дә бу кадәр көч, мондый гайрәт, дөрес юнәлеш алып, яхшылык юлыннан киткән булса! Нинди зур эшләр башкара алган булыр иде егет...

Г. Бәширов Мифтах образы аша акылын эшкә җикмичә эчке инстинктка, кәеф-настроениегә буйсынып кына яшәргә өйрәнгән кыйблясыз рухның фаҗигасын күрсәтә. Үз-үзен дә, кешеләрне дә, катлаулы заманны да аңламаган көчле шәхеснең индивидуаль бунты һәлакәт белән тәмамлана. Җинаятьләре арткан саен, гаярь егет иленнән, халкыннан, кешеләрдән ерагая бара, Мифтах белән җәмгыять арасында стена үскәннән-үсә бара, һәм шушы фикернең логик төгәлләнеше буларак, герой урмандагы ерткыч кебек, япа-ялгызы калып үлә.

Бу әсәрне укыгач, басыла килгән кайбер повестьларда, хәтта романнарда да шушындый гомумиләштерүләр, тирән мәгънә булсын иде дип куясың. Ә бит бу бер хикәя генә иде. Димәк, эш әсәрнең күләмендә түгел, ә язучының үзендә, иҗат эшенә булган мөнәсәбәтендә икән.

Әйе, Р. Мостафин фикере белән һичшиксез килешәсең: Г. Бәшировның «Сарут»ы — соңгы елларда иҗат ителгән хикәяләрнең иң яхшысы. Аңа өстәп, мин Ә. Еникинең матбугатта инде мактап телгә алынган «Тынычлану» хикәясен дә атар идем. Икесе дә — әдәбиятыбызның горурлыгы булырдай әсәрләр. Өлкән әдипләребез вакыйга сөйләп чыгу белән генә чикләнмичә, аңа тирән фикер, фәлсәфә дә салганнар. Безнең күп кенә хикәяләребезгә, тагын бер баскычка күтәрелү өчен, нәкъ менә шул нәрсә җитми. Күренгәләп килгән хикәяләребезнең кайсында «Сарут»тагы кебек характерны җентекләп тикшерү, аның үсешен, нәтиҗәсен күрсәтү бар соң? Өстән-өстән генә язабыз, тормыш күренешләрен сөйләп чыгабыз да тынычланабыз. Анализлау, тирәннән сөрү җитенкерәми безгә.

Соңгы вакытта хикәя жанрында күпмедер җанлану сизелә, әмма бу җанлану әлегә күләм исәбенә бара. «Менә бу хикәя ичмасам!» диярлекләре сирәк очрый. Шулай да хикәяләр языла тора, басыла тора, арада әдәби эшләнеше шактый камил булганнары да очрый. Шушы уңайдан В. Шукшинның хикәя турында әйтелгән гыйбрәтле сүзләре искә төшә: «Даже если и есть умение ее рассказать, надо еще почувствовать, что она нужна. Нужна ли? И это-то в «профессии» рассказчика едва ли не самое трудное — понять: нужен ли ты сейчас со своей историей». Димәк, яхшы хикәяче булу өчен әдәби осталык кына аз, укучыга җиткерәсе вакыйганы сайлый белергә дә кирәк. Бүген хикәяләргә нәкъ менә шушы нәрсә җитми дә инде.

Яшьләрнең актив рәвештә хикәя яза башлавы куандыра. Мин үзем, мәсәлән, киләчәктә безнең хикәячеләребез булыр дигән өметтә яшим. Яшьләрнең хикәя язулары шуңа дәлил булып тора. Алар әлегә көч туплый, осталыкка өйрәнә. Хәзер хикәяне өлкән буын әдипләребез белән яшьләр генә яза. Урта буын тулысынча повестька тотынды.

Инде кайбер гомуми фикерләргә күчкәнче, А. Гыйләҗев повестендагы Мирвәли язмышына күз салып алыйк. Язмышын кәтмәгәндә икенче якка борып җибәргән колхозлашу чоры килеп җиткәндә, Мирвәли — инде утызга якынлашып килүче өйләнгән ир. Авылның күзгә күренеп торган егете, Шәйхразый бай малае, ярлы кызы Шәмсегаянны ала. Ләкин карун ата моның белән һич тә килешә алмый, тавыш чыга, Шәйхразый бай киленне талак әйтеп аерырга яки икесенә дә өйдән чыгып китәргә куша. Горур холыклы, сүзен сүз итәргә яраткан Мирвәли, әлбәттә, соңгысын сайлый. Яшь хатыны белән ятим карчык Таифә өенә урнаша. Шулай, дөнья хәлләренә колак салмыйча, ваемсыз һәм бәхетле генә яшәп ятканда, иң элек Мирвәлинең әнисе үлеп китә, аннары карчыгының кырыгын да уздырырга өлгермичә, тап-таза йөргән Шәйхразый бай да, юан имән кебек, көтмәгәндә гөрселдәп ава. Кырык тераүле Таифә карчык йортында яшәп яткан Мирвәли кинәт кенә бай йортның бердәнбер хуҗасы булып кала. Тик Мирвәлинең канат җәеп очарга рухланып йөргән бер көнендә авыл советы шундый карар чыгара: Мирвәли, кулак малае буларак, атасының бөтен байлыгын халыкка тапшырырга тиеш, шул очракта гына ул туган авылыннан куылмаячак.

Кискен хәлгә, экстремаль ситуациягә куелган Мирвәли алдына бөтен котылгысызлыгы белән сайлау проблемасы килеп баса. Һәм менә шунда көчле рух, үзенчәлекле характер үзен сиздерә башлый.

Совет чыгарган хәбәрне ишеткән Мирвәли соң дәрәҗәгә җитеп тузына:

«Аның үзеннән — хуҗадан башка барын да хәл иткәннәр?!» — дип ярсый ул, йөрәгендә ачу, нәфрәт, үч кайный. Һәм аның кайнарлыгы, гаярьлеге үзенекен итә. Китәргә! Барысын да юк итеп, барысына да төкереп, үч алып китәргә кирәк!

«Этләргә танау сөртерлеге дә калмасын!»

Мирвәли ит чаба торган бүкәндә кием-салым, туннар, ситсалар, чаршаулар турый.

«Ашаган кешенең эчәгесе әйләнеп чыксын, ашказаны бөрешсен!»

Монысы инде лар-лар бодай, арыш өстенә дегет мичкәсен аударганда, борчак, ясмык өстенә көл, керосин, пычрак су агызганда әйтелгән сүзләр. Шырпы тотып йортка да ут төртмәкче була Мирвәли, Шәмсегаян коткарып кала. Күршеләр бар, карап булулары мөмкин. Һәм «алар, кара күләгәләр булып, авылдан икәүләшеп чыгып китәләр...»

Ах, ничек үкенәчәк, бәргәләнәчәк әле гаярь егет бу дуамаллыгы, акылсызлыгы, ужәтлеге өчен!.. Туган авылына, туып үскән җиренә төкереп, аны мәсхәрәләп чыгып киткән Мирвәлинең сызланасы көннәре алда әле!

Шәмсегаян белән утыз ел читтә үткәргән нурсыз гомеренең тоташ бер сызлану булганлыгын ул хатынының үле гәүдәсен арбага салып Карачурага кайтып барганда, юлда гына аңлаячак. Үз-үзенә ачы сораулар бирә башлагач кына.

Ә ничек үтте соң ул утыз ел гомер? «Утыз еллык озын гомереннән бәхетле айлар-атналар түгел, минутлар, мизгелләр эзләде! Эзләгән саен аның маңгаена салкын тир мулрак чыга барды. Чөнки андый минутлары юк, аларны хәтер сакламаган иде»,— ди автор.

Ә мәхәббәт? Бәхет?

Аларны саклап калу өчен дә тулы канлы тормыш, якты язмыш, канатлы гомер кирәк икән бит. Үлем түшәгендә яткан Шәмсегаянның сүзләре үзәкне өзә: «Сөйләшәсе иде дә... Мирвәли... Сүзләр юк! Синең белән сөйләшү дә онытылган, үпкәләмә!» Ә ничек яратышып өйләнешкәннәр иде югыйсә. Нинди якты өметләр белән башлаганнар иде тормышларын... Әмма эшләнәсе эш инде эшләнгән, гомер узган, хәзер, Шәмсегаянның васыятен үтәп, Карачурага кайтып егыласы гына бар, тик кайтасы да, кеше күзенә күренәсе дә килми. Булырлык, көч җитәрлек эш түгел бу. Ә кайтырга кирәк.

Мирвәли йөгән киерткән кебек арба кырыеннан бара, арбада аның изге фәрештәсе, гомер буе үзенә юлдаш булган, ялгышлы язмышын уртаклашкан һәм, гаебе булмаса да, шул хатаның корбаны булып Шәмсегаян ята.

Ә менә Мирвәлинең исән булуы кемгә кирәк, кемне сөендерә аның дөньяда яшәве, Карачурада аны кем көтеп тора. Кулы белән булдыра алмаса да, күңеле белән күптән яндырды бит инде ул бу авылны. Тик авылга берни булмаган. Мирвәлинең күңеле генә кара күмергә әйләнеп пыскып ята. Бәлки гаебеңне танып, авылдашлар алдында баш орыргадыр?!

Шәмсегаянны җирләгәч тә Мирвәлигә әле күпне татырга туры килә. Хатынын кызганалар, аны — юк. Читләшәләр. Үзен санга сукмауны бик авыр кичерә ул. Андыйга күнекмәгән. Гомер буе үзенчә, беркем белән хисаплашмыйча яшәгән.

Буш нигезенә кагылган усак казыкны күргәч тагын бер үртәлә Мирвәли. «Бүген, ул кайткач кына какканнармы әллә?..»

Авылда әле онытмаганнар аның кылган эшләрен. Утыз ел аның исемен берәү дә баласына кушмый икән. Ул гынамы соң! «Үз җирен каһәрләгән кешене, өстебез ялангач чагында күпме кием-салымны тураклаган кешене, күз карасыдай кадерле игенне дегет белән аралаган кешене, күпме мал-туарын агулап киткән кешене... Гафу итәргә, сыендырырга, урын бирергә дисеңме?! Белмим, белмим...» — дип җавап бирә Мирвәлигә бердәнбер адашы. Ләкин Мирвәлинең барыр җире юк, картлык якынлаша, сыеныр урын кирәк. Аның авылда каласы килә. Ничек итеп? Әмма халык хөкеме беркайчан да кирәгеннән артык каты булмый. Соңгы минутта үлем карарын юкка чыгаргандай: «Җизни... олы башың белән әллә кайларга китеп йөрмәссең инде, үзебездә генә калырсың...» — дип, балдызы аңа коткаручы кулын суза.

Чын язучы үзенең геройларын гомер-гомергә олы эшләр, авыр язмыш, зур мәхәббәт белән сыный, шулар аша үткәрә. Сынауларны үткән герой гына (димәк, әсәр дә) әдәбиятта кала, вакыт аңа мәрхәмәтле була, еллар тузаны аны күмеп китми. Егерме ел элек язылган «Өч аршын җир» повесте да бүген язылгандай актуаль яңгырый. Чөнки аның нигезендә мәңгелек конфликт ята. Шәхес һәм җәмгыять — конфликт шуннан гыйбарәт. Дөресрәге, әсәрдә без үзен җәмгыятькә, аның прогрессив көчләренә, халыкка каршы куйган индивидуалистның тупикка барып терәлүен, рухи яктан үлә башлагач кына үзе йөз чөереп йөргән халык алдына килеп тезләнүен күрәбез.

Г. Бәшировның Мифтахы яшьли үлеп китә, шуның аркасында үзенең хатасын да, фаҗигасын да аңламый кала. А. Гыйләҗев исә үз героена барысын да җитәрлек татыта, повесть ахырында Мирвәли инде гомеренең заяга узганын аңлый һәм фаҗиганың сәбәпчесе фәкать үзе генә икәнне дә танырга мәҗбүр була.

Бер үк проблемага багышланган «Сарут» хикәясе белән «Өч аршын җир» повестьларын тормышның шундый да рәхимсез, шундый да каты була алуыннан тетрәнеп, бу ике язучының тормышны бизәмичә, шомартмыйча, бөтен катылыгы һәм рәхимсезлеге белән күрсәтергә көч, кыюлык табуларына сокланып укыйсың. Иҗатта үзеңә таләпләрне киметмәгәндә, җиңел юлдан барырга тырышмаганда, заманның төрле кызыктыруларына ымсынып алданмаганда, нинди әсәрләр язып була икән ләбаса!

Әсәрләрдә уңай герой гына түгел, тискәре герой да, тиешле ракурста бирелсә, уйланырга мәҗбүр итә, байтак фикерләр уята. Соңгы елларда иҗат ителгән «Әтәч менгән читәнгә» (А. Гыйләҗев), «Хәсән Вәгыйзович» (Т. Миңнуллин), «Һәлакәт» (В. Нуруллин) повестьларында да тискәре образлар аша бүгенге көннең әхлакый мәсьәләләре күтәрелә, көн кадагына суга торган гыйбрәтле хәлләр тасвирлана. Бу — язучыларның бүгенге көн турында кайгыртып, борчылып яшәүләре турында сөйли.

Объектив хакыйкать күп кенә субъектив хакыйкатьләрдән җыела, ди Р. Мостафин. Бу чыннан да шулай. Авырткан җирдән кул китми дигәндәй, шушы сөйләшү вакытында һәрбер автор үзен борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшә һәм шулай итеп гомуми картина, прозабызның бүгенге хәле ачыклана бара. Әйе, хәлләр бигүк шәптән түгел икән шул. Бу нәтиҗә белән барысы да килешәләр шикелле. Минем дә, төп мәсьәләгә кайтып, прозабызның бүгенге хәлен үзем өчен ачыклыйсым, кайбер уңышларыбыз булуга да карамастан, гомумән алганда проза өлкәсендә арттa калуыбызның сәбәпләрен аңлыйсым килә.

Ф. Зөлкарнәевнең: «Миңа калса, безнең прозада патриархальлек төсмере сакланган тормыш идеалы өстенлек ала», — дигән сүзләре игътибарга лаек. Ни өчен? Соңгы елларда бераз югалып калуыбыз, минемчә, гомер бакый авыл темасында көчле булган, күбрәк шул теманы сөргән-сукалаган татар прозасының фән-техника революциясе чорында, республикада зур тизлек белән шәһәрләшү процессы барган бер дәвердә язучыларыбызның аптырабрак калуы белән аңлатыладыр. Язучыларыбыз — барысы да диярлек — авылдан чыккан кешеләр. Ә авылда тел стихиясе. Шәһәрдән безнең әдәбиятка кадрлар бик аз өстәлә. Шәһәр балалары язарлык дәрәҗәдә ана

телен белмиләр, яки бөтенләй башка өлкәләргә китеп баралар. Шулай булгач, безнең әдәбият авылдан килгән талантлы кешеләр хисабына дәвам итә.

Унны авылда бетереп шәһәргә килгән кешенең күңеле, әлбәттә, авылда кала. Шуңа күрә дә утызар ел шәһәрдә яшәгән язучыларыбыз һаман авыл турында язалар, кайтып-китеп йөреп, авыл белән даими элемтәдә торалар.

Тагын шунысы да бар: авылдан килгән кеше барыбер тиз генә арада чын мәгънәсендәге шәһәр кешесе булып китә алмый. Шәһәр материалы, кешелек дөньясы туплаган бөтен рухи һәм интеллектуаль байлыкны саклаучы организм буларак, авыл тормышына караганда катлаулырак та, авыррак та. Анда конфликтлар кочлерәк булса да, ныграк яшеренгән. Аларны тотып алуы, аңлавы, бигрәк тә сәнгать чаралары белән тасвирлап бирүе җиңел түгел. Ә авылда барысы да күз алдында, ярылып ята. Аннан соң шәһәр материалында милли характерны тотып алуы авыррак, ул икенче шартларда яши, монда инде күнегелгән, традициягә әверелгән алымнар белән генә эш итү җитми, эзләнү, яңалык таләп ителә.

Озын сүзнең кыскасы шул: шәһәрләшү процессы тиз бара торган республика буларак, безнең татар прозасының киләчәген мин шәһәр тормышына игътибарны арттыруда күрәм. Чөнки шәһәр материалы язучыдан, Р. Мостафин сүзләре белән әйтсәк, «гасырыбызның әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләре югарылыгында хәрәкәт итү»не таләп итәчәк. Моның өчен язучыдан да бик күп нәрсә сорала. Беренче чиратта, әлбәттә, интеллектуализм. Әсәрләребезнең бөтенсоюз аренасында яңгыраш тапмавының бер сәбәбен мин нәкъ менә шул интеллектуализм җитмәүдән дип уйлыйм. Әмма урта буын язучыларыбызда мондый мөмкинлекләр бар. Әдәбиятка килүче яшьләребез дә бу эшкә вакытында тотынсыннар, үзләрен төрле яктан әзерлекле кешеләр итеп тәрбияләсеннәр иде. Чөнки прозада тышкы бизәк ясап кына көн итү заманнары үтеп бара.

Талантлы язучы белән урта кул язучыны янәшә кую талантлы язучыны хәлсезләндерә, дип дөрес язә А. Гыйләҗев. Моны күреп талант иясенең күңеле төшүе, үзенә куйган таләпләрне дә киметүе бар. «Нигә ул кадәр тырышам, көч куям соң әле? Хезмәтемне барыбер күрүче, бәяләүче юк. Башкалар аннан-моннан эшләп тә шул ук дәрәҗәдә йөриләр»,— дип ул да ашык-пошык язылган әсәрләрен бастырырга мөмкин һәм бу нәрсәнең соңгы елларда практикага кереп баруы үзен сиздерә дә.

Җитлекмәгән әйберләр газета-журнал редакцияләренә торган саен күбрәк килә, редакция хезмәткәрләре аларны дөньяга чыгару өчен торган саен күбрәк көч, вакыт сарыф итәләр. Әмма эшне редакторларга гына йөкләп, барыбер, яхшы сыйфатлы әдәбият булдыра алмаячакбыз. Монда язучы үзе, таләпләрне киметмичә, әдәбият эшенә йөрәк һәм намус эше итеп карарга тиеш. Безгә, әдәбиятның барыннан да элек сәнгать икәнен онытмаган хәлдә, ниндидер темаларга, юнәлешләргә иллюстрация ясаудан туктарга вакыттыр, күрәсең. Соңгы вакытта әдәбиятка журналистика мәсьәләләрен хәл итү йөкләтелә башлады шикелле һәм кайбер иптәшләр шушыннан бик оста, оператив файдаланалар да.

Зур сөйләшүләр вакытында тема өчен мактап кына калмыйча, сүзне күбрәк сәнгатьчәлек турында алып барасы иде. Таләпләрне дә: кешене, заманны аңлауга син нинди яңалык керттең? — дигән принциптан чыгып куясы иде.

Соңгы елларда эшче темасына язылган әсәрләрнең сәнгать ягыннан йомшак булуы — әдәбиятка журналистларча килү, аны иллюстрацияләү чарасы итеп кенә карауның бер нәтиҗәсе. Бүгенге әдипләребез кеше рухының гел үзгәреп торган яшәешен чагылдырганда гына, көчләрен шул юнәлештә сарыф иткәндә генә халкыбыз ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек, заман таләпләренә җавап бирерлек прозабыз булачак безнең. Ул чакта бәлки «бөтенсоюз аренасында яңгырамыйбыз» дип чаң кагулар да бетәр.

Сүзне: әйдәгез, җитдирәк булыйк әле, егетләр, барысы да үзебездән тора бит, дип тәмамлыйсы килә.

Хөрмәтле укучылар!

Бүгенге проза турында дискуссия дәвам итә. Сездән хатлар, фикерләр, мәкаләләр көтәбез.

Роберт Әхмәтҗанов

# ҖИЛ УҢАЕНА БОРЫЛМА!

РЕПЛИКА

Тәнкыйть — ут кебек изге, пакь. Ул һәрбер күгәрек-тутыкны, рухи инфекцияләрне зарарсызландыра. Шуңадыр да «тәнкыйть утына тоту» дигән тәгъбир киң таралган әдәбиятта. Икенче бер урында без тәнкыйтьне иҗатыбызга гадел хөкем алиһәсе — Фемида итеп сынландырабыз.

Барыннан да бигрәк, тәнкыйть предметлы, ягъни конкрет әсәрләргә таянып фикер йөртергә тиешле, дибез. Юкса элеккегедән килүче инерция, комплиментарлык инерциясе алып узачак. Моның шулай икәнлеген раслар өчен ерак барасы юк. Безнең сүз дә «предметлы» булсын, һавада асылынып калмасын өчен конкрет мисалларга таянырга тырышыйк.

Табигый ки, шигърияткә мөнәсәбәтле кеше буларак, мине аерым җыентыкларда һәм көндәлек матбугат битләрендә шигъри әсәрләребезгә карата әйтелгән тәнкыйть сүзе кызыксындыра. Аларны мин даими рәвештә күзәтеп-укып барам. Шигърият иленә кергән тәнкыйтьчеләребезнең теге яки бу әдипкә карата ничаклы объектив булуы, бәяләрдәге логик эзлеклелеге, стилистикасы, терминологиясе һ. б. сыйфатлары игътибарны җәлеп итә.

Күренекле тәнкыйтьчебез Р. Мостафин «Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты» исемле мәгълүм мәкаләсендә, язучының тәнкыйтьче ролендә чыгуын хуплап, «биредә таләп ике яклы булырга тиеш: тәнкыйть мәкаләләре язарга алынган шагыйрь яки прозаиктан без фәнни тирәнлек һәм тәфсилле анализ таләп итәргә хаклы, алар, үз чиратында, тәнкыйтьчеләрдән тел, стиль төзеклеге һәм мавыктыргыч итеп яза белүне таләп итәргә тиешләр»,— дип язган иде. Биредә без нәкъ менә шул таләпләрдән чыгып эш итәргә булдык та инде. Әйтелгәннәргә өстәп, без тагын: «Шагыйрь исә тәнкыйтьчедән һәр иҗади шәхеснең талант табигатен аңларга омтылуын таләп итәргә хаклы»,— дибез. Юкса, әлеге дә баягы дигәндәй, исемнәрне тәрләндереп, субъектив фикер уйнатып, иҗат алымнары, юнәлешләре һәм осталык турында бик якынча фикерләрне абсолютка тиңләп, укучыны бутавың гына бар.

Мин дә бу язмамны баштан ук безнең кайбер тәнкыйтьчеләребез белән бәхәскә кереп башладым. Әлбәттә, бу — ертыктан сүтек эзләү булып кабул ителмәстер. Чөнки биредә сүз һәр «сүтек» турында түгел, күзгә күренгән зуррак «ертыкларга» гына кагылачак.

Иң әүвәл шунысы күзгә ташлана: тәнкыйтьче үзенең бәясен санап чыгуга, теркәүгә нигезли.

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, әйтик, әдәбиятка бер чорда килгән шагыйрьләр турында сүзне менә болай башлый: «...И. Юзеевны, мәсәлән, әдәбият мәйданына мәктәп эскәмиясеннән килде дияргә була... 1955 елда... аңа нибары егерме ике яшь иде. Арада иң өлкән саналган Г. Афзал беренче шигырьләрен утыз дүрт яшь тулганда дөньяга чыгарды. Шул ук 1955 елда Х. Камаловка — егерме тугыз, Ш. Галиевкә — егерме җиде, Р. Гәрәйгә егерме дүрт иде. Шулай да иҗат һәм эстетик платформалары ягыннан алар бер-берсенә шактый якын торалар иде...». Яшьләренең ни-

чәдә булуы бер хәл, тик менә «беренче шигырьләрен чыгарган» вакытта ук «иҗат платформаларының» аныклануы исә бик үк ышандыра алмый диясе килә. (Сүз уңаеннан, бездә шагыйрьләрне әнә шулай төркемләп-төркемләп санау һәм гомумиләштерү шаблоны әле дә гамәлдән чыгып бетми. Әйтерсең, бездә һәрбер иҗади шәхес үзенә бер индивидуум түгел, әйтерсең, шагыйрьләр төркемләп, «детсадлап» үсә! Моның үзенә бер сәбәбе шул булса кирәк: төркемләп санау җиңелрәк, берсе дә төшеп калмый, чагыштыру өчен дә җиңел, билгеле).

Тәнкыйтьче шагыйрь Ш. Галиевнең «Тормыш тозы» исемле шигырен тәнкыйтьләп, аңардан өч строфа китерә. Без исә кыскалык өчен шул строфаларның соңгысын гына китерик:

**Ә тормыш — тозлы тир түккән**
**Җир уллары кулында.**
**Җирдә иң кирәк тә шулар —**
**Сүземнең тозы шунда.**

«Сүз дә юк, әдәби яктан шигырь **бик яхшы** эшләнгән. Икенче бер шагыйрь өчен ул **зур** уңыш булып саналыр иде. Әмма... Ш. Галиевтән фәлсәфи тирәнлек, чын дулкынлану һәм кайнарлык белән сугарылган әсәрләр көтәсең,— ди автор. (Биредә һәм алга таба да ассызыклар безнеке). «Бик яхшы» сыйфат билгесе белән тамгаланган строфаны укучы үзе дә бәяли алыр. Ә менә ни өчен «икенче бер шагыйрь өчен ул зур уңыш булып саналыр иде» икән? Бу — үз бәяңне абсолютка тиңләп, укучыга тагуның бер мисалы түгелме? Тәнкыйтьче үзе үк каршы чыккан комплиментарлыкның аз булса да чагылышы юкмы монда?

Аннан соң, шагыйрьнең иҗат лабораториясенә тирән керүгә омтылыптыр инде, кайбер тәнкыйтьчеләр төп игътибарны шигърияттнең тышкы, механик күренешләренә юнәлтеп, схематизм юлына кереп китәләр. Р. Мостафин, «Җаваплылык тойгысы» дигән китабындагы (1979) «Хис һәм фикер берлеге» исемле мәкаләсендә Р. Фәйзуллин иҗатының уңышлы якларына шактый тукталганнан соң, мондый фикерләр дә әйтә: «...Р. Фәйзуллин шигырьләре еш кына шактый коры булып чыгалар. Аңарда тасвирлы эпитетлар, чагыштырулар, метафоралар аз». Сүзен тагын да дәвам итеп, автор болай ди: «Мин шагыйрьне корырак, фикерләренең **ясалмарак** булганы өчен гаепләргә җыенмыйм. Аның **иҗат үзенчәлеге** шундый. Өстәвенә, бу үзенчәлек аның матбугатка чыккан беренче шигырьләреннән алып бүгенге көнгә хәтле дәвам итә». Сәеррәк түгелме: ясалмалык, янәсе, шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге булып чыга икән!

Тәнкыйтьче, белгәнебезчә, башкалар иҗатын укып-бәяләп утыручы техник-контролер түгел, ә бәлки үзе дә әдәби иҗат кешесе, фәлсәфи-эстетик байлык тудыручы. Алай гына да түгел, ул — әдәбиятка туры юнәлеш бирүче дә. Әдәби-иҗтимагый тормышыбыз аңа бу өлкәдә зур ышаныч күрсәтә. Әдәби жанрлар үскән, баеган һәм үр менгән чакта әдәби тәнкыйтькә дә таләпләр үсә бара.

Шигырь, поэтика хакындагы тәнкыйть мәкаләсе үзе дә шигъри тел белән язылган, мөкәммәл әсәр булырга тиеш, билгеле. Тәнкыйть мәкаләсе үзенең принципиаль-объектив рухы, фәнни атамаларының төгәл кулланылуы, камил стилистикасы һәм логик эзлеклелеге белән ышандыра, күңелләрне җәлеп итә. Кайбер мәкаләләрдәге урынсыздан исем санаулар, төрле терминнарның шыплап тутырылуы, фикер эзлеклелеге булмау, күпсүзлелек күңелне кайтара.

Танылган тәнкыйтьчебез Тәлгат Галиуллин үзенең «Бизәкләр төрлелеге» исемле мәкаләсендә («Казан утлары», 1981, 6 нчы сан) терминнар муллыгын менә ничек аңлата: «Хәзерге тәнкыйтьтә поэзиянең тематикасы һәм предметы турында сүз алып бару оят эш, фәнни методикадан читләшү, хәтта күпмедер күләмдә яман аты чыккан вульгар социологизм тегермененә су кою кебегрәк бәяләнә. Шуңа күрә без еш кына бу төшенчәләрне катлаулырак категорияләр, чит телләрдән иңгән авыр терминнар белән алыштырабыз, мәсьәләгә әйләнеч юллар белән килергә мәҗбүр булабыз» (?!). Мондый хаҗәт нидән килеп чыгадыр, бик үк аңлашылмый, минемчә. Тик менә бу урында, җөмләләрне катлауландырып, сыйфатларның үтә мул палитрасын киң кулланып кына фәннилеккә ирешеп булмый шул, иптәшләр, диясе килә. (Әйтерсең лә фәнни методика шигърият фәненең үзеннән килеп чыкмый, ул бары мәҗбүрият кенә!)

Менә Т. Галиуллин мәкаләләрендә әдипләребезгә карата кулланылган палитрадагы сыйфатларның кайберләре: «С. Хәкимнең **уйчан, тирән мәгънәле, реалистик** поэзиясе..., Ф. Фәйзуллин белән Р. Харисның **шартлы алымнарга** бай, **дәртле, көтелмәгән** борылышлы, хыял ачышына киң таянган **романтик** лирасы..., Н. Арслановның **тыгыз** хисле, **салмак** агышлы стиле..., Ш, Галиевнең **итагатьле, тыйнак...**, Р. Гатауллин, Р. Мингалимовларның **романтик, тарихи-интеллектуаль...»** Тагын берничә абзацтан соң: «...Р. Фәйзуллин **көтелмәгән** лирик борылышлар һәм ассоциация шагыйре», **шартлаулы, көтелмәгән** алымнар» кебек чагыштыруларның, сыйфатламаларның мул фонтаны бәреп чыга. Әйе, чыннан да, укучы үзе дә бу диңгездә адашып, «көтелмәгән борылышлар» артында кала. Ә дәлилләр кайда? Предметсыз тәнкыйть чәй башы (заварка) салынмаган тонык суны хәтерләтә. Хөрмәтле тәнкыйтьчебез берүк кичерә күрсен— мәкаләдәге стиль чуарлыгы, атамалардагы төгәлсезлекләр, уйлап җиткерелмәгән чагыштырулар шактый өстә ята шул...

Шигырь тукымасына, фикер структурасына, сүз сурәтенең тылсымына кермичә, өстән-өстән генә язылган мәкаләләр әлегә күренгәләп тора. Аларның авторлары арасында без яшь тәнкыйтьчеләрнең исемнәрен дә күрәбез. Кайбер иптәшләр язучы иҗатына бәя биргәндә үз-үзләренә үк каршы чыгалар, мәкаләләренең азакларына җитәрәк сүзне нәрсәдән башлаганнарын оныталар кебек. «Казан утлары»ның 5 нче (1981 ел) санында шагыйрь Р. Гатауллинның «Чакыру» китабына рецензия язган ике яшь автор, асылда, шагыйрь иҗатына әйбәт бәя бирәләр, аңа теләктәш фикерләр белән чыгалар, симпатияләрен ачык белдерәләр: бу — яшь тәнкыйтьчеләрнең хәтта азрак борчылу чалымнарында да сизелә. Поэзиягә шундый актив якынлашуны хупларга гына кирәк иде. Әмма чагыштырулардагы ашыгу-кабалану, логик эзлеклелек җитешмәү игелекле фикерләргә дә күләгә төшерми калмый икән. Менә бер мисал.

«Максатка ни илтә?» исемле рецензиянең авторы Ф. Зөлкарнәев бер абзацта: «...стильләштерү алымын **оста** куллануы исә шагыйрьнең **шактый үк** югары поэтик культурага ия икәнлеген раслый... Гомумән алганда, болар Р. Гатауллин иҗатын бизи торган сыйфатлар» дигән фикерне әйтә дә, шуннан соңгы өченче абзацта ук: «Шагыйрьнең **стиле корырак.** Сөйләмнең музыкаль җегәрен, колакны иркәли торган аһәңлекне ул сирәк куллана. Сурәтлелек тә күп түгел. Еш кына хисне сөйләп аңлата» дигән капма-каршы фикер белән чыга. Табигый сорау туа: нәрсә әйтергә тели автор, нинди каланчадан торып яза ул? Бу да — шаблон чире: мактаудан соң һичшиксез, «ләкин...» дип беткәне дә булсын бездә — шагыйрьне уңай яктан гына телгә алсаң, күбрәк булмасмы, янәсе. Һәрхәлдә, тәнкыйтьченең позициясе ачык, аңлаешлы булырга тиеш. Ә биредә уңай фикер — бер багана, тискәре фикер — төгәл бер багана. Көчләр тигез! Мондый очракта тәнкыйтьнең файдасы коры сүз көрәштерүгә генә кайтып калмыйммы? Тәнкыйтьче һич тә флюгер сыман «үз кыйбласын» үзгәртергә тиеш түгел. Ул теләсә кайсы исем белән җиңел генә жонглерлык та итмәскә, бәяләрдә дә сак булырга, принципиаль да булырга тиеш! Чөнки һәр исем артында — бер шәхес, бер язмыш.

Тәнкыйтькә тәнкыйть белән чыгу, әлбәттә, үзмаксат та, «тел кычытканнан» гына сүз уйнатырга теләү дә түгел. Бу — дәвамлы күзәтүләр нәтиҗәсеннән килеп туган ихтыяҗ! Чыннан да, тәнкыйтьчеләребез үзләре үк таныганча, бездә анализлы тәнкыйтькә караганда, билге куя торган тәнкыйть өстенлек итә әле. Мәкаләләребезгә социаль яңгыраш, фикер ачыклыгы һәм форма төгәллеге җитми! Бу бигрәк тә поэзия тәнкыйтендә шулай.

Шигърияттә булсын, проза өлкәсендә булсын, гомумән, барлык әдәби жанрларда иҗат итүчеләр хакында: «Аның үз иҗат почеркы, иҗади йөзе бар, үз тавышы бар»,— дип бәяләү гадәткә кергән. Тәнкыйть тә юкса — әдәби жанрларның берсе. Ә менә аның хакында нигәдер алай әйтелми. Тәнкыйть мәкаләләребез һәм рецензияләребез инкубатор чебешләредәй бер-берсенә охшамасын, әдипләр алардан үз исемнәрен һәм «һ. б.»ларны эзләп тормасыннар, үз иҗатларының асылын күрсеннәр иде.

Альберт Яхин

# ФИКЕР ДӘЛИЛЛЕ БУЛСЫН!

Соңгы елларда без әдәбиятыбызның, аерым алганда, әдәби тәнкыйтьнең уңышлары турында басым ясап сөйлибез. Бик хаклы рәвештә, әлбәттә. «Казан утлары» журналында әдәби тәнкыйтьнең чын мәгънәсендә үз урынын табуы, мәкаләләрдә әдәби процессны иңләү колачы киңәя төшүе, фәнни тирәнлекнең арта баруы да шуңа дәлил. Мөһим иҗат проблемалары, бүгенге әдәбият фәненең үзәгендә торучы мәсьәләләр күтәргән хезмәтләр шактый еш басыла. Флүн Мусинның, мәсәлән, хәзерге заман уңай герое үзенчәлекләрен билгеләгән, Тәлгат Галиуллинның поэзиябез хәзинәсен күптөрле күренеш итеп тикшергән, Фатих Урманчеевның бүгенге татар әдәбияты һәм аның фольклор әсәрләре белән бәйләнеше мәсьәләсен шактый тирән ача алган мәкаләләре истә калган. Равил Кукушкин әдәбият тарихына мөрәҗәгать итә һәм поэзиябезнең бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән ягын — балалар өчен язылган әсәрләрне тарихи планда анализлый. Ринат Мөхәммәдиев белән Фәрваз Миңнуллин мәкаләләрендә җитди мәсьәләләр күтәрелә.

Яшь тәнкыйтьчеләр дә әдәби осталык серләрен әсәрләрнең тукымасына кереп ачарга омтылалар. Кайнарлык, күтәренке пафос аларга конкрет анализдан чыгып, фикерләрен өзеп әйтергә комачауламый. Яшь тәнкыйтьчеләр арасында яңача фикерли белүче, шаблонга ябышып ятмыйча, чирканчык алмый-нитми әсәр эченә чумарга торучылар бар. Киләчәктә дә шундый өметле яшьләргә игътибар итәргә кирәк диясе килә.

Әдәби тәнкыйтьнең соңгы елларда күбрәк мактауга йөз тотуына үзенең борчылуын «Литературная газета» гына да берничә мәртәбә белдерде. Мондый кимчелектән без дә мәхрүм түгел, әлбәттә. Шулай да, әйтеп үтәргә кирәк, гомуми чиргә әйләнгән макташу гадәтен безнең «Казан утлары» журналы, әдәби җәмәгатьчелек һәрвакыт дәвалый белде. Безнең тәнкыйтьтә турысын әйтеп сөйләшү принцибы нигездә сакланып килә. Фәрваз Миңнуллин, мәсәлән, хәтта Рафаэль Мостафинның юбилее уңаеннан язган мәкаләсендә дә тәнкыйтьченең уңай якларын күрсәтү белән чикләнми. Шул ук вакытта чеметкәләп, усалланып та вакланмый, иптәшләрчә бик җитди итеп, шактый уйланырлык кимчелеген турыдан-туры әйтеп бирә: бүгенге татар әдәбиятын тарихыннан аерып каравын искәртә. Тәлгат Галиуллин да «Бизәкләр төрлелеге» дигән мәкаләсендә («Казан утлары», 1981 ел, 6 нчы сан) Равил Фәйзуллин шигырьләрендә рационалистик фикернең еш кына тойгы, хисне тарайтуга китерүен кисәтә, М. Әгъләмовның кайчак «үзәге табылмаган, мәгънәсе ачылмаган» шигырьләр язуын әйтә.

Кызганычка каршы, әдәби тәнкыйть үзе дә хатадан хали түгел. Сүз барыбыз өчен дә диярлек уртак кимчелекләр турында бара.

Без, тәнкыйтьчеләр, язучылардан әсәрләрендә дәлил, мотив чынлыгын таләп итеп бик дөрес эшлибез. Ләкин дәлилнең мәҗбүриятлеге һәм ышандыручанлыгы (ә безнең өлкәдә — фәннилеге) тәнкыйтьчеләргә дә кагылырга тиешле таләп бит. Газета-журналларда басыла торган әдәби тәнкыйть хезмәтләренең иң типик кимчелеге итеп мин дәлилсезлекне санар идем. Дәлилсезлекнең иң таралган формасы — теләсә нинди тезисны әйтү белән чикләнү.

«Бүгенге заманның югары интеллектлы укучысы сүз художнигының акыл һәм хис көчен чагылдырган кыска шигырьләрне юксына башлады»,— дип яза, мәсәлән, «Сүзне олылау» мәкаләсендә Зиннур Мансуров. Бу юлларны уку белән сорау бирәсе килә. Каян белә соң автор югары интеллектлы укучының ни теләгәнен? Кемнәр соң алар — «югары интеллектлы» укучылар? Ә бит шундый һавалы сүзләр Равил Фәйзуллин миниатюраларын мактау өчен генә кирәк. Р. Фәйзуллин әсәрләренә бәя бирү безнең максатка керми. Сүз бу әсәрләргә багышланган тәнкыйть әсәрләренең пафостан уза алмаулары турында гына бара.

«Бу шигырь — бөтен дөньяның катлаулы тарихы һәм катлаулы бүгенгесе турында»,— дип яза Бикә Рәхимова. Бөтен дөньяны берүзе иңләгән һәм башкаларга тема да калдырмаган шигырь Фәннур Сафинныкы.

«Чорның эстетик фәлсәфи тәҗрибәсе нигезендә ул проблемаларга яңадан-яңа төсмерләр өсти. Бу исә аның иҗатында бербөтен үсеш процессы тудыра, шигырьләрнең логик эзлеклелеген көчәйтә»,— дип яза яшь тәнкыйтьче Хәкимҗан Янов. «Чорның эстетик фәлсәфи тәҗрибәсе»н туплауга мисал итеп мондый юллар китерелә:

> **Юләр икәнсең, Ниса,**
> **Аңлар идең ичмаса.**
> **Мәктәбебез чын булмый ич**
> **Күчерүче булмаса.**

Шигырь авторы Резеда Вәлиева үзе дә мондый мактауга шат булмагандыр.

Тезиска дәлил рәвешендә мисал китереп котылу шулай ук шактый киң таралган. Яшерен-батырын түгел — анализсыз, аңлатусыз китерелгән мисалларны адым саен очратабыз. Хәтта кайбер фәнни мәкаләләребез дә эчтәлеге сөйләп чыгылган мисаллар җыелмасын хәтерләтә башлый.

Әдәби әсәрләрне хис һәм фикер нисбәте ягыннан анализлау — бик кирәкле эш. Хис белән фикерләүне янәшә кую белән үк шул күренешләрне өйрәнүче фәннәрне әдәбият белеме белән янәшә күрәсе килә башлый.

Без шагыйрьләребезнең капма-каршы ике төркемгә бүленүләрен күптәннән язабыз. Аларның бертөрләре чынбарлыкка фикер «стихиясе» белән килә, икенчеләре чынбарлыкны хис белән кабул итәләр. Беренчеләре «интеллектуаль» дип аталалар, икенчеләре я «лириклар», я традицион юлны яклаучылар, дип йөртеләләр. Мондый бүленешнең дөрес булуы да мөмкин... Ләкин эш бүлеп кую белән генә бетми. Бу юнәлештәге тикшерүнең дәвамы да сорала. Хәзергә исә бу өлкәдә тирәнрәк керүгә омтылу шул ук фикерне төрлечә кабатлаудан узмый: берәүләр тормышка фәлсәфи караш белән киләләр дә хис стихиясенә чумалар, икенчеләре, киресенчә, хис белән тормышны кабул итеп, фикер белән аннан соң эш итә башлыйлар. Фикер белән хис шундый бәйләнешләргә кертелә ки, кайсы алдан, кайсы арттан килә икәнлеген аермый да башлыйсың.

Тәлгат Галиуллин язуынча, Роберт Миңнуллин «табигать хозурлыгы белән кеше характеры, холкы, аның кичерешләре арасында якынлык эзли». Рәшит Әхмәтҗанов, аңардан аермалы буларак, табигый матурлык белән сәнгать арасында эчке якынлыкка» омтыла.

Ә Муса Җәлил? Т. Галиуллин үзенең «Дыхание времени» китабында язганча, ул да «ищет в природе родной страны качества, отражающие стремления человека к красоте и гармонии...» (210 б.)

Чыннан да, бездә шагыйрьләр шулкадәр күбәеп китте ки, хәзер алар өчен әзер такъбирләр дә җитми башлады...

Фәннур Сафин, Б. Рәхимова язуынча, «фәлсәфи тирәнлеккә чакыра». Роза Хәлиуллина да «фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый» (Л. Хәйдәрова рецензиясендә). Шулай итеп, фәлсәфилек барлык шагыйрьләргә дә хас сыйфатка әйләнә.

Фикер һәм эмоция ягыннан әсәргә анализ ясау, кабатлап әйтик, иҗат принципларын билгеләүче үзәк мәсьәләләрнең берсе. Шуңа күрә ул моннан соң да тикшерү объекты булуыннан туктамасын иде. Ләкин бу теманы үстерү өчен «интеллектуальлек», «фәлсәфи фикер» кебек бергә кушып йөртелә торган төшенчәләрнең эчтәлеген аныграк белү шарт.

«Интеллектуальлек»не гадәттә шагыйрьнең әсәренә салган рационалистик фикердән эзлибез. Язучы гадәти хәлләрне югары сфералар белән бәйләп карый икән, әйтәсен әйтеп бетерә икән, ул бик нечкәләп, тирәннән, катлаулы итеп уйлый белүче дип исәпләнә. Ләкин бу юл белән барып, без язучыга бәя бирү ысулын артык гадиләштермибез микән?

Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә бик чирле һәм бик тә яшәргә теләгән гармунчы егет бар. Менә алар күк капусы ачылганда Гомәр белән бергәләп сәламәтлек ялварырга ашыгалар. Чирле егетнең теләге кабул булсын өчен, аның саулыгын теләп, Гомәр дә ялварырга сүз бирә. Гармунчы тиз бара алмый,

артта кала. Шул чакны ул Гомәрнең ыштаны ертык икәнлеген күреп ала. Һәм күк капусы ачылганда үзенә яңа ыштан да сорап өлгерүен үтенә. Шулай итеп, әсәрдә кыршылган ыштан белән үз гомере авыру егетнең намус бизмәненә салына. Кешелеклелек үлемнән өстен булып чыга.

Гомәр ага бу вакыйганы үзенчә гади һәм тыйнак итеп сөйли. Өстәп тырнак очы кадәр генә дә фәлсәфә кормый. Ул аны кирәк дип тә санамый. Чын сәнгать остасы өчен фәлсәфи фикер сурәтләнгән вакыйгалардан үзе һичшиксез чыгарга тиешле нәтиҗә икәнлеген яхшы белә. Фикерне, фәлсәфиме ул, башка төрлеме, укучы үзе, әсәр эчендәге сурәтләр логикасыннан чыгып таба. Гомәр ага башкаларның да фикерләү дәрәҗәсе югарылыгына ягъни интеллектуальлегенә ышана, шуңа күрә яшәеш һәм үлем, яхшылык һәм начарлык, табыш һәм югалтулар бәйләнешен, зур фәлсәфи фикерләрне ике малай мөнәсәбәтеннән табуны укучының үзенә тапшыра.

Илдар Юзеевның «Онытылмас бәет» исемле пьесасында авылдашларын, хатынын алдап качкан шаян егет күп еллардан соң баеп, ләкин картаеп кайта. Баласына ата кеше булуын раслатыр өчен, халыктан үзен тануларын үтенә. Ләкин авылдашлары өчен ул хәзер юк кеше. Качкын карт яшь чагындагы кебек биеп, җырлап күрсәтә. Шаян җырын ул элеккегечә елмаеп, көлеп, шаярып җырларга мәҗбүр. Карт елмая да, елый да. Ләкин авылдашлары аның ышанычын акламыйлар. Танымыйлар. Алдыйлар. Бу алдауның әхлакый яктан акланган фәлсәфи нигезен Илдар Юзеев шулай ук үзе сөйләп бирми. Ул да тамашачысының интеллектуаль яктан югары дәрәҗәдә булуына ышана.

Мисаллардан күренгәнчә, интеллектуальлек әсәрдә турыдан-туры әйтелгән зур фикер рәвешендә генә ятмый. Аның тагын да нечкәрәк, куәтлерәк формасы фәлсәфи фикерне нәтиҗә рәвешендә, эзлекле логик агыш рәвешендә табуны әзерләп куюда икән. Әсәрләрдә ярылып яткан рационализмга гына игътибар итеп, татар әдәбиятының тарихи традициясен генә түгел, бүгенге зур уңышларыбызны да күрми үтүебез бар.

Әдәбиятны фольклор һәм милли традицияләр белән бәйләү проблемасы да тәнкыйть мәкаләләрендә хаклы рәвештә күп мәртәбәләр күтәрелә. Халык иҗаты белән бүгенге әдәбият бәйләнешен без әле һаман һәр икесе арасында, дөресрәге, әдәби әсәрдә фольклорга тышкы охшашлык эзләү белән чикләнәбез. Җырларда, мәсәлән, психологик параллелизм дип аталган поэтик алым бар. Ул үзенең төрле күренешләре белән, барлык шагыйрьләргә дә хас, универсаль алым. Шулай булгач, аны аерым язучыларда табу, бу чәчәкнең яфрагы бар, дип исбат иткән кебек, билгеле нәрсәне кабатлау булыр иде.

Фатих Урманчеевның «Дастаннарга лаек замана» исемле хезмәте тиешле фәнни югарылыкта язылган. Хәтта фәнни тикшерү ысулларын бик яхшы белгән Ф. Урманчеев та күбебезгә хас чирдән котыла алмаган. Фольклорга якын диген нәтиҗә чыгару өчен, аңарга нибары бер шигырьдә «дастан» дигән сүзне очрату җиткән.

Газета-журнал битләрендә актуаль мәсьәләләр күтәргән, җитди тема рәвешендә куелган, берьюлы берничә язучы әсәренә караган мәкаләләр да шактый күп басыла. Аларны яхшырту мөмкинлекләре бармы әле? Бар дип уйлыйм. Потенциаль үсеш мөмкинлеген мин, мәсәлән, бер типик кимчелектән котылуда күрәм. Ул проблеманың, яки тезисның куелышына карый. Без аны еш кына материалның үзеннән чыгарасы урында укучыга әзер көе, мәҗбүри тагабыз. «ФТР заманында фәлән-фәлән алга сөрелә», «хәзер үзәк матбугатта фәлән тема беренче планга куела», «таләп ителә», «тиеш», «мәҗбүри» кебек сүзтәләр һичнинди бәхәскә дә, дәлилгә да урын калдырмыйлар. Шул рәвешле тезис бирелә, ә татар әдәбияты күренешләре шул тезис калыбына сыйдырыла.

Дворецкийның «Человек со стороны» пьесасын Татар дәүләт академия театры сәхнәгә куйгач, андагы төп герой Чешковка безнең матбугатта бик тә кире бәя бирелде. Ул антигерой дәрәҗәсенә җиткерелеп юкка чыгарылды. Әле да онытмыйм, без аны бер дә юкка, йомырка карагын суккән карчыклардай пыр туздырдык. Ни өчен? Булдыксыз кешеләргә карата йомшак булмаганы өчен. Әлбәттә, аны уратып алган кешеләрнең шундый сыйфатларын телгә алмадык. Ә ни өчен шулай иттек? Чөнки кайбер үзәк газеталарда кайбер авторлар Чешковны шул ук «җитешсезлеге» өчен туздырганнар иде.

Хәзер шул ук авторлар Чешковны, урланган йомырканы табып кергән күршедәй, күкләргә күтәреп мактыйлар. Ни өчен? Үзәк матбугатта «эшлекле кеше»не ныклап мактый башладылар. Без бу тезисны да хакыйкать итеп кабул иттек. Кайбер тәнкыйтьчеләрнең кайбер тезисларын фәннең соңгы сүзе итеп башкаларга да тәкъдим итә башласак, шундый көлке хәлләргә төшүеңне көт тә тор.

Без, тәнкыйтьчеләр, язучыларны тормыш эченә керергә чакырабыз. Тормыш байлыгы язучы өчен, беренче чиратта, кеше мөнәсәбәтләренең бик катлаулы яклары һәм төрлелеге ул. Анда кешеләрнең социаль яклары да, социаль-психологик мөнәсәбәтләре дә, фикер-бәхәсләре дә, кичерешләре дә керә. Әгәр дә тәнкыйтьче язучы иҗатын гомумиләштереп күзалларга, анализларга тиеш, дисәк, тормышның бу якларын өйрәнүче фәннәрне һичшиксез белергә тиешбез. Философияне дә, социология, логика, психология һ. б. фәннәрне чынлап торып үзләштерми, әсәрдә чагылдырган шул күренешләр турында нәрсә сөйләргә мөмкин? Аерым әсәрләргә карата шактый урынсыз кулланыла торган «интеллектуаль» сүзен мин әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләргә кирәкле мәҗбүри сыйфат дияр идем. Уңай үрнәк эзләп ерак барасы түгел. Хатип Госман, Гали Халит, Йолдыз Нигъмәтуллина, Нил Юзиевларның иҗатын белгән кеше, аларның татар, рус, чит ил әдәбияты тарихы белән бергә күп фәннәрнең соңгы казанышларын да үзләштерүләрен сизеп сокланмый калмый.

Сүз ахырында Рафаэль Мостафинның «ЭВМ ни әйтер» исемле мәкаләсенә тукталасым килә. Мәгълүмат бирү рәвешендә язылган бу хезмәт, укыгач, кызыклы нәтиҗәләргә китерә. ЭВМ Муса Җәлил иҗатына карата хәтта Рафаэль Мостафин кебек танылган тәнкыйтьче тәкъдим иткән үзенчәлекләрнең дә шактыен кирәксезгә чыгара. Ул субъектив нәтиҗәләрне һәм һәркемгә хас гомуми сыйфатларны гомумән кыйммәтле информация дип исәпләми. Шигырьләрдән объектив чыгарылган сыйфат күрсәткечләрен таләп итә. Миңа калса, бу эшкә хәтта тәнкыйтьче үзе дә хәйран калган кебек күренә.

Машина як-якка каранып тормый, турыдан ярып, фәннилек таләп итә. Мәкаләдә шул фикер, әйтелмәсә дә, ярылып ята. Аңа кушылмый мөмкин түгел.

# ШИГЫРЬ ЯЗАРГА ӨЙРӘТӘМ...

Мәскәүдә әдәбият институты каршындагы Югары курсларда укыганда, бүлмәмә күршем Зөлфәт килеп керде. Чәчләре тузган, зәп-зәңгәр күзләре Парнас тавының иң текә кыясына кунган бөркет күзләре сыман яна, ике кулы давылда бәеннән ычкынган тегермән канатлары шикелле болгана,— димәк, шигырь язган һәм шатлыгын минем белән уртаклашырга тели.

Шулай булып чыкты да. Тотынды укырга шигырен — егерме квадрат метрлы бүлмә тараеп, кечерәеп калды. Сыймый шагыйрьнең хисләре бүлмәгә, аңа киңлек кирәк, аңа, авызлыкларын чәйнәп, иксез-чиксез дала буйлап чабарга кирәк, атмосфера катламын тишеп чыгып, галәмгә очарга, Сатурнның кыршавына басып Андромеда йолдызлыгына сикерергә, аннан яңадан планетабызга кайтып, Тын океанга чумарга, андагы берәр кашалотны кочаклап үбеп, ярга чыгарга да, аякларын-кулларын җирдәге материклар өстенә салып, татлы, илаһи йокыга талырга кирәк. Күңеленнән шулай эшләде дә Зөлфәт. Укып бетергәч, юашланып, ишек яңагына сөялде, гөнаһсыз күзләрен миңа текәп, сүзсез калды.

Мин нишләргә тиеш идем? Әлбәттә, шигырь тәэсиренә бирелеп әсәрләнергә һәм:

— Гениально! — дип кычкырырга тиеш идем.

Бу моментта шагыйрьнең күңеле белән бик сак булырга кирәк. Чөнки мондый чакларда шагыйрь (һәм, гомумән, һәр иҗат кешесенең) йөрәге ачылып шәп-шәрә кала, ул тиз яралана, ул яраны төзәтүе авыр була.

Ходаның биргәненә шөкер, тупаслык бездә җитәрлек инде:

— Аңламадым,— дидем.

Миннән мондый мәгънәсез һәм рәхимсез сүз көтмәгән Зөлфәт аптырап миңа карап торды.

— Шигыреңнең нәрсә турында икәнен аңламадым,— дип кабатладым.

Башын артка чөйде Зөлфәт, уң кулын югарыга ыргытты һәм:

— Шигырь нәрсә турында була аламыни! Поэзия бит ул нәрсә турында була алмый! Шигырь ул шигырь!..— дип, ишекне ачык калдырып чыгып китте.

Гафу үтендем микән, хәтерләмим. Юк шикелле. Чөнки «Шигырь нәрсә турында була аламыни!» дигән сүзе белән ул мине наданлыкта, примитивлыкта гаепләгән сыман тоелды. Мин ул вакытта да, хәзер дә әдәбиятның һәрбер жанры нәрсә турындадыр булырга тиеш дип саныйм.

Берничә көннән бу хакта Зөлфәт белән кара-каршы утырып бәхәсләштек. Ул рәхәтләнеп миннән көлде, мин бирешмәдем. Хәтта мин аны шигырь язарга да өйрәтергә керештем.

— Әгәр дә,— дидем, — илһам килеп, шигырь язарга утырсаң, иң элек, язачак шигыреңдәге фикерне проза белән, ягъни мәсәлән, салкын акыл белән кәгазьгә теркәп куй. Аннан эшкә йөрәгеңне, хисләреңне җик. Менә дигән аңлаешлы шигырь туачак,— дидем.

Идәнгә ятып, тәгәри-тәгәри көлде Зөлфәт. Шигырь турында сүз чыкса, әле дә шул вакыйганы сөйләп көлә. Мин дә аңа кушылып көлгән булам, ләкин күңелемнең кайсыдыр бер җирендә «ә бит мин ул хәтле үк хаксыз түгел» дигән уй ята.

Әлбәттә, мин «өйрәткәнчә» шигырь язу мөмкин түгел хәл, ул чыннан да көлке. Кызганычка каршы, бездә проза теле белән сөйләп бирерлек шигырьләр күренгәләп тора. Рифмага салынган прозаны мин шигырьгә, андый шигырьләр язучыны шагыйрьгә санамыйм. Поэзиядәге образлар системасы бөтенләй башка икәнен бүтәннәргә

аңлата алмасам да, үзем аңлыйм. Шигырь ул күңелдә уйнаган хисләр давылының тышка бәреп чыгуыннан туган әдәбият жанрыдыр.

Ләкин ни генә булмасын, минемчә, шигырь аңлашылырга тиеш. Әгәр дә ул аңлашылмаса, икенче берәүгә тәэсир итә алмый. Аннан соң, дөньяда һәрбер нәрсәдә, һәр хәрәкәттә логика бар. Хәтта стихиядә дә. Без хаос дип санаган нәрсәләрдә дә үзенең логикасы ята. Ни өчен шигырьдә шул жанрга гына хас логика булмаска тиеш? Әгәр логика бар икән, димәк ул күпләргә аңлашылырга тиеш. Билгеле, шигырьнең тәмен тояр өчен күпмедер дәрәҗәдә әзерлек тә кирәктер. Ләкин мин һәм башка бик күпләр — кулына китап тотып карамаган томана түгел ләбаса. Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Хәсән Туфан кебек үзебезнең классикларны да, башка халыкларның поэзиясеннән дә хәбәрдар, хәзерге заман шагыйрьләрен дә аңларга тырышкан кеше.

Шушы урынга хәтле язганнарым кереш сүз генә иде. Минем әйтергә теләгән фикерләрем конкрет шигырь турында. «Казан утлары»ның 1982 елгы 11 санында Казан дәүләт университеты студенты Ркаил Зәйдуллинның дүрт шигыре басылып чыккан. Яратам мин бу малайның шигырьләрен, өметем зур ул егеткә. Мин аңарда иҗат кешеләренә иң кирәкле сыйфат — тынгысызлыкны күрәм. Җаны тынгысыз аның, яшьлеккә хас бунтарьлыгы да бар. Бик әйбәт. Яшь чакта да бунтарьланмагач, картайгач ни кала?! Мыштым гына каш астыннан карап йөргән малайлардан куркам мин. Чаттан торып берәр этлек эшләп, җанны өшетерләр сыман. Әдәбият ачык йөрәкле (душа нараспашку) затларны яратарак төшә.

Димәк, Ркаилның дүрт шигыре. Баштагы өч шигыренә бер сүзем юк. Кәҗүнни тел белән әйткәндә, кайбер җитешсезлекләре булуга карамастан, әйбәт, йөрәккә, күңелгә һәм акылга да тәэсир итә торган шигырьләр. Менә дүртенчесен аңламадым. Ркаилның үзенә шул турыда әйткән идем дә, заманында Зөлфәт миңа караган сыман карады. Өлкән кешенең хәтерен саклап, миңа надан, дип әйтмәде әйтүен, әмма елмаеп каравында шундыйрак теләк ята иде кебек.

Менә хәзер журналны алдыма куйдым да Ркаилның шигырен аңларга тырышып утырам. Аның өчен мин, Зөлфәт көлсә көләр, Ркаил шигырен сүтеп җыярга телим. Чын шигырьне сүтеп җыярга мөмкин икәнлегенә ышанып эшлим бу эшне.

Иң элек, сүтәр алдыннан Ркаилның шигырен тулысынча күчереп алыйк.

**Кырмыска оясына кулны тыздым.**
**Кырмыскалар учым буйлап йөгереп узды.**
**Гөжләп куйды бөтен бер ил.**

**«Кем ул анда тынычлыкны бозып йөри!»**
**Җанны асраганда, мәгънә күреп**
**Кыса эчендәге яшәештән!**
**[Бөтен бер ил карап тормый булыр**
**Ярдәм көтеп табигатьтән, өстән.]**

**Һәрбер нәрсә канунлашкан монда,**
**Һәркемнең үз эше үз йортында.**
**Мөмкин кадәр тизрәк,**
**Мөмкин кадәр күбрәк кутәрәсе.**

**Юк монда моң төшенчәсе!**
**Яшәү өчен яшерен көрәш бара,**
**Куәтсезләр бөлә, куәтсезләр үлә...**
**...Никтер шушы кырмыска оясын**
**Таяк тыгып болгатасы килә.**

Шигырь техникасына тыгылмыйм — мин аны тикшерүне бу очракта максат итеп куймадым. Теленә дә кагылмыйм. Гәрчә, кырмыска иленең гөжләвен мин күз алдыма китерә алмыйм. Шөпшәләр иле, умарта кортлары иле гөжләгәнен ишеткәнем бар, кырмыска иленең гөжләгәнен ишеткәнем юк. Бәлки минем колак ишетеп бетермидер, шагыйрь колагы сизгеррәк буладыр? Ярый, анысын калдырып торыйк та, мәгънә ягына күчик.

Беренче өч юл миңа аңлашыла. Дөнья, мохит, яшәеш турында уйланып, шагыйрь урманга килеп керде, ди. Төрле бөҗәкләрне күрде дә, аларның көн итүен безнең

көн итүебез белән чагыштырып, ниндидер уртаклык яки аерма эзләргә керешә, ди. Менә кырмыска оясы. Бер ил. Үзенә күрә «җәмгыять». Болар ничегрәк яшиләр икән дип, шагыйрь кырмыска оясына кулын сузды, ди. (Хәер, сузганга гына кырмыскалар уч буйлап йөгереп үтмәсләр, шагыйрь, күрәсең, кулын кырмыска оясының эченә үк тыгып алгандыр). Табигый, тик торганнан кемдер ояларына кул тыккан икән, илләренә кул сузган икән, кырмыскаларның: «Кем ул анда тынычлыкны бозып йөри?» — дип уйланырга, ачуланырга хаклары бар. Шигырьнең бу юлы да миңа аңлашыла. Ары киттек.

**Җанны асраганда, мәгънә күреп**
**Кыса эчендәге яшәештән!**

Нәрсә аңлата бу сүзләр? Кем әйтә болай дип? Кырмыскалар дисәң, җөмлә куштырнаклар эченә алынмаган. Шагыйрь кырмыскалар өчен сөйләргә керешәме? Булуы бик мөмкин, анысын да кабул иттек, ди. Ә менә җәя эчендәге сүзләрне һич кенә дә аңлый алмыйм. Нинди фәлсәфә ята анда, нинди мәгънә? Хәтта мин ул турыда фараз кылырга да алына алмыйм. Я берәр ахмаклык әйтеп ташлармын дип куркам.

Җәя ябылды. Аннан соңгы дүрт юл аңлашыла. Шагыйрь уйланулардан соң бер нәтиҗәгә килә. Нәтиҗәсе дөрес — кырмыскалар үз илендә барысы да аерым бер тәртип белән көн итәләр. Ләкин табигать кануннары буенча, инстинкт кушканча яши бирәләр. «Һәркемнең үз эше үз йортында». Нишлисең, табигать шулай яраткан: кырмыска көн-төн чабарга, бала үстерергә, тамак туйдырырга, өен кул тыгып уйнаучылардан сакларга тиеш. Җитмәсә, агачларны корт баскан, аларны юк итеп, урманны саклап калу эше дә табигать тарафыннан кырмыскаларга йөкләтелгән...

«Юк монда моң төшенчәсе!»

Монда инде, Ркаил йөрәк маем, гафу ит, мин сиңа бер сорау бирәм: каян беләсең? Бәлки алар үз телләрендә көйләр көйләп моңланалардыр? Синең «гөжләү» дигәнең бәлки аларның кычкырып җылауларыдыр? Бәлки алар ап-ак биләүләргә төрелгән балаларына: «бәгырькәем, үсеп буйга җитәрсең, агачларны корытучы кортларны юк итәрсең» дип көйлиләрдер. Эшкә киткәннәрнең кайберләре кайтмый калса, моңланып, бәет чыгаралардыр? Ашыкмыйк моң юк дигән нәтиҗә чыгарырга.

Моннан соңгы ике юл аннан алдагы дүрт юлның дәвамы буларак аңлашыла. Ләкин монда да тел төгәлсезлеге. Куәтсез кырмыскаларның үлүләре аңлашыла, ә бөлүләре ничегрәк? Бәлки, син кырмыскаларны онытып кешеләргә күчкәнсең? Иртәрәк түгелме? Буталдың түгелме?

Ә инде кырмыска оясына таяк тыгып болгатырга теләвең — монысы инде, Ркаил дус, хулиганлык. Каян килде әле синең башыңа андый миһербансыз фикер? Кырмыска оясының, ягъни кырмыскаларның ни гаепләре бар синең алда? Ни начарлык эшләделәр алар сиңа? Ояларына кулыңны тыккач, тешләделәрме? Соң, җаным, теләсә кая кул тыгып йөрмә. Бәлки син аю яки арслан авызына кулыңны тыгарсың да, аннан бөтен җәнлекләрне үтереп бетерәсем килә дип шигырь язарсың. Болай мыскыл итебрәк язганга үпкәләмә, шаяртам гына. Беләм, синең кырмыскаларда үчең юк. Син бары тик аңлашылмый торган шигырь генә язгансың. Бәлки синең теләгең дә изгедер, күңелең яхшылыктадыр: үз кабыгына бикләнеп, бүтәннәрнең шатлыгын-кайгысын күрмичә һәм күрергә теләмичә үз мәнфәгатьләре өчен генә яшәүче, бүтәннәрдән алда мөмкин кадәр тизрәк, мөмкин кадәр күбрәк умырып калырга җыенучы моңсыз, гамьсез бәндәләргә каршы йөрәгеңдә давыл кузгалгандыр. Каның уйнаганга чыдаша алмыйча шигырь язгансың син. Әмма, шул хисләреңне безгә сөйләгәндә, кызып китеп буталгансың, кешеләрнең яшәү законнары белән кырмыскаларның яшәеш формаларын аерып җиткермәгәнсең. Параллель куярга ярамаган нәрсәләрне параллель куйгансың. Ягъни образны дөрес сайламагансың. Шуңа да шигырь аңлашылмый. Аны сүткәчтен җыеп булмый. Мондый чакта инде, чыннан да, фикереңне башта проза белән язып кара, дигән ахмак киңәш бирәсе килә.

Сүзем шушы урында бетте. Ләкин нәрсәнедер әйтеп җиткермәдем төсле. Бәлки шигърият бакчасына кереп болганып йөрүем өчен шагыйрьләрдән гафу үтенергә телимдер. Нишлим, шигъриятькә гашыйк мин. Гашыйк кеше үзенең яратканын һәрьяклап камил итеп күрергә омтыла. Шуңа күрә мин дә шигырь язарга өйрәтеп азапланам. Ялгыш сүзләр ычкындырган булсам, гафу итегез, Парнас бөркетләре.

ТМИН.

Диас Вәлиев

# ДИОГЕН ФОНАРЕ

Кешенең явызлык яки, киресенчә, яхшылык хакына кылган һәр гамәле, эше күп төрле сәбәпләр һәм шартлар җыелмасыннан гыйбарәт. Ләкин шулай да эшнең үзәгендә шәхес мәсьәләсе торадыр, мөгаен. Кем син, кеше? Нәрсәгә сәләтле син? Яшәвеңнең мәгънәсе нәрсәдә? Вакыйгалар агышын үзгәртергә, көтелмәгән кыен хәлләрне аралап — җиңеп чыгарга көчең җитәрлекме, әллә боларның берсе дә синнән бәйле түгелме? Һәм иң мөһиме: җиңүчеме син, әллә җирдән шуышучы суалчан гынамы? Тормыш ул — туктаусыз үсеш, ә бу үсешнең һәр мизгеле — көрәш. Шул ук көрәштә сынатмаслык чамаң, рухи ныклыгың бармы?

Кешегә, кешенең асылына карата булган теге яки бу концепция — бер үк вакытта тормышка, киләчәккә карата булган караш та ул. Әнә шул күзлектән карап фикер йөрткәндә, кешенең теләсә нинди хәрәкәте, эш-гамәле, шул җөмләдән әдипнең язган һәрбер юлы ахыр чиктә барыбер киләчәк көн өчен эшләүче сәяси хәрәкәт булып санала. Егерменче гасырның соңгы чирегендә тормыш һәм үлем белән «уйнау» өчен кешегә куелган шартлар әнә шундый. Җир шарындагы хәрәкәт бер яктан тынычлыкны, тормышны, гуманизмны яклаучы, икенче яктан аны буарга омтылучы көчләр арасындагы чик сызыгы теге яки бу дәүләт чиге буйлап кына түгел, иң әүвәл кеше йөрәге аша уза. Шуңа күрә, табигый ки, бүгенге кеше политикадан бер генә карыш та читтә тора алмый. Безнең заманда битараф вакыйгалар, нейтраль эшләр юк. Талантсыз язылган әсәрләрне, мәсәлән, битараф дип әйтеп буламыни?! Һич юк! Алар искиткеч зур зыян китерәләр, кешелекне артка сөйриләр. Телибезме без моны, теләмибезме, үзебезгә хисап бирәбезме, юкмы — әмма гомеребезнең һәр мизгелендә без дөньяны чолгап алган бөек көрәштә катнашучылар булып исәпләнәбез. Шулай дип уйлыйбыз икән, димәк, газета битләрендә басыла торган йөзләрчә эре һәм вак хәбәрләр дөнья тормышындагы күп санлы сәяси күренешләрнең аерым өземтәләре генә түгел, ә бәлки андагы искиткеч куәтле процессларның якты чагылышы да. Һәм бу хәрәкәт мәйданы бөтен җир шары, икенче төрле итеп әйткәндә, кешене чолгап алган мохит белән генә чикләнми, аның эчке дөньясын — рухын да биләп ала. Алай гына да түгел, кеше рухы хәлиткеч көрәш кырына әверелә.

Кеше рухы...

Дөнья сәнгатендә мин аның өч төрле сурәт-портретын күрәм. Китап битләреннән, рәссамнар иҗат иткән сурәтләрдән кешеләрнең үзләре һәм аларның рухлары өч төрле типта булып күз алдына килеп баса. Бу өч төрле тип гүя тормышның үзен гәүдәләндерә.

Атеистик әдәбиятта кайчагында «мәхәлләдәшләр» («примыкающие прихожане») дигән сүз очрый. Болар гадәттә дин белән кызыксынмаучы, алай гына да түгел, аңа карата кире мөнәсәбәттә торучы кешеләр. Ләкин шуңа да карамастан, бу аларга табыну, никах уку һәм, гомумән, башка шундый төрле дини йолаларны башкаруда катнашырга комачауламый. Андый тип дөньяны, көндәлек «литургия»ләрне дә шундый ук осталык белән башкарырга сәләтле. Һәм ул аларны алдан күнегеп куйган ниндидер җитез хәрәкәтләр ярдәмендә башкара да. Әйе, бу — мәхәлләдәшләрчә яшәә

атлап барырга өйрәнгән кеше тибы. Аның ярты өлеше һәрвакыт юл чатында. Әйтерсең ул берникадәр уйга чумып калган һәм тышкы яктан этәреп җибәрүне генә көтә. Андый кеше теге яки бу микрошартлар калыбының тонык бер күчермәсен хәтерләтә. Аның өчен тормышта үзенең матдилегеннән, физик яктан исән булуыннан тыш башка бер генә кадерле нәрсә дә юк. Шуңа күрә ул — барлык диннәрнең һәм барлык модаларның тырышып-тырышып табынучысы. Ул бөтен нәрсәгә хезмәт итә, яхшылыкка кушылган кебек яманлыкка да шул ук дәрәҗәдә кушыла ала һәм, шартлар үзгәрүгә карап, тегесенә дә, монысына да бик җиңел хыянәт итә. Төшенчәләр берберләренә соңгы чиккәчә капма-каршы булганда да, бу тип өчен моның берниндн аермасы юк. Аның янында яхшы эшлиләр икән, ул да яхшы эшләргә тырыша. Әгәр аракы эчсәләр, ул да эчә. Кемнең дә булса кул-аякларын тәрегә кадаклыйлар икән, ул да кадаклаша.

Бертольд Брехтның «Теге солдат ни дә, бу солдат ни» дигән пьесасында менә мондый диалог бар:

— Әгәр без аны солдат Джерайа Джинга әверелдерсәк, ул моңа ничек карар икән?

— Андыйлар теләсә нәрсәгә әверелә алалар. Буага ыргытсаң, ике көннән соң аның бармаклары арасында йөзү ярылары үсеп чыкканлыгын күрерсең.

Һәм үсеп чыгачак та. Чөнки ул — «яңәшә атлаучы бөтендөнья гражданины», аның берninди катлавы, берниnди сыйныфы юк. Аның уенда бары тик нинди дә булса файда алу һәм башкалардан өстен булу. Анда шәхес дигән нәрсәнең эзе дә калмаган, бөтенләйгә эреп юкка чыккан, аны үз-үзен саклап калу инстинкты алыштырган. «Миңа сезнең берниnди шәхесегез дә кирәкми, миңа бары тик яшәвем кирәк, шәхес булып яшимме, юкмы — минем өчен барыбер. Әйе, мин — теләсә нинди сүзне, теләсә нинди фикерне җиңел язып була торган кара такта»,— ул әнә шулай дип фикер йөртә. Ә ул такта үзенә барлык сыйфатларны — яхшылыкны һәм яманлыкны, инануны һәм өметсезлекне аңлата торган тамгаларны сыйдыра. Тормыштагы хәлләрнең үзгәрүенә карап ул тамгаларның берсен икенчесе белән бик җиңел алыштырып була.

Кызыклы тип, әмма куркыныч тип. Егерменче гасырда кешелек кавеменең өлешчә шактый зур тизлек белән түбәнлеккә төшә баруы — утызынчы елларда герман рухының фашистлашуы, җитмешенче елларда Чили феномены, бүгенге көндә америка аңының милитаризацияләнүе җирдә менә шушы типның яшәве белән бәйләнмәгәнме икән? Чыннан да, бу тип кешесе әлеге трагедияләрнең төп башкаручысы түгелмени? Ләкин, кабатлап әйтәм, шартлар үзгәргәндә, ул шундый ук осталык белән характеры ягыннан нәкъ капма-каршы булган рольне, ягъни уңай рольне дә уйнарга сәләтле. Шундый типны Горький үзенең «Клим Самгинның тормышы»нда искиткеч зур осталык белән сурәтләде. Социаль тормыштан бөтенләй читтә торган, әмма теләсә нинди партиягә сыланып, бик ансат «социальләшә» алган йөзе... Бөек язучы сакланырга кушып калдырган васыятьләрнең берсе, минемчә, әнә шуннан гыйбарәт.

Беллетристика һәм драматургия бу кеше хакында күп яза, әйе, аның турында күп язарга яраталар. Ләкин ул кигән битлек астыннан, ул ихласланып уйнаган роль артыннан художник аның чын йөзен һәр очракта да күреп бетерәме? Монда мимикриягә сәләтлелек коточкыч! Бу кеше икейөзле Янус түгел. Ул Янусны да алдар, чөнки күпйөзле ул, хәтта санап чигенә чыга алмаслык күпйөзле. Һәм менә шуңа күрә дә художникның аннан алданмавы искиткеч зур әһәмияткә ия. Ә художник үзе, кеше буларак, шушы ук типка охшаса... ул чагында нәрсә? Ул чагында художникның һәм аның героеның укучыны яки тамашачыны алдый алмавы кыйммәт. Микродөнья кешеләре рәтендәге мондый художник талантлы, хәтта бик-бик талантлы булырга мөмкин. Бу очракта инде ул үзенең микродөньясын бөтен Галәм моделе итеп күрсәтергә тырышачак. Чын сәнгать беркайчан да социаль һәм әхлакый ориентирлар турында онытмаган. Башкарылуы ягыннан бик үк начар булмаган әсәрләрдән аермасы да бәлки шундадыр аның. Хакыйкатьне һәм рух матурлыгын эзләүчеләр алдында ул ачкан капка һәрвакыт зур дөньяга алып чыккан.

Хәер, бу хакта соңыннан. Менә кешенең икенче портреты. Монда инде башка буяулар, рухның башка сурәте. Биредә инде шәхси максатлар, шәхси эгоизм социаль мәнфәгатькә, араларында ул кеше үзе яши торган даирәләр мәнфәгатенә талкырланган. Әгәр беренче тип кешесе һәрвакыт микрошартларның, ниндидер микродөнья-

ларның колы булса һәм үзенең йөзен, карашларын үзгәртсә, икенче тип кешесе, юк, микродөньяларда таянмый. Аның таянычы булып чынбарлыкның эрерәк өлешләре хезмәт итә: бөтен эшчәнлеге, бөтен рухи тормышы киңрәк колачтагы шартлар һәм вакыйгалар белән билгеләнә. Ул инде микродөнья түгел, ә макродөнья кешесе. Максатлары нәрсәдән гыйбарәт соң аның? Максатларны аңа вакыт үзе билгели. Ә эшләгән эше? Анысын да чор бирә. Әгәр галим икән, бу очракта ул фәннең бүгенге көндә нинди югарылыкта торуыннан чыгып эш итә. Ул дәвам итүче, әмма башлап җибәрүче түгел. Аның фәнни фикерләве, дөньяга карашы тарихи үсешнең шушы чорына характерлы булган билгеле бер гыйлемнәр җыелмасына нигезләнә. Әмма ул промышленность кешесе булса, аның да максатлары бөтен эшчәнлеге экономиканың шулай ук хәзерге вакыттагы торышы, халык хуҗалыгы үсешендә промышленностьның тоткан урыны һәм аның алдында торган бурычлар белән билгеләнә. Һәм, ниһаять, әгәр ул политик, яки, әйтик, шагыйрь икән, аның эшчәнлегенең киң колачлылыгын һәм эчтәлеген чор таләп иткән теге яки бу парламентлар билгели. Җыеп кына әйткәндә, бу типтагы кеше — вакытның ниндидер бер өлешендә Тарих кушкан йомышларны үтәүче. Ул тормыш-көнкүреш кешесе түгел, тарих кешесе. Аның адымының көче, ныклыгы, яшәвенең кирәклеге нәкъ менә шунда. Ләкин һәр нәрсәнең чиге була. Бу тип кешеләрә рәтенә кергән галим, табигать аңа нинди генә зур талант биргән булмасын, фәндә ул барыбер һичберниндин яңа революция дә, яңа ачыш та ясамаячак. Аның фикерләре бәйдә. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул фикерләрнең үсеше аерым бер фәнни масштабта гына бара. Ул бары тик шул масштаб чикләрендә генә ачыш ясый. Промышленность җитәкчесенең дә, әлеге типларның бер вәкиле булган шагыйрьнең дә эшчәнлекләре бер үк дәрәҗәдә чикләнгән. Аларның көче — үзләре яши торган тирәлекнең көчендә. Бу тирәлекнең милли, социаль, сыйнфый төшенчәләрне кулланып эш итәрлек шактый киң колачлы булуы да бик ихтимал. Ләкин ул төшенчәләр никадәр генә киң булмасын, алар барыбер чиксез түгел. Алар чикле, шуңа күрә үзләренең үсешләрен билгеле бер вакытка кадәр генә дәвам итәләр. Тарих кешесенең рухы, шулай итеп, чиста такта түгел, ә вакыт тарафыннан көчле символлар уелган такта булып чыга. Бу символларның, бу тамга-билгеләрнең төрлечә булулары мөмкин. Әмма алар һәрвакыт бар һәм икенче типтагы кешенең рухында һәрвакыт яши. Шуны да әйтергә кирәк, бу тамгалар аерым бер вакытныкы, аерым бер социаль-тарихи милли мохитныкы. Сыйнфый-милли кеше тибы катлаулы, аның модель-үрнәкләре күп төрле, рухы чорга береккән, я консерватив, я прогрессив тенденцияләре белән бербөтен булып аңа аерылгысыз бәйләнгән. Классик әдәбиятта без моның менә дигән үрнәкләрен күпме кирәк, шул кадәр таба алабыз. Ләкин монда да художникның социаль карашы үзенең әһәмиятен югалтмый. Монда да кешелекнең тарихи тормышын, сыйнфыйлыкны, тормыш сәхнәсендә уйнаучыларның билгеле бер социумга табынган булуларын чагылдырган көчләрнең капма-каршылыгын күрү өчен талант кирәк.

Һәм менә, ниһаять, өченче портрет. Мин тагын Горькийның исемен телгә алам. Бу кеше аның теоретик хезмәтләре битләреннән калкып чыга. Күрәсең, бу образ бөек язучының күңелендә уйлану, аңларга, төшенергә тырышу чорында тугандыр. Ул аны туктаусыз борчый, мәсьәләне чишүне таләп итә. Горькийның яңа рух масштабларына туры килерлек гомумиләштерелгән яңа формалар өлкәсендәге эзләнүләре, киләчәк социалистик сәнгатьнең үз алымнарын булдыру буенча эшләве, безнеңчә, нәкъ әнә шуның белән бәйләнгән. Кем ул өченче төргә кергән кеше? Үз-үзен чыннан да дөньяны үзгәртә алырлык көч дип танучы кеше үзе үк түгелме?

Әйе, ул — Җир планетасы кешесе, Галәм кешесе. Горький аны язып өлгермәде. Андый кешене язу — катлаулыдан-катлаулырак, чамадан тыш авыр эш. Дөнья әдәбияты гасырлар буена үткән юлга күз ташласаң, аның, гомумән, әнә шул биеклекне яуларга омтылганын күрәсең. Совет әдәбияты турында да шуны ук әйтергә кирәк. Бу өченче кешенең, күпкырлы кешенең, микродөньяда да, макродөньяда да түгел, ә мегодөньяда яшәүче кешенең гомуми кыяфәтен бик сирәк әсәрләрдә генә очратасың.

Сәнгать, кешенең фикерләү акты, тойгы, хәрәкәте кебек үк художникның субъектив дөньясы һәм объектив дөнья очрашкан ноктадыр ул, мөгаен. Шул күзлектән караганда, бүгенге дөнья сәнгате турындагы дәгъваларның нәтиҗәсен түбәндәгечә

билгеләргә мөмкиндер шикелле: кайчакта әле художникның субъектив дөньясы, туктаусыз катлаулана барган объектив чынбарлык белән чагыштырганда, чиктән тыш ярлы. Бу формула сәнгатьнең үсеш юлын да күрсәтә. Дөньяны эстетик үзләштерү — аны эмоциональ, турыдан-туры күзәтүләр, теркәп барулар ярдәмендә үзләштерү генә түгел, социаль, әхлакый һәм сәяси үзләштерү дә дигән сүз. Ә бу исә үзеңнең сәнгатьтә чагылыш тапкан «мин»еңне киңәйтүне, аны чынбарлык белән бертигез масштаблы итүне сорый.

К. Марксның «1844 елгы экономик-философик кульъязмалар»ында мена мондый юллар бар: «Хосусый милекчелек безне шул кадәр берьяклы итте ки, нинди дә булса әйбер, үзебез аңа ия булганда гына, ул безнеке булып исәпләнә...» Хосусый милекчелек бетерелгәннән соң гына кешенең барлык хисләре һәм тойгылары тулы азатлыкка ирешә, дип нәтиҗә ясый Маркс. Дөрестән дә, кеше үсешенең хәзерге чорында безнең субъектив «мин»ебезгә үзебез хуҗа булган нәрсәләр генә: тән-гәүдәбез, кулларыбыз, киемнәребез, йорт-җиребез, хәрәкәтләребез, уй-тойгыларыбыз, сыйнфый һәм милли горурлыгыбыз гына керә. Аннары безнең өчен ят булган объектив дөнья башлана. Әмма ул чагыштырмача гына ят, безнең рухыбыз ярлы булганлыктан, шартлы субъектлылык әсирлегеннән арынып җитә алмаганлыктан гына шулай чит булып тоела. Күпкырлы кешенең концепциясе тышкы дөнья белән аерылгысыз элемтәдә. Без — бер-беребездән аерылгысыз. Бу кеше башкаларда да, табигатьтә дә — бөтен нәрсәдә үзен күрә. Аның зурайтылган «мине» әйтерсең лә бөтен нәрсәне үз кочагына ала, теләсә нинди шәхси мәнфәгать чиген атлап чыга. Бу уңайдан тагын Горькийның: «Чын сәнгатьнең арттырып күрсәтергә хокукы бар», дигән сүзләрен искә төшереп үтәсе килә. Өченче тип кешенең «мин»е билгәлән чикләр гади «мин» чикләреннән киңрәк. Ул — шәхси эгоизм рамкаларыннан чыккан, үзеннән сыйнфый милли, раса һәм башка комсызлыклар тиресен салып аткан кеше.

Шундый коммунистик кеше концепциясе турында сөйләгәндә без бөтен дөнья тормышы һәм дөнья сәнгате алдында торган иң-иң катлаулы, хәтта кеше ышанмаслык авыр бурыч турында сөйләмибезмени? Шундый бурыч алга килеп баскан икән, димәк, ул кешелек алдына килеп баскан һәм үзен хәл итүне таләп итә...

Маркcның афоризм дип әйтерлек шундый сүзләре билгеле: «Кешене кеше итеп җәмгыять үзе ничек тудырса, кеше үзе дә җәмгыятьне шулай тудыра». Беренче типтагы кешене сурәтләүче сәнгать социаль ансамбльне тулаем, ягъни шәхес типологиясен теге яки бу социаль калып (икенче кеше) белән турыдан-туры бәйләнештә гәүдәләндерә һәм җәмгыятьнең кешене ничек тудыруын тасвирлый. Бу очракта идеал турында сүз булуы мөмкинме? Ай-һай, бик шикле. Җәмгыятьнең кешене тудыруын күрсәтү белән бергәттән, үзе җәмгыятьне тудыручы кеше образын иҗат итүне төп максаты итеп куйган сәнгать кенә идеалга якынаерга мөмкин. Кеше җәмгыять продукты түгел, ә аның иҗатчысы, тудыручысы, дөнья тарихының объекты түгел, ә субъекты, аның ялган герое түгел, ә чын герое. Кемнең субъектив «мин»е бөтен дөнья белән кушыла, ул инде үзе — бөтен дөнья. Әлбәттә, яңа дөнья иҗат итәргә көченнән килә торган шундый куәтле кеше образын тудыру — сәнгатьнең төп идеалы. Вакытның реаль хәрәкәте чынбарлык, тормыш тукымасында аның төсен, кыяфәтен торган саен ачыграк күрсәтә, дөнья тарихы аренасына килүенең муафыйклыгы, закончалыгы турында сөйли. Бу идеалга сәнгать гасырлар буе омтыла, әлай гына да түгел, үзенең бөек әсәрләрендә — Микельанджело, Сервантес, Бетховен, Шекспир, Пушкин, Достоевский тудырган образларда аңа максималь якын килә. Бүгенге сәнгать алдында да шушындый ук якынаю бурычы тормыймы икән? Әмма моңа ирешү өчен бик күп уйланырга, бик күп нәрсәнең асылына төшенергә кирәк.

Сизиф турындагы бик-бик борынгы мифны искә төшереп узыйк.

Бөтен Грециядә үзенең акылы һәм хәйләкәрлеге белән дан тоткан Сизиф патша соңгы сәгате сугар алдыннан да үлем белән бәхәскә керә һәм үлем алласы Танатны богаулап куя. Танат аның тәненнән җанын суырып алып, мәетләр патшалыгына илтеп ташлый. Сизиф анда да исән килеш җиргә әйләнеп кайту хәйләсен таба. Котылгысыз нәрсәдән качарга һәм шуның белән вакыт агышын бозарга ниятләгән өчен аллалар аны, авыр таш күтәреп, гомер буе биек тауга менәргә хөкем итәләр. Бу мифның төп мәгънәсе кешелекнең тырышлыгы, көч түгүе файдасыз дигән нәтиҗә чыгаруга кайтып кала. Кешелеккә азатлык бирелмәгән, ди миф, ләкин ул моны борын-

гы кол авызыннан әйттерә. Чыннан да, бу борынгы мифны яңадан кучереп язып, аның асылына төшенергә вакыт түгелме икән? Сизиф чиктән тыш күп көч түгеп тау түбәсенә менеп җитәм дигәндә генә кулындагы таш ычкынып аска тәгәри. Ничәмә-ничә тапкырлар һаман шул ук хәл кабатлана. Ләкин Сизиф уңышка ирешәчәгенә ышана һәм яңадан тауга үрмәли. Әйе, эш шунда — аллалар турында, үзенә бирелгән җәза турында ул инде күптән онытты! Ул бөтен гомере буена котылгысыз хәлне җиңеп чыгарга, эшләп булмаганны эшләргә омтыла. Нәрсә, тегендә соңыннан ул башка кешегә әвереләчәкмени? Юк! Сизиф гомер буена үлем белән йөзгә-йөз басып тора. Ул аллалардан көчлерәк! Таштан көчлерәк! Таудан көчлерәк!

Сизифның соңгы тапкыр текә тауга ничек күтәрелүен күз алдына китерергә мөмкин. Мин аның ыржайган тешләрен, катып калган, шул ук вакытта чамасыз киеренкелектән көзән җыергандай тартышкан йөзен, кулларын һәм аякларын күрәм. Менә ул иңендәге йөген тау түбәсенә куя, аңа куллары белән таяна. Аннары бөтен буена торып баса һәм... көчле көлү авазы яңгырый. Юлындагы барлык киртәләрне җиңгән азат кешенең шатлыклы көлү авазы!

Бөек сәнгать мәңгелеккә мәгънәсез эшкә хөкем ителгән кызганыч колны түгел, нәкъ менә шундый кешене — аллаларны, Ташны, Тауны җиңгән, үзенә караганда да көчлерәк булып чыккан Сизифны гәүдәләндерергә омтылган һәм омтыла. Бу — кешелекнең әлегә тормышка ашмаган хыялы һәм эзләнүләренең күптәнге ярсу газабы...

«Бу дөньяга мине кем җибәргәнлеген белмим мин. Дөньяның нәрсә икәнлеген, үземнең кем икәнлегемне дә белмим. Мин тулысынча коточкыч билгесезлек эчендә. Нәрсә ул минем тәнем, хисләрем, җаным нәрсә... мин боларның берсен дә белмим...»

Болар Блез Паскаль сүзләре. Әйе, кем мин, кеше? Һәм ни өчен килдем мин бу дөньяга? Фикерләүнең дөнья тарихында моңа охшашлы сораулары аз түгел. Хәтта, сораулар дип әйтү дә дөрес үк булмас. Ялвару, инәлү, ыңгырашу һәм кычкыру болар. Ә тормыш агымы куган каек кешене һаман каядыр агыза да агыза. Ул гомере буе ишкәк ишә, үзе барырга ашкынган җирнең ярларына җиту теләге белән яна. Бу турыда хәзер, җирнең язмышы кыл өстендә торган вакытта, сөйләргә ярыймы? Ә ни өчен ярамасын? Кешенең кулы руль-ишкәген тагын да ныграк кысып тотмас дип кем әйтер? Тарихның кыен моментларында сәнгатьнең әһәмияте тыныч вакыттагыдан һич тә ким түгел. Киресенчә, артыграктыр да, мөгаен. Ышанычлы, боеручан, оптимистик аваз бик зур көчкә ия. Азат кеше — социаль тормыш хәрәкәте ул. Өченче кешенең иң зур газап белән туу тарихның трагик сәгатьләрендә бара. Егерменче йөзнең беренче чирегендә яңа заман җиле аңа кадәр яшәп килгән бөтендөнья структурасын пыран-заран китерде, Шәхес һәм дөнья бүген аерылгысыз, кеше фикерләве субъектив һәм объектив бербөтен булып әверелергә омтылу. Бу хәтта фикерләү дә түгел, камиллеккә ирешеп җитмәгән дөньяны үзгәртеп корырга тырышу гына. Монда инде сүз кешелекнең бөтенләй башка рухтагы офыкларга чыгуы турында бара.

Диоген үзе яшәгән шәһәрчек урамына яна торган фонарь тотып чыккач, беренче очраган кеше гаҗәпләнеп:

— Көндез нигә кирәк булды сиңа ут? — дип сораган.

— Кеше эзлим, — дип җавап кайтарган Диоген һәм фонарен узып баручының йөзенә үк китергән. — Аны эзлим мин.

Кеше үзен эзли, үзенең асылын...

Һәм әдәбиятның, гомумән, сәнгатьнең мәңгелек сюжеты шуннан — кеше эзләүдән гыйбарәт.

Инде үземнең бу эссема нокта куяр алдыннан мин дә Диогенның сакланып калган фонарен йөземә якын китердем. Көзгедән миңа өч кеше йөзе карап тора. Өчесе дә ачулы йөзләр.

Ә алар һәр кешедә бар.

— Кем җиңәр? — дип сорадым мин кабатлап үз-үземнән.

Һәм үзем үк җавап бирдем:

— Соңгысы...

# БОРЫНГЫ ҺӘМ ЯҢА БӘЙРӘМ

Сабан туе — элек-электән халкыбызның бердәм үткәрә торган уртак бәйрәме ул. Борынгы заманнарда аны язгы чәчү алдыннан бәйрәм итә торган булганнар. Язгы чәчү — игенче тормышында бик мөһим һәм авыр эш, бөтен ел тәүлегендә тормыш иминлеге аның ничек үткәрелүенә бәйле. Шул ук вакытта, җәй башы һәм яз ахыры табигатьнең чәчәк аткан, яңарган чагы, көннәрнең озын, җылы вакыты. Нәкъ шушы дәвердә бер-береңбелән аралашу уңай да, күңелле дә бит.

Борынгы кешеләр мөһим хезмәткә керешер алдыннан җилкенеп алуны, бер уңайдан изге рухларның күңелен күреп, аларга корбаннар биреп, көзгә мул уңыш бирүләрен ялваруны кирәк дип санаганнар. Беренче буразналарга орлык белән бергә пешкән йомыркалар ташлау нәкъ менә шул йолалардан калган.

Заманалар үтә торган; халыкның көнкүреш рәвеше, әхлакый һәм фәлсәфи карашлары үзгәрү нәтиҗәсендә, йолалар да үзгәргән. Узган гасырда инде сабан туе изге рухларга мөнәсәбәтен югалткан һәм язгы эшләр алдыннан үткәрелә торган күңелле бәйрәм төсен алган.

Бу бәйрәмне халык һәрчак яратып, зур күтәренкелек белән үткәргән. Ләкин, кызганычка каршы, аның тулы тәртибен тәфсилләп язып баручылар булмаган диярлек. Халык йолаларын өйрәнүчеләрнең төп игътибары нигездә мәйдан өчен бүләк җыю тәртибендә һәм мәйданның үзенә юнәлтелгән. Язгы йолалар исә сабан туе белән бәйләнештә каралмаганнар, аның белән берлектә өйрәнелмәгәннәр. Хәлбуки, соңгы вакыттагы тикшеренүләр сабан туеның иртә яздан башлап үткәрелә торган тулы бер йолалар тезмәсе икәнлеген исбат итәләр. Бу йолалар Казан һәм Чепца буе татарларында, керәшен татарларында киң таралыш алган. Мишәр татарлары авылларында исә, кагыйдә буларак, бу йолаларның кайберләре генә бәйрәм ителгән. Мәсәлән, «кызыл йомырка көне» (балаларның өйдән-өйгә кереп манган йомырка җыюы), пешкән йомырка белән уйнау һ. б.

Мамадыш, Кукмара, өлешчә Арча, Саба районнарында, Татарстанның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгышындагы күп кенә авылларда, Киров өлкәсендәге Вятские Поляны районының татар авылларында сабан туен озак вакытка сузылган йолалар рәвешендә үткәрү гадәткә кергән.

Бу түбәндәгечә эшләнә:

Кар эреп, җир ачылу белән, авыл картлары, җыен җыеп, сабан туен кайчан, ничек үткәрү мәсьәләсен хәл кылалар. Алар билгеләгән бер көнне бала-чага йортлар буйлап сөт, май, йомырка, ярма җыярга чыга. Шул азык-төлектән басуда яки су буенда балаларга ботка пешерелә. Аны «дәрә боткасы», ә республикабызның көньягында һәм көньяк-көнчыгышында «карга боткасы» дип атыйлар.

Күп якларда «дәрә боткасы»ның нинди мәгънә аңлатканын белмиләр. Ә менә Вятские Поляны районының Түбән Шөн авылында безгә шундый бер риваять сөйләделәр: кайчандыр бер байның Дәрә исемле кызы ташу вакытында Вятка елгасына батып үлгән, ди. Кара кайгыга баткан ата кеше һәр язда ташу вакытында кызын искә алу мәҗлесе үткәрә башлаган. Бу күп еллар шулай дәвам иткән һәм гадәткә кереп калган.

Икенче көнне ак тула оеклар, яңа чабаталар һәм яңа күлмәкләр кигән балалар авыл буйлап манган йомырка җыярга чыгалар. Һәркайсының кулында — чүпләмле

сөлге башыннан тегелгән бизәкле букча. Һәр өйдән чыкканда ул бүлтәя, авырая бара, чөнки һәр хуҗа хатын балаларга нинди дә булса күчтәнәч әзерләп куйган: йомырка манган, бавырсак, татлы күмәч пешергән я конфет сатып алган. Кайбер авылларда өйгә беренче кергән ир баланы мендәргә утыртып: «Аягың җиңел булсын, тавык-чебеш мул булсын!» — дип теләк телиләр. Аңа күчтәнәч башкалардан күбрәк бирелә.

Мишәр татарларында бу йола «кызыл йомырка көне» дип атала. Кичтән йорт хуҗасы үзе җиңел аяклы дип санаган берәр ир кешене яисә ир баланы иртүк үзенә «бусагадан керү» йоласын үтәргә чакырып куя. Чакырылган кеше таң белән керә, үзе белән алып кергән кырык таякчыкны өйгә чәчеп ташлый, әтәч булып кычкыра, тавык булып кыткылдый, йорт хуҗасының мал-туары, кош-корты, умартасы үрчесен, дип тели. Кунакны сый-хөрмәт итәләр, бүләк бирәләр. Узган гасырның ахырында гадәттә «бусагадан керү» өчен ир кешеләрне чакырсалар, соңгы елларда күбесенчә үсмерләрне чакырганнар.

Беренче кергән ир баланы мендәргә утыртып теләк теләү керәшен татарларында күбрәк таралган.

Балалар йомырка җыюдан туктагач, шул ук иртәдә «сөрән сугу» башлана. Бизәлгән атларга атланган егетләр, сигезәр-унар төркем булып җыелып, авыл буйлап йөриләр, һәр йорт каршында туктап, кайчак ишек алдына ук кереп, йомырка сорыйлар. Аларга чи йомырка бирәләр, ул йомыркалар бер савытка җыелып бара. Авылны йөреп чыккач, егетләрнең иң чаясы һәм җитезе капчыкны әләктереп ала да бар көченә басу ягына чаба. Башка егетләр гадәттә аны куып җитәләр, йомыркаларны бергәләшеп пешереп ашыйлар. Бу куышу мәйданда булачак чабышка әзерлек булып тора. Күп кенә урыннарда мәйданга атна-ун көн кала бергәләп ат чабыштыру — «ат аягы кыздыру» да үткәрелә торган булган.

Кайбер авылларда «сөрән сугу»дан тыш «җәяүле сөрән» дә булган. «Исәкәй» булып, ягъни танымаслык итеп киенгән берничә ир кеше, йомырка сорап яки сый-хөрмәт өмет итеп, өйдән-өйгә йөриләр. Күчтәнәч бирмәгәннәрне кычкырып-кычкырып төрлечә үчеклиләр, әмма соңгысы сирәк була, чөнки берәүнең дә саран дип дан аласы килми.

Тагын да берничә көннән, чәчү тәмам якынлашкач, ат менгән егетләр мәйданда җиңүчеләр өчен бүләк җыярга чыгалар. Кайбер якларда бүләкне авыл картлары җыя. Бүләк җыючыларга теләгән кеше иярә, шулай итеп төркем шактый зур була. Һәр өйдә бу төркемне көтеп алалар. Узган сабан туеннан соң төшкән яшь киленнәргә өмет аерата зурдан — алар чүпләмле сөлге әзерләп куялар. Бу — алар үз куллары белән әзерләгән бүләк. Бүләкләрне я ат йөгәненә, я егетләр биленә, я махсус шуның өчен әзерләнгән колгага һәркем күрерлек итеп элеп куялар. Сөлгенең иң бизәклесе колга башына ук эленә. Аның зурлыгына, матурлыгына карап, киленнең осталыгына, уңганлыгына бәя бирелә. Сөлгенең иң шәбе, сабан туеның иң олы бүләге итеп, мәйдан батырына биреләчәк. Монда инде яшь киленнәр ярышы бара дигән сүз. Берәүнең дә уңмаган булып күренәсе килми, билгеле. Яшь кызлар бүләккә чиккән кулъяулыклар яки башка берәр төрле кул эше бирәләр. Әбиләр дә сандыкларын актара, һич булмаса йомырка булса да чыгара. Һәр бүләккә лаеклы рәвештә аерым рәхмәт сүзе әйтелә: тапкыр-шаян сүз белән, әйтем-мәкаль белән, яшь егетләр җырлап-биеп тә алгалый. Мәсәлән, Пермь өлкәсенең күп авылларында бүләк җыйганда җырлана торган «сөрән җырлары» хәзергә кадәр сакланган.

Икенче көнне таңнан халык мәйданга барырга әзерләнә. Һәркем бәйрәмчә киенергә тырыша. Төрле авылларда мәйдан төрле көнгә билгеләнә, шунлыктан мәйданга тирә-яктан бик күп кунаклар килә. Шунысын да әйтергә кирәк: сабан туена янәшә авылларда яшәүче рус, чуваш, мари, мордва һәм башка милләт кешеләре дә килә торган булганнар, бу бәйрәмдә милләтләрне аеру сизелмәгән.

Ат дугаларына кыңгыраулар, сөлгеләр, тасмалар, чәчәкле тукымалар тагыла, халык шау-гөр килеп, басуга, гадәттә парга сөрелгән кыр ягына агыла.

Ярышлар кагыйдә буларак ат чабышыннан башлана. Атларны биш-ун чакрым ераклыкка алып китәләр, алар шуннан мәйдан янына чабып килергә тиеш булалар, чөнки бүләкләр мәйданда, бөтен халык алдында бирелә, җиңгән атлар мәйданны әйләнеп чыгалар. Атлар чапкан арада мәйданда йөгерешчеләр ярышы башлана.

Монда, яшенә карап, берничә төркем кеше йөгерешә. Аннан соң башка төр ярышлар үткәрелә, һәр ярышта җиңүчеләргә бүләк бирелә, алар өлкәннәргә дә, кечеләргә дә эләгә. Ярышларның иң мөһиме һәм кызыклысы булып көрәш санала, бүләкнең дә иң зурысы ат чабышында җиңүчегә һәм сабан туе батырына саклана.

Бу бәйрәмдә егетләр көчен, җитезлеген, ныклыгын күрсәтсә, җырчылар һәм музыкантлар осталыгын күрсәтәләр. Сабан туе көннәрендә яшьләр, гомумән җыр сөючеләр, яңа җырлар ишетеп, отып калалар. Бик күпләр ул җырларны кырда да, кышкы озын кичләрдә дә, аулак өйләрдә дә җырлап күңел ачачаклар, юаначаклар әле.

Сабан туе яшьләрнең кичке уены белән тәмамлана. Кичләрен су буйларыннан, әрәмәлекләрдән, болыннардан гармун, скрипка моңнары, яшьләрнең дәртле җырлары ишетелә. Бу уеннарда яшьләр бер-берсенең күңелен ачалар, үз тиңнәрен табышалар, вәгъдәләр бирешәләр. Шунысын аерым билгеләп үтәргә кирәк: халыкның күп җыелуына һәм ярышлар вакытында хисләрнең тыелгысыз ташып торуына карамастан, сабан туйларында тәртип бозу һич булмаган.

**Сабан туеның беренче, иң тулы варианты,** гомумән алганда, менә шундый тәртиптә үтә. Анда түбәндәге этапларны аерып күрсәтергә мөмкин: 1) халыктан җыйган азык-төлектән балаларга ботка пешереп ашату («карга боткасы»); 2) балаларның манган йомырка җыюы; 3) ат менгән егетләрнең йомырка җыюы һәм аны пешереп ашавы («атлы сөрән»); 4) танымаслык булып киенгән ирләрнең йомырка җыеп йөрүе («җәяүле сөрән»)— монысы булмаска да мөмкин; 5) мәйдан өчен бүләк җыю (гадәттә ат менгән егетләр җыя); 6) мәйданда ярышлар; 7) яшьләрнең кичке уены.

**Сабан туеның икенче варианты беренчесенә** караганда кыскарак. Бәйрәмнең төп өлеше һәр авылда икегә бүлеп үткәрелгән. Бу вариант Арча һәм Балтач районнарының күпчелек авылларына хас. Ул түбәндәге этаплардан тора: 1) мәйданга атна-ун көн кала егетләрнең бизәлгән атларда чабышуы («ат аягы кыздыру»); 2) балаларның манган йомырка җыюы; 3) бүләк җыю (еш очракларда бу эшне ике-өч ир кеше башкара, алар бүләкләрне иңбашларына куйган таякка бәйләп баралар; 4) мәйдан; 5) яшьләрнең кичке уены.

**Сабан туеның өченче варианты** шулай ук озын түгел, ул Арча һәм Биектау районы авылларына хас булып тора. Анда: 1) балаларның манган йомырка җыюы; 2) бүләк җыю, ул гадәттә ат менгән егетләр тарафыннан башкарыла; 3) мәйдан; 4) яшьләрнең кичке уены.

Башка вариантлардан үзгә буларак, бирешдә сабан туе көннәрендә егетләр төркем-төркем бер-берсен кунакка чакырып сыйлаганнар — бу «сөрән йөрү» дип аталган. Күрәсез, «сөрән» сүзе бу якта башкачарак мәгънә алган. (Кайбер урыннарда «сөрән» өч чатлы таякны аңлата — аңа җыйган бүләкләрне тагып баралар). Кайсыбер авылларда ул гомумән юк.

Сабан туеннан соң, явым-төшем булмаса, чәчү башланган. Аның беренче көне— «орлык чыгару» барлык татарлар өчен дә уртак йола булып санала. Чәчү алдыннан мунча якканнар, «тазарынып чыкканнар», чиста кием кигәннәр. Кырга барганда, урамда беренче очраган кешегә, юлыбыз уң булсын, дип, пешкән йомырка бирел киткәннәр. Җиргә беренче орлыклар белән бергә йомыркалар да ташлаганнар. Өлкәннәргә иярел басуга килгән бала-чага аларны җыеп ала торган булган. Ул көнне күп эшләмәгәннәр, җиргә ашъяулык җәеп, күршеләрне чакырганнар, бер бөтен ипине башлап ашап бетергәннәр. Табын изге теләкләр белән җыелган:

> **«Игеннәр мул булсын,**
> **Еллар имин килсен,**
> **Урып-җыйганда көннәр аяз торсын,**
> **Орлыклар йомыркадай эре булсын».**

Совет власте елларында да сабан туе халкыбызның көтеп алган һәм яраткан бәйрәме булып калды. Бик авыр сугыш елларында гына аны иркенләп үткәрү мөмкинлеге булмады, ә инде илгә иминлек килү белән, ул тагын да ямьлерәк итеп уздырыла башлады.

Дөрес, тормыш шартларының үзгәрүе бу бәйрәмне оештыруда да чагылыш тапты. Халыкның тормышы яхшырганнан-яхшыра бара, аерым төбәкләрдә яшәүче кешеләрнең көнкүреше арасындагы аерымлыклар кимегәннән-кими. Нәтиҗәдә

сабан туе уткәру тәртибендәге аерма да югала бара. **Беренчедән**, бу бәйрәмне һәркайда бер үк чорда — уңайлырак чакта, язгы эшләрдән соң, печәнгә төшәр алдыннан уздыра башладылар. Шулай да ул бөтен республикада берьюлы түгел, төрле көннәрдә: башта авылларда, аннары район үзәкләрендә һәм иң соңыннан зур шәһәрләрдә һәм Казанда бәйрәм ителә. Элегрәк сабан туен һава торышына карап билгеләгәннәр, хәзер аны якшәмбе көнне бәйрәм итү гадәткә керде. Казанда аны Татарстан юбилеена — 25 июньгә туры китерәләр.

**Икенчедән**, сабан туен уткәрүнең уртак бер формасы да барлыкка килде. Ул өч өлештән гыйбарәт: 1) бүләк җыю; 2) мәйдан; 3) яшьләрнең кичке уены. Ә «карга боткасы» пешерү, балаларның өй борынча манган йомырка җыеп йөрүләре бүгенге көндә онытылып бара дияргә була.

Бүгенге көндә сабан туен милли бәйрәм дип саныйлар. Нәтиҗәдә, Татарстаннан читтә яшәүче, электән аны бәйрәм итмәгән татар авылларында да аны бик теләп уткәрә торган булып киттеләр. Мәсәлән, Киров өлкәсендәге нократ татарлары һәм Горький өлкәсендә яшәүче татарлар турында шулай дип әйтергә була. Татарлар күпләп күчеп килгән зур шәһәрләрдә дә сабан туен милли бәйрәм төсендә уздыру еш очрый. Мисалга, Мәскәүнең Измаил паркында, Ташкентта, Ленинградта, Чиләбедә, Свердловскида, Түбән Тагилда һәм башка урыннарда уздырылган сабан туйлары борынгыдан килгән традицияләрнең яңа җирлектә халыклар дуслыгын ныгытуга, интернациональ бердәмлекне үстерүгә хезмәт итүен күрсәтәләр. Чөнки бу бәйрәмнәрдә якын-тирәдә яшәүче барлык милләт вәкилләре бик теләп катнаша.

Һәр авылда һәм район үзәгендә бәйрәмне уздыру буенча махсус комиссия төзелә. Бу эштә совет һәм партия хезмәткәрләре актив катнаша.

Соңгы елларда сабан туен флаг күтәрүдән башлау очраклары күренә башлады. Флагны күтәрү хезмәт алдынгыларына һәм узган елны сабан туе батырына ышанып тапшырыла.

Мәйданда һәвәскәр җырчыларның, биючеләрнең чыгышларын оештыру да сабан туен уткәрүдә бер яңалык булып тора. Арча сабан туенда, мәсәлән, һәр елны диярлек физкультурачыларның парады һәм чыгышлары була. Мондый чыгышлар Казан районнарында да олы юбилей елларында аеруча әзерлекле, тантаналы һәм истә калырлык итеп оештырылган иде.

Брежнев шәһәрендә сабан туен уткәрүгә зур яңалыклар керттеләр. 1973 елдан башлап биредә сабан туе чорында җыр бәйрәме уздырыла, күмәк хорның чыгышында меңнәрчә кеше катнаша.

...Мәйдан уртасында ике малай көрәшне башлап җибәрәләр. Анда чиратлашып үсмерләр, яшьләр, ир-егетләр көрәшә, шул ук вакытта мәйданның төрле урыннарында башка төрле ярышлар бара: гер күтәрү, колгага үрмәләү, бау я таяк тартышу һ. б. Шаян ярышлар: көянтә белән сулы чиләкләр күтәреп яки йомырка куйган кашык кабып узышу, капчык киеп йөгерешү, бер аякны икенче берәүнең аягына бәйләп, парлап йөгерешү, күзне бәйләп, таяк белән чүлмәк вату, капчык сугышы... Нәкъ менә шушындый ярышларда аеруча күп кеше катнаша да инде. Элекке заманнарда хатын-кызлар мәйданда тамашачы гына булып торганнар. Хәзер алар да бик күп ярышларда катнашалар, бәйрәм яме өстенә ямь өстиләр.

Бүген сабан туе батырына бик зур бүләкләр — келәм, радиоалгыч, сәгать һәм башка бүләкләр тапшыралар. Күп кенә урыннарда, борынгы йоланы искә алып, тере тәкә бирәләр. Мәйдан көрәшләрендә беренче чыныгу алган һәм шуннан соң танылган спортчы булып җитешкән егетләр дә аз түгел. Хәзерге вакытта татар көрәше күңел ачу чарасы булып кына калмады, спортның бер төре булып китте. Соңгы елларда татар көрәше буенча Татарстан һәм РСФСР беренчелегенә ярышлар да уздырыла башлады.

Мәйдан иртәнге 10—11 дән алып, сәгать 2 гә, 3 кә кадәр дәвам итә. Бу вакыт эчендә буфетлар сәүдә итә, күпләр, чирәмгә ашъяулык җәеп, табын коралар, самавыр куеп җибәрәләр. Ә кичен болында яисә клубта яшьләр уены була. Күп очракта һәвәскәр җырчы һәм биючеләрнең ярышы шунда оештырыла.

Мондый кичәләрне уздырганда да һәркемнең осталыгы, фантазиясе зур роль уйный. Минзәлә районының Күзкәй авылында, мәсәлән, сабан туе алдыннан, авылның бөтен халкын һәм сабан туена кайткан кунакларны чакырып, клубта зур кичә

үткәрәләр. Бу кичәнең максаты — колхозның ирешкән уңышларын, авыл тормышының матурлыгын күрсәтү. Кичәләр «Сагындыра туган як», «Игенчене хөрмәтлә, и башыңны икмәккә» дигән исемнәр астында уза. Монда өлкәннәргә «Хезмәт ветераны» медальләре тапшырыла, ярыш алдынгыларын ипи-тоз белән каршы алалар. 25—50 ел бергә тигез-тату яшәгән кешеләрнең алтын һәм көмеш туйларын билгеләп үтәләр. Яңа өйләнешкән кешеләрне хөрмәтлиләр, яңа туган бәбиләрне регистрацияләлиләр. Елына бер мәртәбә бергә җыелган туган-тумача, кардәш-ыру арасында болар барысы да бик хуплап, куаныч белән кабул ителә, туган якка мәхәббәтне, авылда намус белән эшләүчеләргә хөрмәтне арттыра.

Әйе, хәзерге вакытта сабан туйлары элекке белән чагыштырганда күпкә зуррак, киңрәк, ямьлерәк уза. Аны оештыручыларга да зур җаваплылык йөкләнә.

Бу уңайдан сабан туйларында борынгы традицияләрнең һәм һәртөрле яңалыкларның алган урыны хакында ныклап уйланырлык мәсьәләләр бар. Әйтик, бәйрәмне оештыруга өлкәннәр һәркайда да актив катнашмыйлар, мәйданга хөрмәтле кунаклар рәвешендә генә чакырылалар. Ә нигә соң әле аларны бөтен бәйрәмне уздыру буенча җиң сызганып эшләүче, мәйдан барышында тәртип саклаучы да итмәскә?

Тулаем алганда да сабан туен оештыручыларның абруен бик нык күтәрергә кирәк әле. Кешегә бу вазифаны йөкләү — олы ышаныч һәм ихтирам күрсәтү булып саналсын, аларның сүзе һәркем тарафыннан зурлап кабул ителсен. Шулай булмаса, иркен һәм шау-шулы мәйданнарны тиешле оешканлык белән үтәп чыгу бик кыен эш.

Сабан туйларын колхоз-совхоз һәм район үзәкләрендә үткәрү белән канәгатьләнү гадәткә кереп бара. Бу хәл кечкенә авылларда яшәүчеләрне, бигрәк тә өлкәннәрне һәм балаларны бәйрәмнән мәхрүм итә, чөнки үзәктән шактый ерак урнашкан авыллар да бар бит, аларга сабан туена барып җитү ансат түгел. Хәлбуки, көнбатыш Кама аръягы (Чистай, Алексеевский, Әлки, Чирмешән) һәм Идел аръягы (Апас, Кама Тамагы, Буа) районнарында соңгы елларда сабан туен район үзәгендә генә уздыру белән чикләнергә омтылалар. Ярышларда әллә ни күп кеше катнашмаса да, бүләкләр артык зурдан булмаса да, кечкенә авылларда бәйрәмне бик күңелле үткәреп була, чөнки бередә бер-берсен яхшы белгән, якын иткән кешеләр җыела.

Авылларда җыелган бүләкләрнең бер өлешен колхоз-совхоз яки район үзәгендә булачак сабан туена илтеп бирү очраклары да бар. Монда инде кемнең нинди бүләк биргәне онытыла, кешеләрнең бу эш белән кызыксынуы кими. Чыннан да, бүләгеңнең кемгә бирелгәнен үз күзләрең белән күрә алмагач, аның ни кызыгы калсын? Шулай итеп, бүләк җыю сабан туеның бер өлеше булудан туктап, әйбер сорашуга гына кайтып кала.

Шул ук вакытта бүләк җыюдан бөтенләй үк баш тартуны да күңелле күренеш дип булмый. Баулы районының Бәйрәкә авылында һәм башка кайбер урыннарда соңгы вакытта бүләк җыюны кирәк санамыйлар. Кирәк кадәресен алырга колхозның байлыгы җитәрлек, дип исәплиләр. Әлбәттә, хәзерге хуҗалыкларның күбесе бай. Әмма бәйрәм уздырганда аның матди ягына гына түгел, рухи ягын да истән чыгармаска иде. Бүләк җыйганда, халык үзенең юмартлыгын күрсәтә, ярышларда җиңүчеләргә үзе биргән бүләкләрне тапшырып хөрмәтли. Кешеләрне бу изге мөмкинлекләрдән нигә мәхрүм итәргә?

Еш кына татарча көрәш сабан туеның үзәге булып кына калмый, ул җитди ярышларның берданбер төре булып та китә. Чөнки ат чабышларына, йөгерүгә, сикерүгә, гер күтәрүгә җитәрлек игътибар бирелми, алар тиешенчә игълан ителми. Аларга бүләкнең дә кечкенәсе генә бирелә. Сабан туен көрәш буенча ярышларга гына кайтарып калдыру һич тә дөрес булмастыр.

Сабан туе заман үтү белән үзгәрә, аның эчтәлеге баеый, төсмерләре арта. Ул халыкның иң яраткан бәйрәмнәреннән берсе һәм киләчәктә дә шулай булсын!

**РӘҮФӘ УРАЗМАНОВА,**
тарих фәннәре кандидаты.

## Ильтани Илялова

# ТАТАР СӘХНӘСЕНДӘ ТӘРҖЕМӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Сәнгатьнең бүтән төрләре кебек татар театры да үз кабыгына гына бикләнеп яшәми. Ул илебез халыкларының театрлары белән даими рәвештә аралашып яши. Мондый элемтәләр һәр халыкның сәхнә сәнгатен баета. Ә бу аралашуның формалары күп төрле: аңа тугандаш республикаларга гастрольгә барулар да, фестивальләр, культура көннәре, конференцияләр дә керә... Алар вакытында шәхси танышлыклар барлыкка килә, башка республика коллективлары, режиссерлары спектакльләр куярга чакырыла. Билгеле, төрле чорларда үзара элемтәләрнең төрле формалары алгы планга чыга. Ә без биредә тәрҗемә ителгән әсәрләрне татар сәхнәсендә кую турында сүз алып барачакбыз.

Тәрҗемә итәргә пьеса сайлап алуның үзенә бер төрле кануннары бар. Беренчедән, биредә үз драматургиябездә күтәрелмәгән проблемалы әсәрләргә игътибар ителә. Мәсәлән, соңгы ун елда безнең театрларыбызның афишаларында И. Дворецкийның «Чит кеше»се, Җ. Җаббарлының «Айдын»ы, Б. Горбатовның «Бер төн»е, Л. Леоновның «Ябырылу»ы, А. Абдуллинның «Уничтожить председатель»е (ТДАТ), А. Салынскийның «Барабанчы кыз»ы, Ч. Айтматовның «Анам кыры» (Әлмәт театры), А. Макаенокның «Трибунал»ы (Драма һәм комедия театры), А. Каһһарның «Кадерле әниләр»е (Минзәлә театры) кебек әсәрләр күренде. Аларда совет кешеләрен төрле яктан һәм яңача ачкан проблемалар куела, бүгенге кешенең тормышка мөнәсәбәте карала.

Икенчедән, башка телләрдә язылган пьесаларны куеп, безнең театрларыбыз үзләрен кызыксындырган мәсьәләләрне тирәнрәк алып карыйлар, тамашачыларның игътибарын шуңа юнәлтәләр. Мәсәлән, В. Распутинның «Авылдашлар, акча кирәк», М. Байҗиевның «Кияү белән кәләш», «Хуш, Назлыгөл», Ч. Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәй генәм» кебек әсәрләре татар театрына шунысы белән якын: аларда әхлак проблемалары тирәнтен карала. М. Кәримнең «Ай тотылган төндә», «Ташлама утны, Прометей» трагедияләре дә кешеләр хакына, бөек идея хакына батырлыкка бару турындагы татар драмаларына аваздаш. Әнә шундый батырлык мифологик герой Прометейны совет герое, шагыйрь Муса Җәлил белән берләштерә.

Бу мәсьәләдә кызыклы һәм мөһим бер яңалык бар. Элегрәк — сугышка хәтле елларда — бөтен милли коллективлар да диярлек рус пьесаларын гына тәрҗемә итәләр иде. Соңгы чорда исә илебезнең күп милләтле сәхнәсендә барча халыкларның әсәрләре дә актив куелып килә. Хәзер «Совет пьесасы» төшенчәсенә молдаван И. Друцэның да, әзербайҗан Р. Ибраһимбәковның да, белорус А. Макаенокның да, кыргыз Ч. Айтматовның да, татарлардан Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗевларның да әсәрләре керә.

Шушы уңайдан барлык милли театрларда да булган бер күренешкә тукталырга кирәк. Режиссерлар тәрҗемә пьесаларны куйган чакта, ә актерлар исә уйнаганда,

теге яки бу конфликтны, проблеманы ачалар, геройның психологик асылын күрсәтәләр. Ә характерларның саф милли сыйфатларын гына сурәтләү төп максат булып тормый: кыргыз яки грузин героен уйнаучы актер әлеге милләт вәкилләренә хас булган тышкы билгеләргә, чалымнарга гына йөз тотмый. Әгәр шул юлдан гына китсәң, кыланчыклыктан артык берни килеп чыкмас иде. Чөнки бер генә кеше дә, шул исәптән актер да, үз милли характерының гасырлар буена формалашып килгән сыйфатларын, кием салган кебек, тиз генә салып ташлый алмый. Бөек итальян актрисасы А. Расторининың «мин теләсә кайсы рольне үз милләтемә хас кайнарлык белән уйныйм»,— диюе дә нәкъ менә шул турыда. Мондый мисаллар аз түгел. Әлбәттә, тәрҗемә әсәр спектаклендә аны башкаручы милли коллективның үз характеры күренә. Безнең татар театры, мәсәлән, тыйнак, шигъри-эмоциональ, лирик җанлы артистлары белән күпләргә билгеле.

«Хуш, Назлыгөл» спектакле уңае белән сәнгать фәннәре докторы А. Анастасьев язган фикер кызыклы. Ул болай ди: «Заманча, милли үзенчәлекле бу спектакль геройларында без хәзерге Татарстанның яшь кешеләрен күрәбез»[1]. Димәк, «Хуш, Назлыгөл»дәге характерларда милли кыргыз тибы түгел, ә хәзерге татар халкының милли тибы чагылдырылган. Ә аларда исә гомум интернациональ сыйфатлар, башка халыклар белән уртак әхлакый идеаллар ачык күренә. Үз әдәбиятларының чиген үтеп чыккан язучылар — Айтматов, Друцэ, Ибраһимбәков, татар драматургларыннан Миңнуллин, Хәсәенов, Вәлиев иҗатына мөрәҗәгать итсәң дә, аларда гомуми һәм милли якларның бергә үрелүе аермачык күренә.

Татар театрында куелган тәрҗемә спектакльләрнең художество кыйммәте төрлечә булуга карамастан, аларның барысы өчен дә уртак бер уңай як бар: берсендә дә милли билгеләрне механик рәвештә генә күчереп алуга омтылыш сизелмәде. Характерлы мисал: татар академия театрында «Кызыл яулыклы гүзәлкәй генәм» куелды. Авторы кыргыз, режиссеры үзбәк, актерлары татар булган бу спектакльдә өч культура бергә кушыла. Айтматовның тыштан беркадәр кырыс күренгән, уй-хисләрен түгеп-чәчми торган геройлары югары шигърияткә, кайнар хисләреккә омтылган режиссерның милли характерында үзенчә чагылыш тапты. Шушы ике башлангыч татар актерларының традицияләре, үзенчәлекләре белән бергә кушылып, аларга гына хас булган үзенә бер сәнгать күренеше тудырды. Спектакльдә нечкә хиссият, йомшак моң, кычкырып тормаган шигърият, элегизм сизелә. Әмма бу спектакльне иҗат итү җиңел булмады. Чөнки режиссер һәм актерлар әдәби материалга төрлечә карыйлар иде. Кайбер рольләрне башкаручылар үз геройларын гадәти һәм элекке әсәрләр буенча таныш булган кешеләр итеп санады. Ә режиссер Т. Ходжаев әсәрне сәхнәдә күрсәтүне поэтик планда күзаллады, ул шигърият турында сүз алып барды, характерларны төптән-тирәннән ачып бирүне таләп итте. Нәтиҗәдә, актерлар спектакль геройларын көнкүрештә еш очрый торган персонажлар дип уйлаудан баш тартырга, кеше җанының, күңел кичерешләренең үзенә бер төрле рухи күтәренкелеген аңларга тиеш булдылар. Спектакльдәге көнкүреш детальләре исә кешенең төп сыйфатын ачарга ярдәм итүче фактлар булып кына калдылар...

Менә юл мастеры Байтимер (аны Ш. Биктимеров бик оста уйнады!) үзенең ярдәмчесе белән авария булган урынга ашыга. Ярдәмчесе иң башта машинаны чыгарырга тели. Байтимер аңа болай ди: «Башта — кеше, ә машина — аннан соң». Ул моны үзеннән-үзе аңлашыла торган нәрсә кебек һәм, шул ук вакытта, кире какмаслык итеп тә әйтә. Нәкъ менә шушы «Башта — кеше» дигән сүз мастерның үзен дә, бөтен спектакльне дә характерлый.

Бу спектакль театр үсешендә мәгълүм бер этап булды һәм бөтенсоюз күләмендә югары бәя алды. Тәнкыйтьче В. Сахновский-Панкеев язганча: «Айтматов геройларының рухи тыйнаклыгы, хисләрдә һәм сөйләмдә тыенкылыгы хәзерге театрның мәҗбүри таләбенә җавап бирде, тамашачы күңеленә хуш килде. Кыргыз язучысы повестьларының инсценировкалары күп кенә театрларга һәм актерларга үзләренең моңарчы күрелмәгән рухи һәм иҗат мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итүе... гаҗәп түгел. Г. Камал исемендәге театрда да шулай булды»[2].

Төрле милли культуралар аралашканда актерлар һәм режиссерлар уртак иҗатта

[1] А. Анастасьев. На 45 языках. М., 1972, 40 бит.
[2] Журнал «Театр», № 9, 1967.

бер-берсен баеталар. Башкорт режиссеры Л. Вәлиевнең һәм әзербайҗан режиссеры А. Кязимовның татар театрлары белән эшләве, мәсәлән, ике як өчен дә бик файдалы булды. Спектакльләрне сәхнәгә куючылар татар артистларына күтәренке-героик стилистикага якынаерга булышу белән бергә, аларны психологик яктан тирәнәергә мәҗбүр иттеләр. Мәсәлән, А. Кязимов сәхнәгә куелышны күтәренке манерада хәл итеп, характерларның психологик эшчәнлегенә дә бик зур игътибар бирде. «Айдын»-да көндәлек тормыш интонацияләре юк, характерлар да беренче карашка гадәти түгел: чөнки режиссер әзербайҗан сәнгатенә хас күтәренке стилистиканы бирә. Шулай итеп, татар һәм әзербайҗан театрларының уртак иҗаты үзенчәлекле синтез барлыкка китерде.

Башкорт режиссеры Л. Вәлиев «Ташлама утны, Прометей!» (М. Кәрим) трагедиясен сәхнәгә куйганда да стиль үзенчәлекләре аермачык чагыла. Әсәрдә героика, югары эмоциональлек, милли характерның үзенчәлекле сыйфатлары оста күрсәтелә. Ә. Закиров эшләгән сәхнә бизәлеше — биек колонналар, күк гөмбәзен җилкәсендә күтәреп торучы Атлант, тамаша залы өстенә үк чыгып торган пандус та — спектакльнең героик-монументаль стилистикасын көчәйтә. Г. Камал театрының бу спектаклендә башыннан ахырынача сузылган бер ачык фикер бар: кешелек хакына, аның алга китеше, үлемсезлеге хакына батырлык эшли белү, үз-үзеңне корбан итә алу. Монда Дон Кихот темасы да, бернинди кимсетелүләргә карамастан, иң бөек гаделлеккә ышанычын югалтмаган хыялый кеше темасы да укыла. Шунда ук — бүтәннәр хакына шәхси газапларга баручы революционер темасы да, кешегә нәрсә кирәген башкалардан ачыграк, ераграк күрүче, күбрәк белүче юлбашчы темасы да бар. Нәкъ шул проблеманы ача торган күренешләрдә мәгънә акцентлары да бик дөрес ясалган. Иң әйбәт эшләнгән күренеш — Прометейның әнисе Фемида белән (Р. Таҗетдинов һәм Н. Ихсанова) очрашуы. Монда Ихсанованың трагик рольне башкару осталыгы гаҗәп матур ачылды. Шунлыктан бу өзектәге фикер тәгаллеге, аның югары трагизмы һәм үтә көчле эмоциональ тәэсире бөтен спектакль барышында үзәк урынны алды да. Биредә мифологик сюжет арткы планда кала, каһарманлык, патриотик идеягә бирелгәнлек темасы, хатын-кыз һәм ана хәсрәте, улына батырлыкка фатиха бирү темасы алгы планга чыга. Бу — заманча, җанлы тема. Ул ассоциатив рәвештә Муса Җәлилнең, совет иле геройларының батырлыкларын хәтердә яңарта.

Тәрҗемә пьесалар спектакльләрен иҗат иткәндә актерларның бик күп яңа яклары ачылды. Характер логикасында эзлеклелекнең, фикерләрне чагылдырганда эчке азатлыкка ирешүнең иң ачык күренүе актер Ә. Шакиров өчен «Чит кеше» спектаклендә (Манагаров), Г. Исәнголова өчен «Хуш, Назлыгөл» спектаклендә (Назлыгөл) булды. Моңарчы комедия актеры буларак танылган Р. Шәрәфиевне «Ябырылу» драмасында тамашачы бөтенләй икенче яктан күрде (бик катлаулы драматик роль булган Федор Таланов образы). «Кияү белән кәләш» спектаклендә кичерешләр тирәнлеге һәм эчке драматизмны бирә белү белән яшь актриса Ф. Хәйруллина да яңа яктан ачылды.

Иң кыен бурычларның берсе, мөгаен, «Баһадирлар» («Третья, патетическая») спектаклендә Ленин образын иҗат иткәндә Ш. Биктимеров алдына килеп баскандыр. Ленин образын тудыруда совет театрының бай тәҗрибәсе бар. Аны беренче башкарган Б. Щукин, М. Штраух исемнәре яхшы билгеле. Әмма бу бөек образны үзләренчә күрсәткәндә, соңгы буын актерлар да тирән дулкынлану кичерәләр, мәсьәләнең гаять катлаулылыгын тирән аңлыйлар. Ш. Биктимеров та үзен бик озак әзерләде. Чорыбызның иң югары идеалы гәүдәләнгән мондый образны тудыру өчен тормыш материалын еллар буена аңлы һәм интуитив рәвештә туплый бару, үз күңеленнән үткәрү кирәк. Биктимеров та юлбашчы тормышы турында бик күп әдәбият укый, аның речьләре язылган грампластинкалар тыңлый, документаль фильмнар карый, Ленин турындагы фильмны татарчалаштыруда катнаша, радиопостановкаларда Ленин ролен башкара, Мәскәүдәге Ленин музеенда күп тапкырлар була. Иң мөһиме — ул В. И. Ленин әсәрләрен тирәнтен өйрәнә. Иҗат эше көнен дә, төнен дә дәвам итә, театрда да, өйдә дә, урамда да... Тапшырылган эшнең гаять катлаулылыгы, җаваплылыгы аңа тынгылык бирми.

Бервакыт, инде спектакль сәхнәгә чыкканнан соң, Ш. Биктимеров педагогия институты студентлары белән очраша. Актерлар спектакльдән бер өзек уйнап күрсә-

тәләр. Биктимеров бу юлы бүтән галстук бәйләгән була. Һәм студентлардан берәү аңа шул фактны әйтә. Шунда инде Биктимеров: «әгәр тамашачы костюм деталендәге аз гына төгәлсезлекне дә сизә икән, юлбашчы ролен башкаручы артист эчке линиясе никадәр төгәллек белән алып барырга тиеш!» — дигән тирән бер фикергә килә.

Русчадан тәрҗемә ителгән пьесалар белән эшләүне дәвам итеп, театр Б. Горбатовның «Бер төн» исемле инде бераз онытылып та барган драмасын сәхнәгә куйды. Ул фашистлар Германиясен җиңүнең 30 еллыгына куелды һәм татар академия театры тормышында әһәмиятле күренеш булды. Б. Горбатовның фронттагы шәхси күзәтүләре нигезендә 1944 елда ук язылган бу әйбәт пьесаны коллектив яңадан, үзенчә ачкан кебек булды. Башта тискәре персонажлар группасы бик көчле язылганлыктан, пьесага күпмедер дәрәҗәдә шикләнеп карау да булган иде. Шуңа күрә, бу драманы куярга алынган театрга да әсәрнең көчләр нисбәтен төгәл, уңай геройлар һәм уңай пафос файдасына хәл итәргә кирәк иде. Г. Камал исемендәге театр спектакленең төп отышлы ягы шул — бирелә тирән уңай программа төгәл ачып бирелә. Тирән психологик драма жанрында, нәкъ Чеховныкыча атмосферада хәл ителгән, көчле икенче планы булган бу әсәрдә көчләр бик ачык бүленгән. Тискәре персонажларның зур группасына уңай геройларның да монолит бердәм группасы каршы куела. Бу әсәрнең төп фикеренә — совет кешеләренең җиңелмәслеге, какшамаслыгы турындагы фикергә китерә.

Театрның Л. Леонов әсәре «Ябырылу»ны сәхнәгә куюы да (режиссер М. Сәлимҗанов, художнигы Ә. Закиров) әлеге тёманың дәвамы булды. Бу, әлбәттә, бик катлаулы бурыч иде. Чөнки анда, төп концепция ачык булган хәлдә, төрле стильләр бер-берсенә нечкәлек белән үрелгән: психологизм, рухи хәрәкәтләр тирәнлеге, кискен гротеск, күзгә бәрелеп торган сатира һәм плакат стиле... Әсәрдә карт врач Таланов семьясы һәм тормыш, киләчәк ягында булган кешеләр йомшак җылылык, эчкерсез психологик якынлык белән сурәтләнә. Ә сәхнә гротескы фашистларга каршы юнәлдерелгән. Режиссер М. Сәлимҗанов та авторга төгәл иярә бара. Ул зур игътибар бирелгән төп персонажларны табып, килешмәүчән ике лагерьны капма-каршы куя. Театр өлкән Талановларга — Иван Тихоновичка (Ә. Шакиров) һәм Анна Николаевнага (А. Галиева һәм Н. Ихсанова) бик җылы карый. Бу ике образны актерлар иң яхшы реалистик традицияләрдә — тыйнак һәм күпсүзлелекне яратмаучы өлкән яшьтәге интеллигент кешеләрнең психологиясенә тирән үтеп иҗат итәләр. Чал чәчле, төз гәүдәле Иван Таланов-Шакиров тыныч, шау-шусыз, басынкы-сабыр кеше. Әмма, шулай да, бөтен вакыйгалар барышында, кайчагында турыдан-туры үзе күренмәгән килеш тә ул үзенең барлыгы белән бөтен сәхнәне тутырып тора кебек. Аның чын патриотизмы, совет кешесенең көченә тирән ышануы — төп характер сыйфаты булып чыга. Үзенең хаклыгына тирән ышанган Анна Таланова да ире Иван Тихоновичка тиң. Ирле-хатынлы Талановлар образларын иҗат итүче актерлар гомер юлын бергә үткән бу ике кешенең рухи якынлыгын, карашлар бердәмлеген күзгә бәрелерлек итеп үк күпертмичә, әмма бик төгәл бирәләр. Тискәре персонажлар исә (Фаюшин-Биктимеров, Кокорышкин-Мифтахов) үткен гротеск, хәтта фантасмография аша күрсәтелә.

Шул рәвешчә, татар театрында СССР халыкларының тәрҗемә пьесаларын кую труппаларның иҗади интересларын һәм мөмкинлекләрен киңәйтә, театрны тар рамкалардан алып чыга һәм милли культураларның тагын да якынрак аралашуына булышлык итә. Р. Гамзатов мондый диалектика турында РСФСР язучыларының II съездында бик матур итеп әйткән иде: «Үз тауларыннан ерак киңлекләргә очмаган бөркет — ул әле бөркет түгел, чебеш кенә. Шулай ук ерак киңлекләрдән туган оясына әйләнеп кайтмаган бөркет тә — бөркет түгел!»

Әйе, илебездәге барлык халыкларның сәхнә сәнгате кебек үк, безнең татар театры да ике планда — үзенчәлекле милли культура күренеше булып һәм, шул ук вакытта, күпмилләтле совет театры белән бер юнәлештә үсә. Чынбарлыкка һәм аның прогрессив көчләренә тугрылык, социалистик гуманизмны раслау, халыкчанлык, партиялелек, коммунистик идеаллар өчен көрәшүче хезмәт иясенең матурлыгын раслау — менә бу сыйфатлар бөтен совет театры өчен уртак.

-------------

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

24—25 февральдә язучыларның Тукай клубында 1982 елгы әдәби ел йомгакларына багышланган ачык партия җыелышы булды.

Үткән елда дөнья күргән әдәби әсәрләр турында язучы Ә. Гаффар (проза), тәнкыйтьче С. Маннапов (поэзия), сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова (драматургия), филология фәннәре кандидаты Н. Хисамов (әдәби тәнкыйть), шагыйрь Р. Миңнуллин (балалар әдәбияты), язучы М. Хәбибуллин (очерк), язучы Л. Хәмидуллин (тәрҗемә) һәм Н. Орешина (рус әдипләре иҗаты) чыгыш ясады. Докладлар буенча фикер алышуларда әдипләр Г. Ахунов, Н. Арсланов, В. Нуруллин, Г. Рәхим, Разил Вәлиев, Л. Ихсанова, Р. Фәйзуллин, Р. Мостафин, Г. Иделле, Р. Хисмәтуллин, Ф. Зөлкарнәев, рәссам Э. Зарипов һ. б. катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## «ЧАЯН»НЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫ

4 февральдә Пресса йортында «Чаян» сатира журналының беренче саны чыгуга 60 ел тулуга багышланган тантанага республика газеталары һәм журналлары, радио һәм телевидение журналистлары, нәшриятлар хезмәткәрләре, иҗат союзлары вәкилләре җыелды.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев редакция коллективын, газета-журналлар нәшрияты работникларын, «Чаян»ның авторлар активын һәм укучыларын алтмыш еллык юбилей белән котлады.

«Чаян»ның алтмыш еллык иҗат юлы турында журналның баш редакторы Р. К. Зәкиев доклад ясады.

Татарстан журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов, КПССның Ленин райкомы беренче секретаре Г. И. Карунин, Казан авиация производство берләшмәсе эшчесе Г. В. Кириллова, Башкортстанда чыга торган «Һәнәк» сатирик журналының баш редакторы М. И. Сәлимов, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Р. М. Харисов, ТАССР художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев һәм башкалар тәбрик сүзләре әйттеләр.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Ю. М. Воронин, КПССның Казан шәһәре комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова катнашты.

## САТИРИК РӘСЕМНӘР КҮРГӘЗМӘСЕ

28 январьда Татарстан художниклар союзының күргәзмә залында «Чаян» журналы чыга башлауга 60 ел тулуга багышлап, әлеге журналда актив катнашучы художникларның сатирик әсәрләреннән оештырылган күргәзмә ачылды. Анда барлыгы утызлап авторның 500 гә якын әсәре куелган.

Күргәзмәне ачу тантанасына ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның атказанган художнигы Ә. И. Тумашев, «Чаян» журналының баш редакторы Р. К. Зәкиев, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. П. Игнатьев художникларыбыз иҗаты турында сөйләделәр, аларга киләчәктә дә иҗат уңышлары теләделәр.

Күргәзмәне ачуда ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре Ю. М. Воронин һәм М. М. Мусин катнашты.

## ОПЕРА ФЕСТИВАЛЕ

8—18 февральдә Казанда Ф. И. Шаляпин исемендәге икенче опера фестивале узды. Бөек якташыбызның тууына 110 ел тулуга багышланган бу фестивальдә катнашу өчен Мәскәүдән, Киевтан, Пермь һәм Саратовтан, Одесса һәм Уфадан бик күп сәнгать осталары килде. СССР халык артисты А. Ведерников, РСФСР халык артисты В. Егудин, РСФСРның атказанган артистлары — халыкара конкурс лауреаты Н. Лебедева, Ю. Григорьев, Ю. Горбунов һәм башка сәнгать осталарының иҗатлары белән танышу казанлылар өчен куанычлы вакыйга булды.

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры зур сәнгать бәйрәмендә «Алеко» спектаклен әзерләде. Театрның «Кармен» спектакле дә фестиваль афишасын бизәде.

Фестиваль көннәрендә А. М. Горький музеенда Ф. И. Шаляпинның тормышы һәм иҗатына багышланган күргәзмә оештырылды. Шаляпин укуларында Казан, Мәскәү музыка һәм театр белгечләре чыгышлар ясадылар. Фестивальдә катнашучылар Казан шәһәре предприятиеләрендә һәм уку йортларында опера сәнгате сөючеләр белән очраштылар.

## ҖӘЛИЛНЕҢ МУЗЕЙ-КВАРТИРАСЫ

Татар халкының мәшһүр улы, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил 1940—1942 елларда үзенең гаиләсе белән Казанның Горький

урамындагы 17-нче йортта яшәгән. Биредә шагыйрь байтак күренекле әсәрләрен иҗат иткән.

15 февральдә Җәлилнең туган көнендә, бу бинада шагыйрьнең мемориаль музей-квартирасын ачу тантанасы булды. Әлеге тантанада катнашу өчен Мәскәүдән М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә Җәлил, кызы Чулпан да килделәр.

Музей-квартираны ачуга багышланган митингны ТАССР культура министры И. Н. Алиев ачты. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Совет сугыш ветераннары комитетының Казан секциясе председателе отставкадагы полковник С. Ә. Таһиров, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты С. В. Михалков, митингта чыгыш ясап, ялкынлы шагыйрьнең героик тормышы һәм иҗаты турында сөйләделәр.

Музей-квартирада КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар булдылар һәм андагы экспонатлар белән таныштылар.

## «ЯҢАВАЗ»НЫҢ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАРЫ

Мәктәптә укучы иҗат көчләрен әдәбиятка, әдәби тәнкыйтькә якынайту максаты белән, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе каршында республика яшь тәнкыйтьчеләре студиясе оештырылды. Аның эшен «Казан утлары» журналы хезмәткәре Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) житәкли. Студиянең беренче утырышы Казандагы 55 нче мәктәптә шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин белән очрашу, икенчесе Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә экскурсия формасында үткәрелде. Укучылар иң яхшы рецензиягә уздырылган конкурста катнаштылар. Анда җиңеп чыгучылар танылган татар язучыларының автографлы китаплары белән бүләкләнде.

●

Ленин орденлы «Камгэсэнергострой» берләшмәсе коллективларының үткән елгы дәүләт планнары һәм социалистик йөкләмәләре тулысынча үтәлгән иде. Татарстан атом электр станциясе объектлары төзелешендә средстволар үзләштерүнең план үтәлеше 183 процент тәшкил итте. СССРның 60 еллыгы хөрмәтенә барган социалистик ярышка актив кушылган «Атомэнергострой», төзелешне механикалаштыру, юллар төзү идарәләре һәм йортлар төзү комбинаты аерата зур уңышларга ирештеләр.

●

«Камгэсэнергострой» берләшмәсе коллективлары унберенче бишьеллыкның үзәк елында Татарстан атом электр станциясе төзелешендә 22 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарырга (шул исәптән 4 миллион сумлыгы — планнан тыш), 26 мең квадрат метр торак мәйданны булачак хуҗаларына тапшырырга вәгъдә бирделәр.

●

Күптән түгел Рәис Сәләхов житәкчелегендәге участок беренче торак йортны тапшырды. Аны салуда О. Васильев житәкчелегендәге монтажчылар һәм Е. Колбасова бизәүчеләре үзләреннән зур өлеш керттеләр. Беренче ордерлар «Атомэнергострой» идарәсе һәм йортлар төзү комбинатының иң яхшы эшчеләренә бирелде. Биредә тагын бернича торак йорт, балалар бакчасы, өч ашханә, мунча, спорт комплексы һәм елга причалы төзелеп кила.

●

Февраль аеның беренче якшәмбесендә Татарстан атом электр станциясен төзүчеләре яши торган Кама Аланы поселок советына беренче сайлаулар булып узды. Халык депутатлары итеп сайланучылар арасында Брежнев йортлар төзү комбинатыннан — участок начальнигы Р. Сәләхов, участок партоешмасы секретаре Ө. Гайнуллин, мастер П. Фәизов, бригадирлар Е. Колбасова, А. Федоров һәм башкалар бар.

●

Журналның АЭСтагы әдәби пост членнары, Брежнев шәһәре язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев белән язучы Газиз Кашапов һәм «Атомэнергострой» идарәсенең партия комитеты секретаре Рифкат Катиев АЭС төзүчеләрнең пионер базасында булдылар, Октябрь революциясе ордены кавалеры Әнвәр Ибраһимов монтажчылары белән очраштылар.

●

АЭСнең Түбән мәйданында котлован казу эшләре башланып китте һәм байтак кына эш башкарылды да инде. Бу эштә бригадир Волков житәкчелегендәге механизаторлар үрнәк күрсәтеп эшлиләр.

●

Беляхчи авылында яшәүчеләрне яңа урынга, шәһәрдәгечә барлык уңайлыклары булган поселокка күчерүгә әзерлек эшләре дә дәвам итә. Беренче йортларның нигезләре салынды инде.

# ИЛДАР ЗАРИПОВ «БӘЙРӘМ»Е

Ленинградның Рус дәүләт музее залларындагы мәшһүр рәссамнарның хезмәтләре арасында даими экспозициядә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ленин комсомолы премиясе лауреаты Илдар Зариповның да «Өйдә» һәм «Нефтьче Әхәт абый» дип аталган картиналары лаеклы урын алган. Ул — Татарстан рәссамнарыннан мондый дәрәҗәгә ирешкән беренче кеше. Якташыбызның «Өйдә» дигән хезмәте традицион авыл темасын яңача ачып бирә белүе белән тамашачылар һәм сәнгать белгечләре игътибарын бик тиз үзенә тартты. Чыннан да, Илдар Зарипов көн дә булып торган гадәти, ләкин чынлап дулкынландыра торган тормыш шатлыгы, ана мәхәббәте, гаилә бәхете турындагы күренеш-хәлләрне ихлас күңелдән һәм дөрес тасвирлый.

70 нче еллар башында яшь рәссам бер-берсен тулыландырып торган күп кенә картиналар иҗат итә. Алар сюжетлары буенча гына түгел, кеше тойгыларының камиллеген ачкан образларның эчке бербөтенлеге белән дә бер-берсенә бәйләләр. «Шатлык», «Бишек», «Әткәй», «Нефтьче Әхәт абый», «Бәйрәм», «Казан гүзәле Зөлфия» кебек хезмәтләр төп идеяләре буенча үзләре якын торган «Өйдә» картинасына килеп кушылалар. Бу полотнолардагы төп герой — хезмәт кешесе. Аның җинелчә генә тупаслыгы аша без эчке дөнья сафлыгын, мәһабәт күңел киңлеген күрәбез.

Хатын-кыз образларында исә рәссам аларның холык-фигылендәге сафлык, әдәплелек, оялчанлык һәм наз шикелле төп сыйфатларны тасвирлый. Алар — чын аналар, татар хатыннары, йорт утын саклаучылар, гаиләләренә якты мөлаемлек, ямь һәм йөрәк җылысын бүләк итүчеләр.

Гаиләгә кагылышлы сурәтләрдә еш кына нәни бала һәм ата белән ана мәхәббәте үзәк урынны ала. Әлеге картиналар композицион һәм сынлы сәнгатьнең пластик чишелешләре белән бәйләләр. Вакыйгалар, гадәттә, татарча, күз явын алырлык пөхтә итеп җыештырылган авыл өендә бара. Бу сериядәге барлык хезмәтләрдә дә Бәхет, Мәхәббәт һәм Матурлык хакимлек итә. Ләкин «Бәйрәм» дип аталганы һәм нәкъ менә бәйрәмгә багышланганы бер генә. Аның сюжеты гап-гади. Һәм бу гадиләштерү, безнеңчә, алдан уйлап эшләнгән эш.

...Язгы иртә. Өй эче яз нурлары һәм шатлыклы бәйрәм яктысы белән өртелгән. Әти кеше җайлап кына сабыеның урындыгына килеп утырган. Янындагы улы өреп тутырылган, искиткеч җинел шарга сузылган. Олы бәхеткә ия булган бу күренештә үзе күренмичә генә әни кеше дә катнаша. Чөнки аның күзгедәге шәүләсе, нәкъ автор алдан ук уйлаганча, гаиләнең бәхетле һәм дустанә яшәвенә ишарәли.

Бу тормышчан күренеш күңелгә бәйрәм рухы, пөхтәлек һәм тынычлык алып килә. Кайнап торган кызыл төснең саргылт-кара төсләр белән аралашуы композициянең үзгә бер ритмик төзелешен тәэмин итә.

1982 елда рәссамыбыз әсәрләренә багышланган аерым күргәзмә Мәскәүдә зур уңыш белән барды. Әлеге күргәзмәдән ике хезмәтне Мәскәү Дәүләт Третьяков галереясе үзенең даими экспозициясенә сайлап алды. Рәссамның шулай ук зур уңышы бу, әлбәттә.

Илдар Зарипов иҗаты тамашачыларны үзенчәлеге һәм сәнгать өлкәсендә бертуктаусыз матурлык эзләве белән җәлеп итә. Аның иҗаты һаман үсә, яхшы якка үзгәрә торган иҗат. Рәссамның иҗатындагы табыш-казанышлары күп төрле, алар бүгенге кешенең рухи дөньясына, яшәешебез асылын ачуга юнәлтелгәннәр.

**В. А. ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

●

Тышлыкның дүртенче битендә: Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышыннан бер күренеш.

Рөстәм Мансуров слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ